

# КАЗАН УТЛАРЫ

4
АПРЕЛЬ
1982







**ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ. С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле китабына ясалган рәсемнәр.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4
1982
АПРЕЛЬ

## *Бу санда*

СССРның төзелүенә 60 ел

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Без — халык. Шигырь . . . 3

БЕЗНЕҢ ЛЕНИНИАНАГА ЯҢА ЮЛЛАР

Үзбәк шагыйрьләреннән . . . 4
Әрмән шагыйрьләреннән . . . 6

Н. ФӘТТАХ. Сызгыра торган уклар. Роман . . . 8
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Бу җырлар... Шигырьләр . . . 70
РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ. Яңа шигырьләр . . . 76
А. ШАМОВ. Кире беткән кыз. Хәрби корреспондент язмасы . . . 80
Р. НИЗАМИЕВ. Мең авазлы заман. Шигырьләр 97
Р. МИРХӘЙДӘРОВ. Безне онытмагыз... Повесть 101
Р. ЮНЫСОВ. Очыш. Шигырьләр . . . 116
М. ВӘЛИЕВ. Зилә. Новелла . . . 119

ДУСЛАР ҖЫРЫ

В. ГОНЧАРОВ. Шигырьләр . . . 127
А. ЕМЕЛЬЯНОВ. Сыбызгы. Хикәя . . . 128

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 112 ЕЛ

Р. САБИРОВ. Ульяновлар . . . 138
Ә. БУЛАТОВ. Юлбашчының гомерлек юлдашы 142

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Р. МАКСУДОВ. Өй туйлары соңламас . . . 146

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХИСАМОВ. Лена вакыйгаларына — 70 ел . . . 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. НУРУЛЛИН. Әдәбиятта шартлылык турында

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

## КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ЯГЪФӘРОВ.** Бик кирәкле эш . . . . . . . 165
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Бишек тирбәлергә тиеш . . . 167

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ш. САФИН.** Шиһабетдин Мәрҗани кулъязмасы 171

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Х. ЗӘБИРОВ.** Мин Тукайга ышанам . . . . . 175
**К. ХӘМЗИН.** Шагыйрьне искә алу . . . . . . 176

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ.** Ватан сугышы елларының көлке капчыгыннан . . . . . . . . . . . . . . 179
**Р. КӘШФЕЛЗАДӘ.** Бер риваять . . . . . . . 186

**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . . . . 187

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **ЗӘКИ НУРИ**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*, **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

Производствога бирелде 22/XII-1981 ел. Басарга кул куелды 11/III-1982 ел. ПФ 09008. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049 экз. Заказ Д-465. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Без — халык

*Халык зур ул...*

Г. Тукай

— Без — халык! — дип әйткән өчен хәтта
Кыйналганбыз...

Чорны тетрәндереп,
— Әйе, без — халык! — дип торып бастык,
Ленинчылар булып күтәрелдек!

Күтәрелдек изге көрәшләргә
Юксылларның мәгърур Алыплары,
«Кузгал, уян!» диеп җыр башладык,
Җиңүләргә ул җыр алып барды.

Байрак итте халык Азатлыкны,
Ильич исеме белән җиңеп чыкты,
Таянычка мохтаҗ булган халык —
Таянычы хәзер тынычлыкның.

Тарихларның күпме гарасатын
— Әйе, без — халык! — дип җиңеп үтте.—
Ышанычка мохтаҗ иде халык,
Ышанычы хәзер кешелекнең!

Ильич якташ, Ильич юлдаш һаман —
Барыбызга безнең бер нур инде.
Кемнәр генә безгә таянмыйлар!
Таяналар — димәк, без зур инде.

# БЕЗНЕҢ ЛЕНИНИАНАГА ЯҢА ЮЛЛАР

*Үзбәк шагыйрьләреннән*

## Шөкрулла

### Мавзолейда

Дулкынланам. Йөрәк тынгы белми.
Тибә алмый һич тә тынып ул.
Ильич исән. Бары вакытлыча
Ята кебек күзен йомып ул.

Бертуктаусыз агыла монда халык,
Мәхәббәте җирнең үлемсез.
Бу дөньяны Ленин яратканга,
Яши алмый дөнья Ленинсыз.

Бәрчә тамыр бер йөрәктән тибә,
Һәм шул йөрәк канны саф итә.
Халык улы, халык йөрәге ул,
Гомергә Ул — безнең саф иртә.

## Жуманияз Җаббаров

### Аның бүлмәсендә

Кремльдә бер бүлмә бар — зур, киң түгел,
Җирдә аңа тиңне табу мөмкин түгел.

Гади ишек. Бусага да биек түгел.
Керсәң, әйтә: «дулкынланам» диеп күңел.

Күпләр юкка музей диеп йөри аны —
Монда яши планетаның Төре җаны.

Вакыт монда зур тынлыкта гүли-дулый,
Һаваны ул Ленин белән бергә сулый.

Кара савыты кара белән иртүк тулы.
Карандашны очлаган кул — Ленин кулы.

Бер өстәлне күпме кәгазь каплап тора —
Шул ук кулның җылысын ул саклап тора.

Һаман эштә. Ул үзе дә шунда төсле,
Күз дә нурлы, уй да якты, кул да көчле.

Кемне булса каршыларга-күрмәгә ул,
Чыккандыр күк бары күрше булмәгә ул.

Кем беләндер гаплэшә Ул — сүзе әзер...
Тагын монда атлый төсле үзе хәзер.

Түргә гүя шул ук бөек кеше үтә —
Аны монда мәңге үлмәс эше көтә.

Утырыр да сорар төсле: «Инде,— диеп,—
Сезне тыңлыйк, сезнең йомыш нинди?» — диеп.

## Хөснетдин Шәрипов

### Таяныч нокта

Син акылга сыймас нәрсә идең,
Күп фикерне тарттың үзеңә.
Син — химера... Син — Архимед җене...
Күп әйтелде. Тыңла. Түз генә.

Бу дөньяда синең серле җисем
Бик күпләрне бик күп уйлатты.
Чишелмәде серләр... Яңгырау булып
Гасырларны ләкин уятты!

Күп булдылар көчле, нык кешеләр,
Сөйләп, язып, ярсып сугышта.
Теләделәр сине бар итәргә,
Тырыштылар җигик дип эшкә.

Кайберләре аның патша булды,
Кайберләре базда, тирләде...
Картайса да, искерсә дә тарих,
Уңай җавап шуңа бирмәде.

Тик бервакыт кинәт калкып чыгып,
Шул чуарлык, шул чор өстенә,
Ильич бирде бердәнбер җавапны
Мәңге үлми торган көч белән!..

Планетаны авызлыклыйм дигән
Камчылы зат түгел иде Ул.
«Таяныч бар — ләкин күктә түгел,
Һәм кылычта түгел»,— диде Ул.

Иңе белән этте җир шарын ул,
Таянды да эшче иңенә.
Күз карашын җирнең мәңгелеккә
Юнәлтте Ул кояш иленә.

## Әрмән шагыйрьләреннән

## Гурген Маари

### Владимир Ильич һәм Ваан Терян турында сүз

*ӨЗЕК*

Әрмәннәрне бик күп шагыйрь зурлаган —
Кучак, Чаренц, Варужан һәм Туманян...
Ә, минемчә, җирдә әле җырчының
Синең кебек бәхетлесе тумаган.

Юк, көнләшмим, шигырьне син һәрчакны
Ничек кенә матур итеп язмыйсың —
Син бит Ленин кулын кыскан шагыйрьсең,
Сокландыра шушы данлы язмышың!

Син бит Аңа әрмән халкы сәламен
Алып кердең үзе ачкан ишектән.
Син бит Аның ерак-ерак чорларга
Барып җитәр әмерләрен ишеткән.

Син бит күргән Аның армый-талмыйча,
Көне-төне ничек хезмәт иткәнен —
Чал тарихның зур чирәмен күтәреп
Яңа тормыш орлыклары сипкәнен.

## Аршабир Дабни

### Гомернең алтмыш минуты

Таң-иртә. Кызыл мәйданны
Төнге йомшак кар баскан.
Кинәт курант чыңлый. Постка
Кем ул атлый алмашка?
Ул — солдат. Әрмән улы ул.
Шахтер булган. Саф кеше.
Ул изге урынга баса —
Ул Мавзолей сакчысы.

Килә. Честь бирә. Йөрәктә
Дөрли тетрәүгә тиң ут.
Курантлар сукканчы, шунда
Узачак алтмыш минут.

Тик алтмыш минут... һәркайсы —
Бер гомер дә, бер чор бит.

Ул җилгә каршы очуны
Зурлый торган бер җыр бит.
Тик алтмыш минут... һәркайсы —
Бер төн, бер таң, бер мизгел.
Әйтә гүя ил солдатка:
— Без бергә! Син бул сизгер!

Уйлый солдат: бу зур постта,
ди, бөтен дөнья торыр —
Бик күп буынның бәхетле
солдаты монда торыр.
Тик алтмыш минут... һәркайсы —
бер маяк булып яна.
Ул — Ленин яктысы. һәркем
Сокланып карый аңа.
Күптән теләде ул — Кызыл
мәйдан буйлап йөрергә,

Якыннан карап Ленинның
Якты йөзен күрергә...

Кайчандыр аның әткәсе
Нәкъ шушы постта торган.
Кырык беренче елда аны
Фашист пулясы кырган.
Ул да баш куйган — улының
Шушы көне килсен дип.
Ул да нәкъ Ленинча яши
һәм көрәшә белсен дип.

һәм менә изге уй уйлый
Шул постта торып егет:
Җир шарының һәр кешесе
Шунда бер торыр кебек!

# Бабкен Карапетян

## Йөрәк ерактан күрә

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

...Паровозны кара төтен урый
һәм тирләтә аны ашыгу...
Ә ул тыңлый көпчәк дөбердәвен,
Мич каршында тора басып ул.

Ул — кочегар. Утка күмер өсти.
Дусты аның — оста машинист.
Шәп сызгырта кара төнне ярып,
Корыч юрга әйбәт ярсый ич!

Кесәсендә паспорт — әйтеп тора:
«Бу — Иванов Константин» дип.
һәм очына күңел — көчле давыл
Кубәр минут инде якын дип.

Ул кочегар булып киеп алган
Ивановның иске кепкасын,—
Күкрәгендә йөрәк нәкъ Иванов
Йөрәгедәй нигә типмәсен?!

Ташкүмерне мичкә Ленин сала,
Шуңа поезд чаба җилдереп.
Ул — кочегар. Еракларга карый,
Киләчәккә гүя кул биреп.

Күңел күзе күптән инде күрә
Питер аны ничек көткәнен.
Кара төннәр җирдә бетсеннәр дип
Ут-йөрәкләр очкын сипкәнен.

Россиянең туар таңы итеп
Күрә күңел халык бәхетен...
Ә хәзергә кулда — көрәк... Күзгә
Я җылы пар керә, я төтен.

...һәм машинист әйтә: — Иванов,—
ди,—
Күмер салма. Җитте. Кирәкми.
Карый Ленин Питер утларына...
Ә йөрәге күрә еракны!..

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре

## Нурихан Фәттах

# СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

*Беренче китап*

## XI



Күренмештән соң кунакларга ашарга китерделәр. Беркадәр вакыттан соң — ашагач, өсләрендәге бай киемнәрен кыршылып беткән тире туннарга алыштырып, туглар күтәреп, барабаннар кагып, бөтен ил-көн Туман каган өе яныннан Изге-таууга таба юнәлде.

Иң алдан акбүз атка атланып Туман каган белән Баргынтай баба барды. Алар артыннан күп санлы җәяүлеләр — камнар, багучылар, күрәзәчеләр, агай-энеләр атлады. Һәрбер ыру үзе белән житәкләп корбан малы алып барды. Бернинди шаушу, ыгы-зыгысыз, изге бер тантана белән әкрен генә атлап барган озынча төркемнең башы тау итәгенә килеп җиткәндә, кышкы кояш инде бик нык зурайган, кызарган һәм кара җир астына таба төшеп бара иде. Шул ук вакытта юл уңаена арттан туктаусыз искән ачы җил дә, кешеләр изге җиргә килеп җитү белән, кинәт кенә туктап калгандай булды. Бу исә көннең озакламый төн белән алышыначагын белдерә иде.

Туман каган белән Баргынтай баба туктадылар, арттан килүчеләрне беравык көтеп тордылар. Озакламый бөтен тау итәге җәяүле халык белән тулды. Барлык ырулар, килеп җитеп, үзләренең билгеле урыннарына баскач, Туман каган белән Баргынтай баба житәкчелегендәге Сөнәнкәләр беренче булып тау башына үрли башлады.

Каган белән Баргынтай баба Изге-тауга көнчыгыш яктан менделәр. Атланып килгән атларын алар аста калдырдылар. Ат урынына алар икесе дә корбан малларын житәкләделәр: иң алдан атлаган каган үгез тезгенен тотты, Баргынтай бабага алаша бирделәр. Башка корбан малларын көчлерәк, тазарак ирләр житәкләде. Каты, текә тауда малларның аяклары тайды. Турыга, текәгә менәселәре килмичә алар ничек тә читкә тайпылырга тырыштылар, кычкырдылар, киреләнделәр. Ләкин таза куллы ирләр кыл арканнарны нык тоттылар. Сукмаенча, куркытмыйча, шулай да өзлексез әйдәп, житәкләп, кирәк булса этеп-төртеп, күтәреп аларны һаман югарыга менгерделәр.

Тау башына менеп житкәч, барысы да тынып калды. Һәм биеклек

---

Дәвамы. Башы 3 санда

тәэсирснә, изге, илаһи бер тәэсиргә бирелеп, сокланып, исләре китеп, озак кына ерактагы киңлекләргә, кара-кучкылланып, тоташ булып күренгән алыс[1] тауларга карап тордылар. Кайсы гына якка борылсаң да, бөтен тирә-як моннан уч төбендәгедәй ап-ачык булып күренә иде. Шул ук вакытта киңлек, иркенлек һәм серле, изге бер тантана хөкем сөрә иде бу кичке кояш нуры төшкән ялгыз калкулык башында! Монда кешне ирексездән үзен күккә, Тәңрегә һәм изге ата-бабаларга якынрак итеп тоя сыман иде.

Тау өстендә, уртада, юан-юан карагай бүрәнәләрдән өелгән сигез почмаклы бура — корбан корымы калкып утыра иде. Киез өй сыман астан өскә таба тарая барган бу биек бураның түбәсе юк. Бураның дүрт ягында ишек кебек дүрт ачыклык калдырылган, шунлыктан анда җәен-кышын, язын-көзен җил-яңгыр, кар-буран уйнап тора иде.

Туман каган белән Баргынтай баба изге бурага берничә адым житмичә туктадылар, тезләнделәр дә, Сөн бабага атап дога кылдылар. Җил кискән кырыс чырайлы ирләр, тын алырга да куркып, бер читтәрәк басып тордылар. Дога укылгач, каганга төтәсләп торган кисәү башы китереп тоттырдылар. Кисәү башын ул шунда ачык җиргә өеп куелган коры тал чыбык, камыш өеменә якын китерде. Күп тә үтмәде, чыртлап коры камыш янганы ишетелде. Бармак башыдай ут, камыштан-камышка сикереп, чырт-чырт килеп, куе чытырлык арасыннан житез генә шуыша башлады, югары үрләде, төтен чыгарды һәм бер мәлне кинәт гөлт итеп китте дә, бөтен зур өемне ялмап алып, куанып бии башлады.

Инде караңгыланып килә иде. Кызыллык сүнә барган офык ягына, аста, төн ягыннан далага, иләмсез зур киез кисәгедәй булып, болыт булып, томанлы салкынлык якыная. Изге-тау башында учак яна башлау белән, тау итәгендә дә анда-монда утлар кабынды.

Корбан малларын дөрләп янган ут яктысында, сигез почмаклы бура янында чалдылар. Малның канын аерым савытларга җыеп, бура эченә алып керделәр. Сигез мөгешле изге корылма эчендә, уртада, яртылаш җиргә күмелеп, Сөн-баба кылычы калкып тора иде. Каган тезләнеп изге кылычның бакыр сабыннан тотты. Баргынтай баба, келәү әйтеп, канны кылыч төбенә агызды. Җиргә түгелгән корбан каны, әйтерсең, кылыч тимере буенча каганга күчте һәм ул үзендә искиткеч бер җиңеллек, дәрт тойды һәм шул ук вакытта барлык языклардан-гөнаһлардан арыну-арыклану сыман бер үзгәреш кичерде.

— Бетмәс-төкәнмәс көч-куәт бир, Тәңрем. Илем-көнем бай булсын, терлекләрем күп булсын, дошманнарым аяк астында аунап ятсыннар! — диде Туман каган келәү әйтеп.

Чалынган малны шундук тунадылар, итен-иткә, сөяген-сөяккә аердылар да, сөяген җыеп яндырдылар, итен, эчәк-бавырын түбәнгә, далага алып төштеләр. Каган ыруының — Сөнәнкәләрнең барлык кешесенә корбан ите өләшенде. Кайберәүләр, учак ягып, турыдан-туры шунда Сары-су буенда казан астылар, кайберәүләр — ярлыраклар, күп балалылар, үзләренә тигән өлешне бик кадерләп, өйләренә алып кайтып киттеләр.

Сөнәнкәләр корбан биргәч, тау башына Куяннар менде, Куяннардан соң — Аланнар, Аланнардан соң — Сөйбуләр... Бер ыру икенче ыруны шул рәвешчә алыштыра торды.

Корбан бирү таңга чаклы дәвам итте. Бөтен тирә-якта — далада, тау башында — йөзләгән утлар янды, меңләгән кешеләрнең сөйләшкән, көлгән, кычкырган тавышлары ишетелде. Казаннарда итләр пеште, бурдакларда кымызлар күперде. Әле анда, әле монда жыр-бию, уенкөлке башланып китте.

[1] Алыс — ерак.

## XII

Сөн бабага атап корбан бирүдә бары ирләр генә катнашты. Хатын-кызлар, бала-чага барысы да өйләрендә торып калдылар. Өлешкә тигән корбан ите кайтып җитү белән, киез өйләрдә җанлану башланды. Хатыннар шундук тышка чыгарып казан астылар, учак дөрләтеп җибәрделәр. Кул яссуыдай кечкенә өлеш итләренә кушып, казаннарга бөтен куйлар салдылар. Өйләр, учаклар арасында чыр-чу килеп шат күңелле балалар чабышып йөрде. Бәйрәм көн дип өстәлләргә яхшырак, затлырак азыклар куелды. Шулай ук бәйрәм көн дип, һәркем бер-берсенә карата ягымлы, кечелекле булырга тырышты.

Бөтен ил-көн, бөтен урда дөньясын онытып бәйрәм иткәндә бары Күрекле бикәнең генә күңеле борчулы булды. Дерт-мерт килеп ул әледән-әле ишеккә каранды, әледән-әле тыштагы тавышларга колак салды. Туктаусыз тынгысызланып ул өлкән углының кайтып керүен, я булмаса аны алырга җибәрелгән кешеләрнең кайтып җитүен көтте. Барысын да алдан уйлап эшли алмавына ул үкенеп бетә алмады. Башта ук аны карап-күзәтеп кенә торырга кирәк булган, башта ук аны беркая җибәрергә кирәк булмаган. Кечерәк кайгысына бирелеп ул әнә зуррак кайгысын онытып җибәргән! Күренмеш алдыннан беркая бармасын дип ичмасам Туңгак та кисәтеп куярга оныткан. Күренмештә ил башы каганга буйсыну белдермәүнең нәрсә икәнлеген алар әнә икесе дә онытып җибәргәннәр!

Шулай пошынып утырганда, кемнеңдер кереп килгәне ишетелде. Бу каган кешесе булып чыкты. Ул бикәгә корбан ите алып килгән иде. Үзенең өлкән бичәсенә, балаларына каган быел да башка еллардагы кебек түш ите җибәргән иде. Корбан итенең күплегенә-азлыгына, яхшымы, түгелме икәнлегенә игътибар итәргә тиеш түгеллеген белсә дә, йомышчы чыгып киткәч тә бикә итне җентекләп карарга тотынды. Элекке еллар белән чагыштырганда ул бернинди үзгәреш күрмәде.

Бикәнең йөзе яктырып китте, күңеле беркадәр тынычлангандай булды. Корбан итен ул шундук пешекчеләргә бирде, шуңа өстәп тагын йөз кешегә җитәрлек итеп туңдырылган ит алырга кушты да, тыштагы, таган өстендәге зур бакыр казан астына ут дөрләтеп җибәрде. Казанга тутырып су салгач, ит салгач, казанның зур агач капкачын каплап куйгач, калганын пешекчеләргә тапшырып, ул яңадан өенә кереп китте. Ләкин өйдә дә озак тора алмады, нindидер эшлисе эше бар кеше сыман, ул аннан кире чыкты. «Ә!» диде ул кинәт, эшлисе эшен исенә төшереп. Артта, икенче бөҗрада ул өлкән улына дип өй корган иде. Өйдә аның кырнагы Табылдык булырга тиеш. Никтер аның хәзер менә шул кырнакны күрәсе, аның белән сөйләшәсе килеп китте. Кичәдән бирле ул кызның беркайда күренгәне юк — исәнме ул, юкмы, бер-бер хәл булып авырып-нитеп китмәдеме? Аларга күз-колак булып торганың яхшы.

Шундыйрак уйлар белән ул өлкән углының өенә китте. Өйдә, идән уртасында, сүнәр-сүнмәс кенә булып, учак кызарып ята иде. Өй эче ярым караңгы, шулай да монда кемнәрдер барлыгын шәйләп була. Ләкин бикәне беркем дә каршы алмады. Ул монда үз өенә кергән кебек килде дә керде. Учактан читтәрәк тезләрен кочаклап, башын иеп утырган кырнак аңа бары күтәрелеп кенә карады. Кызның саксызлыгы, салкынлыгы бикәнең кытыгына тиде. Аның күңелендә ачу тойгысы кабара башлады. Шулай да ул үзен тыеп калырга тырышты һәм күзләрен уттай яндырып әдәпсез кырнакка карап торуында булды.

Шул чакны ул түрдә, биек урын-җирдә сузылып яткан нindидер яшь бер ир кешене күреп алды.

— Балам, син түгелме соң?! — диде ул аның кемлеген сизенеп.

Ятактагы ир кеше ашыгып башын калкытты, торып утырды һәм чиктән тыш куаныч, курку һәм гаҗәпләнү белән:

— Әни?! — диде.

— Син... кайттыңмени, улым? Кайда очраштыгыз? Атаңны күрдеңме? — диде бикә, улына бер-бер артлы сораулар яудырып.

— Кем белән очрашырга тиеш идем соң мин? — диде Албуга берни аңламыйча.

— Сине куып житеп, кире алып кайтырга дип мин йөзбашы Жирәнне җибәргән идем.

— Мин үзем кайттым. Күренмеш буласын искә төшердем дә, кире борылдым. Менә... өлгермәдем.

— Әйе, өлгермәдең,— диде әнисе күңелсез генә.

Ике арада кинәт кенә сүз өзелеп калды: Албуганың күңелсез яңалыкны ачыклап торасы килмәде, бикәнең аны шулай ук сөйләп торасы килмәде. Әле генә күргән кебек, ул кол кызга борылып карады.

— Син, балам, ник эндәшмисең? Авырмыйсыңдыр ич? — диде ул аңа кыты гына.

Табылдык, тагын бер күтәрелеп кенә карады да, эндәшмичә башын түбән иде. Аның яшь, дәртле күз карашында, учакта пыскып яткан утлы кузлар кебек, усаллык һәм дошманлык чагылып калды. Бер елдан артык ире Туман каганның башын-күзен әйләндергән, чын мәгънәсендә аны уч төбендә биеткән бу гүзәл кыпчак кырнагын бикә элегрәк тә яратмый иде. Күрәсең, кырнак үзе дә каганның көнчел бичәләрен, үзеннән ямьсезрәк, өлешсезрәк карабашларын яратып житкермәгәндер. Күрәсең, әле дә ул үзендә шул элекке яратмау, күрәлмау тойгысын саклап утырадыр. Көндәше бикә алдында шулай түбәнсенеп утыруы өчен аның күңеле, бәлки, телгәләнәдер дә.

Бу кырыс, горур кыз янынннан бикә болай гына чыгып китә алмый иде. Олы бәйрәм көнне үзенең барлык ачуын, кире тойгыларын эченә йотарга кирәклеген аңлап, йомшарып ул аның янынарак килде, чүгәләп кызның башыннан сыйпагандай итте.

— Сиңа ни булды, балам? — диде ул тагын пошынып.

— Булмады! — диде кырнак һәм кырт кына читкә борылды.

— Булмагач, ник эндәшмисең: мин — синең бикәң!

— Эндәшәсем килми!

— Син миңа эндәшергә тиешсең! Минем углымның кырнагы минем белән бил бөгеп сөйләшергә тиеш!

— Мин синең углыңның кырнагы түгел! — диде Табылдык, башын горур чөеп.— Мине Кортка-бикәгә озатыгыз. Мин абаларга китәм. Минем монда бер көн торасым килми.

Кызның кискен сүзләре, үз-үзен бәйсез, горур тотуы, аннан да бигрәк, аның тышка бәреп торган ниндидер кайгысы бикәне уйланырга, сагаерга мәҗбүр итте. Кызык, нишләп торасы килми икән аның шундый яшь углан янында?

— Китәсең килсә, китәрсең, балам,— диде ул кызмыйча гына.— Шулай да кычкырып әйтмә ул сүзләреңне — ишетсәләр, хәзер алып китәрләр!

Бикә югарыга, төннеккә ымлады. Яшь, матур аякларын кочаклап, үз-үзенә йомылып, үз кайгысына бирелеп утырган гүзәл кыпчак кызы бикәнең кисәтүен уйлап та бирмәде.

— Мин алардан курыкмыйм. Мин алар янында булдым инде,— диде ул бераздан пошмас бер тынычлык белән.

Бикә ни әйтергә дә белми аптырап калды. Нишләгән бу аңсыз карабаш? Шул ук мәлдә аның күңелен бер сизенү яктыртып җибәрде. Ул шундук улы ягына борылып карады. Углының күз карашында, кыяфәтендә, үз-үзен тотышында бикә аның әз генә дә бу сылу, яшь хатын белән кызыксынмавын күреп алды.

— Улым, нишләп... авызыңа су каптың? — диде ана кеше.
— Нәрсә, әни? — диде углан дәртсез генә.
Ул, ахрысы, бөтенләй башка нәрсәләр турында уйланып утыра иде.
— Нишләп кызыңны кыерсытасың, улым?
— Мин аны кыерсытмыйм, әни.
Бикәнең сизенүе дөрес булып чыкты — Табылдык ачылып, үзгәреп китте.
— Ул минем белән сөйләшми, бикә! — диде ул кинәт күңеле тулып.— Ул мине күрми дә, ишетми дә. Ул мине утын агачы дип уйлый, әхрысы. Мин әле яшь, чибәр, дүрт саным төгәл — ник яратмый ул мине?!
— Әйе, яратмыйм мин аны, әни,— диде углан авырлык белән телен әйләндереп.— Атам каганга кире җибәрсеннәр... я син аны үзеңә ал.
— Минем ни языгым бар?! — диде Табылдык, тыела алмыйча.
Бикә тынып калды. Аңа бик авыр, бик кыен иде. Ул үзенең улын да бик яхшы аңлады кебек, ләкин шул ук вакытта кол кызның да аңлашмаслык бернинди сере юк иде.
— Чин кызы мине каганнан аерды, ул минем белән тәгин углан арасын бозды. Күземне йомсам мин аны икебезнең арада күрәм! Эт кебек, җылан кебек синең улың янында сузылып ята, бикә!
Күрекле бикә, улына ымлап, аңа якынрак килергә кушты. Яшь углан буйсынып учак янына килде, әнисе алдында тезләнде.
— Бир әле уң кулыңны, улым.
Албуга карышмыйча әнисенә уң кулын сузды. Бикә кол кызның да кулын үз кулына алды да, җиңелчә көлемсерәп, яшьләргә күрешергә кушты.
— Нинди кайнар! — диде ул кыпчак кызының кулын мактап.— Уты бөркелеп тора. Менә ул яшьлек!
Албуга, әллә кызның кул кайнарлыгыннан, әллә әнисенең хәйләсеннән уңайсызланып, җиңелчә генә кызарынып куйды. Аның салкын, дәртсез тәненә исерткеч җиңеллек, җылылык дулкыны йөгереп үтте. Табылдык ирексездән елмайды һәм яшь тамчылары тамып торган сөрмәле матур күзләрен тутырып әле бикәгә, әле угланга карап-карап алды.
— Җүләрләр! — диде ана кеше, ачусыз гына шелтәләп.
— Олуг бикә! — диде кыз тәэсирләнеп.— Әни! Әнием, дип әйтергә ярыймы сиңа, олуг бикә? Минем беркемем юк — әнием дә, әтием дә. Аягың астында туфрак булырмын — «әнием» дип әйтергә рөхсәт ит миңа, олуг бикә!
— Менә... аның аягы астында туфрак бул,— диде бикә көлемсерәп, белексез углына ымлап.— Шундый буем-сыным була торып, шундый яшьлегем-гүзәллегем була торып, су сөлегедәй яшь углан янында борын салындырып утыраммы соң мин?! Курыкма, «әнием», дип әйт, кызым.
— Бай бул, әнием! — диде Табылдык, бикәнең кулын үбеп.
— Менә, татулаштыгыз да, — диде бикә, китәргә җыенып.— Улым, кара аны, корбан ите ашарга кызың белән бергә кил!
— Килермен, әни,— диде Албуга әкрен генә.

## XIII

Яшьләрне шулай үзара килештергәч, татулаштыргач Күрекле бикә үз алдына уйланып, сәер бер тойгы белән өйдән чыгып китте. Ник шулай тырышты соң әле ул? Кем өчен? Улы өченме, кырнак өченме, әллә

соң үзе өченме? Ник кирәк булды аның менә шулай яшьләр эшенә килеп кысылуы?

Бераз гына ул үзен алар алдында уңайсыз сизде. Бу аңа үзенең әрсезлеге, тупаслыгы булып та, начарлыгы-яманлыгы булып та тоелды. Ләкин шул ук вакытта ул менә шулай эшләргә тиеш иде сыман. Ул — ана кеше — үз улының, тагын углының ничек атлавын, ничек тын алуын да белеп торырга, читкә тайпылса — туры юлга чыгарырга, егылса — күтәреп торгызырга тиеш түгелмени?! Ул аны сакларга, якларга, кирәк булса, аның өчен утка-суга керергә тиеш түгелмени?! Аның улы чыннан да барлык кешеләрдән, барлык кешеләргә хас төрле кайгы-борчулардан өстен булырга тиеш түгелмени?! Менә алар үзара якынайсыннар, бер-берсен яратышсыннар, шуннан соң инде ул — аның углы — чин кызын исенә дә кертеп чыгармас!

Янында моңаеп кызы утыра, ул аны яратмый, имеш! Тәнеңә уты үрләсә, яратырсың, углым. Дөньяда әле беркемнең дә яратудан баш тартканы юк. Тәңре безне яратышу өчен, бер-береңә бәхет, куаныч бирү өчен яраткан.

Өлкән улы белән кыпчак кызы турында уйлаганда бикә шулай да үзен, аннан да бигрәк, үзе белән икенче бер ир арасындагы мөнәсәбәтләрне күз алдында тотты бугай. Үзе дә ул моны сизеп алды. Һәм шундук аның уй җепләре чуалып калды.

«Яратмаса, бик шәп!» дип уйлады ул бераздан улы турында. Чин кызын яраткан кебек яратса, бик тиз ул аның... кыпчак кырнагының сүзенә колак сала башлаячак. Менә монысы инде иң яманы булыр! Туман каганның да бер авызы пешә әле ул чин кызы белән. Болай да инде чибәр кызлар аның җилкәсенә менеп утырганнар. Аның углы беркайчан да андый булмас. Ул — ана кеше — моңа юл куймас!

Ул арада бикә үз өенә кайтып житте. Ләкин ул өенә кереп тормады, казан янына барып, итнең кайнавын-кайнамавын белеште һәм бары шуннан соң гына кире кайтып, авыр өс киемнәрен алыштырды да, чаршау артына узды. Шул вакыт аңа кунак килүе турында әйттеләр.

— Кем? — диде бикә.

Теше төшеп беткән ишек сакчысы кортка шаяртырга ярата иде: елмайган кебек итеп ул сирәк тешле уртларын ачты да, авызын кыйшайтты. Күрекле бикә көлеп җибәрде.

— Исәнтәймени? — диде ул, кем килүен чамалап.

— Шул инде, шул.

— Керсен.

Исәнтәй, килеп керү белән, гадәтенчә баш иде, тезләнде һәм авызын ишек сакчысы кортка күрсәткәнчә дип әйтерлек кыйшайтып елмая-елмая, түргә узды. Күрекле бикә аны, аяк өсте басып торган килеш, учак янында каршы алды.

— Изге бәйрәм көнендә котлыйм сине, олуг ана! — диде Исәнтәй.— Илең-көнең имин, малың-туарың күп булсын.

— Шулай булсын, Исәнтәй,— диде бикә.

«Ни кирәк аңа мондый чакта?» — дип уйлады бикә һәм бу кыек авызлы, кыек уйлы кеше ни генә сөйләсә дә, ни генә әйтсә дә, сак һәм уяу булырга дип алдан ук үз-үзен кисәтеп куйды.

— Барлык ирләр корбанда. Син нишләп торып калдың, Исәнтәй?

— Мин анда булдым, олуг ана,— диде Исәнтәй елмаеп.— Мин сиңа бүләк китердем. Карыйсыңмы?

«Бүләк» сүзен ишетү белән бикә, баштагы кырыслыгын томалап, йөзенә елмаю билгесе чыгарды. Исәнтәйнең бүләгеннән баш тарту ярамый иде, әлбәттә. Ул ак киез өстендәге мендәргә утырды, кунагына урын күрсәтте. Исәнтәй утырды, куеныннан сырлап-бизәкләп ясалган көн савыт чыгарды, савытның капкачын ачып, бүләген бикәгә якынрак китерде. Кан төсле ал ефәккә төренеп әлеге көн савытта нык шомар-

тылган зур ташлы алтын каптырма балкып ята иде. Каптырманың тавык йомыркасы кебек калку-озынча, боз төсле үтә күренмәле яшькелт ташы уртасында сыңар күз булып икенче таш — күк таш, аның уртасында өченче таш — энҗе бөртеге ялтырап ята иде. Мондый гүзәл каптырманы күреп бикә елмаеп җибәрде. Кулы үзеннән-үзе күн савытка үрелде.

— Матур нинди, олуг ана! — диде Исәнтәй, сөенеченнән нишләргә белмичә.

Бикә каптырманы кулына алды, иплэп кенә, саклап кына аны төрлечә тоткалап, әйләндергәләп карый башлады.

— Нишләп аны элегрәк алып килмәдең... күренмешкә кадәр? — диде бикә чын күңелдән үкенү белдереп.— Күренмешкә тагып чыккан булсам, бөтенесенең күзе ут булыр иде!

— Теге яктан килде, бикә,— диде Исәнтәй, көньякка ымлап.— Бүген генә килде. Соң түгел. Бүген — бәйрәм, иртәгә—бәйрәм.

— Алам! Бик матур! — диде бикә соклануын яшерә алмыйча.— Бүләгең өчен ни телисең, Исәнтәй?

— Юк, юк! — диде Исәнтәй, кулын селтәп, бик нык хәтере калган кеше сыман.— Мин сатмыйм. Мин сиңа бүләк бирәм, олуг бикә. Каган мине ярата, бикә дә мине яратсын, хе-хе...

— Ярар алайса. Рәхмәт! Йомышың булса, туп-туры үземә кил.

Соңгы сүзләрен ул ничектер уйламыйчарак кына, үзенә яхшылык эшләгән һәркемгә әйткәндәгечәрәк кенә итеп әйтте. Исәнтәй исә, бикәнең нәкъ шундый сүзен генә көтеп торган сыман, кыюланып аңа таба якыная төште һәм кеше-кара ишетә күрмәсен дигәндәй, авызын учы белән каплап, пышылдап:

— Сиңа сүзем бар, олуг бикә,— диде.

— Нинди сүз, Исәнтәй? — диде бикә, бүләктән күзен алмыйча.

— Хатын-кыз сүзе,— диде Исәнтәй көлеп.— Андый сүзне ир кеше әйтми, хатын-кыз әйтә.

— Ир кеше авызыннан хатын-кыз сүзе ишетү кызыграк та ул.

— Теге чин кызы... Сөенеч... — диде Исәнтәй, ы-мы итенеп,— Асрау карчык аша әйткән: мин тәгин угланны сагынам, мин тәгин угланны яратам дигән...

— Яратса, шуннан ни булган? — диде бикә гамьсез генә.

— Сөенечнең тәгин угланны күрәсе килә, бикә! — диде Исәнтәй пышылдап.— Очраштырырга кирәк. Беркем белмәс — син дә мин, без дә алар.

«Менә ничегрәк икән эшләр!» — дип уйлады бикә үзалдына. Әле генә ул үз углы белән бер карабашның арасын җайлады, инде менә икенче карабаш белән араларын җайлар. Ярар, ана кеше җайлады да ди. Исәнтәйгә монда ни калган? Ник кысылмакчы була әле ул алар арасына?

Әле генә мактап алган бүләге аңа кинәт бик авыр булып тоелды. Шундук аның күңелендә бу ямьсез, җирәнгеч кешегә карата баягы сагаю, шикләнү тойгысы калкып чыкты. Шул ук вакытта ул Исәнтәйгә кисәк кенә сыртын да кабарта алмады. Аның икеләнүен күреп Исәнтәй янә пышылдарга тотынды.

— Сиңа әйтми ярамый, олуг бикә. Каган карт дип әйтә ди Сөенеч.

— Миңа әйтүең яхшы булган, Исәнтәй. Мин — ана кеше барысын да белеп торырга тиешмен. Шулай да син бернәрсәне онытмансың: тәгин угланның кызы бар, аңа беркем кирәкми. Изге корбан бәйрәме көнендә минем углым андый эшкә катнашмас.

— Шулай, олуг бикә, шулай! — диде Исәнтәй, бик тиз килешеп.— Мин дә шулай уйлыйм. Асрау карчык миңа әйтте, мин сиңа әйттем.

Сөйләнә-сөйләнә ул арты белән ишеккә таба чигенде.

— Тагын шундый сүзләр сөйләнсә, асрау карчыкның телен кистерермен! — диде бикә янап.

— Тәгин углан өйдәме соң үзе?

— Аның янына барып йөрергә киңәш итмим, Исәнтәй.

— Ул өйдәмени?

— Өйдә,— диде бикә, үзе дә сизмәстән.

— Сау бул, олуг бикә, хуш! — диде Исәнтәй һәм ашыгып чыгып та китте.

## XIV

Чак-чак кына калышып аның артыннан бикә дә чыкты. Исәнтәйнең ашыгуы аңа бик шикле тоелды. «Кая китәр икән?» дип уйлады ул,ерагая барган карачкыны күздән югалтмаска тырышып. Исәнтәй кызулап төньякка таба юнәлде. «Артыннан күзәтеп барырга берәрсен җибәрергә кирәк» дип уйлады бикә. Ул тиз генә кире өйгә керде. Ләкин Исәнтәй артыннан китәргә тиешле кешесен ияртеп кире чыкканда Исәнтәй инде каршы яктагы икенче бичә Сырга бикә өе артында күздән югалып өлгергән иде. «Күрәсең, аңа да бүләк бирмәкче буладыр» дип уйлады Күрекле бикә, үз-үзен тынычландырып. Өйдән үзе белән алып чыккан хатынны ул шулай да Сырга бикә өе ягына җибәрде.

— Өенә кермә. Читтән генә күзәт — ул шунда булырга тиеш,— диде ул хатынга шыпырт кына.

Бикә әлеге хатынның ярым караңгыда ерагая барганын күзәтеп торды да, яңадан казан ягына китеп барды. «Сырга бикәгә нәрсә бирер икән?» дип уйлады ул Исәнтәй турында.

Бикә бик нык ялгышты. Исәнтәй Сырга бикә өенә кереп тормады — юл яздырыр өчен ул юри шулай анда киткән булды. Өй артына ышеренгәч ул бөтенләй читкә — өченче божра ягына ашыкты. Өченче божра артына чыккач әйләнеп бераз җир килде дә, атына атланып, туптуры Изге-тауга, Туман каган янына ашыкты.

Исәнтәй Сары-су буендагы киң яланга килеп җиткәндә, Сөнәнкәләр күптән инде корбан биреп тау башыннан төшкәннәр иде. Берничә җирдә, кара төнне ярып, ялкынланып учаклар яна, казаннарда корбан итләре пешә. Бер казан белән икенче казан арасындагы ачык урыннарда кешеләр кайнаша, әле анда, әле монда шат күңелле төркемнәр күренә.

Каган өчен яланда үгез тиреләреннән аерым алачык корылган иде. Исәнтәй алачыкны ерактан ук күреп барды. Ләкин алачык янына килеп җиткәч, ишек янындагы торгаклар аны каган янына кертүдән баш тарттылар.

— Каганга минем ашыгыч сүзем бар — кертегез! — диде ул таләп итеп.

Битлек кигән камнар аны, ай-васна, әрсезлегенә карамыйча, ике куллап эләктереп алдылар да берни әйтмичә читкә алып китә башладылар. Исәнтәй кинәт бар көченә кычкырып җибәрде. Аның ямьсез тавышы колакларны ярып як-якка таралды. Якындагылар тавыш килгән якка борылып карадылар, шул ук мәлдә дип әйтерлек алачыктан ашыгып каган килеп чыкты.

— Ни булды? Кем кычкыра? — диде ул каранып.

Каганны күрү белән камнар туктап калды. Исәнтәй, аларны як-якка җиңел генә селтәп җибәрде дә, каганның аягы астына барып егылды.

— Ник кычкырасың?— диде каган исе китеп.

— Кулымны каердылар,— диде Исәнтәй ялганлап.— Бөек каган, ашыгыч хәбәр бар,— диде ул аннары, тавышын әкренәйтеп.

— Әйдә, кер,— диде каган.

Кысан алачыкка керү белән Исәнтәй як-ягына каранды, аннары суларга тыны җитмәгән кебек ашыгып:

— Колының өйдә, бөек каган! — диде.

— Өйдә?! — диде каган ышанмыйча.— Аны алырга киткән кешеләр очратмый кайттылар.

— Өендә качып калгандыр ул, бөек каган. Анасы әйтмәгәннәр,— диде Исәнтәй.— Сылтау бар: күренмештә булмады, буйсыну белдермәде — өендә качып калган! Анасы белән икесен дә хәзер үк кулга алырга кирәк, бөек каган!

Әйе, бу бик яхшы, бик уңай сылтау иде! Ләкин мондый сылтауга таянып эш итәргә Туман каган әлегә күңеленнән әзер түгел иде. Бүген ул, дөнья кайгыларын онытып, тулысынча дин-йола, ата-баба кайгылары белән мәшгуль иде. Аннан соң аның күңелендә тәгин углына карата бернинди дошманлык тойгысы да юк иде. Аның күңелендә бары яман төш тәэсире дә, анасы Кортка-бикәнең әйткән сүзләре генә ике арада киртә булып ята иде. Исәнтәйнең киңәше дөрес сыман булып тоелса да, ул ашыкмаска булды.

— Тырышлыгыңны истә тотармын, Исәнтәй,— диде ул кыек авызлы кешенең баш өстеннән читкә карап.— Бүген минем андый эшкә кулым бармый.

Исәнтәйнең авыр башы аска иелде.

— Тагын бер уйлап кара, бөек каган! Ятып калганчы атып калырга кирәк! — диде ул соңгы бер омтылыш белән.

— Мин уйладым инде,— диде каган коры гына.— Иртәгә дә килеп бил бөкмәсә, анда күз күрер.

Хуҗасы тибеп җибәргән эт кебек, Исәнтәй башын тагын да ныграк аска иде, бөтен гәүдәсе бөрешеп, бөгәрләнеп калды. Әрнеп ыңгырашу сыман бер өн чыгарды да, арты белән чигенә башлады.

— Шулай да син күз-колак бул,— диде каган болай гына.

— Булырмын, бөек каган! — диде Исәнтәй сөенеп.

«Булмаган кая ул!» дип уйлады ул үзалдына.

## XV

Бәйрәм шау-шуы, бәйрәм ыгы-зыгысы төн уртасына чаклы дәвам итте. Икенче көнне төштән соң бөтен ил-көн — агай-эне, бәкләр Туман каганның олы җыен вакытларында гына торгызыла торган Күк өенә җыелдылар. Күк өй Ак өйдән биегрәк тә, иркенрәк тә иде. Аның идәннән алып түшәмгә кадәр бөтен эче тоташ күк ефәк белән бизәлгән. Идән уртасына бик зур ак киез җәелгән, киез уртасына — ишектән кергәч тә сул якка алтынлап, сырлап ясалган биек тәхет куелган, тәхетнең ике ягында да каганның якын кешеләре өчен калку урыннар җәйләнгән иде.

Тәхеткә каган иң яхшы киемнәрен киеп чыкты. Аның уң ягына өлкән бичә Күрекле бикә утырды, сул ягына Котлуг бәк утырды. Башка бичәләр, бәкләр барысы да үзләренә тиешле урыннарга урнаштылар. Каганның дүрт бичәсеннән туган балалары бөтен бер оя булып тәхет каршысына, ак киез өстенә утырдылар. Алар арасында бүген дә бары тик уң кул тучи тәгин углан Албуга гына юк иде. Урдадагы хәлләрне якыннан белеп, күзәтеп килә торган һәм шуңа карап бүген, иртәгә ни буласын алдан юрарга күнеккән кешеләр тәгин угланның юклыгын бик тиз күреп алдылар, үзләренчә фараз кылдылар һәм күршеләре белән пышылдашып, гайбәтләшеп алырга да өлгерделәр.

Барлык кеше жыелып беткәч, каган аяк өсте басып, олы киңәшнең башлануын белдерде. Сары-су буена корбан бәйрәменә җыелыр алдыннан бөтен ил буенча кешеләрнең, шулай ук терлек-туарның сан исәбе алына иде. Кайда күпме кеше, күпме терлек булуына карап каган үзенә буйсынган бәкләрдән салым ала һәм үзенең йорт-җир, хуҗалык эшләрен дә ил-көннең көченә, байлыгына карап җайлаштыра иде. Олы киңәштә сүз иң элек шул турыда була. Бәкләр, ыру башлары монда шулай ук үз ыруларындагы, үзләренә буйсынган төбәкләрдәге төрле эшләрне, бәхәсле мәсьәләләрне кузгаталар, ил белән, ыру белән идарә итүгә кагылышлы нәрсәләрне тикшерәләр иде. Барыннан да бигрәк, быелгы кышта кая, кайсы якка яу чабу яисә яу чапмау мәсьәләсе дә каралачак. Каган өендәге олы киңәш башлыча шуның өчен җыела.

Башта каган агай-энене үз ыруындагы, үз урдасындагы хәлләр белән таныштырырга тиеш иде. Бер-берсенә терәлеп, тыгызланып торган һәм бер кешедәй тынып калган ирләр Туман каганның нәкъ шундый сүзләр әйтүен көттеләр. Ләкин сүзне каган бөтенләй икенче нәрсәдән башлады.

— Уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга кичәгенәк күренмештә булмады, бил бөгеп миңа буйсыну белдермәде,— диде Туман каган бөтен өй эченә кычкырып.— Бүген ул мондамы?

Ирләр, барысы берьюлы тыннарын кысып, бер-берсенә карашып алдылар һәм чиктән тыш бер кызыксыну белән күтәп тора башладылар. Нәрсә булыр, Тәңрем — күк күкрәп яшен яшьнәрме, әллә кояш балкырмы?

— Монда, бөек каган! — дип кычкырды Бүзбала бөтен өй эчен яңгыратып.— Ул кичәгенәк авыру булган, шуңлыктан күренмештә була алмаган.

— Монда булса, керсен,— диде Туман каган.

Ишектән тәхеткә кадәр киң ара калдырып ирләр үзара кысыла төштеләр һәм, чак-чак кына башларын борып, уң кул тучи бәк тәгин угланның кергәнен көтә башладылар. Менә ишек ачылып китте, анда житез атлап, башын югары тотып яшь угланның килеп кергәне күренде. Кыяфәтенә караганда ул бер дә авыру кешегә охшамаган иде. Тук-Сыртлан карачы аны җитәкләп диярлек ак киез янына алып килде. Албуга, ике аягы белән дә ак киез өстендәге үгез тиресенә басты да, башта каганга, аннары ашыкмыйча гына бүтәннәргә карап чыкты һәм берниндн каушау, уңайсызлану сиздермәгән бер тынычлык белән, үзен нык, горур тотып:

— Бөек каган! — диде.— Мин ишетеп тордым: Бүзбала карачы мине кичәгенәк авырып килми калган дип белдерде. Мин авырып калмадым. Мин — тап-таза! Мин, күренмеш буласын онытып, Тарлавыкка китеп барганмын. Ярты юлда исемә төште дә, ашыгып кире борылдым. Тик менә кайтып кына җитә алмадым. Мин үземнең хатамны таныйм. Бөтен ил-көн, агай-эне алдында мин сиңа буйсыну белдереп бил бөгәм, бөек атам!

Мондый сүзләр ишетеп Бүзбаланың йөзе үзгәреп китте. Каганның да, өлкән бичәнең дә йөзләренә гаҗәпләнү һәм чак-чак кына каушау билгесе чыкты. Башкалар да, ни уйларга да белмичә, аптырабрак калдылар. Кайберәүләр мондый нәрсәгә куәләтә сөенеч белдерделәр, күпчелек исә: «Авырып калса ни дә, авырмый калса ни — барыбер түгел мени?!» — дип уйладылар. Бүзбала авырды дип әйткән икән, шуннан да яхшы сылтауның кирәге дә юк лабаса инде! Ата белән ул үзара килешсә, татулашса, шул җитмәгәнмени?

Кайберәүләр яшь угланның төзәтмәсенә икенче төрлерәк карарга тырыштылар. «Яшь булса да, күз буяганны яратмый» диделәр алар үзара. Шулай ук куркаклардан да түгел — кара, нинди туры, кыю карый атасының күзләренә!

— Мин синең буйсынуыңа ышандым, улым! — диде каган, уңайсыз тынлыкны бозып. Шуннан соң ул шактый кырыс итеп Бүзбалага эндәште: — Син, Бүзбала карачы, моннан соң да миңа ялган сөйләсәң, телеңнән дә, башыңнан да колак кагарсың! — диде.

Бүзбала куркуыннан ап-ак булды.

— Миңа әйттеләр! Килеп әйттеләр, бөек каган! — диде ул калтыранып.

Уң кул тучи бәк тәгин углан үзенә тиешле урынга килеп утырды. Туман каган тагын бер мәртәбә олы киңәшнең башлануын белдерде дә, үз ыруындагы, урдадагы хәлләр турында сөйләргә керешге.

Җир-су, көтү-көтүлек турындагы, ыруларның үзара ыгы-зыгысы турындагы сүзләр гадәттәгечә бик кискен һәм шау-шулы булды. Даладагы талашлар, ызгышлар яңарып, көчәеп, монда да кабатланды. Берәүләр җирнең, суның азлыгына, уңайсызлыгына үпкә белдерделәр, икенче берәүләр күршеләреннән зарланды. Ил башы каган берәүләрне килештерде, икенче берәүләрнең кайбер ирекләрен тартып алды, аеруча усалрак, килешмәүчәнрәк күршеләрнең эшләрен исә яргучылар[1] карамагына калдырды.

Олы киңәш көне буе барды. Бик күпләрнең монда язмышы хәл ителде. Шунлыктан кызыксыну, киеренкелек әз генә дә йомшап тормады. Ләкин бөтен ил кайгысын бер көнне генә хәл итеп бетерерлек түгел иде. Күп кенә сораулар, мәсьәләләр башка көннәргә калдырылды һәм Туман каган бүгенгә олы җыенның төкәнүен белдерде. Иртәннән бирле берни ашамаган, көне буена аяк өсте басып торган агай-энеләр җиңел сулап куйдылар һәм ашыгып ишеккә таба агыла башладылар.

Бу вакытта инде кояш җир астына төшеп йокыга талган, кышкы дала өстенә салкын караңгылык җәелә башлаган иде. Бу көннәрдә күктән күзен алмыйча, айның, кояшның, йолдызларның үзгәрешен, хәрәкәтен күзәтеп кенә торган Баргынтай баба, күк гөмбәзендә яшь айның очлы мөгезе күренү белән, Туман каганга хәбәрче җибәрде. Ил башы, иртәнге кояшны котлаган кебек, кичке айны да котлап каршы алырга, келәү әйтергә тиеш иде.

Күк өйнең көнчыгыш ишегеннән кунаклар, көнбатыш ишегеннән каган чыкты. Туң җир өстенә җәелгән киезгә тезләнеп ул яшь айга үзенең изге теләкләрен юллады. Шуннан соң ул Күк өйдән бер ике йөз адым чамасы читтәрәк урнашкан Ак өйгә таба атлады.

Олы киңәштән соң Ак өйдә олы аш-су башланды. Аш-суга каганның барлык бичәләре, балалары, туган-тумачалары һәм шулай ук ил читеннән килгән барлык бәкләр чакырылды. Үзенең мөнләгән кунакларын каган иң яхшы ашамлыклар, эчемлекләр белән сыйлады.

Исәнтәй олы туйга дип Таштугайдан үзенең көйче, җырчы кызларын чакырткан иде. Кунаклар ашап туктаган арада Исәнтәйнең курчак кебек итеп төзәндергән, бизәндергән, битләренә кершән яккан, кара чәчләре күпереп торган чибәр кызлары ят җырлар җырладылар, төрле уен коралларында уйнадылар. Кызлардан соң тәхет каршысындагы ачык урынга җиде-сигез яшь ир чыкты. Болар Исәнтәйнең кәмитчеләре иде. Ирләрнең дүртесе дүрт почмакка утырды. Бик каты шаулатып ике ир шул чакны озын чүлмәк сыман барабан төбен дөпелдәтергә тотынды, икенче берсе алдына каплап куелган агач табак төбенә куллары белән алмаш-тилмәш бәрә башлады. Шул ук вакытта берни аңлатмый торган җансыз кыяфәттәге бер ир кеше таяк башына эленгән җиз кыңгырауларны чыңлатып-чыңлатып алды. Алар шулай төрле тавышлар белән шау-шу куптарганда ярым шәрә өч яшь ир бер яктан икенче якка тәгәрмәч булып тәгәрәделәр, бер-берсенең кулына, җилкәсенә басып, каядыр югары менеп киттеләр дә, маймул кебек янә аска сикереп төш-

---

[1] Яргучы — хөкем эшен башкаручы, казый.

теләр, үзләре белән алып кергән озын бамбук таягына уралып, әлләниләр кыландылар.

Туман каган ашаганда тәхет күрке булып, аның вак-төяк йомышларын башкарып торучы гүзәл Сөенеч үз янындагы икенче бер кол кызга елмаеп нидер әйтеп куйды. Икенче кол кыз, Сөенечнең сүзләрен сөн теленә әйләндереп, каганга пышылдады. Туман каган, аңлаганлыгын белдереп, ым какты һәм, чак-чак кына башын борып Сөенеч ягына карап алды. Шуннан соң ул җырчы кызлар белән кәмитче ирләрне яхшылап сыйларга кушты. Тәхет тирәсендәге бу ымлашуны якын-тирәдәге ирләр, хатыннар барысы да күреп, күзәтеп утырдылар. Тәгин углан, бу якка карамаска тырышса да, караңгы төндә балкып янган утка карамыйча булдыра алмаган кебек, әледән-әле Сөенеч ягына күз төшергәләми булдыра алмады. Ул бары атасының күз карашы белән очрашмаска гына тырышты.

Исәнтәй кәмитчеләре уйнап туктау белән, уртага анадан тума сөн яшьләре чыкты. Алар кылыч белән сугыш биюе биеделәр. Бары дини йола бәйрәмнәрендә генә күрсәтелә торган бу куркыныч биюне кунаклар тын да алмый күзәтеп утырды. Уртада дүрләп янган ут яктысында ялт-йолт килгән кылычларын әле югары күтәреп, әле бер-берсенә каршы чәкәштереп һәм туктаусыз дөпелдәгән барабан тавышларына буйсынып, җитез ирләр төгәл, кискен хәрәкәтләр ясадылар. Шул ук вакытта алар, бию хәрәкәтләренә туры китереп, кычкырып-кычкырып җибәрделәр.

Кызу, дәртле бию, ничек кисәк кенә башланып киткән булса, шулай ук кисәк кенә туктап калды. Барабаннар тынды, күз алдында ялт-йолт килгән кылычлар күренмәс булды, һәм яшь, таза, матур тәнле ирләр, көчле җил аударган камыш кебек, барысы бергә идәнгә егылдылар. Кунаклар, дәррәү кубып, биюче яшьләрне алкышларга тотындылар.

Алар шулай шаулашкан-гөрләшкән арада биючеләр тын алып, хәл җыеп яттылар да, туп кебек атылып яңадан тордылар. Шул чакны өйнең уртасында — тирә-ягын таш белән әйләндереп алган түгәрәк учкарда гөлт итеп, бик зур булып ут кабынып китте. Моңарчы өстенә киез каплап куелган коры тал-камыш өеменнән өскә төтен белән аралашып ялкын күтәрелде. Ут-ялкын зураеп, бөтен өй эче көндезгедәй яктырып калгач, кинәт тагын барабаннар дөпелдәргә тотынды. Биюче шәрә яшьләр «алас! алас!» дип кычкыра-кычкыра, күз иярмәс тизлек белән ут аша сикерергә кереште.

## XVI

Туман каган күп эчсә исерә, исерсә холыксызлана башлый иде. Бу юлы да шулай булды. Җыр-биюләрне ул тыныч кына карап, күзәтеп утырды. Исәнтәйнең кызлары җырлаганда, биегәндә ул әле шактый аек иде. Кәмитчеләр уйнаганда аның инде күз аллары әлҗе-мәлҗе килә башлады. Ул әледән-әле үзенең тучи бәк тәгин углы ягына карап алды. Ул аның да үзенә каравын, аннан да бигрәк, чин кызына күз салгалавын күрми калмады. Бер-ике мәртәбә ул чин кызының да яшь углан ягына карап елмаюын күреп алды. Аның моңа ачуы килде. Ләкин ул моңа берничек тә аркылы төшә алмады — бер-берсенә карашкан өчен генә ул үзенең углын да, кырнагын да берничек җәзалый алмады. Үзалдына үртәлеп ул бары буза гына эчте.

Исереп чыгырдан чыга башлаганда аның күзенә дунху бәге Начин нойон чалынып калды. Начин нойонның ул Сары-су буена соңлап килүен исенә төшерде. Кичәгенәк аңа Начин нойонның тагын бер этлеге турында җиткергәннәр иде. Дунху бәге һәр елны түләнелә торган каланын — җиде мең үгез тиресе алып килгән булган. Ләкин ул җиде

мең тиренең йөзгә якыны бозык булып чыккан. Кичәгенәк Туман каган шуның өчен генә аңа бәйләнеп тормаска булган иде — андый йөзгә якын тиреләрне кайчагында теркәүчеләр үзләре дә юри бозык итеп күрсәтергә тырышалар. Хәзер ул менә шуны исенә төшерде һәм күңелендә җыелып килгән бар ачуы аның берьюлы тышка бәреп чыкты.

Шәрә яшьләр ут аш сикереп туктагач та ул, бөтен өй эченә кычкырып, дунху бәген үз янына чакырды. Начин нойон утыз яшьләр чамасындагы озын буйлы, таза бер ир кеше иде. Үзенең җәенке табак бите белән, кара сызык кына булып күренгән кысык күзләре белән ул башкалар арасында бик нык аерылып тора. Ашыгып, елмаеп, шулай да эчке бер сагаю белән ул тәхет каршысына килеп тезләнде.

— Көпчәк булып тәгәрә! — диде каган аңа.

Начин нойон агарынып китте.

— Эчем авырта, бөек каган! — диде ул, эчен тотып урталай бөгелә-бөгелә.

Өй эчендәге күп санлы кунаклар куркып, аптырап тәхет ягына карадылар.

— Кабатлап әйт — ишетмәдем! — дип кычкырды каган, урыныннан торып.

— Эчем авырта, бөек каган! — диде дунху бәге кызганыч йөз белән.

— Башын чабарга! — дип кычкырды каган ярсып.

Шулай итеп, туйның яме юкка чыкты. Начин нойонны ике яктан ике ир тотып алды. Кычкыртып аны ишеккә таба өстерәделәр.

Каганның исерек чакта бирелгән боерыклары кайчагында җиренә җиткерелми кала иде. Чөнки бу хакта аның «исерек чакта әйтелгән боерыкларны чынга алмаска» дигән сүзләре бар иде. Шуны истә тотып, дунху бәгенең башын чапмадылар.

Икенче көнне, каган йокыдан торгач, аңа кичәге хәлне исенә төшерделәр. Начин нойон турында ишетү белән ул барысын да яңадан күз алдына китерде. Хәзер аның дунху бәгеннән бигрәк, үзенең өлкән углы, чин кырнагы һәм шуларга бәйле уңайсыз бер киеренкелек эчен пошырды. Кызны үзенә тартып алса да, нишләптер ул аны тулысынча үзенеке итеп хис итә алмады. Никтер ул чая, чибәр, шома кыз гел яшь, сылу углан турында гына уйлыйдыр шикелле тоелды. Начин нойонны ул кичерергә булды.

Дунху бәген, кулларын-аякларын бәйләп, тирән базга ташлаганнар иде. Каганның кичерү турындагы боерыгын җиренә җиткерү өчен тоткын янына Бүзбала үзе китте. Төне буе күзенә йокы кермәгән, кайгыдан ярым үлек хәлгә килгән бәк янына бау-баскыч суздылар. Базга бер ир төшеп, Начин нойонның кулларын, аякларын чиште, аңа баскычтан менәргә булышты. Җир өстенә тартып чыгаргач дунху бәгенә аның аклануын әйттеләр, өенә кайтып ял итәргә куштылар. Үзенең эчке тойгыларын яшерергә күнекмәгән беркатлы Начин нойон, үлемнән котылуын белгәч, сөенеченнән елап җибәрде. Чәчен-башын тырнап, кычкырып-кычкырып елады-елады да, кинәт тиле сыман көләргә тотынды. Куанычын болай гына белдерә алмагач, җиргә ятып тәгәрәргә кереште, аннары тезләнеп, көнчыгыштан күренеп килгән кояшка:

— Тәңрем! Коткаручым! — дип кычкырды.— Үз аймагыма кайтып җитә алсам, биш яшьлек улымны сиңа корбан итеп бирәм!

Шуннан соң ул карачы Бүзбалага борылды.

— Сиңа, Бүзбала, сөенечкә йөз баш ат, йөз баш сыер миннән. Бөек атам каганга җиткер: мин китергән каланны яртылаш кына дип белсен. Быел мин аңа яңадан дүрт мең үгез тиресе алып киләм!

— Әйтермен, Начин нойон,— диде Бүзбала.

Дунху бәгенә карачының йөзе нишләптер бик кырыс күренде. «Йөз баш ат белән йөз баш сыерны азсынды!» — дип уйлады ул аның турын-

да. Һәм ул бер кызудан өстендәге тупас җирән тукыма белән тышланган тиен тунын салды да, Бүзбаланың кулына тоттырды.

— Ишеттеңме мин әйткәнне, Бүзбала? — дип кычкырды ул аның колагына.— Мә, тунны да ал. Сиңа бүләк.

Бүзбала канәгатьләнү белдереп елмайды, тиен эчле йомшак тунны иңбашына салды да, дунху бәген юатып, аның аркасыннан сыйпап куйды.

— Бар инде, бар, кайтып ял ит,— диде.

Бер кат эчке тун белән генә калган Начин нойон, чатнап торган кышкы салкында алпан-тилпән атлап, елый-елый, көлә-көлә үз авылына юнәлде. Юлда аңа үз кешеләре — ике яшь бичәсе, балалары, ырудашлары очрады. Алар аны каршы алырга киләләр иде. Аның коткарылуы турында алар кай арададыр ишетеп тә өлгергәннәр инде. Өсләреннән салып аңа үз туннарын кидерделәр, үзләре белән алып килгән буш атка атландырдылар һәм шулай кадерләп, елашып үз өйләренә алып кайтып киттеләр.

Өенә кайткач Начин нойон ашады-эчте дә, тәмам тынычланып, онытылып каты йокыга талды. Ул көне буе йоклады һәм бары тик караңгы төшкәндә генә уянды. Бүген көндез далада ат, дөя чабышлары булырга тиеш иде. Шул турыда уйлагач аның тагын чәчләре үрә торды. Ат, дөя чабышларында барлык бәкләр катнашырга тиешләр. Аның килми калуын каган тагын буйсынмау дип уйламас микән?

— Мине алырга берәрсе килмәдеме? — диде ул өйдәгеләргә.

— Килде,— диделәр аңа.— Синең уянганыңны көтеп тора.

Начин нойон аңлап җитмәде, аны кинәт тыелгысыз бер калтырау биләп алды.

— Керсенме?— диделәр аңа.

— Кем?! — дип кычкырды бәк, урыныннан сикереп торып.

— Килгән кеше.

— Керсен! — дип кычкырды Начин нойон һәм шундук кынысыннан хәнҗәрен тартып чыгарды.

«Иң элек аны чәнчелдерәм, аннан соң үзем үләм!» дип уйлады ул өметсез бер ярсу белән. Ләкин ул көткән куркыныч кеше урынына өйгә балкып-елмаеп Исәнтәй килеп керде.

— Олуг нойон, тәңре сиңа күп көч, байлык бирсен! — диде Исәнтәй, бишкә бөгелеп.

Дунху бәге хәнҗәрен кире кыныга тыгып куйды. Җайлап кына түрдәге йомшак урынга утырды. Өйдәге кешеләренә ул кымыз китерергә кушты. Зур агач кубәтәгә салынган кымызны ул башта үзе авыз итте, аннары кунагына бирде. Уртак савыттан кымыз эчкәч, ике арада үзеннән-үзе туганлык, якынлык барлыкка килде.

— Син — нойон, тире тун кия,— диде Исәнтәй.— Мин ефәк бар. Сата.

Ул, сөнчә бик яхшы белсә дә, үзенең кем икәнлеген сиздерү өчен кайчагында шулай юри телне бозып сөйләшә иде. Сөннәрне яратмаган һәм үзе дә сөн телендә бик үк яхшы сөйләшмәгән дунху бәгенә бу, аның исәбенчә, бик тә ошарга тиеш иде.

— Нинди төс? Күпме? — диде Начин нойон.

— Ал төс. Каган төс. Ун төргәк. Сиңа сата,— диде Исәнтәй.— Сөн бәк бай киен, дунху бәк яман киен. Каган сине мыскыл. Каган — яман! Сөн — яман!

— Те! Әйе! — диде Начин нойон, күз алдында үзгәреп.

Йодрыкларын йомарлап ул тезләренә таянды, күкрәген киерә төште. Шулай да әлегә ул Исәнтәйгә ияреп каганны, сөннәрне яманлаудан тыелып калды — кичәге куркуы бөтенләй үк чыгып бетмәгән иде.

— Ал ефәк кирәк? — диде Исәнтәй кабатлап.

— Ал төс — каган төсе. Ал тун киеп мин кая барырмын, кемгә күренермен? — диде Начин нойон.

— Алайса, сары, яшел... — диде Исәнтәй.

— Китер! — диде бәк икеләнүен җиңеп.— Минем дә сөн бәкләре кебек ефәк тышлы тун киясем килә.

— Ун төргәк — ун тире,— диде Исәнтәй бәясен белдереп.— Кыйбат имәс.

— Кыйбат түгел! — диде беркатлы Начин нойон, бик тиз килешеп.— Нишләп син минем аймакка килеп чыкмыйсың? Миңа буза кирәк, дөге, корал кирәк. Чибәр кызлар кирәк! Бармы синдә кызлар?

— Кызлар юк,— диде Исәнтәй.

— Сөн бәкләренә син барысын да табасың,— диде Начин нойон үпкә белдереп.— Миңа беркем килми, берни китерми. Мин урманнар, таулар арасында, ат-сыер арасында яшим. Анда да — сөннәр, сулда да — сөннәр. Миңа чибәр чин кызлары кирәк. Каганның Сөенече кебек! Әйе, те!

Исәнтәй, хуҗаның тынычланганын көтеп, беравык эндәшмичә утырды. Шуннан соң ул яшь, таза нойонга табарак елышты да:

— Нойон теләсә, барысы да була! — диде.

— Ничек?! Кайчан?!

— Начин нойон теләгә чибәр кыз, ефәк, алтын, корал, яшма таш — барысы да күп-күп була!

— Күпме кирәк — бирәм, ни телисең — бирәм! — диде аңа дунху бәге ашыгып.

— Миңа кирәк имәс,— диде Исәнтәй серле пышылдап.— Барысын да сиңа... Чин ваны бирәчәк. Буш. Бүләк.

— Чин ваны? — диде Начин нойон ышанып җитмичә.— Миңа? Ник? Ул бик юмартмыни?

— Юмарт. Үзенә буйсын кешедән ул кызганма.

— Берни аңламыйм,— диде Начин нойон, кысык күзләрен челтчелт йомгалап.— Мин каганга буйсынам. Чин миңа ерак. Чин таулар, далалар артында.

— Начин нойон Чин белән якынай кирәк,— диде Банхуа-Исәнтәй иплән кенә... — Каган сине тала. Сөн явыз, комсыз. Син дунху, шуна килешә.

— Килешмим! — диде Начин нойон, күзләреннән усал очкыннар чәчрәтеп.— Мин аларның бугазын чәйнәп өзәр идем! Тик... дунху көчсез, таркау.

— Тыңла! — диде Исәнтәй, хуҗага тагын да якынрак килеп.— Сөннәрне чәйнәргә сиңа Чин булыша. Үз аймагыңа кайта, теге якка кача, таулар артына.

— Анда минем җирем юк, көтүлегем юк,— диде Начин нойон.— Андагылар мине кырып бетерәчәкләр.

— Тыңла! — диде Исәнтәй тагын да.— Син алардан курка имәс. Син — дунху, алар — дунху. Туган. Син аларны котырта, үз кулыңа ала. Каган Чингә яу киткәч, күп-күп дунху сөнне кыйна! Арттан. Чин кыса, Дунху кыса, Сөн — үлә!

— Те! — диде Начин нойон, килешүен белдереп, дулкынланып.— Сөн дә үлә, каган да үлә! Далада дунху кала! Начин нойон кала!

Ярсып ул кинәт урыныннан сикереп торды, тешләрен шыгырдатып, әрле-бирле таптангандай итте, зур агач күбәтәгә кымыз тутырып эчте дә пошкырып куйды һәм кинәт кенә тынып калды.

— Кызыңны китер, ефәгеңне китер. Бушлай бир. Шунсыз ышанмыйм,— диде ул сүрелә төшеп.

Исәнтәй чыгып китте дә икенче бер чин ирен ияртеп керде. Әлеге ир яхшылап төрелгән төрле төстәге ефәк тукымалар күтәргән иде. Күз-

нең явын алып торган ал, яшел, сары төстәге ефәк тукымаларны Исәнтәй дунху бәге алдына таратып ташлады.

— Барысын да алам! Алын да, яшелен дә, сарысын да! — диде бәк комсызланып.

— Ал,— диде Исәнтәй.— Кызны иртәгә китерерләр.

— Бүген кирәк! — диде түземсез нойон.

— Иртәгә. Бүген соң,— диде Исәнтәй нык итеп.

— Те! — диде Начин нойон килешеп.— Мин аларны! У-у, мин ул сөннәрне, каганнарны!

## XVII

Исәнтәй китеп бераз торгач Начин нойон киенеп өйдән чыкты. Тышта бик салкын иде. Җир өстендәге бөтен нәрсә суыктан чатнап, шыгырдап тора. Әле ныклап кар яумаганга җирнең өсте кап-кара. Нойон унлап сакчы ир алды да, урда ягына карап китте. Читтән генә ул сөннәрнең төнге торгакларын, аерым күзәтчеләрен карап китте. Даланы яхшы белгәнгә ул беркемгә күренмичә барды. Үзенең ни өчен болай каранып, аңдышып йөрүен ул үзе дә бик үк төшенеп җитмәде бугай. Үз гомерендә беренче мәртәбә ахрысы, ул сөннәрне иң явыз дошманнары итеп тойды һәм, дошман булгач, искәрмәстән басып алу өчен ул аларның кайда ничек урнашуларын белергә тиеш иде бугай. Ләкин ул әлегә мондый нәрсәне — каган урдасын басып алуны башына да китерөп карый алмады, ул монын шулай тиешлеген сизенде генә бугай.

Төнге далада иснәнеп, каранып йөри торгач ул шулай да билгеле бер карарга килә алды — тиз генә үз авылына борылды. Исәнтәй җибәргән кызларны көтеп тормаска булды. Аның йөрәге түзмәде, аның үч аласы, талыйсы, җимерәсе һәм, әлбәттә, иксез-чиксез көчкә, байлыкка ия буласы килде. Үз кешеләренә ул, берни сиздермичә, тиз арада күченеп китәргә боерды.

Дунхуларның качып китүләрен сөннәр бары икенче көнне таң аткач кына белделәр. Баштарак аларның юклыгына беркем игътибар итмәде. Начин нойонның авылы божра эчендә булмаганлыктан, төнге торгаклар аны сакламыйлар иде. Шулай да моңарчы өйләр, арбалар булган урында буш җир күреп, сөн ирләре бөтенесен аңлап алдылар. Дунхуларның качып китүе турында шундук каганга хәбәр ителде.

Туман каганның бик нык ачуы килде. Кара син аны! Изге бәйрәм көнендә, абаларга, каганга, түрәләргә-йолага төкереп, сөннәрне хур итеп качып киткән! Баш күтәргән дунху!

Тиз арада ул каравыл агасы Туңгак алыпны, бүген төнлә кизү торган меңбашларын, йөзбашларын чакыртып алды. Ул аларны шелтәләп тә, куркытып та тормады.

— Тереме, үлеме — табып алып кайт,— диде ул Туңгак алыпка әкрен генә, дәһшәтле итеп.

Туңгак алып, мең кешелек алай алып, качакларны тотарга үзе китте.

Туман каган бер кызудан Котлуг бәкне дә чакыртып алды. Котлуг бәкнең биләмәләре Начин нойон биләмәләренә якын гына иде. Начин нойонда Котлуг бәкнең кол хатынынан туган кызы кияүдә иде, шунлыктан дунху бәге Котлуг бәкнең кияве исәпләнелә. Начин нойон, бер яктан Туман каганга буйсынса, икенче яктан Котлуг бәккә буйсына. Куяннар дунхулар белән дус-тату яшиләр һәм кайчагында Котлуг бәк үзенең киявен каган алдында яклап та калгалый иде. Әле генә Начин нойонның кулын-аягын бәйләп базга ташлагач та шулай булды — Туман каган барыннан да элек Котлуг бәк сүзенә колак салды. Ләкин

Начин нойон Котлуг бәккә кияү туры килсә, Туман каганга баҗа туры килә иде!

— Синең киявең... син яраткан дунху колым минем йөзгә төкерде, бабай! — диде каган Котлуг бәккә.— Сөн йолаларын, сөннәрнең изге ата-бабаларын санламаска, каганга каршы баш күтәрергә син өйрәтмәдең микән аны, Котлуг бәк?

— Нишләп мин аны сиңа каршы котыртырмын икән соң? Син дә минем киявем лабаса! — диде Котлуг бәк каган сүзләренә бик нык хәтере калып.

— Кияү белән кияүнең аермасы бар, бабай... Котлуг бәк!

— Сүзең хак, — диде Котлуг бәк элеп алып.— Каган кияремне кол кияүгә алыштырырга минем башыма тай типмәгән!

Дунху бәгенең качып китүе Туман каганның моңарчы ихтыярын буып торган ниндидер богауны өзеп ташлагандай булды. Анда бары ау вакытында гына, дошман белән күзгә-күз килеп сугышкан вакытта гына була торган ныклык һәм омтылыш, гайрәт һәм ярсу кабынды. Төрле яктан чолгап алган яман көчләрдән, күзгә күренмәгән һәм күренгән дошманнардан үзен-үзе саклау өчен, үзенең бүгенгесен, киләчәген, мәңгелеген яклау өчен ул аларны — үзенә каршы килүчеләрне анасы Корткa-бикә әйткәч тә инде тар-мар итеп ташларга тиеш иде. Ләкин моның өчен әлегә тиешле сәбәбе, җитәрлек сылтавы булмады. Хәзер менә ул сылтау табылды. Мондый сылтауны кулдан ычкындырырга ярамый иде.

Туңгак алып качакларны кичкырын бер тау итәгендә куып җитте. Дунхулар, артык каршылык күрсәтмичә, ничек тә таулар арасына кереп яшеренергә тырыштылар. Сөннәр аларның күп кенә кораллы ирләрен үтерделәр, атларын-арбаларын кулга төшерделәр. Начин нойонны эләктереп булмады — ул качып котылды. Ул арада караңгы төште. Туңгак алып, көчен таркатмас өчен, эзәрлекләүне туктатырга мәҗбүр булды.

Шулай итеп ычкынды Начин нойон! Таулар, урманнар арасында, караңгыда аны инде Туңгак алып түгел, әллә кем эзләсә дә таба да, тота да алмас иде. Аны ныклап торып эзәрлекләү өчен, тоту өчен күп көч белән таулар аръягына — санап бетергесез дунху аймаклары яши торган җирләргә басып керергә кирәк булачак иде. Ләкин анда күп көч белән басып керү өчен киң үзәннәр дә, тапталган киң юллар да юк. Ике арада биек койма булып таулар, кыялар калкып утырган өчен дә теге яктагы дунхулар, беркемгә буйсынмыйча, үз ирекләрендә яшиләр иде.

Шуларның барысын да уйлап, Туңгак алып урдага кире борылды.

Туңгак алып каганның боерыгын беренче мәртәбә үти алмады. Каган аны караңгы чырай белән тыңлап торды.

— Дунхуларны буйсындыру өчен кимендә илле меңлек көч кирәк, бөек каган,— диде Туңгак алып.— Илле мең көч белән мин аларны бер кышта тез чүктерәм!

— Мин уйлап карармын,— диде каган теләр-теләмәс кенә.— Бар, өеңә кайт. Уйлашырбыз.

Туңгак алып тынычланып ишеккә юнәлде. Бүзбала белән Салчак алып аны ефәк чыбылдык артында сак кына көтеп тордылар. Ул башын иеп, ишек киезен күтәреп азапланганда, икесе ике яктан чыгып алар аның арттан кулларын эләктереп каердылар, тезләрен аркасына терәп идәнгә егып салдылар. Ауга барганда тәгин угланны үз урынына бастырып, барлык алыплар алдында хурга калдырганы өчен Салчак алып каравыл агасына күптән инде теш кайрап йөри иде. Шуңа күрә дә ул эшен бик тырышып башкарды. Бүзбала да чын күңелдән тырышты. Олы киңәш алдыннан каган бик каты янагач, аңа да үзенең турылыклылыгын күрсәтергә кирәк иде. Әле генә үзләре белән бер табактан

ашаган, үзләренең якын дуслары, сердәшләре булган кешене алар берниндн кызганусыз, ерткычларча тукмадылар. Аның көчлелеген, чыдамлыгын, усаллыгын бик яхшы белеп эш ителде — алай-болай ычкынып китә калса, ихтимал, ул аларны изеп ташлаган булыр иде. Ләкин Туңгак алып берничек тә ычкына алмады. Кулларын, аякларын богаулап аны кичә генә Начин нойон яткан тирән базга ташладылар.

## XVIII

Биек Ак өйдәге яңалыклар тиз арада бөтен урдага таралды. Изге бәйрәм көннәрендә бу көтелмәгән күңелсезлекләр бик күпләрне борчуга салды. Күпчелек моны яманга юрады. Берәүләр моннан фәлән ел элек тә шундыйрак ызгыш-гаулар булуын, аларның ничегрәк тәмамлануын исләренә төшерделәр. Икенче берәүләр кайчандыр булып узган ай, кояш тотылуларны, койрыклы йолдыз атылуларны, шуннан соң ук корылык, яу-кыран килүләрне хәтерләде. Иртәгәсен көчле җил-давыл чыгуын көткән сыман, бөтен урда төнне тынгысыз бер сагаю, шомлану белән уздырды.

Яңа айның җидесендә — изге бәйрәмнең соңгы көнендә Туман каган Күк өйгә яңадан үзенең барлык туган-тумачасын, бәкләрне, агаларны җыйды. Аш-суга түгел, олы киңәшкә җыйды. Шунда ул бөтен ил-көн алдында үзенең сүзен әйтте.

— Йолага, түрәгә туры китереп мин — Сөн иленең башы Туман каган — өлкән бичәм Күрекле бикәдән туган уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга углымны башкаландырырга булдым,— диде ул бөтен өйгә ишетелерлек көчле тавыш белән кычкырып. — Алдан килешү буенча, тәгин углым Албуга Алаинарның Күкәл буыны Елдырым бәкнең Алтын-Бөртек кызына өйләнер. Айак эчелгән, калымның яртысы түләнгән.

Көтелгән яңалыкның иң зурысы иде бу. Ата белән угыл арасында килеп чыккан каршылыкның ни белән бетәсен түземсезләнеп көтеп торган агай-эне каганның мондый карарын ишетеп җиңел сулап куйдылар. Ярый әле, эш алай ук зурга китмәгән икән!

Туман каган дәвам итте.

— Туену өчен уң кул тучи бәк тәгин углыма мең өйлек өлеш чыгарам, миңа каршы баш күтәргән дунху Начин бәкнең Байык суы буендагы җирләрен тәгин углыма бирәм. Начин бәкнең Байык буенда торып калган илен-көнен туену өчен бирелгән мең өй исәбенә кертәм.

Моны әйткәч ул тынып калды һәм өй эчендәгеләргә күз йөртеп чыкты. Байык су буйлары алай начар җирләр түгел иде, шулай да уң кул тучи бәк тәгин углан өчен мең өйлек өлеш... бик-бик аз иде. Сөн илендә бу иң ярлы бәктән дә ярлырак булу дигән сүз!

— Миңа буйсынган дунху бәгенең сөн йолаларына, изге ата-бабаларга төкереп китүе, башбаштаклык күрсәтүе минем күңелемә кара кайгы булып төште,— диде Туман каган яңадан сүз башлап.— Дунху бәге белән Котлуг бәкнең якын туган-тумача булуын истә тотып, Начин бәкне Котлуг бәк котырткандыр дип уйлап, мин Куян ыруы башы Котлуг бәккә үпкәмне белдерәм. Картлыгын, алыплыгын истә тотып, Котлуг бәкне кичерәм. Котлуг бәкнең кызы... өлкән бичәм Күрекле бикәгә, үз артыннан килгән бар байлыгын алып, өлкән углы Албуга белән бергә Байык суы буена күченеп китәргә боерам. Күрекле бикә үлгәнче үз байлыгына — үзе, Албуга — үз байлыгына үзе хуҗа булачак. Күктәге йолдызларның торышын, җилнең, болытларның юнәлешен тикшереп торучы күрәзәчеләрем миңа шуны әйттеләр: өлкән бичәм Күрекле бикә белән углы Албуга минем янда, Ак урда янәшәсендә булганда, Тәңре миңа, ыруыма, илемә-көнемә талау-кыран китерә. Дунху бәге Начинның башбаштаклыгын, таулар аръягына качып китүен күрәзәчеләр

шуннан күрәләр. Ил башы каганга, илгә-көнгә, мал-туарга моннан соң бернинди кыран-талау килмәсен дип мин уң кул тучи бәк тәгин углым Албуга, әнисе Күркле бикә бүлеп бирелгән биләмәләреннән беркая чыкмасыннар, мин үзем чакыртмыйча торып, Ак урдага аяк басмасыннар дип боердым!

Каган әйтәсе сүзен әйтеп бетерде дә, өстеннән тау-таш ишелеп төшкән сыман, шулай да үзен чиктән тыш киеренке тоткан хәлдә, кырыс ирләргә янә күз йөртеп чыкты. Җил кискән тупас, ачулы йөзләрдә шулай ук соңгы чиккә җиткән киеренкелек һәм сагаю күренде. Шул ук вакытта аларның бу киеренкелегендә бушану, иркенләп тын алу билгесе дә юк түгел иде.

Шулай итеп, барысы да аңлашылды. Димәк, каган үзенең өлкән бичәсен дә, өлкән углын да читкә сөрә. Кем аркасында? Билгеле, гүзәл чин кырнагы аркасында! Шулай да акылсыз бу каган. Сөн илендә аңа әллә кызлар беткәнме?!

Әрнеп-ачынып агай-эне шулай уйлады. Арада ниндидер хатын-кызның мышык-мышык борын тартканы ишетелеп китте. Моңарчы тынлык саклап түзеп торган ирләр ирексездән кузгалып куйдылар, ирексездән гөрелдәргә тотындылар. Таулар арасындагы киң үзәнне хәтерләткән биек иркен Күк өй эчендә менә-менә давыл чыгар төсле тоелды.

Ләкин Туман каган үз өендә давыл чыгуга юл куя алмады. Исәнтәй белән алдан барысын да исәпләп куйганга, ул олы җыенны бик оста алып барды. Аннан да, моннан да өзек-өзек тавышлар ишетелеп, өзек-өзек тавышлар гаугага, тавышка күчәргә генә торганда ул, очарга җыенган кош сыман, йодрыкланган ике кулын да югары күтәреп, кискен бер омтылыш ясады да, бар көченә кычкырып:

— Тыңлагыз! — диде.

Агай-эне, ил-көн тынып калды.

— Боерам: миңа буйсынган барлык бәкләр, ыру башлары, тугызынчы айның егерме җиденче көненнән дә соңга калмыйча, коралланып, өчәр ат белән, азык белән кичү янына җыелалар. Соңга калганнарның башы чаптырылачак, баш тартканнарның оялары таркатылачак, мал-туары тартып алыначак, кешеләре коллыкка сатылачак. Чин ягыннан килгән качаклар көн дә хәбәр китерәләр: Җунгода — таркаулык, баш-баштаклык. Бөтен көчем белән мин Чин җиренә басып керәчәкмен, мәңгелек дошманнарымны аяк астына салып, барлык җир-суга баш булып калачакмын. Тәңрем, изге атам-анам минем яклаучым, юлдашым булсын. Амин!

Әле генә ярсып кузгалырга, нәрсәдер кырырга-җимерергә әзер булган ирләр күз алдында икенче кешегә әйләнделәр. Куллар йомарланды, күкрәкләр киерелә төште, күзләрдә утлы очкыннар ялтырады. Алар барысы да — сугышчылар. Кереш тарта башлаганнан алып кына түгел, тумыштан ук алар сугышчылар, кыю ирләр. Җирдә кешечә яшәү өчен аларга — тумыштан ук сугышчы булган кыю ирләргә — әледән-әле үләргә һәм яңадан терелергә кирәк иде. Бу аларның канына, миенә сеңгән. Олы яуның байлык, бәхет, дәрәҗә генә булмыйча, кан-яшь, хурлык, коллык, үлем икәнлеген дә бик яхшы аңласалар да, югарыдан боерык булгач, уйланып, тикшереп торырга аларның хаклары юк. Алар бары җиңәргә яисә үләргә генә тиешләр иде.

Бөтен өй эче күз алдында үзгәреп китте. Уң кул тучи бәк Албуга онытылды, Күркле бикә онытылды. Гүзәл чин кызлары, дунху бәкләре — барысы да кичерәеп, төссезләнеп калды. Һәркемне уртак кайгы-карлы таудай олы, җил-давылдай көчле һәм тормышның, яшәешнең үзе кебек үк серле-куркыныч яу кайгысы биләп алды.

I

Алар белән беркем саубуллашмады, аларны беркем озата бармады. Кичә кичтән үк җыенып божра читенә күченеп чыктылар һәм төнне ачык далада, өсте ябулы арбаларда уздырдылар. Таң атар-атмас борын юлга чыктылар. Мең өйле, төмән өйле киез кала иртәнге томанда ят һәм шыксыз булып, артта торып калды.

Күрекле бикәнең йөрәген, бавырын ачу һәм хурлану тойгысы талады. Үзен, тәгин углын, башка балаларын иäләшкән оядан куалап җибәрүче ире каганга ачулана идеме ул, әллә быел шундый бирешкән, картайган, тешсезләнгән һәм кызын яклап бер сүз дә әйтә алмаган атасына ачулана идеме — моны ул ачык кына төшенә дә алмады.

Туганнарының да, көндәшләренең дә — беркемнең дә үзен юатмаячагын, юата алмаячагын ул болай да алдан ук белде. Аннары ул кемнең дә булса үзен юатуын да теләмәде. Шуңа күрә дә ул менә шулай кеше күрмәгәндә җыенды, кеше күрмәгәндә кузгалып та китте.

Котлуг бәк кызы Күрекле бикә, Туман каганның өлкән бичәсе, шулай итеп, урда өчен кинәт юкка чыкта. Үлде. Тере килеш үлде. Аңа беркем дә булыша алмады — атасы да, яраткан колы да. Ул инде беркемнеке дә — каганныкы да, колныкы да түгел. Каган өчен карт тоелса да, күңеле белән ул әле яшь иде, аның әле тиз генә кабергә керәп ятасы килми иде. Шунлыктан аның һич тә үзенең бу үлеменә ышанасы килмәде. Ләкин аның үлгәнлеген искәртеп, як-якка селкенә-селкенә, тирбәлә-тирбәлә, биек тәгәрмәчле авыр арба каядыр барды да барды.

Бикә утырган арба шактый киң һәм иркен иде. Арбаның өстенә бик зур кабыргалар төсле итеп карама кирәгәләр беркетелгән, кирәгәләр өстенә катлап-катлап киез ябылган иде. Алгы ягында гына ишек сыман ачыклыгы булган, җил-яңгыр үтми торган бу биек арбада җылы һәм рәхәт. Теләсәң, монда аякларыңны сузып җибәреп, йомшак мендәргә терәлеп, йоклап алырга да мөмкин, теләсәң — җайлап утырган килеш, тәрәзә ярыгыннан тышка карап барырга була.

Ләкин урдадан куылган хатынның күзенә йокы да кермәде, күңелендә тәрәзәдән карап бару теләге дә тумады. Арбаның арткы почмагына сөялгән килеш, битен, иäген йомшак яка йонына көртлек сыман яшереп ул тын гына, оеп кына барды да барды. Аның уң ягында, аяк очында берни белми җиде яшьлек улы йоклады, сул ягында песи баласыдай бөгәрләнеп биш яшьлек кызы йоклады. Башка вакытта балаларының йокы аралаш тын алуларына, төшләнеп авызларын чәпелдәтүләренә, сулкылдап-сулкылдап куюларына сокланып туя алмаган ана бүген аларны, әйтерсең, күрмәде дә, тоймады да. Бер үк вакытта ул үзенең өстенә ишелеп төшкән зур кайгысы турында да, томанлы, күңелсез киләчәге турында да, онытып булмастай шикелле тоелган һәм артта кала барган Ак урда, Ак өй күренешләре турында да уйлады сыман. Шулай ук ул тышка, далага да колак салгандай итте.

— Барысы да беттемени, тәңрем?! — диде ул көрсенеп, үзалдына сөйләнеп.

Күктән аңа берниди җавап килмәде. Якында гына туң җир өстеннән шакылдап, тәгәрәп барган көпчәк тавышлары ишетелде дә, дөп-дөп баскан, мөңгерәгән, пошкырган, чәрелдәгән терлек-туар авазлары колакка керде.

Шул чакны киез ишек-тәрәзәнең бер кырые күтәрелә төште, алда — сәкедә дилбегә тотып утырган Чобан, башын тыгып:

— Ни дисең, бикә? —диде.

Бикә аның сүзен аңлап җиткермәде — эндәшмичә, кымшанмыйча үз урынында утыра бирде.

— Син миңа нидер әйттең бугай, бикә? — диде Чобан кабатлап.

— Әйтмәдем,— диде бикә.

Шулай да тыштагы кеше белән эндәшеп-сөйләшеп алгач аңа ничектер җан кереп киткәндәй булды. «Юк, үләргә әле иртәрәк» дип уйлады ул үзалдына, юану эзләп. Атасы, ыруы, балалары исән, шулай булгач, нишләп әле шул кадәр бетеренергә? Ул әле монда — җирдә, кешеләр, терлекләр арасында. Ул бары күченеп кенә бара. Яшь, чибәр бичәләрен генә, гүзәл кырнакларын гына якын күрә торган каганнан үчен алачак әле ул бер заман! Аның углы — тучи бәк, тәгин углан. Ул — Тәңре углы! Аның хокукын тартып алырга беркемнең көченнән килмәячәк. Исән генә булсын аның олы колыны!

— Чобан, Чобан! — диде ул кинәт, йокыдан уянып киткән кеше сыман.

Чобан ишектән башын тыгып карады:

— Әллә тагын колагыма гына ишетелде инде,— диде ул мыгырданып.

— Колыным... Колынкаем күренәме?— диде бикә.

— Кайсысы?

— Икесе дә.

— Өлкәне күренә.

— Чакыр, күренеп китсен.

Бераз баргач арба янында Албуганың тавышы ишетелде:

— Әни, ни булды? Мин монда.

— Ул-бу юкмы, киләләрме? — диде бикә, тәрәзәдән башын тыгып.

— Киләләр!

— Адай андамы?

— Алдан бара.

— Табылдык ничек... кызың?

— Мин монда, әни! — диде кырнак, бикәнең үзе белән кызыксынуына сөенеп.

— Ярар, ярар, барыгыз,— диде бикә күңеле булып.

Әниләренең урыныннан кузгалуын һәм кем беләндер кычкырып сөйләшүен ишетеп, балалар да уянып киттеләр. Уяну белән алар беравык тыңлап яттылар. Әниләре яңадан үз почмагына килеп утыргач, җиде яшьлек малай, башын калкытып:

— Әни, без кая барабыз? — диде.

— Тозлы күлгә! Шуны да белми! — диде абыйсын үчекләп кечкенә кызый Куянкай.

Балаларның әле ана-кам кушкан чын исемнәре юк иде, аларны Бала дип, Малай, Кызым дип кенә йөртәләр. Шулай да малайга инде Кече-Тай, кызыйга Куянкай дигән исемнәр тагылып өлгергән иде.

— Әле иртә — йоклагыз,— диде әниләре балаларны яңадан йоклатмакчы булып.

— Мин торам, әни,— диде Кече-Тай, ишеккә таба шуышып.— Мин абыкайлар янына чыгам.

— Мин дә! — диде Куянкай.

— Иртә әле, иртә! — диде бикә балаларын тынычландырмакчы булып.

Ләкин ул арада Кече-Тай ишек-тәрәзәдән башын тыкты да, чәрелдек тавыш белән:

— Абыкай! Ат китер! — дип кычкырды.

— Миңа да! — диде Куянкай, кече абыйсы янына килеп.

— Барыгыз алайса, бар! — диде бикә. Балаларга ул жылы киемнәрен табышты, киендерде, чәчләрен сыйпап, рәтләп куйды. Арба янына ат китерделәр. Балалар узышып, төртешеп, ачык ишектән чыктылар, янәшә атлап барган атларга атландылар да, күздән дә югалдылар.

Балалар чыгып киткәч, арбада буш, иркен булып калды.

— Чобан, Чобан!— дип кычкырды бикә.— Кем бар анда — әйт әле, миңа да ат китерсеннәр!

## II

Алар сөзәк калкулык итәгеннән бардылар. Сулда — көнбатышта күңелсез караңгылык җәелеп ята, уңда — көнчыгышта бераз гына ачыла башлаган күк чите һәм шундый ук караңгы бушлык барлыгы беленә иде. Инде кыш башланса да, күлләр, елгалар боз белән капланса да, кар әле төшмәгән.

Иң алдан, юл күрсәтеп, як-якны күзәтеп коралды кылавызлар барды, алардан бераз калышып — каравыллар, каравыллардан да арттарак йөз кешелек коралды алай барды. Коралды алай артыннан утлыйутлый, иренеп кенә, йокымсырап кына көтүләр теркелдәде. Икешәр, дүртәр, алтышар үгез җигелгән авыр арбалар, озын койрык булып, көтүләр артыннан бардылар. Арбаларга бикәнең киез өйләре, кием-салымнары, савыт-сабалары, бөтен бер кышка житәрлек азык-төлеге — барлык байлыгы, барлык кирәк-ярагы төялгән иде. Арбаларда шулай ук картлар, карчыклар, бала-чагалар, авырулар барды. Корал тота белгән, ат өстендә утыра алган барлык таза кеше — ирләр, үсмерләр— барысы да атка атланган иде. Көтүләрне, арбаларны алар алдан гына түгел, арттан да, ян-яклардан да карап, күзәтеп баралар.

Аларның байлыгы, билгеле, болар гына түгел иде. Бикәнең әле көтү-көтү маллары, меңләгән кешеләре бар. Алар Тозлы күл байларындагы далаларда булырга тиешләр иде. Ак урдадан куылу турында каган боерыгы билгеле булгач та, бикә аларга да тиз арада күченеп китәргә һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә — Байык суы буена таба хәрәкәтләнергә дип кеше җибәргән иде. Өч-дүрт көннән алар барысы да Диңгез-күл буенда очрашырга тиешләр.

Бикә арбадан чыгып атка атлануы белән, әнисе янына Куянкай килеп житте.

— Абыкайларың кая?

— Мине ияртмәделәр,— диде кызый үпкәләп.

— Әйдә минем белән,— диде бикә үзенең кече кызына.

— Мин сине көттем, әни! — диде Куянкай.

Бикә, кызын ияртеп, арбалар, терлекләр килгән юнәлешкә каршы якка — койрыкка таба китте. Аның барысын да үз күзләре белән күреп, тикшереп чыгасы килде. Каршы яктан килүче арбаларга, кешеләргә, терлекләргә караштырып алар ашыкмыйча гына бардылар. Атка атланган бикәне ирләр, хатыннар сәламләп каршылады. Узып барышлый гына, исәнлек-саулык сорашкан арада гына бикә алардан тегесенмонысын белеште, берәрсенә кыска гына җавап кайтарды, я булмаса берәр киңәш бирде. Кечкенә түгәрәк битен ачып, йомшак тун якасын кайтарып куйган Куянкай әнисенең әле бер ягына, әле икенче ягына чыкты һәм бертуктаусыз тәтелдәп, нигә алай да, нигә болай, дип барды, я булмаса бер дә юктан кычкырып көләргә тотынды.

Кырыс ирләр, хатыннар баш иеп, ым кагып Куянкай белән дә исәнләштеләр. Мактап аңа берәр сүз әйтеп куйдылар, кайберләре көнләшеп, эчләреннән генә: «Бикә кызы шул — анасының итәгеннән төшкәч тә атка менгән. Безнекеләр аның яшендә сарыкка, кәҗәгә атланып йөриләр» дип уйладылар. Чыннан да, арбалар янынан шыбырдашып,

теркелдәшеп барган тук сарыкларның йомшак сыртына караларның бишәр-алтышар яшьлек балалары атланып утырганнар иде. Арада аталары, аналары алдында — атка атланган балалар да күренгәләп калды. Бикәнең Куянкае масаеп, куанып, үз яшьтәшләренә, танышларына берәр сүз кычкырып китте. Берүзе бер атка атланып килгән кыю бикә кызына яшьтәшләре исләре китеп карап калдылар.

Бикә койрык белән тигезләшкәндә, арттан килүче кораллы ирләрнең үзара кычкырышуларын, ни турындадыр сүз көрәштерүләрен ишетеп калды. Иртәнге эңгердә бикәнең якынлашып килүен сизмичәрәк калдылар бугай. Колагына чалынып калган өзек-өзек сүзләр буенча бикә аларның нәрсә турында кычкырышуларына төшенеп өлгерде. Болар төрле ырудан, төрле төбәктән җыелган ирләр иде. Күпчелеге Куяннар булса да, алар арасында каган биргән ыбыр-чыбыр да житәрлек. Тәгин угланга өлеш чыгарганда каган үзенә ярамаган төрле холыксызларны, башбаштакларны, я булмаса чирле-морлы, булдыксыз кешеләрне дә биргән иде. Бикәгә бу турыда әйткәннәр иде инде, ләкин урдада ул андый нәрсәләр белән кызыксынып тормады. Моның өчен аның вакыты да, теләге дә булмады. Аннан соң ул каганның ирләрен бөтенләй диярлек белми иде. Каган ирләрен яхшы белгән кеше — Туңгак алып янында булган булса, тәгин угланга ул теләсә нинди ыбыр-чыбырны бирдермәс иде дә соң, менә ул юк. Таяныр кешең булмаганда нинди кыен! Башын ашадылар микән инде аның? Каян беләсең, ничек беләсең аны? Тагын бер-ике көн тоткарланган булса, белә алган булыр иде дә бит — булмады, ашыкты, күзем күрмәсен диде, тизрәк китеп котылыйм диде. Ичмасам өлкән колыны да ислерәк түгел. Аңа таянырга әле иртәрәк. Барысы да үз башыңа калса, җиңел булмас бу башбаштаклар белән.

Үзара әйткәләшүче ирләрнең усал-усал тавышларын ишеткәч, күрекле бикәнең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ирләр кемнең «яхшырак», кемнең «батыррак» булуы, кемгә буйсыну-буйсынмау турында сүз көрәштерәләр. Каган ягыннан кушылган ирләр Куяннар янында борын чөяргә чамалыйлар иде бугай. Куяннар исә, күпчелек буларак, аларның үзләреннән дә яманрак усалланалар.

Ирләр, ниһаять, бикәне күреп алдылар һәм барысы берьюлы диярлек тынып калды.

— Иминлекме, Җирән? — диде бикә, йөзбашына эндәшеп.

— Иминлек, бикә.

— Колынымны күрмәдеңме? — дигән булды бикә болай гына.

— Монда булдылар алар.

— Булдылар да, ары киттеләр,— диеште Куяннар.

— Буран булмагае — бил сызлый,— диде Җирән.— Кызурак барыргае.

— Атлар пошкыра!

— Аяктагы яра сызлый башлады — буран була,— диештеләр ирләр, Җирәннең сүзен куәтләп.

Әлерәк кенә каршы очраган башка ирләр, хатыннар да шундыйрак сүзләр әйткәннәр иде. Бикә үзе дә көндез көчле җил-давыл чыкмагае дип уйлаган иде — барысы да бер үк нәрсәне кабатлагач, ул инде ышанмый булдыра алмады һәм ышыграк җиргә барып җиткәнче кызуларга кирәк дигән карарга килде. Ләкин кая чаклы барырга, кайда тукталырга — бу хакта инде алдан баручы остарак көтүчеләр белән сөйләшергә кирәк иде.

Бикә, койрыкны әйләнеп, олауларның сул ягына чыкты һәм кешеләрне, терлекләрне узып, кызурак бара башлады. Ул тагын да үзенең кешеләрен, арбаларын күздән кичерде, артка таба барганда күрми калган берәрсе белән исәнлек-саулык сорашып алды. Иртәнге салкында ат өстендә тирбәлеп барган саен, кешеләр белән сөйләшкән саен аның кү-

нелендәге авыр уйлар, кайгы-пошынулар, төннектән чыгып киткән төтен кебек, тәмсез ис кебек, каядыр чыгып, таралып бетте. Шул ук вакытта аны үзенең иле-көне белән, малы-туары, байлыгы, балалары өчен моңарчы беркайчан да булмаган авыр, катлаулы бер тойгы — зур җаваплылык тойгысы биләп алды. Элегрәк ул, никадәр авыр һәм кыен булмасын, үзенең өлкән бичә, каган бичәсе икәнлеген аңлап яшәде. Шунлыктан ил-көн, мал-туар турындагы кайгылар, борчулар аңа әллә ни катлаулы булып тоелмады. Хәзер ул менә үзе генә калды. Үзенә буйсынган ирләр киләчәктә дә үзара шулай ызгышып торсалар, кемгә буйсыну-буйсынмау турында баш ватсалар, нишләр ул алар белән? Берәр яктан көтелмәгән кыран килсә, яу килсә, яклармы соң алар аны, әллә, киресенчә, үзенә каршы кул күтәрерләрме? Нindирәк кешеләр соң алар чынлап та каган биргән ыбыр-чыбыр? Тиешенчә белми торып ничек яшәмәк кирәк алар белән, ничек итеп аларны каравылга, сакка куймак кирәк? Бөтен эшне үз кулыңа алыргамы, тешне кысып олы колыныңа бирергәме? Ах, булсын иде аның янында хәзер теге атаклы Кол!

Әлегә ул берни хәл итә алмады, ул бары уйланды, пошынды гына.

Озакламый көн яктырды. Кара, тун дала өстенә якты кояш балкып чыкты.

— Кояш чыкты, әни! — дип кычкырды Куянкай очынып.

— Чыкты, кызым, чыкты. Читкә тибәрелгән кешеләргә дә кояш бертигез елмаеп карый. Барлык кешеләр аның өчен бер. Тик менә кешеләр үзара талашып, сугышып бүлгәләп алып бетергән бәхет кенә тигез түгел, кызым.

— Бәхет нәрсә соң ул, әни? — диде Куянкай.

— Бәхет ул, кызым, көч-байлык... яшьлек-матурлык,— диде бикә.

— Әнием, син нинди матур! — диде бала чын күңелдән сокланып.

Көтмәгәндә мондый мактау ишеткәч дүрт бала анасы куанып елмайды.

— Әни, син көләсең! Әни, син — бәхетле! — диде Куянкай.

— Бәхетле, кызым, бәхетле,— диде ана кызының күңелен кырасы килмичә.

Аның күзләренә яшь килде.

— Син миннән дә бәхетлерәк, кызым.

— Ник? — диде Куянкай.

— Син — яшьрәк.

Үзалдына ул уйлап куйды: «Син әле дөньяны... кансыз, көнчел дөньяны белмисең. Шуңа күрә дә бәхетле син, балам»,— диде.

### III

Албуга кылавызлар артыннан барды. Мөмкин булса ул алардан алгарак та чыгар иде, сакчыларны, олауларны, кылавызларны — барысын да артта калдырып, буш иркен далада үзе генә барыр иде дә барыр иде. Әйе, үзе генә. Аты белән, уйлары белән серләшеп барыр да барыр иде.

Әнисен борчыган уйлар аны да борчыды. Аның да күңелен әрнү, хурлану, өметсезлек тойгылары биләп алды. Билгеле, ул әнисе кебек үк борчылмады, газаплы уйлары, тойгылары да аның икенче төрлерәк булды. Ул үзенең уң кул тучи бәк — бөтен Сөн илендә каганнан кала икенче дәрәҗәдәге кеше икәнлеген әз генә дә исеннән чыгармады, ләкин бу турыда белү генә аның күңелсез уйларын томалый алмады. Ул үзенең өйләнергә тиешлеген һәм шуңа күрә, өйләнгән барлык угланнар кебек, атасы урдасыннан башкаланып чыгарга тиешлеген дә аңлады. Ләкин моны аңлау шулай ук анда юану, я булмаса һич югы үз-үзенә

ышаныч тойгысы бирә алмады. Барыннан да элек ул үзен әнисе белән бергә читкә тибәрелгән, урдадан куалап җибәрелгән итеп белде. Уң кул тучи бәк угыллары өйләнеп башка чыккач, үзләрен үзләре туйдыра алсыннар өчен, башкалар арасында аерылып торсыннар өчен элекке каганнар аларга ярым-йорты мең өй түгел, кимендә биш мең, алты-җиде мең өйлек ил-көн биргәннәр. Туман каган аны тулар-тулмас мең өй белән әнә, типкәләп, хур итеп дунхулар җиренә куалап җибәрде.

Нилләр көтә, кемнәр көтә анда аны, тәңрем?!

Шулай үзалдына уйланып барганда, арттан аны әнисе куып җитте.

— Нишләп үзең генә? — диде әнисе.— Адай кая, Кече-Таебыз кая? Кызың кая?

— Алар... теге якта калдылар,— диде Албуга уйларыннан тиз генә арына алмыйча.

— Абый, мин әни белән килдем! — диде Куянкай олы абыйсына эндәшеп.

— Син зур кыз бит инде,— дигән булды абыйсы Куянкайны мактап.

Бераз җир алар атларын янәшә атлатып бардылар. Бикә олаулар башына килеп җиткәндә көн инде яктырган иде. Ләкин кояш чыгып күп тә үтмәде, сул яктан, көнбатыштан көчле җил исә башлады. Һавада кар бөртекләре күренгәләде. Ачык далада иң яманы менә шушы җил белән каяндыр очып килгән кар бөртекләре иде.

— Әни, буран чыга! — диде Албуга.

— Борылыйк, улым, — диде бикә.

Алар атларын кире бордылар һәм каршыга килүче кешеләргә таба ашыктылар. Тиз арада алар янына кораллы ирләр, көтүчеләр җыела башлады. Олаулардан бер читкә туктап алар тиз генә киңәшеп алдылар. Бу тирәдә буран вакытында көтүләр, җигүле арбалар белән качып-ышыкланып торырлык бер генә уңайлы урын да юк иде. Шуңа күрә, кинәт җил-давыл чыга-нитә калса дип, барысын да алдан уйлап, кисәтеп куярга кирәк иде. Бу як далаларны яхшы белгән карт көтүчеләр туктамаска, киресенчә, ашыгыбрак барырга киңәш иттеләр. Алар исәбенчә, бер ярты көн барганнан соң комлы калкулыклар булырга тиеш иде.

Бикә көтүчеләр сүзенә колак салырга булды. Көтүләр, арбалар кызурак бара башладылар. Төштән соң карт көтүчеләр әйткән комлы калкулыклар янына барып җиттеләр. Бөтен ил-көн туктап калды. Шуны гына көтеп торган кебек кинәт буран чыкты. Күк йөзен тиз арада болганчык тоташ кар каплап алды. Тоз сыман каты, эре бөртекле кар янгыры, шапылдап-шакылдап, берәзлексез киез түбәләргә бәрде, биткә-аркага бәрде, ат сыртларын камчылады.

Арттан, алдан, ян-яклардан килүче сакчы ирләр, көтүчеләргә әйләнеп, билгеләнгән тәртиптә тезмәләргә бастылар һәм ары-бире чабып, таралышырга гына торган терлекләрне куып йөрделәр. Тәгин углан да көтүчеләргә кушылды һәм тамак ярып кычкыра-кычкыра, әле җилгә каршы чапты, әле аркан барды, төркемнән качып киткән терлекләрнең юлына аркылы төште.

Шулай үз-үзен белешмичә анда-монда чабып йөргәндә ул, җилгә каршы баскан килеш, тыныч кына бер читтә буран тынганын көтеп торган ниндидер ирләр төркеменә юлыкты. Бөтен җирнең-күкнең асты өскә килгән чакта, барлык кеше терлекләр тирәсендә булашканда, берберсенә сыенып тик торган ирләрне күреп ул бик нык аптырап калды. Кемнәр болар? Әнисенең ирләреме, аның үзенекеме, әллә бөтенләй чит кешеләрме?

Ирләрнең битлекләре төшерелгән, йөзләре томаланган булганлыктан, ул аларны таный алмады. Кар-буранга каршы күзләрен кысышты-

рып торганлыктан, ирләр дә аны күрмәделәр, сизмәделәр ахрысы.

— Таралсыннар! — диде ирләрнең берсе.

— Качсыннар! — диде икенчесе.

— Кырылсыннар! — диде өченчесе.

Алар, билгеле, көтүләр турында шулай сөйләнәләр иде. Сүзләрен тагын углан аермачык ишетте, ләкин мәгънәсен тиз генә төшенә алмады. Шуңа күрә ул аларны танырга да, белергә дә тырышмады. Алар кычкырган сүзләрнең мәгънәсен дә, аларның шулай буранда качып торуларын да ул соңыннанрак — буран тынып, үзе дә тынычлангач кына аңлады.

Буран озакка сузылмады. Бу әле бала буран гына иде. Аның «анасы» әле арттарак булырга тиеш иде сыман. Җир өстенең уентыграк, чокырлырак төшләрен, коры үлән төпләрен кар белән тигезләп, тирә-якны агартып-яктыртып, ул кисәк кенә туктап калды.

Буран тыну белән, кешеләр башлыкларын, битлекләрен күтәрделәр, күзләрен зуррак ачып, үзгәргән, яктырган далага карадылар һәм анда-монда тулган карларны каккалап-суккалап төшерделәр. Көне буена эчмәгән терлекләр кар яларга тотынды.

Күчмә авыл, калкулыклар арасында беркадәр тоткарланып торгач, яңадан кузгалып китте. Яңадан авыр көпчәкләр әйләнде, көчәнеп камыт баулары, тәртә баулары шыгырдады һәм түбәсе ябулы биек арбалар, диңгез өстендәге көймәләр кебек, җиңелчә генә тирбәлеп-чайкалып, дала дулкыннары өстеннән алга үрләделәр.

Алдан уйланганча, алар бүген төнне Уймак күл буенда кунарга тиешләр иде. Күл буена алар караңгы төшкәч кенә барып җиттеләр. Көндезге буран монда да чокыр-чакырларга, түмгәк, үлән араларына күп итеп кар тутырган иде. Шуңа күрә, терлекләрне сугару өчен күлдә бәкеләр тишеп азапланасы булмады. Арбалар тугарылды. Көне буена авыр йөкләр тартып килгән үгезләр, дөяләр, атлар тибенгә җибәрелде.

Бикә өен, тагын углан өен тәртәләре югары күтәртелгән арбалар белән әйләндереп алдылар. Арбалардан җыйналган боҗраның тышкы ягына, капка янына, шулай ук көтүләр янына төнге каравыллар куелды. Тагын углан, әнисенең әйткәнен дә көтмәстән, торгакларны, каравылларны үзе билгеләде. Үз-үзен белештермичә ул гел очынып-җилләнеп йөрде. Беренче мәртәбә ул үзен унлап егеткә түгел, бәлки бөтен бер ил-көнгә баш итеп, хуҗа итеп тойды.

## IV

Үз өенә ул тирә-як тынып калгач, күктә йолдызлар күренә башлагач кына кайтып керде. Җылы, якты өйгә пешкән яшь ит исе чыккан иде. Тыштагы коры салкыннан соң монда тынычта, җылыда искиткеч рәхәт, күңелле иде.

— Бүген мин аерым казан астым! — диде Табылдык аны сөенечле хәбәр белән каршылап.

— Шулаймыни? — диде Албуга елмаеп.

Табылдык аңа чишенергә булышты, авыр киемнәрен, билбавын алып куйды.

— Әнидән сорадыңмы соң? — диде углан, учак өстендәге тимер казанны караштырып.

— Ул үзе әйтте. Ул мине ярата! — диде Табылдык куанып. — Утананы үзе арыклады, итне үзе бирде, казанга үзе су салды.

— Каяле, эчендә ниләр бар икән моның? — диде Албуга, киез өстенә аякларын бөкләп утырып.

— Мин сиңа... бөтен бер тәкә пешердем! — диде Табылдык, казанның капкачын ачып.

— Бөтен бер тәкә! — диде углан төкрекләрен йотып.

Иртәннән бирле ул авызына берни капмаган, ашыйсы килүдән аның инде башлары әйләнә башлаган иде. Ике колагыннан тотып ул учак өстендәге тимер казанны күтәреп алды да эчендәге барлык итне зур агач табакка каплады. Итне ул корыч пычак белән үзе кисте, үзе турады. Башта ул үзе авыз итте, аннары иттән, пычактан күзен алмыйлмаеп утырган ягымлы кызына бирде. Итнең ул яхшы, йомшак кисәкләрен генә ашады да, калганын шулай ук Табылдыкка тоттырды. Хуҗасының юмартлыгына күңеленнән бик шат булса да, Табылдык алай комсызлык күрсәтмәде — үзенә бирелгән кисәкләрнең йомшаграк итләрен ул кире углан алдына куя торды.

— Үзең аша. Сиңа көчле булырга кирәк. Бер ашаганда бер куй да ашамагач, нинди алып ир син?! — диде кырнак хуҗасын җиңелчә генә шелтәләп.

— Күп була. Артыгы бармый,— диде Албуга.— Бер ашаганда бер куй ашарга иртәрәк әле миңа.

— Бер дә иртә түгел,— диде Табылдык.— Менә кымыз эчеп җибәр дә тагын ашарсың.

Тәгин угланнан ул бер-ике яшькә өлкәнрәк иде. Шуңа күрә үзен бераз гына тәҗрибәле санап, өйрәтергә хаклы санап, җиңелчә генә аны «кыздырып» алган булды, көлеп шаяртып аның авыз читләрен сөрткәләде. Мондый вак-төяк шелтәләрне, булышуларны ул угланның ачуын китермәслек итеп кенә, көлештереп кенә эшләде, һәм шулай итеп, ике арада киеренкелек, читсенү дигән нәрсә әкренләп югала барды. Албуга да аңа инде элеккечә сыртын кабартып тормады. Кызның ягымлылыгы, йомшаклыгы, күндәмлеге көннән-көн аның күңелен эретә барды. Кыз салып биргән кымызны Албуга иратып, рәхәтләнеп эчте. Кымыздан соң ул, көчләп булса да, тагын ит ашап куйды.

— Туйдым! Шартлыйм! — диде ул көлеп.

Зурайган шәрә корсагын ул ике куллап сыйпап алды.

— Каяле, тулды микән? — дигән булды Табылдык та, аның таштай каты эченә үрелеп. — У-у, монда әле тагын бер куйга урын бар!— диде ул көлеп.

— Җитәр, кыстама инде,— диде Албуга ашаудан баш тартып.

— Ярар, кыстамам.

Хуҗасының тавышында ул чак кына ризасызлык сизеп алды.

— Үзең аша,— диде углан, табакны бөтенләе белән кызга таба этәреп.

— Ашармын,— диде Табылдык.

Тәгин углан аның сөяк кимерүен караштырып беравык тынып утырды да, аягына басты, киемнәренә үрелде.

— Мин, булмаса, торгакларны тикшереп кайтыйм әле,— диде ул үз-алдына сөйләнеп.

Сөякләрен ташлап Табылдык шундук аягына басты, хуҗасыннан элек аның киемнәрен эләктереп алды да, киендерергә әзер булып, аның каршысында туктап калды.

— Әллә чыкмыйсыңмы? — диде ул угланның күзләренә карап.

— Нишләп алай?

Кыз ни әйтергә белми аптырабрак калгандай булды. Сине сагындым, миңем янда гына тор дияргә, үзенең күпмедер дәрәҗәдәге өстенлегеннән файдаланып, аңа нинди дә булса киңәш бирергә аның әлегә кыюлыгы җитмәде.

— Ирләр арасында сиңа аң булырга кирәк,— диде ул.

— Нинди ирләр арасында? — диде Албуга.

— Нинди ирләр икәнлеген белмим. Бүген мин әллә нинди сүзләр ишеттем,— диде Табылдык.

Тагин угланның үз-үзеннән канәгать, тук, бәхетле йөзе шундук үзгәреп китте. Келт итеп бүген буран вакытында очраган теге ирләр исенә төште, колагы төбендә яңадан аларның өзек-өзек сүзләре ишетелгәндәй булды.

— Нәрсәләр ишеттең? — диде ул сагаеп.

— Берсе әйтә: мин барыбер качам! ди... Икенчесе әйтә: мин талап качам, ди. Тагын берсе әйтә: башкалар Чингә яу чапканда, чин кызларын алып кайтканда, без монда сыер сыгрыйгы иснәп ятабыз, ди. Тагын берсе әйтә...

Табылдык, аның нәрсә әйткәнен исенә төшерә алмагандай, төртелеп туктап калды.

— Нәрсә әйтә?!— диде Албуга, кызының беләгеннән тотып алып.

— Син... миңа ачуланмассыңмы? — диде Табылдык икеләнеп.

— Ачуланмам. Барысын да әйт,— диде углан.

— Алар каган сине урдадан сөреп җибәрде дип уйлыйлар. Сине беркайчан да Ак урдага кайта алмас дип уйлыйлар,— диде кыз.

— Шул гынамы? — диде Албуга.

— Түгел. Берсе әйтә: тәгин углын каган үлемгә җибәрде, ди. Алты йөз-җиде йөз өй белән ничек итеп анда башкаланып яшәмәк кирәк, ди. Үз җирләренә барып җитү белән дунхулар безне кырып салачаклар, ди.

Албуга, башына суккандай, тынсыз-өнсез калды. Үзенең, энисенең нинди ышанычсыз, тотрыксыз хәлдә калганлыгын ул инде болай да белә иде, шуңа күрә Табылдык әйткән сүзләрдә әллә ни яңалык та юк иде. Бу бары үзең сизенгән, үзең төшенгән куркыныч нәрсә турында чит кеше авызыннан ишетү һәм шуның белән үз шигеңне, үз сизенүеңне ныгыту гына булды. Аның өчен күп нәрсә яңадан ачыкланып калгандай булды, ләкин менә тук, канәгать килеш яңадан шомлы, куркыныч чынбарлык белән очрашу аны каушатып җибәрде.

Аның үзгәргән, бозылган кыяфәтен күреп, яшь хатын чын-чынлап куркуга төште. Ул аңа табарак тартылды, аны кочаклап алды, иркәләп, яратып аның аркасыннан, иңбашларыннан сыйпалады.

— Нишләп болай коелып төштең әле син? — диде ул йомшак кына, гөр-гөр килеп. — Ир кеше усалрак, кырысрак була ул. Син алып ир, син — тучи бәк тәгин углан! Теләсә кем сүзенә колак сала башласаң!

— Колак салмыйча да ярамый,— диде углан.

— Колак салсаң да, каушап калырга кирәкми,— диде яшь хатын аны яклап һәм сиздермичә генә үзенең киңәшен дә кыстырып.

— Мин барында син тыныч бул. Мин сиңа көч бирермен, кыюлык бирермен, яшь богам! Мин үлем тырнагында булдым, мин абалар авызыннан ычкындым. Мин инде беркемнән, бернидән курыкмыйм кебек. Мин бары синнән генә куркам бугай... яратмассың дип, ташларсың дип куркам бугай...

— Курыкма! — диде углан уяну билгесе сиздереп.

Кызын ул кочаклап алды, аның җылысын тоеп, аның дәртле көчен тоеп һәм шул ук вакытта тынычлана барып ул сүзсез генә аңа карап торды. Андагы бу үзгәрешне, эчке борылышны яшь хатын бөтен тәне белән сизде.

— Мин — кырпак. Беркайчан синең бичәң була алмам,— диде ул кайнар пышылдап.— Шулай да мин синең мәңгелек юлдашың булырмын. Миннән алда үлсәң, беренче булып мин синең кабереңә кереп ятырмын — теге дөньяда мин синең аяк астыңда йомшак мендәр булырмын. Тик минем әле үләсем килми. Минем үләсем килмәгәч, син дә үлмәячәксең — шуны онытма! Теләсәң, ун кызга, йөз кызга өйлән, тик мине генә читкә тибәрмә!

— Мин сине читкә тибәрмәм. Мин сиңа ышанам! — диде углан тәмам күңеле эреп.

— Инде чыксаң да ярый,— диде Табылдык бушанып, җиңеләеп.— Минем елыйсым килә, сөенечтән елыйсым килә. Син югында мин иркенләп елармын.

— Мин барында ела. Мин тыймыйм,— диде углан.

— Минем сиңа яшьле күз белән күренәсем килми. Син бар. Торгакларны тикшер. Мин сине танга чаклы көтәргә дә әзер,— диде Табылдык.

Ул ашык-пошык аны киендерергә тотынды. Әле көлде, әле борынын тарткандай итте һәм үзенең кайгысын да, шатлыгын да, үлемен дә, яшәвен дә үз кулында тоткан яшь ирдән — кырыс та, куркыныч та тоелган олуг ирдән аерылырга теләмичә, ялгыш кына әле аның кулына, иңбашына орынып алды, әле аның күзләренә елмаеп карады.

## V

Яшь хатын белән тулы аңлашу, тулы якынлык барлыкка килсә дә, тагын угланның күңел төбендә үз язмышы, энисе һәм ил-көн язмышы турындагы борчылу тойгысы торып калды. Кызның кайнар иркәләвеннән аерылып, кара, салкын тышка килеп чыккач, әлеге берни белән бетереп булмый торган борчылу, пошыну тойгысы барлык уйларны, тойгыларны күмеп, яңадан өскә калкып чыкты. Аның хәзер энисен күрәсе, бик кирәкле нәрсәләр турында сөйләшәсе килде.

Бикә өендә тагын йөзбашы Җирән белән баш бага Кортага да бар иде. Албуга килеп кергәндә алар нидер киңәшеп, сөйләшеп утыралар иде. Адай белән Кече-Тай да шунда эниләре тирәсенә елышканнар. Кечкенә кыз Куянкай, аякларын, кулларын як-якка ташлап, ястык-мендәр арасында йоклап ята.

Бикә үзенең өлкән углын түргә, үз янына чакырды. Ирләр, тагын угланга буйсыну белдереп, аның алдында баш иделәр, сүзсез генә читкәрәк тайпылдылар.

— Синең керүең яхшы булды әле, улым,— диде бикә.— Эшләр шәптән түгел безнең. Менә шул турыда сөйләшеп утыра идек.

— Ни булды тагын?

— Әлегә булмады. Йоклап ятсак, булыр,— диде бикә.

— Каган безгә үзенең башбаштакларын, башкисәрләрен биргән,— диде баш бага Кортага.— Алар ачыктан-ачык буйсынмау белдерәләр, теләшәләр, төрле имеш-мимешләр сөйлиләр. Мин үзем дә ишеттем. Менә башкаларга да ишетелгән.

— Ишетү генәме! — диде йөзбашы Җирән.— Нишләргә алар белән? Кире урдага кайтарып җибәрергәме, берсен калдырмый кырып бетерергәме?

— Нәрсә уйларга да баш җитми, улым,— диде бикә дә.— Син менә ни әйтерсең икән?

Барысы да җавап көтеп, тагын угланга текәлделәр. Аны шулай сынап карау өчен юри генә сөйләнәләр идеме алар, чынлап сөйләнәләр идеме — Албуга моны төпченеп тормады. Бөтенесен үз кулына алырга, бөтенесен үзенчә эшләргә дип ул инде күптән уйланып йөри иде һәм ул инде моңа әзер дә иде бугай. Тик моңарчы ул энисенең бу эшкә ничегрәк караячагын гына белми иде. Әнә хәзер алар барысы да аннан акыллы сүз көтәләр.

— Сез әйткән башбаштак, башкисәр ирләрне атам каган миңа дип бирде. Алар — минеке. Шулай булгач, аларны мин тыячакмын, — диде

ул әкрен генә сүзгә башлап. — Мин аларны кире дә кайтарып җибәрмәячәкмен, кырып та бетермәячәкмен. Мин аларны буйсындырырга тиешмен!

— Сүзләрең алтын, улым! — диде бикә, улының шундый төпле, акыллы итеп сөйләвенә исе китеп.

— Белеп сөйлисең! — диде баш бага Кортага да.

— Икәүнең — берсе өстен, берәүнең — бүрке өстен, — диде углан.— Бездә элегә, әни, беркем дә өстен түгел. Мин мал-туарны әйтмим, коралды ирләрне әйтәм. Башбаштаклык безнең үз арабыздан башлана, әни.

Бикәнең дә, ирләрнең дә кинәт колаклары үрә торды. Яшь угланның сүзләре аларны сөенергә дә, сагаерга да мәҗбүр итте.

— Безнең эле кайгыдан айныганыбыз юк. Без көтүчесез көтү кебек таралып, туарылып, кем ничек тели шулай барабыз, — диде Албуга дәвам итеп.

— Син, углым, менә шул таркау көтүнең көтүчесе була алырсыңмы соң? — диде ана сак кына, иплэп кенә.

— Мин, әни, туганда ук көтүче булып тумаганмын мени? — диде уң кул тучи бәк тәгин углан.

— Шулаен шулай да... — диде әнисе ы-мы итенеп.

— Яшьрәк дисеңме? — диде Албуга әнисенең уйларын сизенеп. — Кайчан да булса дилбегәне мин барыбер үз кулыма алырга тиеш түгел мени?

— Йөзбашы Җирән! — диде бикә, башын калкытып. — Бүгеннән башлап син дә, синең ирләрең дә тулысынча минем углым Албугага буйсынасыз!

— Буйсынабыз, бикә! — диде йөзбашы Җирән, баш иеп. Шуннан соң ул тәгин углан ягына борылды, аңа да баш иде: — Моннан соң мин сиңа буйсынам, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде.

— Бай бул, әнием! — диде Албуга әнисенә. — Бүгеннән башлап мин синең коралды ирләреңне дә, атам каган биргән үз ирләремне дә бер йодрыкка туплаячакмын.

— Бирсен, таңрем! — диде бикә чын күңелдән сөенеп.

— Мин болай уйлыйм, — диде Албуга йөзбашы Җирәнгә карап. — Безгә башбаштаклар белән Куяннарны аралаштырырга, катнаш алайлар төзергә кирәк.

— Шулай итәрбез, — диде йөзбашы Җирән. — Куяннарның ант бозганнары юк, Куяннар синең иң турылыклы ирләрең булыр, олуг тучи бәк тәгин углан.

— Шуңа күрә, — диде Албуга, аның сүзләрен эләп алып, — төнге каравылга бүген бары Куяннарны гына куярга кирәк булган. Инде соң.

— Соң түгел, тәгин углан, — диде Җирән. — Төнлә ул-бу булмасын өчен без Куяннардан гына өстәмә торгаклар билгелик.

— Төнгә мин дә чыгам! — диде Адай шундук тавыш биреп.

Абыйсы усал гына итеп аның ягына карап алды.

— Моннан соң өлкәннәрдән узып авыз ачмаска боерам! — диде ул кырыс кына.

Башка вакытта абыйсыннан мондый каты сүз ишетмәгән Адайның ике күзе шар булды. Үзеннән-үзе калтырана башлаган иреннәрен көчкә тыеп ул үпкәләп тизрәк читкә китеп барды. Тәгин угланның мондый кискенлеген ошатмыйча, өлкәннәр бер-берсенә карашып алдылар.

— Нинди алып ир килгән дип торырсың! — дип мыгырданды Адай хәтере калып.

— Элеккечә минем белән телләшсәң, үпкәләп авыз күпертсәң, беркая чыкмассың! — диде абый кеше тагын да ныграк үткәзеп.

Адай шып булды. Беравык абыйсына каш астыннан гына карап торды да, килешергә теләвен белдереп, буйсынып:

— Моннан соң алай булмас, — диде.

— Ярар, син дә чыгарсың, — диде Албуга йомшап. — Әни, син тынычлап йокла.

— Болай булгач, улым, мин чыннан да тыныч, — диде бикә елмаеп. — Син үсеп җиткәнсең, олыгаеп киткәнсең. Мин күрмәгәндә генә!

— Мин дә үстем, әни! — диде олыларның сүзләрен йотлыгып тыңлап утырган Кече-Тай.

— Үстең, улым, үстең, Кече-Таем! — диде ана кеше, бәләкәй улының башыннан сыйпап.— Үстегез инде — яклаучыларым бар. Сез барында миңа берни куркыныч түгел, балаларым.

## VI

Көтүләр янына, боҗраның тышкы ягындагы төрле төшләргә Албуга Куяннардан өстәмә каравыллар куйды. Үзенә иптәшкә ул Адайны да алды һәм алар икәүләшеп ярты төнгә чаклы сакчылар, каравылчылар тирәсендә булдылар. Йөзбашы Җирәнгә ул йокларга кушты. Төн уртасы җиткәч исә уятты да таңга чаклы йокламаска, әледән-әле төнге торгакларны тикшереп торырга боерды. Шуннан соң алар Адай белән өйләренә кайтып киттеләр.

Икенче көнне авыл иртә уянды. Өйләрне җыеп, арбаларны җигеп яңадан кузгалганчы дип, тәгин углан үзенә буйсынган барлык коралны ирләрне ачык җиргә алып чыгарга һәм сафка тезәргә боерды. Аның йөрәге түзмәде — аның тизрәк үз ирләрен үз күзе белән күрәсе килде. Бармак белән төртеп ул ирләрне үзе санап йөрде. Саный торгач, төпченә торгач, каган биргән ирләр арасыннан ике кешенең юклыгы беленде. Аларның кайчан, ничек юкка чыгуын беркем дә рәтләп аңлатып бирә алмады. Алар, имеш, кичә кичтән үк күренмәгәннәр.

Качакларны эзләргә, тотарга Албуга кеше җибәреп тормады. Киткәннәр икән, китә бирсеннәр — далада әле беркемнең дә җил белән атлы качакны куып тота алганы юк. Инде моннан соң ычкындырырга ярамый. Беркемне дә. Моннан соң инде күз-колак булырга, белеп-тикшереп кенә торырга кирәк булачак!

Тезмәләрдәге ирләрне барлагач, качаклар турында белешкәч Албуга йөзбашы Җирәнгә борылды һәм кызмаска, ачуланмаска тырышып:

— Йөзбашы Җирән! — диде.— Анам бикә сине миңа бирде. Анам алдында син миңа бил бөктең. Моннан соң син кизү чагында минем, бикәнең байлыгыннан ике ат белән ике кеше түгел, ике тун белән ике энә югалса да, мин синең... башыңны чаптырачакмын!

Гомере буена диярлек бикәгә тугрылыклы булган, аның авылында көн-төн каравыл торган, аның азыгын ашап, аның белән якыннан дуслашып беткән һәм бераз гына симерә башлаган, үз-үзеннән канәгать йөзбашы Җирәннең әле беркайчан да мондый куркыныч кисәтү ишеткәне юк иде. Үзлегеннән ул бернәрсә дә эшләмәскә күнеккән, ул бары буйсына, тыңлый, боерыкларны җиренә җиткереп үти һәм шунлыктан үзен буйсынучан, булдыклы, тырыш ир дип исәпли иде. Яшь угланның янавы аңа аяз көнне яшен суккан кебек булды. Ул шаккатты, телсез-өнсез калды. Әле кайчан гына үзе күтәреп йөрткән, атка атландырып йөрткән малай-шалайның, борыны астында ныклап мыек та үсмәгән яшь угланның мондый кырыслыгына каршы ул берни дә әйтә алмады.

Үзенең кискенлегеннән тәгин углан үзе дә каушабрак калды. Ләкин ул инде кире дә чигенә алмый иде.

— Синенчә булыр, олуг тучи бәк тәгин углан, — диде Җирән мыгырданып.

Үзалдына ул уйланып куйды: «Төнә буе анда-монда чабып йөрде дә, әнә йокысы туймаган. Бик авыр булыр бу яшь этәч белән». Әмма сүз куертып аның ачуын китерәсе килмичә, тизрәк читкә китеп барды.

Ала-кола дала өстенә көндәгечә сыек, салкын яктылык тарала башлады. Бөек кояшның җир астыннан калкып килүен күреп, тезмәдәге кораллы ирләр, изге бер тынлык белән, көнчыгышка таба борылдылар. Тәгин углан да тынып калды, башын калкытты һәм кояш чыкканын көтә башлады. Шул чакны аның кырыс, агарынган йөзенә, кояш нуры сыман булып елмаю балкып чыкты. Тезмәнең ерактагы койрыкларына ул уртага таба бөгелергә, үзенә якынрак килергә боерды. Боерыкны тезмә буена тапшырдылар. Күп тә үтмәде, як-яктан озын койрыклар кыймылдап куйды, якыная башлады. Бөтен тезмә, көнчыгышка йөзе белән борылган хәлдә, дуга сыман булып тынып калды.

Тәгин углан энесе Адайны үзе янынарак чакырды.

— Мине арттан сакла. Сөңгеңне әзер тот! — диде ул аңа.

Шуннан соң ул бөтенесенең күз алдында атыннан сикереп төште, өстендәге тунын салып җиргә җәйде дә, башындагы бүреген салып кулына тотты, тунына тезләнде һәм зураеп, яктырып килгән кояшка карап:

— Тәңрем! Олуг атам! Мәңге юлдашым бул, изгелегеңнән ташлама, — дип кычкырды.

Бу аның Кояшка карап әйткән, барлык кеше ишетерлек итеп әйткән беренче келәве иде. Үзенең бик тә кирәкле эш, олы, куркыныч эш эшләвен аңлаудан, үзен кыю һәм башсыз итеп тоюдан аның йөрәге атылып чыгардай булып типте. Ашыкмаска-кабаланмаска тырышып ул башына бүреген киде, өстенә тунын киде дә, яңадан атына атланды һәм күрмәс күзләре белән йөзләгән ирләр ягына карап:

— Ишеттегезме минем келәүне? — дип кычкырды.

Ирләр, ни әйтергә белмичә, каушап калдылар. Сөн иләндә бары ил башы каган гына иртән — кояшка, кич — айга келәү әйтә, бары ул гына Тәңрегә «атам» дип эндәшә ала иде. Нәрсә бу, йола бозумы, әллә каганга каршы баш күтәрүме? Бу шундый изге, серле нәрсә иде — моны аңларга беркемнең дә башы җитмәде. Башкалар гына түгел, тәгин углан үзе дә моны ныклап торып төшенә алмады. Ул бары үзенең Тәңре улы булуын гына белде дә, үзен танымаган, танымаска тырышкан башбаштак ирләр алдында үзенең кемлеген күрсәтергә кирәклеген генә белде. Аның колаклары шаулады, битләре уттай кызды, күзләре исә якындагы Адайдан башка беркемне дә аера алмады.

— Абый, кузгалырга боерык бир! — диде Адай.

— Нәрсә, нәрсә?

— Арбалар җигелде. Кузгалырга кирәк. Боерык бир! — диде Адай кычкырып.

Албуга аңлап алды һәм тамак ярып:

— Кузгалырга! — дип кычкырып җибәрде.

Тезмә тарала башлады. Һәркем үз урынына ашыкты — берәүләр атларын юырттырып олаулар алдына киттеләр, икенче берәүләр көтүләр янына ашыкты. Бөтен ил-көн кузгалып киткәндә сул яктан ачы җил исә башлады.

Тәгин углан, үз-үзенә урын таба алмагандай, каядыр алга чапты. Аның яныннан, күләгә кебек, Адай барды. Алар шулай юырттырып кылавызлар янына ук барып чыктылар, аның юлын кистеләр дә, каршыга таба килә башладылар. Бу вакытта инде аларның кайнарлыгы сүрелә төшкән иде. Тәгин углан әле генә булган нәрсә турында тынычлабрак уйларга тырышып карады. Ул үзенең бик зур ахмаклык эшләвен аңламый булдыра алмады. Ирләр алдында, бөтен ил-көн алдында

Тәңрегә «атам» дип эндәшергә аның бернинди хокукы юк иде. Бу турыда каган ишетсә, күрәсең, аның башыннан сыйпамас.

Каган! Әти! Нинди якын иде ул кайчандыр! Янында ичмасам атасы урынында булган акыллы, дус, якын Туңгак алып та юк.

«Качып кына карасыннар! Әйтеп кенә карасыннар!» диде ул шундук үз-үзенә җавап биреп. Качакларны, башбаштакларны исенә төшергәч аны чиксез нәфрәт һәм ачу тойгысы биләп алды. Алар аны сабый дип уйлыйлар, ахрысы, шуңа күрә качарга, телләшергә ярый, дип беләләр, ахрысы. Качмый торыгыз әле, телләшми торыгыз! Менә ташлап китеп иреккә чыкмакчы, үлемнән котылмакчы буласызмы? Үлсәк — бергә үләбез, яшәсәк — бергә яшибез!

Ул үзенең егетләрен көтеп алды да, сүзсез генә алар алдыннан китте. Егетләрнең күбесе аның яшьтәшләре иде. Алар аның үз ирләре, җан сакчылары иде. Аларга ул үзенә таянган кебек таяна ала. Егетләр һәрвакыт аның янында булырга, аны төрле бәла-казадан саклап калырга тиешләр иде. Ләкин ул бүген аларга аерым алай булып, олауларның уң ягыннан сакта барырга кушты. Алайны көчәйтү һәм каган биргән ирләр белән якынайту, дуслаштыру өчен ул аларга тагын унлап «башбаштак» яшьләрне өстәде. Энесе Адайны ул көчәйтелгән әлеге алайга унбашы итеп билгеләде.

Бер мәртәбә олауларны, көтүләрне карап әйләнгәч ул тагын үзенең егетләре янына килеп чыкты. Адай шундук абыйсы янына килде. Алар беркадәр тарала башлаган алай алдыннан бардылар.

— Ничек, шауладашмыйлармы? — диде Албуга.

— Куяннарга кушылмыйлар. Бер алайда — ике алай, — диде энесе.

Тәгин углан артына борылып карагандай итте — чыннан да егерменләп кешелек төркем арттан икегә бүленеп килә иде. — Алар әйтә: Сөнәнкәләр Куяннарга буйсынмый, Куяннар Сөнәнкәләргә буйсынырга тиеш, диләр, — диде Адай әләкләп.

— Әйтсеннәр, әйтә бирсеннәр, — диде абый кеше, исе китмәгәндәй.

Шулай атларын әкрен генә атлатып барганда, алда, куаксыман кабарып утырган куе үлән арасыннан ялт итеп ап-ак куян чабып чыкты. Ул да булмады, каяндыр югарыдан, баш өстеннән, канатларын сызгыртып бөркет очып төште. Күз ачып йомганчы Албуга җәясенә ук утыртты, атып җибәрде. Качып барган куянны инде эләктердем генә дигәндә, бөркет кошны тимер очлы ук куып җитте. Таштай авыраеп, бөркет кинәт җиргә төште. Үлем тырнагыннан котылган ана куян кырт кына унга борылды да, үзән буйлап чаба башлады.

Ләкин шулай да ул ерак китә алмады — аны тимер башаклы куркыныч ук куып җитте. Зур ак куян сөрлегеп китте, торды, яңадан чапмакчы булды, егылды һәм җир өстендә тыпырчынып итты да тынып калды.

## VIII

Бу шундый көтмәгәндә булды, шундый искәрмәстән булды, — әйтерсең, күктән кинәт яшен ташы төште, әйтерсең, кинәт җир убылды. Куян ыруы кешеләре, котлары алынып туктап калдылар — Куян ыруы кешесе өчен куян үтерүдән дә хәтәррәк нәрсә юк иде. Сөнәнкәләр, башбаштаклар шаркылдап көләргә тотындылар. Тәгин углан ярсып, агарынып шундук артына борылды.

— Кем? — диде ул, үз артыннан килгән егетләргә кычкырып.

Егетләрдән кемнең дә булса «кем» икәнлеген әйтеп өлгергәнче ул «кем»нең кем икәнлеген үзе күреп алды. Бу «кем» башбаштаклар төркеменнән булган бер Төпсә атлы яшь ир иде.

Кыска буйлы, аюдай таза, көчле бер кеше. Башкалардан өлкәнрәк

булгангамы, көчлерәк булгангамы ул ничектер бик тиз күзгә ташлана, гел үзен бәйсез, иркен тотарга ярата иде. Аннары аны чамадан тыш комсыз дип тә сөйлиләр иде. Яуда чагында ул ничек тә үзе генә алга чыгарга, яхшырак, җайлырак нәрсәләрне эләктереп, тизрәк табан ялтырату ягын да карый икән.

Үз төркеме алдыннанрак барган һәм әле генә кереше тартылган җәясен кире тишеп азапланган Төпсәне күреп алу белән, Албуганың күз аллары яктырып киткәндәй булды. Шул кыска гына вакыт эчендә ул әлеге башбаштак ир турында ишетеп белгәннәрен исенә төшереп, шунда ук тиешле карарга да килеп өлгерде. Ул атын кырт кына аңга борды, әле һаман авызы ерык Төпсәнең каршысына килеп басты, кынындай кылычын тартып алды да бар көченә селтәнеп җибәрде. Үз-үзеннән канәгать төс белән елмайган авызлы, зур борынлы кабак баш, ни булганын төшенә алмыйча, юан, таза гәүдәдән аерылып, шапылдап, бәсләнгән ат сыртын кызыл канга буяп, таштай каты җиргә барып төште. Кола-туры ат колакларын шәмрәйтеп, куркып пошкырып җибәрде һәм сыртыннан шуышып ычкына башлаган авыр гәүдәне өстерәп читкә чабып китте.

Боларның барысы да тәгин угланның юлдашлары күз алдында булды. Барысы да, котлары алынып, туктап калдылар. Шул чакны башбаштаклар төркеменнән берәү, башкаларны ырып-ерып, тәгин угланга таба якыная башлады. Ачуы-ярсуы әз генә дә кимемәгән, шул ук вакытта саклык, уяулык тойгысын да югалтмаган Албуга кырын күз белән генә аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торды. «Нишләр икән?!» дип уйлады ул үзенә таба килүчегә каршы юлбарыстай ыргылырга әзер булып.

Аңа таба якынаерга азапланган егет үч иткәндәй угына-җәясенә тотынды. Тәгин угланның белүенчә, бу егет Төпсәнең бертуган энесе Тишек-Таш булырга тиеш. Ул да абыйсы кебек үз таза, явыз, комсыз бер кеше иде. Йола буенча ул абыйсы өчен канлы үч алырга хаклы. Ләкин Тишек-Таш дәһшәтле «Канга-кан!» сүзен кычкырып өлгергәнче, җәясенә ук утырта алганчы, тәгин углан, беренче булып:

— Тишек-Таш! Ташла коралыңны! — дип кычкырып җибәрде.

Егетләр кузгалып куйдылар, Тишек-Ташның нишләргә җыенуын күреп тиз арада аны төрле яктан чолгап алдылар. Егетләрнең барысы да «башбаштаклар» иде! Тишек-Таш та аптырап тормады — атының сыртына басты да, угын керешкә утыртты да...

Аны чолгап алган иптәшләре моны абайлап җиткермәделәр. Алар бары якыннан гына очып киткән бөркет каурыйлы ук койрыгын гына күреп калдылар. Күрделәр дә барысы да берьюлы тәгин углан ягына борылып карадылар. Анда, аның аты өстендә беркем юклыгын күреп, барысы да аһ итеп җибәрделәр. Аны-моны төшенмичә ярсып, алар коралларына тотындылар һәм, сытып ташларга әзер булып, Тишек-Ташны тагын да ныграк уратып алдылар. Шомланып атлар пошкырды, баш өстендә үткер кылычлар ялтырап китте.

Тишек-Таш ук атканда иярennән егылып калган Албуга алар шулай шаулашканда яңадан иярәнә менеп утырды.

— Туктагыз! — дип кычкырды ул үз егетләренә.

Тишек-Ташның күз алдында уйнаган ачулы кылычлар авыраеп түбән төштеләр, кыныларга шуышып кереп тынсыз калдылар. Тишек-Таш, төрле яктан аучылар белән уратып алынган киек кебек, куркып як-ягына карады да, агарынган йөзен бозып, ямьсез итеп еларга керешге. Әле генә үлемнән исән калуы өчен елый идеме ул, бертуган абыйсының коелган каны өчен үч ала алмавы өчен елый идеме — беркем моны белә алмады.

— Таралыгыз! Җибәрегез аны, — диде Албуга боерып.

Тыгызланып бер тирәгә укмашкан йомгак теләр-теләмәс кенә су-

телә башлады. Тәгин углан, Тишек-Ташның тынычланганын көтеп торды да, әчке бер күтәренкелек белән:

— Ирләрем-егетләрем, мине тыңлагыз! — диде.

## VIII

Барысы да, бердәй булып, тәгин угланга текәлделәр.

— Мин бүген иртән Тәңрегә күләү әйттем. Ишеттегезме? — диде Албуга.

— Ишеттек! — диделәр егетләр бер авыздан.

— Мин Тәңрегә «атам» дип эндәштем. Ишеттегезме? — диде углан.

— Ишеттек! — диделәр егетләр.

— Син — каган түгел. Син йола боздың, — диде Тишек-Таш.

— Әйе, мин ил башы каган түгел, — диде Албуга Тишек-Ташка җавап итеп. — Шуны онытмагыз: мин — Тәңре углы!

Мондый сүз ишетеп яшьләр тагын да ныграк тынып калгандай булдылар. Хәтта Тишек-Таш та каршы әйтергә сүз таба алмады.

— Шулай булгач, сезнең өчен мин — каган кебек! — диде Албуга дәвам итеп. — Минем сүзем, минем теләгем — сезнең өчен боерык. Күктә кояш балкып торганда мин ант итеп әйтәм: минем егетләрем арасында, миңа буйсынган барлык ирләр арасында моннан соң башбаштаклар, качаклар, телләшүчеләр булмаячак! Мин, Тәңре углы Албуга, буйсынмаган, телләшкән теләсә кемнең башын чаптырырга боерачакмын. Тотнаксыз, тәртипсез Төпсәнең үлеме сезгә шул турыда искәртеп торсын.

Төпсә исеме чыгу белән, Тишек-Таш ярсып:

— Син аның канын койдың! — дип кычкырды.

— Кан өчен кан койдым! — диде Албуга аңа каршы.

— Син үзең Куяннардан түгел, син — Сөнәнкәдән! — диде Тишек-Таш бирешәсе килмичә.

— Минем әнием, минем дәү әтием — Куяннардан. Сөнәнкәдән мине атам каган куалап җибәрде. Шулай булгач, мин кем ыруыннан булам, Тишек-Таш? — диде тәгин углан.

— Куян ыруыннан! — диделәр егетләр, аны яклап.

Тишек-Таш эндәшмәде.

— Төпсә минем ырудашымның канын койды! — дип кычкырды Адай, абыйсын яклап, ләкин шундук, шүрли калып, тиз генә аның ягына карап алды.

— Төпсә Куян ыруы абасының канын койды? — диделәр башкалар да, Адайның сүзләрен куәтләп.

— Шулай булгач, йола кем яклы, түрә кем яклы? — дип кычкырды тәгин углан бөтен даланы яңгыратып.

— Йола синең яклы! Түрә синең яклы! — диделәр яшьләр.

Бары тик Тишек-Таш кына авыз ачмады.

— Ник эндәшмисең? — диде аңа Албуга.

— Кичер... тәгин углан, — диде Тишек-Таш әкрен генә, кызарынып.

— «Тәңре углы уң кул тучи бәк»... — диде Албуга аны төзәтеп.

— Аңсызлыгым аркасында сиңа кул күтәреп мин ялгышлык эшләдем. Кичер мине, Тәңре углы уң кул тучи бәк, — диде Тишек-Таш, үкенү белдереп.

— Мине тыңлагыз, Тәңре углы уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга сөйли! — дип кычкырды яшь ир үзенең юлдашларына — Сез беләсез булыр: комсызлыгы башыннан ашкан Туман каган минем яраткан кызымны тартып алды. Аныcы гына җитмәгән, ялганчы төш юраучыларның юравына ышанып ул мине дә, минем әнием Күрекле бикәне дә Ак

урдадан читкә сөрде. Сезнең язмыш белән минем язмыш — уртак. Мин туңсам — туңарсыз, миңа җылы булса, сезгә дә җылы булыр. Мин ачыксам, ачыгырсыз, мин тук булсам, сез дә тук булырсыз. Мин кайда гына булсам да, мин кем генә булсам да, сез миңа мәңге турылыклы булырсызмы?

— Булырбыз! — диделәр егетләр дала яңгыратып.

— Син дә турылыклы булырсыңмы, Тишек-Таш?

— Булырмын!

— Барыбыз да! — диделәр Сөнәнкәләр, Тишек-Ташны яклап.

— Антмы? — диде Албуга.

— Ант! — диделәр егетләр, җирне-күкне дер селкетеп.

«Ант» сүзен өч мәртәбә кабатладылар. Албуга кырын күзе белән һаман да Тишек-Ташны күзәтте. Башкаларга кушылып ул да өч мәртәбә «ант!» дип кычкырды.

Яңадан кузгалып китәр алдыннан Албуга Тишек-Ташка эндәште.

— Мин сине кичердем, — диде ул аңа. — Мин сиңа агаң Төпсәнең хатынын, балаларын, үгезләрен, киез өен бирәм.

— Мең яшә, Тәңре углы уң кул тучи бәк! — диде Тишек-Таш каушап һәм куанып.— Үлгәнче колың булырмын, иң кыен чакларыңда арка таянычың булырмын! Утка каршы су булырмын, суга каршы ут булырмын!

— Кәлтә! — диде Албуга ачык йөзле, озын, таза буйлы чибәр егеткә эндәшеп. — Мин күреп тордым: аңсызлыгы аркасында Тишек-Таш миңа угын төзәгәч, беренче булып син капладың мине. Төпсәнең атын, коралларын сиңа бирәм.

— Моннан соң да сине уктан, сөңгедән саклармын. Кирәк булса, тимер туның булырмын, корыч калканың булырмын! — диде Кәлтә дулкынланып.

Йола буенча Төпсәнең хатыны, балалары, мал-туары — барысы да тәгин угланның үзендә калырга тиеш иде. Әнә ул үзенә берни алмады — барысын да өләште дә бетерде. Йола турында беренче булып Кәлтә искә төшерде.

— Сез соң барыгыз да минем егетләрем түгел мени? — диде Албуга. — Сезгә өлеш чыгару ул минем үземә өлеш чыгару түгел мени?

Сөн илендә әле моңарчы беркемнең дә, бер генә алыпның да, бер генә бәкнең дә үзенә тигән өлештән баш тартканы юк иде. Әнә ул баш тарта. Ник? Усал егетләренең күңелен күрү өченме? Ни генә булмасын, мондый тәгин угланны яклап чыннан да утка да, суга да керергә була!

Кәлтә белән Тишек-Таш та, башкалар да бу мәлдә шулайрак фикер йөрттеләр.

Албуга үзе бөтенләй икенче нәрсә турында баш ватты. Куян белән Төпсә белән булашкан арада арттан аларны башка алайлар куып җитеп киләләр иде. Аларга берни сиздермичә, тизрәк моннан кузгалып китүдән дә яхшы нәрсә юк. Егетләргә ул үтерелгән куянны, Төпсәнең башын алып тизрәк кузгалып китәргә боерды. Аннары ул Төпсәнең үле гәүдәсен алып качкан атны тотарга, алып килергә, үле гәүдәне, беркемгә күрсәтмичә, берәр аулак җиргә илтеп ташларга кушты. Бу эшне ул Кәлтәгә тапшырды.

— Иртәгә кояш чыкканчы Төпсәнең хатынына, балаларына берни әйтмәскә, — диде Албуга Тишек-Ташка. Аннары ул башкаларга карады. — Төпсәнең кайда, ничек үтерелүе турында иртәгә кояш чыкканчы бездән башка беркем белмәскә тиеш, — диде.

— Тыныч бул, тучи бәк, беркем берни белмәс, — диделәр егетләр бер авыздан.

## IX

Бүген көн аяз гына булды. Түбә өстендә кызгылт-алтын кояш эленеп торды, үзәкләргә үтеп көнбатыштан ачы җил исте.

Бүген алар Бәнә дигән күл буенда төн кунарга тиешләр иде. Уймак күлдән Бәнә күлгә чаклы ара бер көннән азрак иде. Күл буена алар кояш баер алдыннан барып җиттеләр. Арбалар бүген иртәрәк туарылды, өйләр иртәрәк корылды һәм учаклар да иртәрәк ягылды.

Төнге торгаклар билгеләүне тәгин углан тулысы белән йөзбашы Җирәнгә тапшырырга булды. Иртәнге бәрелештән соң йөзбашы Җирән сүзсезләнеп, хәтта сулыгып-ябыгып калган иде. Тәгин углан белән алар көне буена диярлек күзгә-күз очрашмадылар. Хәзер менә очрашкач ул тәгин углан янында үзен ничегрәк тотарга белми азапланды. Аның, билгеле, яп-яшь углан алдында түбәнсенәсе дә килмәде, шул ук вакытта ул аңа буйсынмый да булдыра алмый иде.

— Төн уртасына чаклы мин йоклыйм, — диде тәгин углан Җирәнгә. — Мин йоклаганда — торгакларга син җаваплы.

— Шулай итәрбез.

— Минем егетләрне төнгә куйма.

— Тегеләрне дә, үзеңнекеләрнедәме?

— «Тегеләрне» дә, — диде тәгин углан. — Төн матур. Аларның боз өстендә уйныйсылары килә. Мин аларга сүз бирдем.

— Шулай итәрбез, — диде йөзбашы Җирән, бер үк сүзне кабатлап.

Үз өенә, үзенең Табылдыгы янына Албуга бүген күтәренке күңел белән кайтты. Икәүдән-икәү генә сөйләшергә күпме сүз, күпме яңалык бүген! Табылдыкның бүген дә үзен җылы өйдә, ит тулы казан янында якты йөз белән каршы алачагын уйлап ул үзалдына елмаеп куйды. Ләкин үз өе янына җиткәч ул, әнисен исенә төшереп, кырт кына борылды да, каршыдагы биек өйгә таба атлады. Көндез ул әнисен читтән генә күреп китте. Бүген аны ничек тә күрергә, сөйләшергә кирәк иде.

Берничә көн эчендә үсеп, үзгәреп, олыгаеп киткән өлкән углын Күрекле бикә аяк өсте каршы алды.

— Сине бүген мактап телгә алдылар, улым, — диде ул, беренче булып.

— Кемнәр мактады, әни? — диде Албуга, «мактау» сүзенә аеруча күңеле булып.

— Ирләр, — диде бикә. — Күргән кешеләр әйтте: бөтенесен шаккатыргансың син бүген.

— Ә, син аны әйтәсең икән! — дигән булды Албуга гамьсез генә.

— Шуны әйтәм, — диде бикә. — Анысы яхшы булган... ирләр алдында үзеңнең кемлегеңне күрсәтүең. Шулай да син... беренче адымыңнан ук кансыз булсаң, башкалар да качышып бетмәсләрме?

Албуганың куанычлы елмаюы сүрелеп калды.

— Җиткерделәрдәмени, әни? — диде ул төшенке генә.

— Җиткерделәр.

«Димәк, ышанычсыз алар шулай да!» дип уйлады углан ачынып.

— Кемнәр, әни, әйтмәссеңме? — диде ул.

— Кемнәр булсын — Җирән! Минем ышанычлы ирләремнең башларын чаба башласаң, мине кем саклар да кем яклар?

«Җирәнмени? Ул бит берни белми!» — дип уйлады шундук Албуга, җиңел сулап.

— Мин барында, башка балаларың барында сиңа тагын кем кирәк соң, әни?

— Шулаен шулай да, — диде бикә пошынып. — Үзеңне корал белән саклаган, үзеңне туйдырган, карап үстергән кешеләрнең башларын чабарга ашыкма әле син, улым. Чабылган башны кире утыртып булмый.

— Кайгырма, эни! — диде Албуга җиңелчә бер күтәренкелек белән. — Кайчагында шулай куркытып кую да ярый ул! Моннан соң уяурак булыр, йокысын ачыбрак йөрер. Шулай да әйтим инде: аның сиңа килеп әләкләшеп йөрүе миңа ошамый.

— Миңа килмичә, кемгә килсен ул?! — диде Бикә Җирәнне яклап.

— Миңа! — диде Албуга. — Ирләр эше ирләргә генә кагыла.

— Әллә нәрсә булды сиңа, улым, — диде ана кеше аптырап, гаҗәпләнеп.

— Берни булмады. Килештек ич, эни: ирләр эше — миңа, кызлар эше — сиңа, дидек.

— Без алай димәдек бугай, — диде бикә, уйлангандай итеп.

— Эни, минем сиңа үтенечем бар, — диде Албуга. — Минем егетләр бүген кич боз өстенә уенга чыкмакчылар. Кызларыңны чыгармассыңмы — аларга күңеллерәк булыр иде.

Бикә көлеп алды.

— Шуны сорарга кердеңме?

— Шуны.

— Шул да булдымы «ирләр эше!» — диде әнисе. — Яшь егетләр боз өстенә уенга чыкканда кызлар йоклап ятыр дип белдеңме... мин әйткәнне көтеп? Сез аларга бер генә сызгырыгыз — җиде кат сакчыны алдап чыгачак алар!

— Мин үзем чыкмыйм, — диде Албуга.

— Адай сызгырсын, алайса, — диде бикә көлеп.

## X

Үзенең хәйләсен Албуга бары Адайга гына әйтте. Беркемгә күренмичә, сиздермичә ул яшьләр арасына чыгарга, аларның, бигрәк тә үз егетләренең нәрсә сөйләшкәннәрен тыңларга булды. Аны: Төпсә турында берәрсе ычкындырырмы-юкмы, дигән нәрсә кызыксындырды. Әгәр дә мәгәр аның егетләреннән берәрсе шул турыда тишкән булса, бүген сүз, аныңча, гел шул турыда гына булачак иде. Төпсәнең үтерелүе турындагы хәбәрнең таралуыннан, таралмавыннан бигрәк, аны бөтенләй икенче нәрсә: егетләрем минем ышанычлымы, юкмы, дигән нәрсә борчыды.

Мондый хәйлә Адайга да ошады. Абыйсына ул хәтта беркая чыгып йөрмәскә кушты, «барысын да үзем эшләрмен, кайгырма!» диде. Ләкин абый кеше барыбер үзенчә итәргә булды.

— Без яшьләр белән уенга чыкмабыз, — диде ул Адайга. — Егетләр, кызлар боз өстенә чыккач, беркемгә күренмичә, икебез ике яктан килербез дә, тыңланып йөрербез. Карангыда безне беркем танымас.

Алар шулай иттеләр дә. Күл өстенә кичке уенга чыгучы егетләргә дә, кызларга да Адай: аягым сызлый, чыкмыйм, диде. Албуганы чакырып килүче булмады. Аның өе, кызы бар лабаса — аңа болай да күңелле!

Күктә тоныk кына булып яшь ай балкый, ялт-йолт килеп йолдызлар җемелдәшә иде. Көндез бер үк төсле булып тоелган җир өстенә, куе, озын күләгәләр белән аралашып, көмеш сыман аксыл яктылык таралган. Тигез күл өсте аеруча матур, серле һәм ягымлы. Югарыдан төшкән тонык ай яктысында боз өсте, яхшы шомартылган көзге төсле булып, балкып-җемелдәп ята.

Авыл күл янына килеп урнашу белән, көне буе атта, арбада селкенеп барган бала-чага боз өстенә иң элек сибелә иде. Кечкенәләр арба өстендәге киез өйләренә кайтып йокларга яткач та, боз өстенә олырак балалар, үсмерләр чыгып җыела. Иң ахырда, караңгы төшеп бөтен авыл йокыга талу белән яшьләр чыга. Бикәнең болай да кызларны яшьләр уенына чыгудан тыйганы юк иде. Бүген исә, ел-

кән углының үтенечен истә тотып, кол кызларны тоткарламаска дип, ул бага хатыннарга алдан ук әйтеп куйды.

Бикәнең кызлары да чыккач, боз өстендәге яшьләр күбәеп китте. Күл тирәсендә уен-көлке, күңелле чыр-чу яңгырап торды. Кайберәүләр үзләренең якын сердәшләре белән читкәрәк, күләгәлерәк җирләргә елыштылар, кайберәүләр бер тирәдә күмәк уеннар башлап җибәрделәр.

Албуга, капкадан чыгып, туп-туры күл буена юнәлде, кычкырып сөйләшкән, көлешкән егетләрнең сүзләренә еректан ук колак салып, шыпырт кына алар янына барып әйләнде дә, камышлы яр буеннан китте. Ярым караңгыда аңа беркем игътибар итмәде. Никадәр колак салып тыңламасын, шулай да ул беркайда да үзе ишетергә теләгән сүзләрне ишетмәде.

Юк, ышанычлы, бик ышанычлы, ахрысы, аның егетләре. Ант иттеләр бит — шул җитмәгәнмени? Юкка йөри, ахрысы, ул болай әллә ниләр уйлап, кычытмаган җирен кычыттырып. Әнә алар... якында гына. Үзенекеләр дә, «тегеләр» дә. Аларда хәзер Төпсә кайгысы түгел. Яннарында яшь кызлар булганда, ник кирәк аларга Төпсәләр, Тишек-Ташлар... уң кул тучи бәк тәгин угланнар?! Бар нәрсәнең — бар кайгының, бар шатлыкның... яшәүнең, үлемнең төп чыганагы шул ук кызлар, бичәләр, аналар түгелме соң, тәңрем?! Шулар аркасында — ызгыш-талаш, шулар аркасында — яулар... шулар аркасында — бәхет, куаныч... Тормышның, дөньяның бар тоткасы алар түгелме соң, тәңрем?!

Кинәт кенә ул тынычланып калгандай булды. Тик шулай да ул бары үзенең егетләре өчен генә тынычланды бугай. Кызлар, бичәләр, аналар турындагы уйлар аңа икенче нәрсәне — йөрәк итенә ук тимере булып кереп утырган һәм беркайчан да онытылмый, югалмый торган нәрсәне исенә төшерде. Караңгыда үзенә елмаеп карап торган гүзәл Сөенеч турында хәзер аның һич тә уйлыйсы килмәде, ләкин ул — сихри күк кызы — уйлыйсы килү-килмәүгә карамастан, һаман үзен искә төшереп торды, һаман арттан, алдан — бөтен яктан, тирә-юньне нурга күмеп торды.

Өстендәге тире киемнәре ике кат иде, аңа бернинди салкын үтәрлек түгел. Ул туп-туры боз өстенә сузылып ятты да, күккә — айга, йолдызларга карап тынып калды. Элек тә ул, җиргә чалкан сузылып яткан килеш, күкне, болытларны, айны, йолдызларны күзәтергә ярата иде. Күпме генә күзәтсә дә, аңа анда һәрвакыт ниндидер серлелек, яшерен көч һәм ниндидер башка тормыш бар сыман тоела иде. Әнисе белән ачыктан-ачык сөйләшкән теге көннән соң — үзенең Тәңре углы икәнлеген белгән көннән соң — ул күккә, йолдызларга бөтенләй икенче хисләр белән, икенче төрле уй-теләкләр белән карый башлады кебек. Үзе белән күк арасында, ай һәм йолдызлар арасында ул уртаклык, якынлык, туганлык табарга тырышты. Ләкин, күпме генә тырышса да, күпме генә баш ватса да, чынында ул бернинди якынлык, туганлык таба алмады, төпсез күк дөньясының тамчы да серенә төшенә алмады.

Шулай уйланып, онытылып ята торгач ул якындагы камышлыкка таба килгән кемнеңдер аяк тавышларын ишетеп калды. Күккә, бушлыкка омтылган уй җепләре шундук өзелде һәм ул, башын сак кына борып, аяк тавышы килгән якка карады. Алар икәү иде. Монда камышлык арасында үзара серләшү өчен киләләр иде. Менә алар аннан бер ун адым чамасы җирдә туктап калдылар. Озак кына кочаклашып, бер-берсенә сыенып тордылар. Бераздан әкрен генә сөйләшкән тавышлары ишетелде.

— Бикә бирмәсә, мин сине тәгин углан аша соратырмын, — диде егет.

Тавышы таныш сыман тоелды. Бу теге Кәлтә булырга тиеш иде.

— Син — кол түгел, син иреклe. Кол кызны сиңа бирмәсләр, — диде кыз.

— Яраткач бирерләр, — диде Кәлтә, үз-үзенә ышанып.

— Кемгә тели, шуңа бирәчәк бикә, — диде кыз.

Кызы да таныш иде. Артык чибәр дә түгел. Шулай да ягымлы Түбет кырнагы.

Әллә боз өстендә сузылып яткан карачкыны күреп алдылар, әллә башка сәбәптән, алар монда озак тормады — ашыкмыйча гына каядыр читкә китеп бардылар. Башкалар парлашып, сөйләшеп йөргәндә үзенең шулай качып-посып ятуы, кешe сүзен тыңлап ятуы Албугага бик оятлы, вак һәм кирәксез нәрсә булып тоелды. Аның торасы, тизрәк үз өенә кайтып, үзенең Табылдыгын күрәсе килде.

Аның да кызы — кырнагы бар лабаса! Кол кыз, Кыпчак кызы. Ул да кемнеңдер якыны, яратканы булгандыр. Нинди дәртле, нинди кайнар йөрәкле ул. Яуда арканга эләккән дә, менә хәзер кулдан-кулга йөри. Терлек кебек, кием-салым кебек. Үлгәнче шулай, мәңгегә. Аның да кешечә яшисе киләдер, үз малы-туары, бала-чагалары белән яшисе киләдер.

Бу вакытта аның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Үзенең кызы турында ул чын-чынлап әрнү һәм кызгану белән уйлады. Кайчандыр үзе күз атып йөргән, кайчандыр чын күңелдән яраткан Табылдыгына аның ниндидер яхшылык, изгелек эшлисе килде. Үзен керфек какмый көтеп утырган кызы янына ул ашыгып-ашкынып кайтты.

## XI

Сары-су буеннан кузгалып китүгә дүрт көн булды дигәндә алар Диңгез-күлгә якынлаштылар. Уннан ике, сулдан ике елга килеп кушылган бу күл Сөн җирендә иң зур күлләрдән санала иде һәм шуның өчен дә ул Диңгез-күл дип аталa иде дә. Җәй уртасында иртәнге кояш белән бергә кузгалып китеп, көне буе атта чабып барсаң да, кузгалып киткән җиреңә бары кояш баеганда гына килеп җитәргә мөмкин. Каршы яктагы ярлары аның күк белән тоташкан һәм, күл өстенә озаклап карап торсаң, бөтен дөньяда судан башка берни юктыр сыман тоела иде. Шундый зур, шундый киң, иркен иде ул Диңгез-күл!

Куе таллыклар, камышлар белән капланган яр буйларында, елга үзәннәрендә, беркемнән, берниндән курыкмыйча киекләр, ерткычлар яши, суларда — күлнең үзендә, елгаларда балыклар мыж килә. Яз көнендә, су өсләре боздан әрчелү белән, бөтен тирә-як монда кош тавышларыннан шау-гөр килеп, яңгырап тора. Бу вакытта Диңгез-күл көньяктан төньякка күченүче кошларның туктап ял итү урынына әйләнә. Кыр казлары, аккошлар, үрдәкләр, һәр төрле су кошлары, оя-оя булып, көтү-көтү булып, бөтен су өстен, бөтен яр буйларын каплап алалар, бер-берсе белән танышып, дуслашып китәләр, я булмаса, киресенчә, көтмәгәндә талашып-ызгышып алалар. Шулай да монда яз көннәрендә күбесенчә дус, тату тавышлар, моңлы-сагышлы тавышлар яңгырый. Бер көтү кош күккә күтәрелү белән, алар урынына ук диярлек, икенче яктан икенче кошлар килеп төшә. Шулай итеп,кошлар базары монда ай буена — төнен-көнен дәвам итә.

Яз көне генә түгел, көз көне дә шулай була. Яз көнендә алар җылы яклардан салкын якларга ашыксалар, көз көнендә салкын яклардан җылы якларга ашыгалар. Бу вакытта инде алар тагын да күбәйгән, ишәйгән булалар, салкын якларда чыккан балалары үскән, канатлары ныгыган була. Алар хәзер ят, яңа җирләргә барып җитәргә ашкыналар — балалар һәрвакыт түземсез була бит.

Кошлар гына түгел, кешеләр дә шулай яз җиттеме, салкын якка

күченәләр, күзгә таба, киресенчә, җылы эзләп, ышык-аулак урыннар эзләп, көн ягына юл тоталаар.

Бары тик алар гына менә — туган җирләреннән куылган-сөрелгәннәр генә — барлык кошлар, барлык киекләр юнәлешенә каршы якка, кире якка кыймылдыйлар. Ник баралар алар анда — җылы, якты эзләпме, әллә бозлы буранныммы?

Күрекле бикә арбадан төшеп атка атланды. Куянкаен да атка атландырып ул аны башка балаларга тагып җибәрде. Бу якларда — Диңгез-күл буе үзәннәрендә аның үзе генә уйланып барасы килде. Ул, арбалардан, сакчы ирләрдән — барлык күчмә олаулардан уңгарак каерылып, комлы үзәннәр, калкулыклар арасыннан китте. Монда аңа бар нәрсә таныш, якын иде. Бу сулар, үзәннәр, таллык-камышлыклар Туман каганның саклау җирләре исәпләнелә. Ул монда язның беренче көннәрендә балык тотарга, аккошлар, кыр казлары атарга килә дә бөтен урдасы белән, бөтен ил-көн белән монда ике айга якын тора иде. Шуннан соң елның-ел буена бу тирәгә беркем якын китерелми, беркемгә балык тоту, кош-корт ату рөхсәт ителми иде.

Һәр елның яз айларын шушында — куе таллар, камышлар янында кыр казлары, аккошлар шау-шуы арасында уздырганга күрә дә бу тирәләр бикәгә аеруча якын, кадерле. Диңгез-күл буйлары аның күңелендә мәңге яз булып, туктаусыз шаулаган дулкыннар булып, очар кошларның сагышлы авазлары булып сеңеп калган иде.

Олаулардан аерылып бикә шулай да ерак китә алмады — арттан аны йөзбашы Җирән куып җитте. Ул, ахрысы, аны күптән инде күздән югалтмыйча килә иде.

— Безнең арттан кемнәрдер якынлашып килә, бикә, — диде ул, бикәгә кыюсыз гына якынлашып.

Бу вакытта Күрекле бикәнең күңел күгендә яңгыраган аккош тавышларыннан, дулкын шауларыннан башка берни дә ишетәсе килми иде.

— Белештеңме — кемнәр? — диде ул, артына әйләнеп карамыйча гына..

— Белешмәдем,— диде Җирән.

Көндәм, сүз тыңлаучан, шулай да йомшак холыклы йөзбашына бикәнең ачуы килеп куйды. Әлек тә шундый булдыксыз иде микән ул, әллә соң Албуга котын алгач кына шундыйга әйләнде микән? Күрәсең, әлек тә шундый булгандыр. Кушкан һәр нәрсәне җиренә җиткереп үтәгәне өчен генә ул аңа — бикәгә — яхшы ир, яхшы каравыл башы булып тоелгандыр. Ир, имеш! Симерә башлаган андый ирнең булганыннан булмаганы мең артык.

— Албугага әйттеңме? — диде бикә янә дә артына борылып карамыйча гына.

— Иң әлек сиңа әйтим дидем, бикә, — диде йөзбашы Җирән, алгарак чыгып. Аның тавышында кирәгеннән артык серлелек, ягымлылык сизелде.

— Андый хәбәрне иң әлек уң кул тучи бәк угланга әйтер идең, Җирән. Өлкән углым белән минем арага чөй кагарга җыенмыйсыңдыр ич син?

— Мин синең белән тагын углан арасына чөй кагарга җыенмыйм, бикә. Мин, бикә, синең белән икебезнең арадагы чөйне... шырпыны алып ташлар идем.

— Анысы тагын ни була инде? — диде бикә, берни аңламаган булып.

— Анысы, бикә, шул була, — диде йөзбашы Җирән көттеребрәк. — Син миңа суындың кебек, мине читләштерә башладың кебек. Шуны әйтмәкче идем мин.

Бикә беравык эндәшмичәрәк барды. Ул аның нәрсәгә ишарәләвен

сизенми булдыра алмады, шулай да берни сизенмәгән булып күренү яхшырак булыр дип уйлады. Элегрәк йөзбашы Җирән үзенең бикәсе белән мондый нәрсәләр турында сөйләшергә батырчылык итми иде. Күрекле бикә — каганның өлкән бичәсе иде, аның тагын якын кешесе бар иде. Менә хәзер аларның берсе дә юк: каганы да, якын дусты да. Шуңа күрә әрсезләнә дә бу йөзбашы Җирән!

Шулай да бикә үзенә буйсынган алып ирнең бер-ике сүз белән авызын томаларга ашыкмады. Кем белә киләчәкне — аның хәлендәге тол хатынга бик үк кырыс булу да килешеп бетми кайчагында!

— Нинди суыну, нинди читләшү турында сөйлисең син, Җирән? — диде ул уйчан гына. — Минем сиңа суынганым да, җылынганым да юк. Кайгым башымнан ашкан чакта... кайчагында тупас күренәмдер. Өлкән углыма мин әйттем. Шулай да син аның үзе белән килешергә тырыш.

— Мин ул турыда әйтмим, бикә! — диде Җирән.

— «Яратам» дип әйтмәкче буласыңмыни соң, Җирән? — диде бикә бик җиңел генә һәм тук, шома битле юан ирнең күзенә карап, көләргә керешеп китте.

Бикә, бала-чаганың берәр ипсезлегеннән, йомшаклыгыннан көлгән кебек, дусларча шаяртып көлде. Ләкин ир кешегә бу мыскыллы көлү булып тоелды.

— Көлмә, бикә! — диде ул хурланып, мескенгә сабышып.

— Көлмичә! — диде бикә. — Минем яшьтә, синең яшьтә... нинди ярату инде ул? Мин сиңа яшь кыз бирермен.

— Ярар, мин китим әле, — диде Җирән, атын кырт кына борып. — Мин, бикә, ялганладым. Котлуг бәк куып килә безне арттан.

Бикә дә атын кырт кына кире борды.

— Син, йөзбашы, нишләп аны башта ук әйтмәдең? — диде ул, гаҗәпләнү катыш ачу белән.

— Курыктым, бикә, — диде Җирән чын күңелдән: — Куркак та түгел кебекмен. Шулай да менә курка башладым... синнән.

— Күрәсең, чыннан да яратасыңдыр син мине, Җирән! — диде бикә, янә дә көлгәндәй итеп.

«Ярату» сүзен ул тагын да бернинди хиссез-тойгысыз әйтте, яратуга катнашы булмаган бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән кебек кенә итеп әйтте. Ләкин Җирәнгә шул да җитә калды.

— Яратмаган кая ул, бикә!

— Бикәңне яратуың яхшы, Җирән, — диде бикә, җиңелчә шелтә белән. — Котлуг бәк турында нишләп башта ук әйтмәдең — менә анысы аңлашылмый.

— Урдадан үпкәләшеп киткәнгә, күңеленне кырасым килмәде, бикә, — диде йөзбашы Җирән.

— Үпкәләшсәк, килешербез! Туган атам ич ул минем!

— Нишлик соң, бикә, берни булмагандай бара бирикме, каршыларга алай җибәрикме? — диде Җирән.

— Тәгин углан белән киңәш. Ул ничек әйтә, шулай эшләрсез.

— Тагын «тәгин углан!» — диде Җирән ризасызлык белән. — «Яратам» дигәндә дә син иң элек аның белән киңәшерсең төсле, бикә!

— Киңәшми дә булмас, йөзбашы Җирән... «яратам!» дип әйтергә туры килсә... — диде бикә елмаеп. — Минем бар тоткам — углым.

— Беләм, беләм! — диде Җирән ашыгып. — Әйтсәм — әйтим, бикә: мин аннан ныграк куркам. Ул бик кансыз күренә.

Сүзне озайтасы килмичә ул, атын куалап, бикәдән ерагая башлады. Аның шулай китеп барышлый гына Албугага карата «кансыз» дип әйтүе ана кешенең өстенә салкын су койгандай булды. Аның үз улын яклыйсы килде, ләкин аны яклардай сүз дә табылмады. Өлкән углының кырыслыгы, кискенлеге аның үзенә дә бик ошап җитмәде. Үз го-

мерендә урдада, далада ул һәртөрле кырыслыкларны, кансызлыкларны күп күрде, тик шулай да ул үз углының хәзердән үк, шундый яшьтән үк кансыз, кырыс булуын теләмәде.

Бикәнең күңеле урыныннан купты. Аның инде баягыча үзе генә уйланып та барасы килмәде, Җирән артыннан да иярәсе килмәде. Атын экрен генә атлатып ул ерактагы олауларга таба китте. Күп тә үтмәде, аңа каршы ике атлы чабып килгәне күренде. Бу аның Куянкае белән Кече-Тае иде.

— Әни! Әни! — дип кычкырдылар балалар ерактан ук, бер-берсен уздырырга тырышып.

Балаларның үзе янына килеп җитүләрен бикә елмаеп көтеп торды. Аларның шат, тере кыяфәтләрен күрү белән, шат, көр тавышларын ишетү белән аның күңелендәге борчулы уйлары шундук юкка чыкты.

— Әни, безнең олы абый Җирәннең башын чаба язган! — диде Кече-Тай сер итеп.

— Чапкан инде! — диде Куянкай.

— Аныкын түгел, Төпсәнекен чапкан ул! — диде малай.

— Ни сөйлисез сез?! — диде бикә коты алынып.

— Чапкан, чапкан! Бәлкә-абый үзе әйтте — ишетеп тордым, — диде малай мактанып.

Бикә, иреннәрен кысып, сүзсез калды. «Булыр. Әйтәм чыш-пыш киләләр үзара! Барысы да булыр аннан!» — дип уйлады ул каушау һәм шомлану белән.

## XII

Ак өйнең ишеге янында кыйнаганда Туңгак алыпның кулын имгәттеләр, базга ташлаганда ул ялгыш басып аягын тайдырды. Авыртуга түзә алмыйча ул бик каты итеп кычкырып җибәрде. Ул көнне ул арыганчы, тамагы карлыкканчы кычкырды. Базның тар авызы ике-өч кат калын киез белән капланган иде. Аны хәтта якындагы сакчылар да ишетмәделәр.

Кычкырып бары үзенең хәлен генә бетергәнлеген ул бик соңлап аңлады һәм, тешен кысып, шундук тынып калды. Моннан берничек тә чыгып та, качып та булмаганлыгын ул бик яхшы белде, шуңа күрә ул түзәргә — барлык газапларны, барлык авыртуларны онытып түзәргә дигән карарга килде.

Ул үзен тамчы да гаепле санамады. Каганга ул турылыклы хезмәт итте. Аның тынычлыгын, аның иминлеген саклап, аның йокысы тыныч булсын дип, авызына капкан сыныгы аркылы утырмасын дип, үз-үзен аямыйча хезмәт итте. Аның турылыклы, булдыклы булуын каган үзе дә белмәде түгел. Шуңа күрә дә ул аны беркайчан да кыерсытмады. Ул аны өйләндерде, өй бирде, мал-туар бирде. Яуда аңа телем чыгарды. Күңеле аеруча күтәренке чакларда ул аңа үзенең кол кызлары янына барырга да ирек куйды. Менә шуңа күрә ул әлеге эштә берничек тә каганны гаепли алмады.

Юк, бөек Туман каганны гаепләргә бернинди сәбәп юк иде. Барысын да ул Исәнтәйдән күрде. Исән-сау котыла алса, чыга алса шушы баздан, иң элек ул аның бугазын чәйнәп өзәчәк, иң элек аны изеп ташлаячак. Аннан соң инде үлсәң дә, тереләй җиргә күмелсәң дә үкенечле булмаячак!

Сөн түрәләрен ул яхшы белә иде. Түрә буенча, гаепле дип уйланылган бер генә кешене дә яргуламыйча — хөкем итмичә мәңге базда калдырмыйлар иде. Аны да кайчан да булса бер чыгарырга, яргуларга тиешләр иде. Чыннан да, ике тәүлектән соң аны да баздан тартып алдылар. Бу ике тәүлек эчендә аңа ашарга да, эчәргә дә бирелмәде.

Якты дөньяга чыкканда ул танымаслык булып үзгәргән — ябыккан, хәлсезләнгән иде.

Үзенең кирәгеннән артык кызып китүен аңлаган каган атаклы алыбының хәтерен калдыруы өчен үкенә дә башлаган иде. Ул инде аны аклау, яңадан үз урынына кую турында да уйлаштыра башлаган иде. Ләкин таш кыядай таза, көчле ирнең ябыгып, шешенеп, ямьсезләнеп калуын, җитмәсә бер аягына аксаклавын, уң як санының йөрмәвен күреп, аның шундук күңеле кайтты. «Эше беткән моның. Бу инде бернигә яраксыз», — дип уйлады ул. Мәгез, теләсәгез нишләтегез, дигән сыман ул аны яргучыларга тапшырды.

Сөн илендә иң зур хөкем — яргу эшен ыру башлары — Куян ыруыннан Котлуг бәк, Алан ыруыннан Барыс бәк, Сөйбү ыруыннан Тук-Тимер бәк башкара иде. Яргучылар аны барлык шартларына туры китереп хөкем иттеләр. Сорашу-белешү өчен таныклар чакырттылар, җентекләп үзеннән, таныклардан сораштылар. Иң ахырда яргучыларның өчесе дә аны — Туман каганның каравыл агасы Туңгак алыпны дунху бәге Начин нойонның качып китүендә гаепсез дип таныдылар. Туңгак алыпка буйсынган кораллы торгаклар бары тик бөҗра эчендәге кешеләрне, өйләрне генә сакларга тиеш иде. Дунху бәгенең авылы бөҗрадан бер ук чамасы читтә, ялан кыр уртасында ялгыз утырганлыктан, аның качуында-качмавында каравыл агасы Туңгак алыпның бернинди катнашы була алмый иде. Инде дунху бәген куып тота алмаган икән, монда шулай ук аны гаепләп булмый. Дунхуларны ул җиңеп, мал-туарларын, кешеләрен кулга төшереп кайткан, — шулай булгач, үз бурычын намус белән үтәгән. Начин нойонның качып котылуы — Туңгак алып эше түгел, анысы — Тәңре эше.

Туман каган яргучыларның карарына каршы берни әйтмәде.

— Аклануың белән котлыйм, Туңгак алып, — диде ул атаклы колының күзенә карап. — Тик мин сине кая куйыйм хәзер? Мин сине өлкән бичәм Күрекле бикәдән алган идем. Биргәнен кире алсын. Син, Котлуг бәк, илтеп тапшыр кызыңа. Өстеңдәге киемнәрең үзеңә булыр. Коралларыңны да кире кайтарып бирерләр. Мин биргән хатының, хатыныңның балалары, мал-туар, атың, өең — барысы да монда калыр.

Туман каган шулай диде. Бөек Туман каган шулай боерды. Аяк астына егылып еласаң, күз яшьләреңне түгеп ялварсаң, бәлки, ул аны кызганган да булыр иде — аты белән хатынын, балаларын, бәлки, үзенә дә бирер иде. Ләкин ул — бөтен Сөн илендә атаклы алып, каганның арка таянычы булган Туңгак алып елый да, ялвара да алмады. Тешен кысып, әрнегән, кан тамган йөрәген йөгәнләп ул үз-үзен ташка, агачка әйләндерде.

Кызы Күрекле бикәнең бу батыр колны яратуын Котлуг бәк белә иде. Ул аны үзе дә якын күрә иде. Каган кушкач ул аны бик теләп үзе янына алды. Юлга чыкканда Туңгак алып атка атланырлык хәлдә түгел иде. Котлуг бәк аны ике тәгәрмәчле җиңел арбада алып бармакчы булды. Туңгак алып, Исәнтәйнең ике тәгәрмәчле, түбәсе ябулы арбасын күз алдына китереп, арбада юлга чыгудан баш тартты. Аның өчен ике атны парладылар да, атлар арасына бишек сыман итеп киез тарттырдылар — сугышта авыр яраланган ирләрне шулай йөртәләр иде. Юл буена ул киез бишек өстендә тирбәлеп килде.

Коточкыч ябыккан, агарынган, бетеренгән ярым-йорты ирне — үзенең яшерен ирен, икенче ирен күреп бикә телсез калды. Янындагы атасыннан, балаларыннан, ырудашларыннан тартынмыйча, бар нәрсәсен онытып ул кайгысыннан еларга тотынды. Ул аның салкын, хәлсез күкрәгенә капланып елады, җансыз ит сыман салынып торган гарип кулын тотып карый-карый, очлы, сөякчел яңакларын сыйпый-сыйпый елады.

Туңгак алып үзе берни эндәшмәде. Кызганыч йөз белән ул, иреннәрен кысып, телсез кеше сыман тик басып торды. Үзе турында ул шулай

ук берни сөйләмәде. Аның турында барысын да Котлуг бәк сөйләде.

Бүген кичкә Диңгез-күл янына барып җитәргә ашыкса да, Күрекле бикә шунда — Туңгак алып белән, этисе Котлуг бәк белән очрашкан җирдә авыл корырга боерды.

## XIII

Котлуг бәк үзенең кышлавына ашыга иде. Аның үзе белән мең кешелек алае бар. Аңа әле кайтып ун меңләп кораллы чиру җыярга һәм тиз арада кире юлга да чыгарга — каган билгеләгән вакыттан да соңга калмыйча, Урта кичүгә барып җитәргә кирәк иде.

Күрекле бикә атасын, ырудашларын яхшылап сыйларга, кунак итәргә булды. Ул үзенең зур өен корды, күп итеп ит суярга кушты. Үзенең ак өенә ул бары атасы Котлуг бәк белән аның атаклы алыпларын һәм үзенең якын туган-тумачаларын гына чакырды. Башка ырудашларын бүтән өйләрдә сыйладылар.

Бикәнең ак өендә аштан соң ата белән кыз, туган-тумача озак кына сөйләшеп-киңәшеп утырдылар. Киңәштә уң кул тучи-бәк тәгин углан белән Туңгак алып та катнашты. Тик алар, бернигә кысылмыйча, тыңлап кына утырдылар. Чынында бу алай олы киңәш тә булмады, бу бары ата белән кыз арасындагы бер сөйләшү-аңлашу гына булды. Алар бер-берсенә үзләренең үпкәләрен әйттеләр, моңарчы кузгатылмаган нәрсәләрен искә төшерделәр һәм әйтешә-әйтешә, чак-чак кына бозылышып китмәделәр. Бикә атасын каган белән ныграк катырак була алмауда, өлкән кызының урынын-дәрәҗәсен саклап кала алмауда гаепләде. Котлуг бәк исә үзен акларга мең төрле сылтау тапты, ин ахырда картлыкка, тегесенә-монысына зарлана башлады. Шулай да алар үзара уртак фикергә килгәндәй булдылар — киләчәктә нишләү, кайда, кайчан очрашу турында килештеләр. Котлуг бәк яуга китәр алдыннан Байык буена — кызы белән тәгин угланның яңа кышлавына сугылып китәргә булды. Ике арадагы килешү шуннан ары узмады.

Ашап туйгач, кызы белән шулай бер иркенләп сөйләшкәч, Котлуг бәк, кичкә каршы булуына да карамастан, юлга чыгарга булды. Үзләренә кирәкле азыкны алар алдан көтү итеп куалап алып бармыйлар иде. Биш көнгә җитәрлек азык-төлекне алар капчыкларга салып, үзләре белән алганнар иде. Шуңа күрә алар бертуктамый төнен-көнен юлда була алалар иде.

Өлкән бичәсеннән туган өлкән кызыннан Котлуг бәк күптән аерылган иде инде. Аның да, Туман каганныкы кебек, дүрт бичәсе, йөзләгән кырнагы бар. Аларның балалары, балаларының балалары үзләре генә дә бөтен бер ыру, бөтен бер гаскәр булырлык. Ул аларның барысын да ярату-кайгырту түгел, күбесен инде онытып та бетергән иде. Шулай булса да, Керүлән буендагы урдасында аның барлык бичәләреннән, барлык кырнакларыннан, кызларыннан ныграк яраткан кол кызы бар иде. Кем белә, бәлки, ул да шуның янына, бәлки чыннан да яуга... үзенең үлеменә ашыгадыр?

Чәчләре агарган, тавышы карлыккан, шулай да үзен элеккечә батыр, киң күңелле һәм яудан-сугыштан башка, аттан-коралдан башка бар нәрсәгә карата үзен өстен тотарга тырышкан атасын озатканда Күрекле бикәгә бераз гына моңсу булып калды. Аңа алар соңгы кат очраштылар һәм соңгы кат саубуллаштылар шикелле тоелды.

Үзенең уллары белән, кызы Куянкай белән бергәләп бикә атасы Котлуг бәкне һәм ырудашларын бик озак җир озата барды. Аларга Туңгак алып та иярде. Уң як саны бөтенләй диярлек йөрмәсә дә, ул атка атланырга теләде. Ияргә аны ике яктан да тотып атландырдылар. Бер җайлап утыргач ул ат өстендә әйбәт кенә барды.

Котлуг бәкне озатып куйгач алар җыйнаулашып кайтыр якка борылдылар. Балалар, бер-берсен узарга тырышып, алдан чапты. Бикә белән Туңгак алып арткарак калдылар. Икәүдән-икәү генә калгач, бикә, кызгану белдереп:

— Авыртынмыйсыңмы? Бик кыен түгелме? — дип сорады.

— Синең янда миңа яңадан канат үскәндәй булды, — диде Туңгак алып.

Бу аның очрашканнан соң бикәгә авыз ачып әйткән беренче сүзе булды.

— Мин сине телсез дә калгансыңдыр дип уйлаган идем — ялгышканмын икән!

— Минем бары шул телем генә исән калды да инде.

— Башың да, йөрәгең дә исән түгелмени?

— Башымны ашадылар, йөрәгемне аяк астына салып таптадылар.

Элек тә ул кайчагында шулай усал, төртмә телле була торган иде. Хәзер исә аның сүзләрендә усаллык кына түгел, әрнү дә, көчсез ярсу да һәм агулы зәһәр дә бар иде. Ләкин бикәнең хәзер бер дә алай сөйләшәсе килмәде. Ул аңа җавап кайтармады һәм, аның тынычлануын көтеп, бераз җир эндәшмичә барды.

— Яшьлек менә шунда үтте инде! — диде ул бераздан, ерактагы су буйларына, таллыкларга күрсәтеп.

— Безнең яшьлек әле башлана гына, бикә, — диде Туңгак алып, ачы елмаеп.

Ул әле тынычланмаган иде бугай. Аның усаллыгы бикәнең ачуын китерә башлады.

— Миннән үч алырга уйлыйсың, ахрысы, син, — диде ул, чак-чак кына үртәлеп.

«Син» дигәч ул тагын нидер әйтмәкче булды — әйтмәде, ләкин, аның ни әйтергә теләвен чамалап, Туңгак алып шундук әләп алды.

— ... кол! — диде ул бикә булып.

— Әйе, кол! — диде бикә ачу белән.

— Үлемнән баш тартып булмаган кебек, мин үземнең коллыктан да баш тарта алмыйм, бикә,— диде Туңгак алып.

— Син мине елатырсың, ахрысы, — диде кинәт бикә йомшап. — Урдадан куылганда да, юлда да мин гел сине уйладым. Очрашкач менә сөйләшеп тә булмый.

— Сөйләшик, — диде Туңгак алып.

— Нәрсә дидем әле мин? — диде бикә шундук җанланып. — Яшьлек шушында узды дидем бугай. Нинди тын монда! Кышын минем бу якларда булганым юк. Яз көннәрендә нинди күңелле монда! Менә шул инде ул яшьлек — аккош тавышыдай моңлы, сагышлы, яңгыравыклы яшьлек...

— Шулай да мин ул яшьлеккә кире кайтмас идем, — диде Туңгак алып. — Минем өчен яшьлек — тамуг булды. Синең яшьлек белән минем яшьлекне чагыштырып булмый. Яшьлекне генә түгел, бөтен тормышны. Синең көнең байлыкта-муллыкта үтә, минеке...

— Синең белән бөтенләй сөйләшеп булмый!

— Сөйләшмик, — диде Туңгак алып.

— Сөйләшеп тә булмагач, нәрсәгә генә кирәк соң син миңа? — диде бикә, Туңгак алыпның үзе кебек төртмәле итеп.

Мондый ачы сүзләр күңеле китек ирнең шундук кытыгына тиде. Ул бөтенләй йомылып, сүзсезләнеп калды.

— Үткәннәрне искә төшермик, бикә, — диде ул бераздан, үтенеч тә, килешү дә сиздергән бер йомшаклык белән. — Элеккеләр әле бетмәгән, яңасы башланмаган.

— Син холыксыз бала кебек, — диде бикә ачусыз гына.

— Бала... балалар, — диде Туңгак алып көрсенеп.

Ул үзенең тегендә калган балаларын, хатынын исенә төшерде. Аңа тагын күңелсез булып китте. Нәрсә генә уйлама, нәрсә турында гына сөйләшмә — күзгә күренмәс очлы шырпы булып, тупас сөңге булып, һәрбер сүз, һәрбер уй сулкылдап торган яралы күңелгә барып төртелде.

— Балалар турында ишетәсең килмимени? — диде бикә аның «бала, балалар» сүзен үзенчә аңлап.

Алып ир эндәшмәде. Элек ул бикәнең балалары турында яратып тыңлый торган иде. Аеруча ул аның өлкән углы белән — аның сөйләгән сүзләре, эшләре-кыланышлары белән кызыксына иде. Җае чыкканда, тагын углан белән икәүдән-икәү генә калганда ул аңа төрле яулар турында сөйли, аны ук-җәя, сөңге белән эш итәргә өйрәтә һәм әледән әле аңа киңәшләр бирә торган иде. Күптән инде алар арасында нык-лы бер дуслык, якынлык урнашкан иде.

— Балалар турында сөйлә, бикә, — диде ул бераздан.

— Үзгәрде минем өлкән колыным, — диде бикә. — Колын түгел, тайга әйләнде. Кире, үзсүзле тайга әйләнде. Субашы булгач та, беләсеңме, нишләгән ул?

— Нишләгән? — диде Туңгак алып кызыксынып.

— Җирәннең башын чабам дип янаган!

— Кара син?!

— Мин курка башладым әле аннан. Җирәнгә янап кына калган, икенче бер ирне... Төпсә дигәнен чабып үтергән!

— Шулай укмыни?!

— Тегесе кырда куян аткан булган. Шуның өчен, — диде бикә, тизрәк углын акларга ашыгып.— Нишләргә дә белмим. Үз баласын ашаган эт кебек... Юк-бар өчен үз ирләрен үзе үтерә торган булса, нишләр ул киләчәктә? Ярый әле син... кайттың. Ул сине генә тыңлый, ахрысы.

— Тыңлый, — диде Туңгак алып, эчке бер сөенеч белән.

— Син аңа әйт, Туңгак. Баш чабу белән шаярырга ярамаганлыгын үткәзеп, сеңдереп әйт!

— Баш чабарга мин өйрәттем аны, бикә, — диде Туңгак алып тыныч кына.

— Үз ирләрен чабып үтерергәме? — диде бикә шаккатып.

— Баш бирми торган, буйсынмый торган ирләрне! — диде Туңгак алып. — Йолага, түрәгә каршы килүче, тәртип бозучы ирләрне бернинди кызганусыз юк итәргә мин өйрәттем. Киләчәктә каган буласы, ил башы буласы кешенең күңеле — йомшак, кулы — каты булырга тиеш, дип мин тукыдым аңа, бикә! Илдәге бар башбаштаклык, бар бозыклык каганның үзеннән башлана. Бәкләр, аксөякләр, каралар барысы да каганнан, үзен Тәңре углы дип атаган кешедән үрнәк алалар, аның яман якларын да, яхшы якларын да кабатлыйлар. Син өлкән углыңның Туман каган кебек булуын теләмисеңдер ич, бикә?

— Теләвен теләмим... Шулай ук мин аның сиңа ошавын да... сиңа кирәгеннән артык ышануын да теләмәс идем.

— Алай булса, мин аны бөтенләй күрмәскә, аның белән очрашмаска тырышырмын. Мине ерактагы берәр авылыңа көтүче итеп җибәрсәң, миңа шул җиткән, — диде гарип ир тирән бер төшенкелек белән.

— Сине кая кую — анысы минем эш! — диде бикә дә ачулы итеп.— Көтүче итеп куярмынмы мин сине, юкмы, әлегә үзем дә белмим. Ни генә булмасын, мин сиңа уң кул тучи бәк тагин углымны котыртырга, аны яманлыкка, кансызлыкка өйрәтергә моннан соң юл куймам дип уйлыйм.

— Кайчагында... кирәкмәгәндә бик изге син, бикә! — диде Туңгак алып мыскыл белән. — Каган сине аерып, куалап җибәрде, уң кул ту-

чи бәк тагин углын читкә типте, мине менә кулсыз-аяксыз калдырды. Кем кансызрак соң? Минме, каганмы?

— Син каган белән минем углымны бутама! — диде бикә, чын-чынлап ачулана башлап. — Туман каган кансыз булган өчен генә мин үз углымның да ерткыч булуын теләмим! Сөйләмә син миңа юк-бар нәрсә!

— Ярар, сөйләмәм, — диде Тунгак алып, ясалма бер күндәмлек белән.

Алар, үпкәләшкән балалар кебек, шактый озак эндәшми бардылар.

— Без юкка кычкырышабыз, ахрысы, — диде Тунгак алып бераздан, тынычлана төшеп. — Мин дә аның кеше үтерүче булуын теләмим. Шулдай да Төпсәнен башын чабып ул дөрес эшләгән! Ул аны бүтәннәргә сабак булсын өчен эшләгән! Син менә шуны аңлый алмыйсың, бикә!

— Аңлыйм да кебек мин аны, — диде бикә дә, тынычлана төшеп. — Аңласам да... куркам. Ак урдада тәхеткә утырасы углыннан үз анасы курка торган булгач...

— Мин дә куркам, бикә, — диде Тунгак алып, аның сүзен бүлеп. — Мин аның кансызлыгыннан курыкмыйм. Мин аны тәхеткә утыра алыр микән, юк микән дип куркам!

— Сөйләмә юкны! — диде бикә кызарынып. — Ул — уң кул тучи бәк тагин углан. Йола, түрә[1] аның ягында.

— Йола, түрә — каган кулында. Тәңре дә аның яклы, — диде Тунгак алып.

Бикәне иң куркытканы, иң өркеткәне, барлык тынычлыгын, барлык өметен-ышанычын какшатып, туктаусыз эчен тырнап торганы нәкъ менә шул нәрсә — тәхет мәсьәләсе иде. Шуңа күрә дә ул бу турыда авыз ачып сөйләү түгел, хәтта уйларга да курка иде. Тунгак алып, аның күңел ярасын бик яхшы белсә дә, сүзне әнә туп-туры шуңа китереп терәде.

Бикә караңгы йөзен кая куярга белмичә, бик озак эндәшми барды.

— Син инде... бетте дип уйлыйсыңмыни? Ул да, мин дә беркайчан да кире урдага кайта алмабыз дип уйлыйсыңмыни? — диде ул янәшә барган иргә карамыйча гына, эчке бер өметсезлек белән.

— Бөтенләй үк бетмәгәндер дә... — диде Тунгак алып. — Көчне көч белән генә җиңеп була. Каганда — көч, тагин угланда көч юк. Көч миндә бар, бикә!

— Синдә?!

Тунгак алып күз алдында үзгәреп китте. Аның ябык, ачулы чырайнда дәрт һәм омтылыш чагылды. Ул бикәнең мыскыллы сүзләрен бөтенләй ишетмәде дә.

— Миндә, бикә, тау-ташларны актарып ташлардай ярсу бар, көчкуәт бар! Миндә, бикә, бер бөртекне мең бөртеккә әйләндерә алырдай осталык бар!

— Каганны җиңү өчен ярсу белән осталык кына аз, — диде бикә кырт кисеп.

— Әнә анда тик яткан көчләр бар! — диде Тунгак алып каядыр сулга, караңгы таулар ягына күрсәтеп.

— Син саташа башладың бугай, Тунгак алып. Анда бернинди көч юк, анда — таулар да урманнар, — диде бикә.

— Юк, саташмыйм, бикә! — дип кычкырды Тунгак алып ярсып. — Таулар, урманнар артында күп санлы, таркау дунхулар бар. Җир йөзендә Сөн каганын җиңсә алар гына җиңәчәк. Бары алар гына — таланган, кыерсытылган, түбәнсетелгән дунхулар, кыпчаклар, хакаслар.

---

[1] Түрә — борынгы төркиләрдә билгеле тәртип кагыйдәләре. Закон.

түбетләр — барлык каралар, коллар гына, бикә! Мин аларны изге яуга күтәрәчәкмен, алар булышлыгында мин синең өлкән углың Албуганы Ак өйдәге алтын тәхеткә утыртачакмын!

## XIV

Төнне алар Дингез-күлдән биш-алты чакрым читтә уздырдылар. Икенче көнне иртүк юлга чыктылар — һәркемнең тизрәк күл янына барып җитәсе, таныш, кадерле җирләрне күрәсе килде.

Албуга, Адайны һәм үзенең егетләрен алып, барлык кешедән алдарак китте. Бикә белән балалар, Туңгак алып һәм башка ирләр бераз алардан калышып чыктылар. Туңгак алып бүген атта яхшырак утыра сыман. Шулай да әлегә аның караңгы йөзендә бернинди куаныч чаткысы күренми иде. Ул, ахрысы, бик нык авыртына. Бикә белән бергә, аның янәшәсендә генә барса да, бүген ул үзен чит кеше, артык кеше кебек тотты.

Күл буена барып җитәргә бер-ике чакрым кала каршыга килүче ниндидер атлылар күренде.

— Кемнәр соң болар? Күл сакчылары микән? — диде бикә, атын тыя төшеп. — Җавап көткән сыман ул Туңгак алыпка карап алды.

— Болар бездән алда киткән угланнар, — диде Туңгак алып. — Мин әле синнән яхшырак күрәм, бикә.

Аның бу кечкенә мактануында кичәге кебек төртмәлек, әчке бер зәһәрлек сизелде. Бикә эндәшми калды.

Чыннан да, Туңгак алыпның күзләре яхшырак күрә булып чыкты. Якынаеп килүче Албуга белән Адайны танып, бикә гаҗәпләнми булдыра алмады. Менә алар килеп җиттеләр, икесе дә баш иеп, башта аниләре белән, аннары Туңгак алып белән исәнләштеләр. Албуганың йөзе караңгы иде. Алсу йөзендә балаларча шатлык нуры балкып торса да, Адай да, абыйсына охшарга тырышып, калын иреннәрен кыскан һәм йөзенә кайгы билгесе чыгарырга тырышкан иде.

Бикә тыела алмыйча көлде.

— Бүген ирләрнең барысының да йөзләре чытык. Ни булды сезгә? — диде ул.

— Минеке чытык түгел, әни, — диде Адай акланып.

— Сакчылар күл буена бер уктан да якынрак килмәскә кушалар,— диде Албуга, анисеннән бигрәк Туңгак алыпка карап.

— Син нишләргә булдың соң, улым? — диде бикә.

— Мин синең сүзеңне көтәм, әни, — диде Албуга.

— Башларын чабарга кирәк булыр, улым, — диде бикә шаяртмакчы булып.

— Кирәк булса, чабармын, әни,— диде Албуга анисенең шаяртуын ошатмыйча.

— Син дәме? — диде бикә уртанчы улына карап.

— Яу булса, мин абый яклы, — диде Адай.

— Син... яу остасы, кем яклы? — диде бикә беркемгә катнашмыйча бер читтәрәк торган алып иргә эндәшеп.

— Мин угланнар яклы, бикә, — диде Туңгак алып.

— Мин әлегә угланнарның нәрсә яклы икәнлекләрен белмим, — диде бикә көлеп.

— Шуңа күрә киңәшергә кирәк, — диде алып ир.

— Киңәшик, — диде Албуга.

— Мин дә! — диде Адай ашыгып.

— Мине катнаштырасызмы соң? — дигән булды бикә.

— Яу эше ирләргә генә кагыла. Киңәш таркалмасын өчен өч кеше дә җитә, — диде Туңгак алып.

— Минем балык ите ашыйсым килә! — диде бикә. — Күл уртасына алачык корып, балык тотып, балык итен ашамыйча мин Диңгез-күл буеннан кузгалып китмәячәкмен!

— Минем дә балык ите ашыйсым килә! — диде Адай.

Албуга түземсез энесенә ачулы күз карашы ташлап алды.

— Күл сакчыларын без бер селтәнүдә юк итә алабыз, — диде ул «киңәшә» башлап. — Шулай да мин ул балык өчен ун кеше канын коярга киңәш итмим.

Ул әле энисенә, әле Туңгак алыпка карап сөйләде.

— Син дөрес әйттең, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде Туңгак алып. — Кеше каны балык канынннан кадерлерәк.

— Сез шулай да минем теләкне искә алмыйсызмыни, «киңәшче»ләр? — диде бикә ашыгып.

— Синең теләкне дә искә алабыз, бикә, — диде Туңгак алып. — Олуг бикәнең балык ашыйсы килә. Балыкны каганның кораллы ирләре саклый. Коралллы ирләр белән сугышырга ярамый. Мондый чакта нишләргә кирәк, олуг тәгин углан?

— «Дошман» белән сөйләшеп карарга кирәк. Илче җибәрергә, — диде Албуга.

— Дөрес! Үзем илче булам. Сез мине озата барырсыз, — диде Туңгак алып угланнарга.

— Мине кая куясыз? — диде бикә.

— Бикә түрдә генә утырырга тиеш. Балык китергәнне көтеп, — диде Туңгак алып, атын кузгатып.

— Без үзебез, эни! Син борчылма! — диде Албуга.

— Үзебез генә, үзебез генә! — диде Адай, барысыннан алгарак чыгарга тырышып.

## XV

Диңгез-күлнең һәр ягына, бер-берсеннән билгеле ара калдырып, унике өй утыртып куелган иде. Унике өйдә үзләренең хатыннары, балалары, мал-туарлар белән коралллы ирләр-сакчылар яши. Күлнең изгелеген, аннан да бигрәк, бу җирләрнең каганныкы икәнлеген яхшы белгәнгә, беркем дә бу тирәгә тора салып терлек сугарырга да тукталмый, киек ауларга да килми иде. Шулай да берәр аңсызы, я булмаса анда берәр үчлеклесе килеп үлән таптамасын, суны пычратмасын дип, әлеге сакчылар көненә бер мәртәбә булса да, үзләренә билгеләнгән җирне караштырып әйләнгәлиләр иде. Күл сакчыларының барысына да унбашы Ябалак карт баш.

Ябалак карт — Туңгак алыпның иске танышы. Күптәнге танышлар булараk алар шактый дусларча, туганнарча исәнләштеләр. Ләкин күл буенда авыл корып, төн куну турында сүз чыккач, Ябалак карт кинәт тынып калды. Өлкән бичә Күрекле бикә белән аның өлкән углының ырдадан куылулары һәм Байык буена барышлый, ихтимал, күл яныннан узып китәчәкләре турында аңа инде алдан хәбәр ителгән иде.

— Бикәнең Диңгез-күлдә балык тотасы, балык ите ашыйсы килә, — диде Туңгак алып.

Нурсыз күзләре төпкә батып, тешләре төшеп беткән Ябалак карт йокыдан уяныпп киткәндәй булды.

— Балык тотасы киләме? Хе-хе?! — диде ул күнеллеләнеп. — Бикәгә каршы киләмме соң! Берење колыны... тучи бәк тәгин углан шушында Диңгез-күл буенда, Манас тугаенда туды. Быел язга чыксак, унсигез ел тула. Оныткандыр дисеңме, Туңгак алып? Таптың онытыр кеше! Барысы да истә, Туңгак алып, бары да истә, угланнар. Язгы бозда, алачык эчендә каган балык тотып утырганда үзем барып әйттем: углын

бар, бөек каган! дидем. Сөенчегә өстемдәге менә шушы тунны бирде. Кырпылган дип исегез китмәсен — мин аны унсигезенче кыш киям. Кайчагында гына. Куанычлы көннәрдә генә.

Ябалак карт, җирән төстәге ефәк белән тышланган төлке тунының чабуын күтәреп, аның эчке ягын күрсәтте. Кунакка килгән, я булмаса йомыш белән килгән ят кешеләр алдында ул шулай каган бүләге белән мактанырга ярата. Туңгак алыпка гына да инде аның бу бишенчеме-алтынчымы мактануы иде.

— Яз көнендәгечә, күл уртасына алачык корып, бикәгә балык тотарга булышсаң, мин сиңа каган бүләгеннән дә яхшырак бүләк бирермен, — диде Туңгак алып.

— Каган бүләгеннән дә яхшырак бүләкнең булганы юк! Булмас та! — диде Ябалак карт кызып. — Йөрмәгез! Якын килмәгез! Каганнан башка миңа беркемнең дә сүзе үтми.

Билен аеллы, бизәкле киң каеш белән буып куйган, бер ягына — җәя, икенче ягына ук савыты аскан, кулына исә шома саплы, сөяк башаклы сөңге тоткан борынгы карт, тәбәнәк буйлы атын кырт кына борды да, үпкәләп-тузынып, «илчеләрдән» читкә китеп барды.

«Илчеләр» уңайсыз елмаешып аның артыннан карап калдылар.

— Их, боздым эшне! — диде Туңгак алып үкенеп.

Албуга шул чакны, берни әйтмичә, карт артыннан куа китте.

— Ябалак баба, мине тыңлале! — диде ул карт белән тигезләшкәч.

Ачулы карт үзе янынннан барган яшь угланга кырын күзе белән дә карамады.

— Мин уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга булам, — танышйсыңмы? — диде углан.

Ябалак карт атын тыя төште.

— Теге... Манас тугаенда туган тәгин угланмы? — диде ул бик үк ышанасы килмичә.

— Шул инде, шул! — диде Албуга.

— Унсигез ел элек булганны каян хәтерләп бетермәк кирәк?! — дип мыгырданды ачулы карт. Әлерәк кенә үзенең яхшы хәтерле булуы белән мактануын ул, ахрысы, онытып җибәргән иде.

— Әни дә монда. Күрекле бикә. Аның сине бик күрәсе килә, Ябалак баба! — диде Албуга ярарга тырышып.

— Әниең? Бикәме? Өлкән бичәме? — диде Ябалак карт, нидер исенә төшереп.

— Әйе, әйе, минем әни! Бикә! Өлкән бичә!

— Ник аны башта ук әйтмәдең? — диде Ябалак карт ачуланган булып.

— Монысы минем энем Адай, — диде Албуга үзе артыннан килеп җиткән Адайны күрсәтеп. — Ел саен яз көне без монда булабыз, сине күрәбез. Онытмагансыңдыр әле?

— Яшьләрне каян хәтерләп бетермәк кирәк! — диде Ябалак карт, чын күңелдән кеткелдәп.

— Без сине онытмадык, Ябалак баба! — диде Адай.

Эшләр болайга киткәч, Ябалак карт, күрәсең, яшьләр сүзенә генә ышанып җитмичә, борылып янадан Туңгак алып янына килде.

— Бикә дә монда мени? Өлкән бичә? — диде ул, «баштарак әйтмәүләренә» бик нык хәтере калганлыгын сиздереп.

Туңгак алып аңардагы бу үзгәрешкә ышанырга да, ышанмаска да белмәде — Ябалак карт элегрәк бер дә андый килделе-киттеле түгел иде.

— Моннан ун сигез ел элек, өлкән бичәнең беренче углы туган елны син, Туңгак алып, яшь арыслан кебек идең! — диде Ябалак карт, аның уйларын сизенгән сыман, кеткелдәп.

— Читлектәге арыслан идем мин, Ябалак баба.

— Без барыбыз да читлектәге арысланнар кебек, Туңгак алып.
— Читлектәге арысланнар бер-берсе белән җиңелрәк килешергә тиешләр иде дә...
— Тагын нәрсә килешеп торасы? Язлыгы — үзегезгә! Миңа күп кирәкми. Бүген бар, иртәгә юк мин.
— Язгын тулысынча үземә алам, — диде Туңгак алып.
— Авылларын күлдән бер ук ераклыгында корсыннар. Мал-туарны ярга якын җибәрмәсеннәр. Яр буендагы камышларны, талларны малдан таптатмасыннар! Киекне атмаска! — дип кычкырды Ябалак карт чәрелдәп, шома саплы сөңгесе белән селтәнеп.

## XVI

Ябалак картның теләген бикә җиренә җиткереп үтәргә тырышты. Арбалар күлдән бер чакрым чамасы җирдә туктап калдылар. Көтүләр күлдән, елга буйларыннан тагын да арырак — комлы калкулыклар арасында калдырылды. Маллар таралмасын, күл янына килмәсен өчен көтүчеләргә булышка сакчы ирләр бирелде.

Төштән соң Дингез-күлгә Күрекле бикәнең төньяктанрак хәрәкәтләнгән иле якынайды. Аларның җигүле арбалары да, мал-туарлары да күбрәк иде. Бикә аларга монда бөтенләй туктап тормаска, ары китеп, төнгә каршы елга буенда авыл корырга кушты.

Яңа урында авыл кору белән, иң элек бикә үз өендә аш-су ясады. Ашка ул олы кунак итеп карчыгы белән унбашы Ябалак картны чакырды. Үзен атап чакырганга картның бик тә күңеле булды. Бикәгә дә, тәгин угланга да кирәкле кеше икәнлеген белгәнгә күрә, табын янында ул үзен шактый иркен тотты. Ашагач-эчкәч әледән-әле кеткелдәп көлгән булды, элеккеләрне искә төшереп, моңаеп җырлап та алды.

— Углан! Балам! — диде ул Албугага эндәшеп. — Яз көне үрдәк артыннан кереп, суга батып үлә язганың исеңдәме? Сигез-тугыз ел элек. Үрдәк яраланган да, камыш арасына кереп качкан. Бу бала, күп уйлап тормаган, бозлы суга ташланган. Ярый әле мин туры килдем шунда.

— Бераз исемдә, — диде Албуга.

— Син соң, бикә, онытмадың микән — шул елны каган аткан беренче аккошны сиңа китереп бирдем. Үз кулым белән. Син миңа аккошның тәпиен бирдең. Кичен каган мине буза белән сыйлады. Менә шул, оланнар.

— Бары да истә, Ябалак баба,— диде бикә моңсу гына.— Каган янында балык тотканны карап тормакчы булгач, син миңа кычкырган идең, анысы да истә.

— Истә булмыйча! — диде карт сөенеп. — Син анда авырлы идең... беренче балаң белән, ахрысы. Анысы кыз иде бугай. Үлде диден. Урыны оҗмахта булсын сабыйның. Авырлы хатын суга караса, судагы балыкны күрсә, баласы балык кебек телсез була дигәнне син белмәгәнсеңдер, бикә. Шуңа үлмәде микән әле синең беренче балаң?

— Исемдә, исемдә! — диде Күрекле бикә. — Син әйткәч мин карамадым ул чакта. Кызымны юкка искә төшердең, Ябалак баба. Арбадан төшеп калган ул. Җәй көне. Йоклап калганмын, сизмәгәнмен. Авырлы хатынга тирән суга карамаска, балыкка карамаска дип беренче мәртәбә син әйттең. Исемдә, исемдә...

— Менә шул! Ярамаганын да беләсең, шулай да карамакчы буласың, — диде карт сүзне кинәт үз ягына борып.

— Миңа инде ярый. Барысы да ярый, Ябалак баба, — диде бикә күңелсез генә.

— Хе-хе. Алай икән, — диде Ябалак карт. Алдындагы кымызны эчте дә, корышкан каты кулы белән авыз читен сөртеп куйды. — Илең-

көнең имин булсын, малың-туарың күп булсын, бикә. Син безне сыйладың, инде мин сыйларга тиеш сезне.

Шулай сөйләнгәләп ул урыныннан торды. Бүтәннәр дә кузгалыша башладылар. Бикә картның тел төбен аңлады. Киенеп алар өйдән чыктылар. Бөтен җир өстен, киң даланы аксыл яктылык белән сыеклатылган караңгылык каплап алган иде. Күктән, көндәгечә елмаеп, йолдызлар карый, йолдызлардан бик нык аерылып, китек табак сыман ай балкый иде.

Яр буена кадәр алар атта бардылар. Яр читенә җиткәч, атларыннан төштеләр дә җәяүләп боз янына килделәр. Күлгә аяк басар алдыннан Ябалак карт кычкырып дога укыды, күл иясенә йолыкка дип алып килгән бер чүлмәк кымызны боз өстенә түкте дә, күңеле белән котылу, җиңеләю тоеп, сөңгесенә тотынган көе, шома боз өстеннән атлап китте. Башкалар аның артыннан иярделәр.

Ярдан ярты ук чамасы ераклыкта боз өстенә киез өй утыртып куелган иде. Киез өй эченә керер алдыннан Ябалак карт янә кычкырып дога укыды, күл иясенә йолык бирде. Өйгә кереп ул зур гына чүлмәктәге майлы чүпрәккә ут төртеп җибәрде. Ут-анага да йолык биреп, өйне арыклагач кына ул бикәне үз янына чакырды.

Киез өйнең тач уртасына түгәрәк бәке тишелгән иде. Су белән бәке төбе арасында юка гына боз элпәсе калдырылган. Ябалак карт, сөңге башагына майлы чүпрәк бәйләп, чүпрәгенә ут кабызды һәм чыртлап янган чүпрәкне бәке турысынарак китерде. Шул ук вакытта ул, ымлап кына, бикәгә якын килергә кушты. Ут яктысына төптән, боз астыннан кара сыртлы балыклар килеп чыкты. Кайберләре уттан куркып тиз генә читкә тайпылдылар, кайберләре әрсезләнеп борыннары белән астан юка бозга төртеп-төртеп алдылар. Бөрежен[1] ике куллап тоткан бикә, тынын кысып, «үз балыгын» көтте.

— Әйдә! — диде карт, пышылдап.

Бәке авызында бикә шома сыртлы, тәңкәле зур балык күреп алды. Ул тимер башлы бөрежен шул тере, шома нәрсәгә бар көченә тондырды. Чатнап боз ватылган, су чайпалган тавыш ишетелде. Һәм авыр бөрежне кемдер үзе белән өстерәп китә башлады. Бикә каушап бөреж сабын ычкындырып җибәрде.

— Эх! — диде Ябалак карт.

Кулындагы утлы сөңгесен ычкындырмыйча ул бер очы бөреж сабына, икенче очы өй кирәгесенә бәйләнгән кыл арканны тотып алды. Су астына киткән арканны ул иплән кенә, тыеп кына учыннан шудыра башлады. Иң ахырда ул аны, ныгытып кыскан килеш, җибәрмичә аяк терәп тотып тора башлады.

— Булды! Әллә кая китә алмый инде ул! — диде канәгать төс белән пышылдап.

Утлы сөңгесен ул аягы астына куйды, арканга ике куллап тотынды да, ух-вах килеп авыр балыкны бәке авызына тартып китерде. Арканга шундук бикә килеп тотынды. Ул тотыну белән, Ябалак карт бауны ычкындыргандай итте. Балыкны боз өстенә бикә тартып чыгарды.

Алачык тирәсендә алай-болай боз ватылып китә күрмәсен дип, ирләр таралып читтәрәк торалар иде. Бикә беренче балыкны тоткач, Ябалак карт үз янына Албуганы чакырды. Икенче балыкны Ябалак карт белән бергәләп Албуга тотты. Аннары өченчесен тоттылар. Анысын Адай тартып чыгарды. Адайдан соң бәке янына җиде яшьлек Кече-Тайны чакырдылар. Куянкай өйдә йоклап калган иде. Кече-Тайдан соң киез өйгә Туңгак алып керде.

Бәке янына ул теләмичә генә атлады, солсыз сул кулына бөрежне

[1] Бөреж — боз вата торган (агач саплы тимер) корал. Сөймән, лом. Романда бөреж «гарпун» мәгънәсендә алынды. Гарпун — балык аулаучылар коралы.

теләмичә генә алды. Беренче кизәнүдә ул балыкка тидерә алмады — бөрежә чак-чак кына кулыннан ычкынып китмәде. Үзенең булдыксызлыгына, гариплегенә ачудан аның маңгаена салкын тир бәреп чыкты.

— Ашыкма! Ул сиңа, теге, яуда кеше үтерү түгел,— диде Ябалак карт өйрәтеп.

Туңгак алып ашыкма дигән саен ашыкты, кабаланды һәм суга берничә мәртәбә төртеп алгач кына бер кечкенә балык тартып чыгарды. Аның тәмам күңеле кырылды.

— Булмый! Миннән булмый, — диде ул ачынып. Бөрежен ташлады да, ашыгып алачыктан чыгып ук китте.

Ул төнне алар бик күп балык тоттылар. Тотылган балыкны, йөккә төяп, үзләре белән авылга алып кайттылар. Төнге эштән соң арып-алҗып, шулай да эчке бер канәгатьләнү, тынычлану белән татлы йокыга аудылар.

Ул төнне бары Ябалак карт кына йоклый алмады.

## ХVII

Икенче көнне далада буран купты.

Кояш иртән әз генә күренеп торды да каядыр килеп чыккан һәм ашыгып көнчыгышка таба агыла башлаган болытлар арасында күмелеп калды. Сөякләргә үтеп исә торган ачы җил ярма сыман каты кар катыш ком бөртекләре алып килде. Көннең бозылачагын терлекләр алдан ук сизенделәр — борчылып кычкыра, тынычсызлана башладылар. Бар яктан да ачык, шыр далада, шыр калкулыклар арасында меңләгән мал-туарны җил-бураннан качырып, саклап калырлык бер генә җайлы урын да юк иде. Андый җайлы урын моннан еракта — көньяктагы таулар ягында гына бар. Анда барып җитү өчен елга аша чыгарга, яр буйларындагы талларны, камышларны таптап үтәргә кирәк булачак. Төнлә кизү торган көтүчеләр, буран чыгасын күреп, ашыгып бикә янына килделәр.

Бикә әле йокыдан тормаган иде. Аны шундук уяттылар. Уятучының шомлы тавышы буенча, өй артында җил ыжгыруы буенча бикә дөньяда ниндидер күңелсез нәрсә булганлыгын аңлап алды. Ул өстенә-башына ашык-пошык киенде дә, көтүчеләрне өенә кертергә кушты. Уллары Албуга белән Адайны, йөзбашы Җирәнне, баш бага Кортаганы, туганнарын чакыртып кеше җибәрде. Туңгак алып якында гына иде.

Күп тә үтмәде, өйгә күшеккән, борчулы көтүчеләр керел тулды. Ашыгып Албуга белән Адай килеп керде. Барысы да җыелып бетеп, киңәшергә-сөйләшергә генә торганда, ут чыккандай тыны бетеп, агарынып Ябалак карт килеп житте.

— Бикә! — дип кычкырды ул килеп кергәч тә, исәнлек тә алып тормыйча. — Бикә! Балыклар исәнме?

— Исән! — диде бикә.

— Исән булса, илтеп бир тизрәк. Үз кулың белән, — диде Ябалак карт.

— Кемгә? Ник?

— Әйткәнемне тыңла — илтеп бир! Күл иясе безгә ачулы. Мин, карт дивана, сезнең сүзгә карап...

— Күл богауда. Ул тик ята, Ябалак баба. Күл иясе түгел, Җил иясе ачуланган — буран куба!

— Өйрәт Ябалак картны, — диде карт, кулын селтәп. — Илтеп бир диләр сиңа. Җил иясе күл төбендә ята. Кичә ул бәкедән чыгып калган. Карт дивана, туң баш! Шуны истән чыгарганмын.

— **Ярар, илтеп бирербез, Ябалак баба.**

— Буран чыкканчы! Тизрәк! — дип кычкырды Ябалак карт, ашыктырып.

— Көтүләрне нишләтергә, Ябалак баба? Таулар арасына ничек булыр? — диде Албуга, картның юлына аркылы төшеп.

— Куыгыз, ку! Таулар ягына куыгыз!

— Ишеттегезме? — диде бикә көтүчеләргә, Ябалак карт чыгып киткәч.

— Ишеттек.

— Әни, көтүчеләргә булышка мин дә барам. Барлык ирләрне көтү куарга җибәрәм, — диде Албуга.

— Мин дә! — диде Адай, абыйсы артыннан ашыгып.

— Туктагыз, — диде бикә улларына. — Балыкларны илтеп бирик. Шуннан соң.

— Сез балыкларны алып китегез. Көтүчеләр янына үзем барырмын, — диде Туңгак алып.

Бикә аңа күтәрелеп карады — алып ирнең кыяфәте бер дә шәптән түгел иде.

— Сиңа... авыр булыр,— диде бикә.— Ятып торасыңмы әллә?

— Мондый чакта ятып торган ирне син ир дип әйтерсеңме соң? — диде Туңгак алып сер сынатасы килмичә.

— Юк, син йөрмә! — диде бикә кырт кисеп. — Менә Җирән барыр көтүчеләр янына.

— Барырмын, бикә,— диде Җирән дәртсез генә.

Урдадан Туңгак алып килеп кушылгач ул бөтенләй сүлпәнләнеп, үз эченә йомылып калды. Элек ул Туңгак алыптан курка, көнләшә иде, хәзер ул аны — гарип ирне күрәлми башлады. Бикә янында үзенең артык кеше икәнлеген күреп ул тизрәк моннан чыгып китү ягын карады.

Җирән чыгып киткәч Туңгак алып та җыена башлады. Бикә, аның мин-минлегенә кагылудан куркып, кал дип артык кыстап тормады. Күз-колак булырга, кирәк булса булышырга дип аңа Адайны ияртергә шулай да бикәнең башы житте. Алар ашык-пошык җыенып, аяк өсте генә капкалап барысы да берьюлы диярлек өйдән чыктылар.

Адай барысыннан да ныграк җитезлек күрсәтте. Өйдән читтә моңаеп, хуҗасын көтеп торган юаш алашаны ул Туңгак алып янына китереп туктатты. Аңа иягә атланырга булышты. Туңгак алып иягә җайлап утыргач, яшь углан үз атына атланды һәм алар калкулыклар ягына китеп бардылар. Юлда аларны уңнан да, сулдан да ашыгып баручы ирләр узып китте. Адай да алардан калышмаска тырышып караган иде дә булдыра алмады — Туңгак алыпның калышуын күреп аңа тыелырга туры килде.

— Бар әйдә, бар, тоткарланма, — диде Туңгак алып.

Адай тыңламады. Әле аны узып китеп, әле көтә-көтә, алар, ниһаять, зур калкулык өстенә килеп менделәр. Җил каршы яктан исә иде. Калкулык өстендә ул көчлерәк, усалрак тоелды. Алар, туры бәргән җилдән битләрен, күзләрен саклап, түбән төштеләр. Чак-чак кына башларын калкытып, тирә-якка күз ташлап алдылар. Бөтен тигезлекне каплап алган көтүләр инде тузыша башлаган иде. Шул ук вакытта андамонда көтүчеләрнең җан ачысы белән кычкырган тавышлары, үгез үкергән, атлар кешнәгән тавышлар ишетелә. Димәк, ирләр көтүләрне бүлеп өлгерә алмаганнар. Димәк, җилгә каршы якта, көтү алдында булучылар җитәрлек түгел. Ни караган Җирән? Кая аның ирләре?!

Туңгак алыпның күңеленә шундыйрак сораулар килде. Калкулык астында, аларның яныннан гына диярлек, көчле җилгә артларын куеп, бик кызу чабып, елкы көтүе узып китте. Шомлы пошкырып, каты тояклары белән каты җиргә дөп-дөп басып каядыр ыргылган атлардан соң, арт саннарын сикертә-сикертә, башларын чайкый-чайкый чапкан сыер көтүе күренде. Сыер көтүе арасында бүленеп калган дөяләр йөгерде.

алар артыннан тупырдашып, бер-берсенә сыенып, җил очырып йөртә торган тере йон төргәкләре кебек, куйлар-сарыклар тузышты.

Бу көтүләрне кем дә булса куалап, билгеле бер юнәлештә алып бара идеме, әллә соң аларны бары җил-давыл гына йөгертә идеме — Туңгак алып аера алмады. Ул арада җил кинәт көчәеп китте, буран чыкты. Бөтен җир-күк тоташ болганчыкка әйләнде. Әле менә якында гына күренгән Адай, кар-буран белән буталып, күздән югалды. Баш өстеннән ниндидер кара-мора нәрсәләр, төбе-тамыры белән йолкынып чыккан үлән төргәкләре очып үтте, каты кар, ком бөртекләре белән бергә каяндыр ваграк ташлар очып килде. Асты-өсте кузгалган бөтен җир-күк дер селкенеп, калтыранып, гүләп торды. Өзлексез шау-шу, сызгыру, ыңгырашу арасында, ярсып кычкырган, үкергән, чинаган тавышлар арасында ниндидер ят, сәер дөбердекләр ишетелеп китте — әллә җир читендә шулай таулар-кыялар ишелде, әллә Тәңре үзенең языклы бәндәләре өстенә ачу белән югарыдан уклар, сөңгеләр ыргытты.

Далада менә шулай кисәк купкан көчле җил-давылдан да куркынычрак берни юк иде. Мондый чакта кеше, бер-берсенә булышудан элек, үзенең терлек-туарына булышырга, ничек тә аны үлемнән коткарып калырга тиеш. Терлек-туарны үлемнән коткарып калу исә үз-үзеңне ач үлемнән коткарып калу дигән сүз иде.

Тигезлек өстеннән җил уңаена ташкын-ташкын булып узып киткән көтүләрне күзәткән бер мәлдә Туңгак алып үзенең җылы өйдән чыгып бик зур ялгышлык эшләвен аңлагандай булды. Бар көченә котырынган мондый җил-давылга каршы ялгыз башы ул берни эшли алмый иде. Ул ялгышты. Ул соңга калды. Ләкин шул ук вакытта ул бер урында катып та тора алмый иде. Үзенең гариплеген дә онытып ул, кемнәргәдер ярдәм итәргә кирәклеген исендә тоткан хәлдә, тыелгысыз җил артыннан иярде. Бу вакытта алар инде Адай белән бер-берсеннән аерылганнар иде.

## XVIII

Анысын анда орып, монысын монда орып, тиешенчә үз көчен күрсәткәч, җил-давыл кисәк кенә тынып калды. Тире бүрекләрнең озын колакчыннарын чишеп җибәргәч, ком тулган күзләрен ертып, як-якка карагач, кешеләр беравык үзләренә үзләре ышанмый тордылар. Дөнья искиткеч тын иде, якты иде — һавада бер генә тузан бөртеге дә, бер генә чүп, кар бөртеге дә юк. Чатнап торган салкын, коры, аксыл күктә, бер гөнаһсыз сабый бала кебек, ягымлы, елмаеп, алтын-сары кояш карап тора. Көнбатыштагы шәрә ком таулары, көнчыгыштагы Диңгез-күл, күл буендагы камышлыклар — барысы да элеккечә тыныч һәм серле. Дөньяда бернинди үзгәреш булмавына ныграк ышандырырга тырышкан шикелле, баш өстендә генә каркылдап каргалар оча, киез өйләр, арбалар тирәсендә чыпчыклар тибенә иде.

Җил куалап киткән көтүләр елга буендагы таллыкка кадәр бардылар да, көтелмәгән каршылыкка очрап, яр буенча үргә — ачык җирдән көньякка таба ыргылдылар. Көтүчеләр һәм шулай ук ашык-пошык җыенган башка ирләр тузынган малларны туктата да, елга аръягындагы таулар арасына куып кертә дә алмадылар.

Атлар, дөяләр, сыерлар елга үзәне буенча югарыга бик озак чаптылар һәм күлдән ерагайгач, ниндидер урман алдында үзләре туктап калдылар. Шактый соңлап килеп җиткән көтүчеләр аларны көч-хәл белән кире борды. Буран тынганда инде алар барысы да бергә тупланган иде. Сарык көтүенең бик аз өлеше генә елга үзәне буенча китте. Сарыкларның күбесе, таллыкка килеп төртелү белән, шунда кереп

буталып бетте. Кайберләре агачлар арасында кысылып калды, кайберләрен эре терлекләр таптап киттеләр.

Балыкны кире күл иясенә илтеп бирергә дип киткән бикә белән тәгин углан давыл купканчы яр буена барып җитә алмый калдылар. Алар җигүле үгезләрен җилгә каршы бордылар да, давыл тынганчы арба эчендә утырып тордылар.

Югалган, таралган терлек-туарны ирләр көне буе барлап җыеп йөрделәр. Тапталып үлгән сарыкларны, егылып аягын сындырган бер дөяне каргалар сыман килеп җыелган ярлы чиннәргә бирделәр. Кайдадыр шушы тирәдә генә — урман, таулар арасында чин качакларыннан оешкан авыллар бар иде.

Авылда көне буена елаган, шыңшыган, ыңгырашкан авазлар ишетелеп торды. Хатын-кызлар ертылган, сүтелгән өйләрен рәтләделәр, көтү куып ерак киткән ирләрен, балаларын көттеләр. Җил чыкканда бер-ике кечкенә бала күл буенда булган — җил аларны боз өстеннән шудырып бик еракка алып киткән. Аларның үле гәүдәләре яр буендагы камышлыклар арасыннан табылды. Бер көтүчене атлар таптап үтергән булып чыкты.

Бикәнең өлкән углы үзе янында иде. Куянкае белән Кече-Тае өчен дә ул бөтенләй диярлек борчылмады — җил чыкканда алар өйдә калган булырга тиешләр. Бикә бары Туңгак алып белән Адай өчен генә борчылды. Җил тынып, балыкны капчыгы-ние белән боз өстенә аударгач, ул тизрәк өенә ашыкты. Анда кече улы белән кызының исән-имин икәнлеген күреп ул яңадан атка атланды да көтүчеләрне эзләп китте. Албуга да әнисенә иярде. Адай белән Туңгак алыпны алар көтүчеләр янында гына булырга тиеш дип уйладылар. Авылдан бер чакрым чамасы китеп өлгермәделәр, каршыга очраган ирләрнең берсе Туңгак алыпны елга буенда ярым үлек хәлдә таптык, дигән хәбәр әйтте.

Бикә белән Албуга ашыгып елга буена чаптылар.

Алар килеп җиткәндә Туңгак алып әле исән иде. Ләкин ул инде аңын югалткан, күзләре йомык иде. Аның янындагы Кәлтә бикә белән тәгин угланга Туңгак алыпны кайчан, ничек табуы турында сөйләргә тотынды. Бикә аны тыңлап тормады. Иелеп, җирдә яткан ирнең йөзенә карады, тын алуын тыңлады, тәнен тоткалады. Туңгак алыпның тәне җылы, тын алуы тигез иде. Бикә ялт кына башын калкытты, өлкән углына боерып:

— Бар, тиз бул! — диде.

— Кая?

— Теләсәң кая бар! Киез китер, кешеләр китер!

Елга аръягында, тәбәнәк калкулык өстендә ялгыз өй утырганын Албуга монда килгәндә үк күреп алган иде.

— Әни, шунда гына илтик! — диде ул, әлеге өйгә күрсәтеп.

— Әйдәгез! — диде бикә.

Кәлтә өстендәге бер кат туның салып җиргә җәйде. Туңгак алыпны шул тун өстенә яткырдылар. Тунның бер як чабуыннан Албуга, икенче як чабуыннан Кәлтә тотты. Бикә арттан аның аякларын күтәреште. Таллык аша чыгуы бик кыен булды. Таллыкны узгач, ялгыз өй ягыннан кемнеңдер ашыгып каршыга килгәне күренде. Бу күл сакчысы Ябалак карт булып чыкты. Дүртәүләшеп алар авыр гәүдәле ир кешене өйгә алып керделәр. Учак янына киез өстенә сузып салдылар. Күтәреп барганда да, өйгә кергәч тә Туңгак алып әледән-әле ыңгырашып куйды, нидер әйтергә теләгәндәй иреннәрен кыймылдатты.

— Эчәргә сорый, — диде Ябалак карт һәм шундук бурдактан кымыз агыза башлады.

Туңгак алып янына Ябалак картның үзеннән элек аның корткасы килеп җитте. Яралы ирне ул җайлабрак яткырды, авыз эченнән генә дога сүзләре укып, аның битен, аяк асларын сыйпалады, изүен чишеп.

тунын ычкындырып ташлады. Карты китергән кымызны ул яралының авызына көчләп диярлек агызды.

— Кайгырма, бикә, минем кортка тотынгач, терелтми куймас. Ул анын телен белә,— диде Ябалак карт карчыгын мактап.

Карчык исә, идәндә сузылып яткан яралы ирдән башка беркемне күрмичә-ишетмичә, туктаусыз укына-укына, бик озаклап, жентекләп капшанды-капшанды да, башын чак кына калкыткандай итеп бикәгә:

— Бөтенләй чишендерергә кирәк, бикә,— диде йомшак, ягымлы бер тавыш белән. — Беләге шешкән, жиңенә сыймый. Тунын ярмый булмас.

— Булышыргамы? — диде бикә.

— Яңа суелган үгез тиресенә төрербез, ана эт сөте эчертербез, — дип сөйләнде карчык бикәне тыңламыйча. — Утлы куз өстендә дә тотарга туры килмәгәе. Каны чыкмаган. Бозык каны эчтә җыелып калган. Шул чыкмыйча савыкмас.

— Болай булгач, тиз генә савыкмый әле ул! — дип куйды Ябалак карт.

Ничектер серле генә итеп ул бикәнең жиңеннән тотты да, ишеккә таба ымлады. Алар, тәбәнәк ишек башына орынмас өчен яртылаш бөгелеп, бер-бер артлы өйдән чыктылар. Тагин углан белән Кәлтә кызулап атлары янына китеп бардылар. Бикә өлкән углына Адайны эзләп табарга кушты.

— Син миңа үпкәләмә, бикә, — диде Ябалак карт яшьләр ерагайгач. — Сиңа моннан тизрәк кузгалып китәргә кирәк.

— Аны калдырыпмы? — диде бикә, өй ягына ымлап.

— Алып китсәгез, юлда ул бүген үк аяк сузачак,— диде Ябалак карт.

— Уйлап карармын, — диде бикә, икеләнгәндәй итеп.

— Уйлыйсы юк, бикә! — диде карт. — Мин барып карадым — балыкны да яр буена гына ташлап киткәнсез. Күл иясе сиңа ачулы. Кит тизрәк, кит моннан, юкса, барлык малыңнан, иленнән-көненнән колак кагарсың.

— Куркытма әле, Ябалак баба, — диде бикә ыңгырашып.

— Мин куркытмыйм сине — иияләр куркыта! — диде Ябалак карт.

— Шул көенчә ничек ташлап китим мин аны?! — диде бикә өзгәләнеп.

— Аягына баскач үзе эзләп табар, я килеп алырсыз, — диде Ябалак карт, бикәне юатырга кирәк табып. — Минем кортканың кулы алтын. Терелтер. Бер дә хафаланма, бикә.

## XIX

Адай исән иде. Көтү ташкынына эләгеп ул башка ирләр белән бергә еракташы таулар, урманнар ягына барып чыккан. Уртанчы улын исән-сау күргәч бикәнең күңеле бераз үз урынына утыргандай булды. Шулай да Ябалак картның кисәтүе аның йөрәген туктаусыз бозып торды. Үзенең иң якын кешесен шул килеш, ярым үлек килеш ташлап китү аңа башка сыймастай нәрсә булып тоелды. Үзе генә бер карарга да килә алмагач, ул уллары белән киңәшеп карарга булды. Алар: ни булса да бүген күтәргә, иртәгә таң белән юлга чыгарга, дигән фикер әйттеләр.

Кичкә таба Тунгак алып телгә килде. Ул үзенең бикәне, тагин угланны күрергә теләвен белдерде. Бу вакытта бикә үз авылында, үз өендә иде. Ябалак карт, атына атланып, бикә белән тагин угланны алырга китте.

Өлкән углын иартеп бикә Ябалак картның елга буендагы өенә бик тиз килеп житте. Иске киезләрдән җыйнаштырылган тәбәнәк, кысан

өйдә Туңгак алып бөтен түрне иңләп-буйлап ята иде. Өстендәге киемнәрен салдырып, аны баштанаяк чи үгез тиресенә төргәннәр иде. Җирән үгез тиресе арасыннан аның бары киң яңаклы чандыр бите генә агарып күренә.

Бикә аның уң ягына, тәгин углан сул ягына тезләнде. Икесе дә сораулы караш белән аның күзләренә текәлделәр. Туңгак алып әле бер якка, әле икенче якка күзләрен генә йөртте.

— Килдегезме? — диде ул аларның икесенә дә эндәшеп.

Ул моны бик тыныч итеп, бернинди сызланусыз, пошынусыз әйтте. Гүя ул яралы да түгел иде, әлерәк кенә аңын да югалтып ятмаган иде.

— Хәлең ничек? — диде бикә, аның йөзенә үк иелеп.

— Хәлем... яхшы, — диде Туңгак алып.

Ул елмаерга тырышып карады. Булдыра алмады. Карт белән карчык күләгә сыман читтән генә, аларның сөйләшүләрен тыйнак кына тыңлап тордылар. Туңгак алып аларны күреп алды.

— Бикә, тәгин углан... сез генә калыгыз, — диде ул.

— Ярар, ярар, — диде Ябалак карт кабаланып, чыгарга җыенып.

Кортка да ашыкмыйча гына киенә башлады.

Өйдә өчәү генә калгач, Туңгак алып ымлап, бикә белән тәгин угланга якынрак килергә кушты. Үзенең колак төбендә генә аларның тын алуларын тыңлап ятты да, бар батырлыгын җыеп сүзгә башлады.

— Минем икегезгә генә әйтәсе сүзләрем бар,— диде ул, ярым пышылдап. — Мин... кучәм.

Бикәнең кашлары сикерешеп куйды, авыз читләре ямьсез булып сузылып калды һәм ул үзе дә сизмәстән борынын тарта башлады. Албуга, бозылган йөзен күрсәтмәс өчен, тиз генә читкә борылды. Туңгак алып аларның тынычланганын көтеп ятты.

— Бүлдермәгез. Тыңлап кына торыгыз, —диде ул. — Киткәнче мин сүземне сезгә әйтергә булдым. Мин, Туңгак алып, Туман каганга биргән антымны бозам сезнең алда. Үлгәч мине... антын бозган кешене... киезгә төреп, куыш агач эченә салып, багана башына элеп куйсыннар.

— Әллә әйтмисеңме, Туңгак? — диде бикә ялыну катыш үтенеч белән.

— Әйтми ярамый, — диде Туңгак алып. — Мин күп уйладым. Сезгә аны әйтми ярамый. Син, бикә, курыкма. Тәгин углан, син дә курыкма. Курыксаң, яшәргә дә кирәкми. Яшәү ул — куркуны җиңү, үлемне җиңү.

— Үлемне!? — диде Албуга.

— Үлемне, туч бәк тәгин углан. Сине, тәгин углан, җир өстендә адым саен үлем сагалый. Каган урдасы әйләнәсендә сине... дүрт җирдә дүрт үлем сагалый!

— Саташмыйсыңдыр ич син, Туңгак?! — диде бикә, коты алынып.

— Саташмыйм, бикә, — диде Туңгак алып, тыныч кына. — Туман каган тәгин угланның дүрт курчагын ясатты. Урда туктаган бер җирдә ул курчакларны җиргә күмдерәчәк.

Албуга агарынып китте.

— Туңгак?! — диде бикә ярдәм сорагандай, кулын күтәреп.

— Бу эшне ул Исәнтәйгә тапшырды. Ана-кам кушуы буенча. Алардан сакланыгыз,— диде Туңгак алып, бераз тынып яткач.

— Ул мине чыннан да үтермәкче буламыни? — диде Албуга, кинәт хәлсезләнеп.

— Әйе, ул сине үтермәкче була, — диде Туңгак алып.

— Шулмы синең әйтәсе сүзең? — диде бикә.

— Шул, — диде Туңгак алып.

— Син, Туңгак, минем өлкән углымны коткару өчен...

— Минем тагын сүзем бар, — диде Туңгак алып, бикәне бүлде-

реп. — Мин Кортка-бикәдән белештем: җиргә күмелгән курчакларның сихерен бетереп булмый. Аларга якын барырга ярамый.

— Анысын мин дә беләм, — диде тагын углан.

— Тыңлап бетер! — диде Туңгак алып. — Дүрт курчакның сихер көчен бетерү өчен сиңа дүрт үлемне җиңәргә кирәк. Әйттемме сине адым саен үлем сагалый дип?! Монысын да мин Кортка-бикәнең үзеннән белдем. Ант эчеп.

Ярым караңгы, кысан өй эчендә авыр тынлык урнашты.

— Аңлашылды, — диде бикә көрсенеп.

— Сезнең алда мин берьюлы ике антымны боздым. Берсе тотмаса берсе тотачак. Шуңа күрә минем теләкне үтәми калмагыз, — диде Туңгак алып бөтенләй чит кеше тавышы белән. — Тагын сүзем бар. Монысы болай гына, йөрәк янганнан гына. Исәнтәй котыртуы буенча каган Чингә каршы бөтен көче белән яу чапмакчы. Мәкерле Исәнтәй корган тозак куркыныч. Миннән башка сөннәр җиңеләчәк. Салчак алып куркак, кара эчле. Яуда ул каушап калачак. Туман каганның субашы булырдай башка ире юк. Бар ышаныч синдә, уң кул тучи бәк тагын углан... Албуга... Алаб Буга!

Яратып, эченә, күңеленә кереп ул яшь угланга карады һәм, үзенең бу яратуыннан курыккан сыман, тизрәк күзен читкә борды да тынып калды.

## XX

Юл буена бикә уйланып кайтты. Шулай итеп, Туңгак алып та юк. Күпме яуда булып, күпме яра алып, күпме үлем белән якалашып исән калган ир. Карусыз, кыю ир. Якын дус, сердәш. Күпме истәлекләр... татлы да, сагышлы да, көлке дә, куркыныч та истәлекләр аңа барып тоташа. Шулай итеп, чыннан да китәр микәнни? Үзенең истәлекләре белән, әйткән сүзләре, күз карашлары, дәртле кайнарлыгы белән артта калып, онытылып, мәңге юкка чыгар микәнни? Никтер ышанасы килми. Кичә генә җир җимертеп, бар нәрсәгә хуҗа булып яшәгән кешенең бүген булмавына ышанасы килми. Ул да китеп барса, бу дөньяда кемгә таянырга, кемгә эч серләреңне сөйләп юанырга, кемнең җылы куенында күңелеңә юаныч табарга? Балалар үсә, түл җыя, ләкин алар беркайчан да сине кул очында йөрткән, иркәләгән ирең булмас.

Күрәсең, чыннан да китәр ул. Берьюлы ике антын бозган кешене җир күтәрә алмас. Антын бозган кешенең тамыры корый, кулы-аягы корыша, күзләре сукырая. Монда инде аңа беркем дә, берни дә ярдәм итә алмаячак.

Туктале, андый нәрсәне кире кайтара торган берәр төрле им-том юк микән? Булырга тиеш. Ләкин аны белсә бары шул Кортка бикә генә белер. Куяннарга ул мәңгелек дошман. Куяннарга ул беркайчан үзенең андый серләрен әйтмәячәк.

Әйе, язмышы шундыйдыр Туңгак колның. Бәхетле дә, бәхетсез дә язмыш. Тугин угланны, аны — бикәне, бөтен ил-көнне коткару өчен ул үз-үзен корбан итте. Әле генә. Күз алдында. Аның шундый изгелеген ничек онытмак кирәк? Соңгы кат, соңгы мәртәбә булса да, аның өчен берәр төрле изгелек — күз күрмәгән, колак ишетмәгән берәр яхшылык эшлисе иде, таңрем!

Өенә кайтып сүнә язган учакны дөрләтеп җибәргәч ул, балаларын җыеп, ашарга утырды.

— Аның бит бер нәрсәсе дә юк! — дип сөйләнде ул әле һаман тынычлана алмыйча, уйларын дәвам итеп. — Бер нәрсәсе! Аты да, өе дә, каккан казыгы да!

— Әни, син аңа бер-ике ат калдыр, арба белән дөяләр калдыр, — диде Албуга киңәш итеп.

— Мин аңа, улым, яңа киездән кышкы өй калдырам, кырык-илле баш сарык, ике сыер, бер-ике дөя белән бер-ике ат калдырам, — диде бикә.

— Ул үлсә, аның мал-туарын Ябалак карт алыр, иеме әни? — диде Адай.

— Тсс! — диде бикә, белексез углына ысылдап. — Алай кычкырып әйтмә андый сүзләрне. Як-ягыңа төкер!

— Әйттем исә кайттым! — диде Адай шундук, як-ягына төкеренеп.

— Мин аңа ярты байлыгымны калдыра алам, — диде бикә моңсу гына. — Монда ул аның белән нишләсен?! Терелгәнче, аягына басканчы туенып торырлык булса, шул җиткән. Картларга булышка бирәр кыз да калдырмый булмас.

Соңгы сүзләрен бикә бераз гына икеләнеп әйтте. Туңгак алып гарип булса да, үзе ялгыз булгач, ул инде аны бөтенләе белән үземнеке дип уйларга күнеккән иде. Аның янында кырнак кыз калдырырга дигән уй анда кинәт көнчеллек сыман бер нәрсә кузгатып куйгандай булды. Шулай да ул андый тойгыга көчәергә ирек бирмәде. Терелсен генә, аягына гына бассын — аның янында ул үзенең иң яшь, иң матур кызларын да калдыра ала.

— Әйе шул, чынлап та, әни! — диде Албуга, әнисенең фикерен куәтләп.

Бикә ашагач шундук өйдән чыгып китте. Аның кол кызлары, хезмәтче хатыннары якындагы өйдә генә торалар иде. Бераздан бикә таза гына, сылу гына бер яшь кызны ияртеп керде. Куе кара чәчле, чем кара күзле, матур тавышлы бу кыз түбетнеке — теге кичне камышлыкта Кәлтә белән серләшеп торган Кара-Тут исемле кыз иде.

— Без аңа менә... Кара-Тутны калдырырбыз, улым,— диде бикә, үзенең тәгин углы белән киңәшкән сыман сөйләнеп. — Эшчән, сүз тыңлаучан, ягымлы. Авыру ир кешегә шундый кыз кирәк тә. Инде алай-болай була икән, малның яртысы Ябалак картка, яртысы кызга калыр. Шул мал-мөлкәте белән Кара-Тутны үзем кияүгә бирермен. Ичмасам күңелем тынычланыр.

— Әни! — диде кинәт Албуга.

— Нәрсә «әни»? — диде бикә, башын иеп торган кызны караштырып.

— Әни, калдырма аны! — диде Албуга. — Без аңа... теге... Табылдыкны бирик.

— Нишләп алай? Син аны яратасың түгелме соң? — диде бикә.

— Әни! — диде Албуга дулкынланып. — Үлем түшәгендә яткан колыңа, өй, мал-туар белән каралар калдырмакчы булып син бик күп бәкләрдән, аксөякләрдән өстен икәнлегеңне күрсәттең. Кем ул сиңа Туңгак алып? Мин моны беләм. Кем ул миңа Туңгак алып? Анысын мин белмим. Ул миңа туган атам кебек булды. Ул мине беренче булып атта йөрергә өйрәтте. Ул мине кылыч, сөңге тотарга өйрәтте, ул мине суда йөзәргә өйрәтте. Ул мине корычтай нык куллы, юлбарыстай кыю йөрәкле, даладай киң күңелле булырга өйрәтте! Аның өчен мин соңгы атымны, соңгы тунымны бирә алам. Аның өчен мин шулай ук яраткан кызымнан да баш тарта алам. Әни! Барлык кешеләрдән, барлык вактөяк кайгылардан өстен булырга дип син миңа үзең әйттең. Синең сүзләреңне мин гел истә тотам. Атам кебек кешегә яраткан кызымны калдырам икән, син каршы килмәссең дип уйлыйм. Аннан соң, Байык буена барып урнашкач, мин болай да өйләнергә тиешмен.

— Шулай шул, — дип куйды бикә килешкәндәй итеп. — Ярар, синеңчә булсын, алайса. Бу түбет кызы да ягымлы, югыйсә.

— Түбәт кызын бүген генә миннән... минем аша ялынып Кәлтә сорады, — диде Албуга. — Синнән сорарга дип үтенде. Алар бер-берсен яраталар. Кәлтә минем иң ышанычлы егетем. Аның яраткан кызын тартып алсам, кемгә охшар идем соң мин, әни? Мин атама охшамаячакмын, мин беркайчан да Туман каган эзеннән китмәячәкмен!

— Бирсен, тәңрем! — диде бикә җиңел сулап.

*Дәвамы киләсе санда*

## Укучының күңел дәфтәренә

### Гарәп мәкальләре һәм әйтемнәре

*Белемне хыял камилрәк итә.*
*Күңел байлыгы — иң матур байлык.*
*Кошны кош белән тоталар.*
*Һәммә ук та мишеньгә тими.*
*Тычканнар гаделлегеннән мәче җәбере яхшырак.*
*Олы җанлы кешеләр гафу итә беләләр.*
*Үзеңә каршы булса да, дөреслекне туры әйт.*
*Хаклы кеше көчле була.*
*Гариплэр алдында чатан булып кыланма.*
*Оятлы булып яшәүдән утта яну яхшырак.*
*Йөрәкләрне аерган юл — юлларның иң озыны.*
*Суганың кирәк түгел — күземнән яшь агыза.*
*Уйсу җирдәге басу кеше суын да йота.*
*Хуҗа кая теләсә — аяк шул якка атлый.*
*Үзеңә тиясе уктан зуррак уклар очырма.*
*Яшерен таш төрән сындыра.*
*Кораб теләгән яктан исә торган җилләр юк.*
*Врачка чирләгәч түгел, ә чирләгәнче күрен.*
*Бавырга файдалы нәрсә бөер өчен зыянлы.*
*Этнең кәкре коерыгы калыпта да тураймый.*

# Равил Фәйзуллин


## Бу җырлар

Бал җыйган кортлар күк,
кояшның нурында
коенган җырлар бу!
Язмышлар кырыннан
җыелган җырлар бу!
Сый итеп, алдыңа
куелган җырлар бу!
Шатлык гөлләре дә,
кайгы гөлләре дә
какты йөрәгемә
язган көннәремдә.
Булдым мин кай көндә
былбыл кош тоткан күк.
Көйдем мин кай төндә
сумала йоткан күк...

Бу җырлар — бәгырьнең
кылына тиюем.
Бу җырлар — гомерем,
нәфрәтем, сөюем.
Тормышны мин шулай
аңлыймын, диюем.

Менә күр, аларны
куйдым күз алдыңа.
Хуш күрсәң — рәхим ит!
Чит итсәң — кагылма...
Теләсәң, җаныңны
үлчәп бак җаныма.

Күңелгә, мөһер күк,
уелган җырлар бу!
Рәхмәтле җаннарга
сыенган җырлар бу!
Язмышлар кырыннан
җыелган җырлар бу!

## Атлар, атлар...

*Ялларыннан җил үтәр*
*Атлар атлар да китәр...*

*...Әллә иярдә туганнар*
*Җир кадерен*
*белмиләрме?*

Җир читеннән Җир читенә
томырылып чапкан атлар!
Башларны иеп, җилләрдә
тезгенне тыйган чаклар!

Атлар, атлар! Елдам атлар!
Күндәм атлар, шәп атлар!
Киңлекне дә, хөрлекне дә
каннарда тойган чаклар!

Кайда мәшрикъ? Кайда
мәгърип?
Ияр — Җирнең үзәге!
(Тик аягың Җирдә түгел,
басканың тик... өзәңге!)

Кичә далада идегез,
бүген чүлдә кешнисез!
Әллә җил кебек гамьсез сез?
Әллә чынлап көчме сез?

Тояклардан Җиргә баткан
ком да, таш та, үлән дә...
Кайсы якны «кыйбла», диде,
ияр, хуҗаң үлгәндә?

Комнар күчәр, көлләр очар...
Һәр яз шытар яшь үлән!
Нинди мәгънә дөнья буйлап
Шулай кабер чәчүдән?

Тояк эзең ярылып ята
тарихи яраларда...
Маңгайларда... Сирәк-мирәк
шәмдәй манараларда.

...Атлар, атлар! Әллә артык
кызурак очтыгызмы?
Тугач, беренче кат баскан
Җирне оныттыгызмы?

Бәлки, кирәк чак булгандыр
җайдакны егарга да!
Кызу башын җиргә бәреп,
акылын сынарга да!

...Атлар, атлар! Йөгерек атлар!
Елгыр атлар, шәп атлар!

Үтте сезнең яшәр чаклар!
Үтте безнең шәп чаклар!

Җирнең яшьлеге дә үткән
сез үткән дәвер белән.
Хәзер көч бүтән рәвештә
дәһшәткә әверелгән!

Хәзер Җирне генә түгел,
Галәмне дә бүләләр.
Хәтта океан төпләрен дә
чикләр белән теләләр...

Бүтән кавемнәр биектән —
карый Кояш йөзенә.
Сез калгансыз картлык килгән
халыкларның күзендә...

## Уйлар юлы — таңнан шәфәкъкача

Бу топольләр?

Көньяк ярлар буйлап
без кайчандыр яшәп киткәнгә
билге булган яшел шәмнәр ул!

Бу каеннар?

Идел буйларында без булганга
истәлеккә торыр ак шәмнәр!

Зәңгәр күктә йөзгән ак болытлар...
алар бит — без!

...Кемнәрнеңдер күзләренә керә кайчак,
әче төтен булып,
без яшәгән чорлар,
гасырлар...

●

Хатлар белән яшим. Гомерем минем —
конвертларда, штемпельләрдә...
Ашкынуны әйтер сүзләр көчсез
хат килерен сизгән көннәрдә!

Эшкә барам. Кичен кайтам. Ансы —
хат көткәндә үткән бер ара.
Яшәү өчен түгел, көтү өчен
туганмынмы якты дөньяга?

Ә алышмыйм барыбер язмышымны
кемнәрнеңдер «чын» яшәвенә,
яшьлек идеаллары хисабына
баеп, симереп, шәбәюенә.

Мин үземчә рухи әзерләнәм
хыялдагы чынга, олыга.
Уйныйм дөньяда — я өзелер,
я бәхетле итәр бер кылда.

## Сорады миннән төштә тоткын кош...

Бармы бер көч — канатларым очын
читлек кисәр хәнҗәр итәрлек?

Шул укмы әле күкнең зәңгәрлеге —
бөтен күзләргә дә җитәрлек?

Калдымы әле җиһан иркенлеге
Киң канатлар җәелеп китәрлек?

...Ачыйм дигәндә читлекнең биген,
уяндым да, ачылды тик керфегем.

●

*Нейтрон бомба фәкать*
*җанлыларны,*
*кешеләрне генә юк итә*

(Газеталардан.)

Каберләрнең яңа формалары —
зур калалар,
таш күперләр,
затлы йортлар,
самолетлар...

Җилләр генә өлгерә алмый
мәет исен таратырга!

## Изге тау башында исемең

Тау башында ташлар тезеп,
яздым мин исемеңне.
Бу изге тауга [1] менәсе
һәр кеше белсен дидем.

Кошлар күреп укысыннар,
алар Күк телен белә!
Җилләр килеп сыйпап үтсен
минем наз белән генә!

Көмеш чыклар кунсын аңа,
шатлык яшьләре булып.
Яшен-таш төшсә дә ярый,
яшьлек яшьнәве булып.

Кар бөртекләре сарылсын,
яңгыр толымы төшсен...
Яннарында чирәм шытсын,
хуш-исле гөлләр үссен.

...Изге тауда — ап-ак ташлар.
Ташларда — синең исем.
Кем өчендер гади исем,
ә миңа — изге исем!

[1] Изге тау — Кырымның Карадаг тавы түбәсе исеме.

## Алтын капка

*— Син «Алтын капка»ны йөзеп чыкканда нинди теләк әйттең?*
*— Алдагы гомердә бөтен капкаларны да икәү бергә үтсәк икән, дидем. Ә син?*

*— Әйтмим...*

Мин тартмадым аңа киндер.
Якмадым буяулар да.
Ә сурәтеңне ясадым
«Алтын капка»[1]лы ярга!

Акчарлакның канатлары
минем пумалам иде!
Ә төсләрне — дулкыннардан,
кояштан алган идем!

Шундый сурәт килеп чыкты —
үзең белмисең генә!
...Җиллрдән көнләп, тиз генә
күчердем күңелемә.

Ул сурәт калды анда да,
нурлы итеп кара гына!
Тик күрә алыр шул аны —
сөюдә янган гына.

## Өчәү

Йоклый алмыйм. Беләм: тагын кемдер уяу.
«Тота» мине үз дулкынында.
Әсир итеп тота. Ычкындырмый. Әйтерсең лә —
мин бер хәнҗәр аның кынында.

Кем ул? Онытылган ярмы? Бер көндәшме?
Үч итепме, сөепме саклый?
Нинди язмыш белән, нинди ният корып,
газапланып мине газаплый?

Йоклый алмыйм. Гипноз? Телепатиями?
Әйтә алмыйм шул анык берни дә.
Беләм шунсын:
мин яраткан кешем бу сәгатьтә
башын салып йоклый чит иңдә...

## Идел буе. Иртә яз.

Ярым корган алмагачын
бер карт йөри акшарлап.

....Калын дулкыннар өстендә
оча ябык акчарлак.

●

Нурлы булсын диеп барган юллар,
көмеш койдым каеш йөгәнгә.
...Йөзләрегез караңгыланмасын
без ду килеп, җилдәй йөргәнгә!

---

[1] Алтын капка — Кырым яры буенда мәшһүр кыя исеме.

Гомер бакый Яхшы белән Яман
якалашкан, канда буталган...
Тарих — сәер: хәтерендә рәттән —
изге җан да, зина кылган да.
Алып бабай өйгән курганнар да,
Герострат яккан храм да,
Клеопатра патша-бикәнең
күкрәген чаккан елан да.

## Бер кичтә

Хаста җан иң соңгы кат керфек какты.
Кактус гөле беренче кат чәчәк атты.
Берәүнең газизе чит илдә ятты.
Күк, ярсып-ярсып, йолдызларын атты.

## Өметсез уйга ышаныч сүзе

Ярлар җимерелә. Илләр какшый...
Ирләр хәлсезләнә... Су кибә...

Тимә!
Алай димә!

Әнә җиргә дәртле яз килә!
Гашыйк җанга күпме наз килә!
Күккә баккан сабый күзләрдән
нурлар сибеп Ай-Кояш көлә!

...Бәлки, туфан калкыр, илләр үрчер...
Кирәк булса, таулар өярләр...
Кояш барда — адәм заты калыр,
сау балалар уйнар чирәмдә!

## Язмыш

Башта ирен
шахта баскан.

Аннан үзен
лашманлыкта
агач баскан.

Туганнарын
гамь баскан.

...Кое төбендә
көмеш беләзек!
Ләм баскан.

## Төнге бер уй

Үрмәләүләр — бәлки, төшүләрдер?
Егылулар — бәлки, менүдер?..

Тыныч халәтләргә кайтыр юлны
якынайтып йолдыз җемелди.

## Утыз ел үткәч кайту

Авылдагы бөтен этләр дәррәү килеп аваз салды.
Адәмнәрдән ник бер таныш йөз күренсен!
Ник берәве хет баш кагып сәлам бирсен!..

Ата-баба нигезендә, әрем баскан түмгәкләрдә
утырды тезен кочаклап, үпкәләгән бала кебек.
Кояш та югалды шәфәкъта...

Аяк тавышлары тынгач зиратка барып килде.
Аннары тагын кайтты да чалкан ятты нигез ташына.
Ярый ай бар!

Таллар артында әвәлгечә чишмә чылтырый.
Күз яшьләре тавышсыз ургыла.
Җирдә түгел, күңелдә бит ул дәрья!
Авазлары гына чишмәдә!..

...Авылда көтү куганда олы юлда иде инде ул.

●

Үлән-яфракларга төшкән чыктан күбрәк хәзер
адәмнәрдә — алтын бөртек, җәүһәр, асыл ташлар...
Мал җанлылар Җирдә арткан саен Рух саега,
кадерсезрәк була бара асыл башлар.

## Ялгыз халәт

Күктә күренеп алды сөйгәнемнең зәңгәр яулыгы!
Язгы җилдән килеп китте җиләк исе!
...Үзләренә бакмасам да, шәүләләреннән күренә
яшь җаннарның наз теләгән дәртле көче.

●

Элек әйттем: «Нигә, дидем,
баштә сине күрмәдем...»

Аннанниләр күрмәдем!

Бу дөньяда күпне белдем,
кадереңне белмәдем!

# Роберт Әхмәтҗанов

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

Вельможалар...
Алар
җырлап-көлеп уздылар
фаэтоннарда!

Ә Тукай калды...
Калды... халыкта.

### Сәфәр алдыннан

*Х. Туфанга*

Офыклар артында ни көтә?
Алсу таң, яланнар җил көтә.
Офыкка чакыра сәфәрләр,
йөрәкне сәйярлек җилкетә.

Юл көтә тулпары, баш иеп,
гүя ул тынлыкны тарсына...
Күк һәм җир тоташкан чикләрдән
китәләр тын утлар каршына.

Үпкәле оланнар тирәндә:
безне, ди, аз гына көтмәде.
Ашыкма, күреп кит безне дә,—
яшь моңнар өлгереп җитмәде.

...Сөйләшеп туймадык таңгача —
төн түгел, еллар да җитмәде.
Кумачы, шагыйрем, тулпарың,—
әйтәсе сүзләрем бетмәде...

### Заман

Ашыгам. Уйлыйм. Җитми һаман
вакыт. «Сәгать ничә?»

Гаҗәпләнмәс тик беркем дә
әйтсәң хәтта: «Үткән төндә
йолдыз яуган!» дисәң.
Тау белән таулар кавыша,
сулар үргә ага...
Заман, синең төсең!

●

Барган саен Тормыш офыгына,
якты мәгънә белән балкый юл чатлары.
Юл өстендә атылып-балкып яна
яшәүнең кабатланмас бөек учаклары!

## Кечкенә кешеләр йорты

Җыелалар
бар да кечкенәләр бу йортка.
Табалар да югалталар,
зурлык даулашалар
тормыштан.

Чыга хөкем!..

— Без — дәүләр! — дип үз-үзләрен юаталар,
зур сүз чыгаралар.
Һәм... яңадан
кечерәеп торалар...
Кала төтен.

## Вәгъдә

«Онытма!» дип әйткән ерак тавышы
еллар арасыннан ишетелде.
Әле дә ул бүген бурап яуган
карлар арасында шикелле.

Күк астына китеп адашкан да
җиргә кайта янә кайтаваз.
Җир үз итми аны, күк ят итә
(җиргә, күккә инде ят аваз!).

...Килде сөю. Булды яратулар,
бүтән ярлар керде йөрәккә...
«Онытма!» дип миңа кычкырганы
онытты мине... Еракта...

Ничә язлар килде, алма карлар
бурап яуды — инде эзе юк.
«О-ныт-ма!» дип әйткән сүзе һаман
офыкларда йөри...
Үзе — юк!

# ФРАГМЕНТЛАР

●

Чәч дулкынын салып иңнәренә,
бер кыз килә, яланаяк.
Көн-диңгездә
күзкәйләре — зәңгәр маяк!

●

Байраклар ышыгында кала алмый
чын сугышчы даны.
Дан — ныгытма гына түгел,
«Ура!» кычкырып кына
алып булмый аны!

●

...Кызган тимер көпшәләрдән
сугышның соңгы төтене
киткәч ай артына,
Илнең буеннан-буена
ишетелде толлар елавы!

●

Дау кырында
кеше булып ауды.
Күтәрелде
һәйкәл булып
мәйданнарда!

●

Гөлләр буенча кардәш без,
йолдызлар аша туган!

●

Кәбестәдәй,
сиздермичә генә
йомыла гомер,
катлаулана...
Сизелмичә кала аның эчендә
ялкау көннәр — күбәләкләр.

●

Балачагым.
Шәфәкъ елгасыннан

кызыл атлар
сузылып
су эчә...

●

Булыр микән әллә котылып —
бөек исемнәргә җыр багышлап,
бөек исемнәргә тотынып?..

Күңелем шундый аязды —
офыгында
бөтен хыялларым күренде!
Яктырды үтәдән-үтә...

●

Кемнең туган сәгате бу?
Шундый тынлык дөньяда!
Ишетәсезме —.
су ышкыла тын ярга,
җил селкенә кыйблада?..

## Иҗатка мәдхия

Син — минем күңел байрагым,
булганым, булачагым.
Син — яз һәм кыш, рәхмәт-каргыш,
яшьлегем, балачагым!

Үткәннәрем, киләчәгем,
рәшәле офыкларым,
нурлы төнем, кара көнем,
кояшлы болытларым;

гомер буе җыйган малым,
аласым-бирәчәгем,
жир җәннәтем, кыяметем,
күрәсе күрәчәгем;

ашыйсы аш, яшисе яшь,
сызылган ызаннарым,
ярыласы яфракларым,
тузасы тузаннарым;

куанасы куанычым,
юаныч, күз яшьләрем,
сөйгән ярым, көндәшләрем,
каләмдәш, илдәшләрем;

абынасы ялгышларым,
таянасы тауларым;
и хыялый язмышларым,
танып көткән таңнарым...

Афзал Шамов

# КИРЕ БЕТКӘН КЫЗ

ХӘРБИ КОРРЕСПОНДЕНТ ЯЗМАСЫ



Газетабызга материаллар җыю өчен фронтның алгы кырыена чыгып китәргә торганда, редактор мине янәдан үз янына чакырып алды да өстәмә эш бирде:

— Менә нәрсә, бая әйтергә онытканмын,— диде ул миңа, язу өстәле янында утырган килеш кенә.— Ай ахырындагы саннарның берсен икенче эшелонга багышлап чыгарабыз. Шуңа кер юучы кызлар турында репортаж кирәк булыр. Татар кызларын очратмассыңмы?

— Кайда соң андый кызлар?

— Икенче эшелонда.

Моны ишетеп, бераз гаҗәпкә калдым. Фронтта никадәр йөреп, ничә итек туздырып, бу турыда уйлаганым юк иде, ничектер, башыма да килмәгән иде. Җитмәсә, татар кызлары! Татар кызларын күрмәгәнгә, аларның нурлы йөзләренә карамаганга ике елдан артык инде.

Гаҗәпләнүем йөземә чыкты булса кирәк. Редактор, әллә моны сизеп, әллә эндәшми торуымны үзенчә аңлап:

— Я, нигә тынып калдың? — дип сорады.— Әллә кызлар янына барасың килмиме?

Яшермим, барасым килә, тик андый урынга ашык-пошык барырга теләми идем. Ни әйтсәң дә, моңа вакыт кирәк. Миңа нибары өч көн бирелгән. Шул өч көн эчендә мин яңа гына батырлык күрсәткән татар сугышчыларын эзләп табарга, алар белән сөйләшергә, алар турында материаллар тупларга тиеш. Ә хәзерге шартларда аны үтәү ансат түгел. Чөнки фронтыбыз ике айдан бирле оборонада тора, утны-давылны кичкән солдатлар теле белән әйткәндә, алгы кырыйда «тынычлык» хөкем сөрә. Алдан ук сизеп торам: итек табаннарын шактый туздырырга, төн йокламаска, окоптан-окопка йөрергә, шуышып барырга, борын белән җир сөрергә туры киләчәк. Җитмәсә, икенче эшелонга да сугылырга кирәк. Юк, вакытым җитмәячәк. Шуңа күрә мин редактордан командировкам срогын тагын ике көнгә арттыруны үтендем.

— Юк,— диде ул, кырт кисеп,— арттыра алмыйм. Редакциянең хәлен беләсең...

Мондый җавапны көтмәгән идем.

Редакторым сүзен дәвам итте:

— Икенче эшелон вакытыңны әллә ни күп алмас. Анда дошманнан яшеренеп, посып йөрисе юк. Эшеңне тиз генә бетерерсең дә чыгып китәрсең...

Моны үзем дә беләм, шулай да вакыт җитмәячәк. Өч тәүлек бик аз.

Армиядә начальник белән бәхәсләшергә ярамавын, бигрәк тә безнең бу озын буйлы, шактый кырыс табигатьле майор белән бәхәсләшү мөмкин түгеллеген истә тотып, репортажның күләмен ачыклау белән генә чикләнергә кирәк таптым:

— Ничә юллык?

— Йөз илледән артмасын.

Сүз шуның белән бетте. Мин ут яуса да, таш яуса да, редакция заданиесен үтәргә ниятләнеп, фронтның алгы кырыена таба юл тоттым.

Майор сүзендә дә хаклык бар. Редакциянең хәле турында дөрес әйтә ул: кешеләребез җитми. Соңгы көннәрдә бер иптәшебез алгы кырыйга киткән җирдән кире кайтмады — яраланды. Бер кеше болай әллә ни күп түгел — бер генә. Әмма редакциядә, редакторны да кертеп санаганда, өч кенә кешенең эшләвен исәпкә алсаң, берәвебезнең яралануы сугышчан составыбызның өчтән берен югалту дигән сүз. Аз түгел. Әгәр редакторыбызның алгы кырыйга барып йөрмәвен, оператив хәбәрләр, мәкаләләр язмавын, бары редакцияләү, газетаның макетын әзерләү белән генә шөгыльләнүен истә тотсак, ул чакта редакция хезмәткәрләренең яртысы, ягъни илле проценты югалды дигән сүз. Бу инде зур югалту!

Яралы иптәшебез хәзер сул кулы белән тырнаштыргалап, госпитальдән хатлар яза, озакламыйча кайтам, ди, безне тынычландыра. Ләкин хатына, җөмлә төзелешенә, бигрәк тә почеркына караганда, тиз кайтмас кебек. Каты яраланган булса кирәк, яшерә шикелле. Кулы гына яраландымы икән? Ачык белмибез. Ә янына барып, хәлен белешергә мөмкинлегебез юк, ерак тылга, Идел буендагы шәһәрләрнең берсенә җибәреп өлгергәннәр.

Моңа чаклы журналистның каләм тота торган уң кулы турында уйлаганым юк иде. Бик кирәк икән кул аңа, теләсә кайсы сугышчыга кирәк чаклы кирәк икән.

Таза, сәламәт аяклар да бик кирәк аңа. Ул, автомат тотып, сугышчылар белән бергә һөҗүмгә бармаса да, аларны куып җитәргә, аларның батырлыкларын үз күзе белән күрергә, алар белән сөйләшергә, алар турында язар өчен илһам алырга кирәк аңа. Илһамсыз хәбәр — җансыз хәбәр.

Сәфәрем әллә ни авыр булмады, хәтта җиңел булды диярлек. Бер урында да үтә алмаслык киртәләргә очрамадым, гадәттәгечә, ятып янсә шыкланып, дошман утының басылганын көтеп торырга, барасы җиргә бара алмыйча, төнне көтәргә туры килмәде, чөнки ике якның да тыныч чагы иде.

Тыныч чак?.. Тынычлык бармы соң монда? Ике яктан да атышлар, көч сынаулар, бер-берләренең ут позицияләрен капшап караулар өзлексез дәвам итә. Кайчак артиллерия дуэльләре булып ала, дөнья үкерә, шаулый, җир актарыла, тузан куба, ыңгыраша, калтырый...

Дошман снайперлары бик актив. Окоплардагы, күз күреме хәтле җирдәге бөтен хәрәкәтебезне өзлексез күзәтеп торалар. Берәр җирдә кешеме, кешегә охшаган берәр нәрсәме янсә пилоткамы күренде исә шундук ут ачалар. Кайчак бу атышларга пулеметлар да, минометлар да, артиллерия дә кушыла, берникадәр вакыт әйләнә-тирә ут чәчеп, үлем сорап, шаулап, гөрләп ала, җир үкерә, җир елый, һаваны әчы төтен, тузан каплый. Аннары атышлар әкренләп тына, тузан басыла, дөньяда бары винтовка, автомат, пулемет тавышлары гына кала...

Хәер, безнең снайперлар да тик ятмый. Алар да яшеренгән урыннарыннан фрицларны күзәтәләр, һәр көнне берничәсен тончыктыра торалар.

Бу юлы миңа, барыннан да бигрәк, дошман снайперларыннан сакланырга туры килде. Кайсы подразделениегә барсам да, моны исемә

төшереп тордылар. Командованиегә рәхмәт, снайпер пулялары очып җитәрлек җиргә юл күрсәтүчесез бер адым да атлатмады. Шулай да бер урында, окопларга барганда, йөгереп узасы бер ачыклыкны үтә алмыйча, казылып бетмәгән траншеяда сәгатьтән артык ышыкланып яттык. Юл күрсәтүчем, гәрчә офицер булмаса да, борынгыдан килгән хәрби традиция буенча элемтәче офицер дип аталган ефрейтор, башындагы пилоткасын, автоматына элеп, траншеядан икс тапкыр чак кына күтәреп караган иде, икесендә дә шундук баш очыбыздан фашист пулялары сызгырып узды.

Юл күрсәтүче егет тишелгән пилоткасын кызганып караштыргалап торганнан соң:

— Я нишлибез, иптәш капитан?— дип сорады.— Маңгаебызга да берәр тишек ясатабызмы, әллә караңгы төшкәнне көтәбезме?

— Караңгыны көтмисе иде,— дидем мин.— Эшем бик ашыгыч.

Җил-давыл белән ярылып, киселеп беткән йөзле, җиңел аяклы бу егет тәҗрибәле сугышчылардан иде булса кирәк. Акыллы соргылт күзләре белән миңа бераз карап торды да сабыр гына әйтте:

— Ашыкмыйк, иптәш капитан. Бик нәләт урын бу. Кайчан моннан эт тә йөгереп үтә алмый. Аннары шуны да исегездә тотыгыз: миңа сезне исән-сау алып кайтырга кушылган. Приказ шундый.

Мин аның сүзе белән килешмичә булдыра алмадым. Шулай да:

— Башка юл юкмы?— дип сорадым.

— Бар. Тик бик әйләнгеч.

Борынгылар белеп әйткәннәр: «Урау булса да, юл яхшы»,— дигәннәр. Без, бабаларыбызның акыллы киңәшен тотып, әйләнеч юлдан баруны яхшырак санадык.

Өченче көн дигәндә блокнотыма күп кенә материаллар, хәрби эпизодлар язмасы теркәлде. Ким дигәндә, газетага алты-җиде хәбәр белән бер очерк язарга җитәрлек иде.

Икенче эшелонга кайтырга уналты сәгать вакытым калды. Әгәр бишесен йокыга, ялга билгеләсәң, тугыз сәгать кала дигән сүз. Юлга ике-өч сәгать чамасы кирәк. Калганы — икенче эшелонга. Җитәр шикелле. Хәер, нигә җитмәсен. Алгы кырый түгел, икенче эшелон. Тыныч җир.

Шундый уйлар белән мин кер юучы кызлар отрядын эзләргә карештем. Кайда соң ул? Урман арасындамы, әллә якын тылдагы берәр авылдамы?..

Батальон штабында аның кайда икәнен әйтә алмадылар. Кайберәүләр хәтта аның барлыгын да белмиләр иде кебек. Шулай идеме икән? Ничектер ышанып җитә алмыйм. Кем белә аларны, бәлки, алар кызларны явыз күзләрдән саклый торганнардыр. Шулай булуы да мөмкин.

Ахырда полк штабына керергә, алардан белешергә туры килде. Полк командирының политик эшләр буенча урынбасары, утыз-утыз бишләр тирәсендә генә булуына карамастан, сакал-мыек үстереп җибәргән, шуның аркасында шактый өлкән яшьтә булып күренгән майор да отрядның кайда икәнен белми иде. Шулай да ул анда бару өчен бик сәер бер шартны исемә төшерде. Отрядка эш белән килгән һәр кеше, дивизиянең медицина эшләре бүлегенә барып, подполковник Орловтан рөхсәт алырга тиеш икән. Мин, моңа бик гаҗәпләнеп:

— Нигә аңардан рөхсәт алырга? — дип сорамыйча булдыра алмадым.

— Командованиенең приказы шундый,— диде ул миңа.

— Сәбәбе?

— Сәбәбе ачык: андый-мондый кешеләрнең ул тирәдә айкалып йөрмәүләре яхшырак. Нәрсә кирәк аларга анда? Ниләре калган?

Кемгә әйтә ул моны? Миңамы? Әллә болай гына, уйламыйча гына

теленнән ычкындымы? Кемнәр соң алар «андый-мондый кешеләр»? Мине дә шундыйлар исәбенә кертәме әллә бу?

Аның уйламый әйтелгән сүзе кәефемне шактый бозса да, мин аңа үземнең «андый-мондый кеше» түгеллегемне исбат итеп тормадым. Эшем ашыгыч, һәр минутым кадерле. Редакциягә тизрәк кайтырга, чираттагы санга материаллар әзерләргә кирәк. Шуңа күрә мин, бу сәер приказ турындагы сөйләшүне кирәксез санап, подполковник Орловка ничек шалтыратырга икәнен генә сорадым. Ниятем, аның белән тиз генә сөйләшеп, хәзер үк отрядка китү иде.

— Моны телефоннан гына хәл итә алмассыз,— дип җавап бирде миңа замполит.— Подполковникның үз янына барырга туры килер сезгә. Шуны таләп итә ул... Бик пунктуаль кеше.

— Еракмы соң ул?

— Урынын ачык әйтә алмыйм. Дивизия штабы тирәсендә булса кирәк.

Шактый ерак иде бу.

— Туктагыз әле, үзегез уйлап карагыз, шундый кечкенә бер эш белән нигә аның янына барырга?!— дидем мин, ачынып. Күңелемдә ачыну гына түгел, кәефем кырылу нәтиҗәсендә туган һәм көчәйгәннән-көчәя барган, ихтыярыма буйсынырга теләми торган ниндидер бер билгесез хис тә бар иде. Шул хискә буйсынып, сүземне дәвам иттердем.— Кирәкмәгәнгә вакыт әрәм итү бит бу! Каян уйлап тапканнар шундый мәгънәсез приказны!..

Тонымның үзгәрүен, бигрәк тә соңгы сүземнең урынсызлыгын үзем дә сиздем. Майор хәл итми бит моны. Ул миңа бары ярдәм итәргә, отрядка ничек барырга икәнен аңлатырга гына тели.

— Командование приказын тикшерү безнең функциягә керми шикелле, иптәш капитан,— диде майор миңа беркадәр коры тавыш белән.— Без аны бары үтәргә генә тиешбез. Моны аңлый торгансыздыр дип уйлыйм.

Аңлый идем, билгеле. Сүземнең хаталыгын танырга мәҗбүр булдым. Нишлим, вакыт җитмәү бәласе.

Майорның корылыгы кими төште. Ул миңа, мыек астыннан елмаеп, сәер генә карап алды да:

— Үзегез беләсез, бу эш минем карамакта түгел,— дип өстәде.— Минем карамакта булса, мин сезне кызлар янына берсүзсез җибәрер идем.

Нигә кызлар янына, нигә отрядка түгел? Ни сөйли бу сакалбай? Кем дип белә ул мине?.. Кызлар!.. Ышаныгыз, бу минутта күңелемдә кызлар түгел, ә йөз илле юллык репортаж гына. Бары шул гына!

Мин, штаб начальнигы землянкасына кереп подполковник Орловка шалтырату теләге белән, майор яныннан чыгып киттем.

Сәгатемә күз төшереп алдым. Я хода, вакыт ничек тиз уза! Минем карамакта бары унбиш сәгать вакыт. Җитмәсә, язгы кояш төнге бишегенә таба тәгәрәп бара. Ничек тә бүген, отрядка барып, күрәсе кешеләрне күреп, эшемне тәмамларга да иртәгә иртә белән редакциядә булырга кирәк.

Алай да болай уйлана-уйлана, атышларга колак салгалап, мин полк штабы землянкасына таба баруымда дәвам иттем.

Алгы кырыйда — тынычлык. Автомат, винтовка, пулемет тавышлары гына ишетелә. Кай минутларда гына аерым минометлар, туплар, үзләренең дөньяда барлыкларын белдереп, ачуланып, үкергәләп алалар...

Алгы кырый сыртның теге ягында булганга, монда дошман пуляларыннан курыкмыйча, башыңны урынлы-урынсыз имичә, ышыкланмыйча йөрергә мөмкин. Пулялар килеп җитми. Тик ара-тирә артиллерия налетлары гына булгалап ала. Алар кинәт башланалар да кинәт бетә-

ләр. Аңа, ничектер, улчаклы игътибар итмиләр. Ни әйтсәң дә сукыр ату.

Солдатлар очрый, офицерлар күренә. Барысы да үз эшләре белән мәшгуль, каядыр баралар, ашыгалар, йөгерәләр. Яшь, таза, чибәр егетләр. Ничек инде алар кызлар отрядының кайда икәнен белмиләр икән?

Әнә, очкандай җиңел атлап берсе килә. Егерме яшьләр тирәсендәге яшь, зифа буйлы егет. Кулында автомат, билендә ике граната, сырлап, бизәкләп эшләнгән ак сөяк саплы хәнҗәр,— бусы трофей булса кирәк. Кыңгыр салган пилоткасы астыннан сап-сары чәче бөдрәләнеп, калкып чыгып тора. Кем ул? Разведчикмы, автоматчымы, әллә берәр командирның бөтен эшне белә, булдыра ала торган чая орденарецымы? Була шундый орденарецлар,— полктагы яисә батальондагы вакыйгаларны, яңалыкларны, командирларның бер-берләренә булган мөнәсәбәтләрен, эч серләрен, күңел кичерешләрен, частьтагы үзгәрешләрне, булганнарын, хәтта булачакларын да кайбер офицерларга караганда алданрак белеп, сизеп торалар.

Бу җиңел гәүдәле егет кызлар отрядының кайда икәнен тәгаен белә торгандыр,—белмәве мөмкин түгел. Туктатам. Кер юучы кызларның кайда икәнен сорыйм. Егет, сабагын яхшы белгән, соравымны күптән көткән яхшы укучы малай сыман, сулуын да алмыйча:

— Урманда, күл буенда,— дип чатнатып җавап бирде, хәтта көнчыгышка таба борылып, урманның кай тирәсендә икәнен дә аңлатты.— Әнә, теге юлны күрәсезме?

— Кайсы?

Еракта күкселләнеп торган урманга таба юнәлгән юллар күп иде.

— Әнә теге, аерым үсеп торган каеннар яныннан уза торганы?

— Юлын күрмим, ә каеннарын күрәм.

Артиллерия уты белән теткәләнгән, сынган, гарипләнгән, әмма шулай да дошманга бирешергә теләмәгән батыр солдатлардай үрә басып калган бер төркем ак каеннар ачык күренә иде. Без басып торган җирдән әллә ни ерак түгел.

— Менә шул юл белән китеп, туп-туры барыгыз,— диде егетем, сүзен тәмамлап.— Чирек сәгать дигәндә күл буенда булырсыз. Отряд шунда.

— Барганың бармы әллә?

Солдат кулын гына селтәде:

— Кызлар кайгысы түгел әле монда.

Бу аның рияланугы түгел, ә чын күңелдән әйтүе иде.

Сары бөдрә чәчле егет яныма ничек килеп туктаган булса, шундый ук җиңел-җитез адымнар белән китеп тә барды.

«Миңа инде подполковник Орловка шалтыратуның кирәге юк», дип уйладым үземчә. Йөри-йөри шактый тузган, үкчәләренә генә түгел, табаннарына да ремонт кирәкле армас-талмас кирза итекләрдән урманга таба атлыйм...

Көн эссе дә, салкын да түгел,— җәяүлегә җан рәхәте. Шинелем беләктә, капчыгым аркада, пистолетым билемдә, сумкамда блокнотым белән бергә һәрвакыт йөртә торган бер граната,— барлык йөгем шул. Хәзер барып җитәрмен дә, кирәкле мәгълүматларны туплап, таң белән үк чыгып китәрмен. Йөз илле юллык репортаж күпмени ул? Кулдан язганда биш бит, машинкада ике бит ярым... Тик татар кызлары гына туры килсен иде...

Шундый матур хыяллар белән каеннар янына барып җиттем, танклар, автомашиналар казып, изеп бетергән юл буйлап сазлы-мүкле урманга барып кердем. Йөземә салкын, дымлы һава килеп бәрелде, саз исе, мүк исе, тагын ниндидер бер ис, яңа гына ярып килгән яфрак

исеме, эллэ кайры исеме,— барысы бергэ кушылып, көчлерэк сизелэ башлады.

Урман эченэ барып кергэч, элеге бөдрэ чэчле егетнең кызлар отрядында булмавына да ышанарак төштем, чөнки ул эйткэн туры юл юк иде монда. Юллар, сукмаклар аралашып, чэбэлэнеп беткэннэр. Сугыш юллары, сугыш сукмаклары иде алар. Шундый сукмаклар, юллар белэн шактый адашып йөргэннэн соң, ниһаять, күл буена барып чыктым. Бик арган идем — аркамдагы капчык та, билэгемдэге шинель дэ авырайды, ял итэсем, хэл җыясым килэ иде. Шуңа күрэ кичке кояш нурлары белэн ялтырап яткан озынча күлне, күл кырые буйлап тезелеп киткэн төтенле, парлы кер казаннарын, алар тирэсендэ кайнашкан кызларны, агачтан агачка сузылган җеплэргэ элемгэн керлэрне күргэч, шөкер, килеп җиттем, максатыма ирештем дип, иркенлэп сулап куйдым.

Хэер, иртэрэк шатланганмын, күрэселэрем бетмэгэн икэн эле.

Сирэклэнгэннэн-сирэклэнэ барган мэһабэт наратлар арасыннан сузылган баткак юл кырыеннан сакланып кына атлап, күл буена якынлашырга да өлгермэдем, кулына штыксыз винтовка тоткан бер карт солдат, куаклар арасыннан килеп чыкты да, гыжлап тавыш белэн:

— Стой! — дип кычкырды.— Кая барасыз?

Аның кинэт каршымда пэйда булуына гаҗэплэнеп, бераз аптырап калдым. Туктадым.

Солдат, аксый-аксый атлап, ашыкмыйча гына яныма килде дэ соравын кабатлады.

— Сезгэ, кунакка,— дип җавап бирдем мин аңа.

Кинаялэп эйткэн сүземне чын мэгънэсендэ аңлады булса кирэк, йөзе сизелерлек кырысланды:

— Ничек кунакка... Кемгэ? Кайсы кызга?

Сүземне төзэтеп эйтергэ мэҗбүр булдым:

— Гафу итегез, кунакка түгел, э командировкага килүем. Газета редакциясеннэн мин... Эш белэн.— Документымны чыгардым.

Солдат аны, караштыргалаган сыман, кире башы белэн тотып, кулында бераз эвэлэп торды да кире кайтарды. Тик шуннан соң гына тавышы тынычлана төште:

— Кем кирэк сезгэ?

— Командирыгыз кирэк. Кайда ул?

Карт солдат, бу чакырылмаган кунак белэн нишлэргэ икэн дигэндэй, уйланып торганнан соң, ни булса шул булыр дигэн бер кыяфэт белэн мине күл буена таба ияртеп алып китте.

Камышлы күл буе җанлы, хэрэкэтле иде. Казаннардан, тагараклардан пар күтэрелэ, яңа гына яфрак яра башлаган таллар исе, күл исе белэн аралашып, сабын исе, сода исе, төтен исе аңкый. Кер юучы кызларның бер-берлэренэ кычкырып эндэшүлэре, аерым сүзлэре, чэр-чүлэре ишетелэ. Берсе экрен генэ, ишетелер-ишетелмэс кенэ җырлый шикелле. Бэлки, җырламый да торгандыр, миңа гына шулай тоеладыр...

Кызларның кайберлэре безне күргэч эшлэреннэн туктап, сабынлы, содалы тагараклары өстеннэн башларын күтэреп, кызыксынып караштыргалап алалар, аннары яңадан эшлэренэ тотыналар. Җиңнэрен иң башларына хэтле сызганып җибэргэн яшькэ эчке күлмэктэн генэ калган, клеенка алъяпкычлы, күн итекле, язгы кояштан каралган йөзле, каралган тэнле яшь кызлар иде болар. Тик өзлексез кер юганга кул- лары белэн белэклэре генэ ак иде аларның. Барысы да диярлек чэчлэрен, сабын-сода күбеклэреннэн сакларга телэп, ак яулык белэнме, сөлге белэнме, матур итеп урап, бэйлэп куйганнар һэм бу аларны тагын да матурлый, бизи, сылуландыра иде.

Солдат мине кызлар янына түгел, э бер читкэ, наратлар арасында

калкып торган землянкага таба нартеп китте. Өстенә ул шактый дөнья күргән хәрби сырма кигән, аны ремень белән нык тырышып буган, кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге, урта буйлы, ямьшәйгән пилоткалы инвалид иде. Сугышларда шактый йөргән булса кирәк — сул кулының ике бармагы юк, уң аягы бераз аксый, тавышы да гыжлый. Әллә салкын тигән, әллә сулыш юллары яраланган.

Мондый карт солдатларны яратам мин. Алар белән бөтен хәрби субординацияләрне, офицер белән рядовой арасындагы тәкәллефләрне бер читкә куеп, тыныч заманнарча гади итеп, күптәнге танышыңны очраткандай рәхәтләнеп, җәелеп сөйләшәсем килә минем. Шундый гади мөнәсәбәтеңне күргәч, синең эчкерсез икәнеңә ышангач, аларның кайберләре сиңа йөрәкләрен ачып салалар, тормыш тәҗрибәләренең байлыгы, дөньяга карашларының киңлеге, ил алдында, халык алдында торган катлаулы мәсьәләләрне аңлый белүләре, рухи көчләре белән сине таңга калдыралар. Бу юлы да мин, шундый кызыклы кешегә тап булдым ахры дип уйлап, аның телен ачу максаты белән отрядка кагылышлы бер-ике сорау бирдем, ләкин аңардан рәсми коры җаваптан башка бер сүз дә ишетмәдем. Хәрби устав рамкаларыннан бер дә читкә чыкмый торган аз сүзле солдат булды, ахры.

Берничә минуттан инде мин түбәсе калын итеп ылыслар белән капланган землянка янында, уртача буйлы, какча гәүдәле бер медицина лейтенанты каршында басып тора идем. Кер юучы кызлар кебек яшь түгел иде ул. Күз төпләре җыерчыкланган, язгы җилләр, кояш нурлары белән киселгән, каралган яңаклары да яшьлек нурын югалткан. Буесыны да, төсе-бите дә әллә ни күңел җәлеп итәрлек түгел. Лейтенант Павлова дип таныштырды ул үзен. Документымны кулында тоткан килеш миңа очлы күзләрен текәп карады да:

— Ә подполковник Орлов запискасы?— дип сорады.

Мин акланырга, подполковник янына бара алмавымның сәбәбен аңлатып бирергә мәҗбүр булдым, командировкам кәгазен дә күрсәттем, редакциягә кайтып житү өчен унөч сәгать кенә вакытым калганын әйттем. Сүзләрем дә, документларым да лейтенантка тәэсир итмәде шикелле,— керфеген дә какмады, хәтта йөзе дә үзгәрмәде. Шулай да, хәрби субординацияне саклап, ягымлы гына җавап бирде:

— Беләм, иптәш капитан, редакциядән икәнегезне дә беләм. Сезгә һәркайда да ишекләр ачык икәнен дә аңлыйм. Шулай да минем өчен командование приказы — закон,— диде.— Җитмәсә, сез тагы төнгә каршы килгәнсез. Иртә белән килгән булсагыз, бер хәер иде, кирәкле мәгълүматларны туплар идегез дә китәр идегез.

— Хәзер нишләргә соң миңа, иптәш лейтенант?— дидем мин, бераз аптырап.— Күрәсең, караңгы төшеп килә. Барыр җирем дә, кунар урыным да юк... Бик ардым, талчыктым. Иртәдән бирле аяк өстендә...

Аның белән бәхәсләшергә, сүзгә килешергә теләми идем, йомшаклык белән алдырып булмасмы дип өметләнә күңел. Шуңа күрә бик үтенгән төс белән:

— Бәлки, иптәш лейтенант, сез миңа бу дядька янында кунарга рөхсәт итәрсез,— дидем һәм бездән бер читтә тын гына басып торган әлеге аксак солдатка башым белән ишарә иттем.

Лейтенанттан барыбер мәрхәмәтле сүз ишетелмәде:

— Юк,— диде ул,— аның янында калырга да рөхсәт итә алмыйм. Аңлагыз, иптәш капитан, подполковниктан выговор аласым килми.

Мин инде подполковникны, аның мәгънәсез приказын сүгеп ташлау гына түгел, бу приказның мәгънәсезлеген аңламаган лейтенантның үзенә дә бер-ике каты сүз әйтеп ташларга әзер идем. Әле яхшы бу ах-

маклыкны эшләмәдем, үземне тыеп калдым. Тонымны мөмкин чаклы үзгәртмәскә тырышып, сорадым:

— Якын тирәдә кайда кунарга мөмкин булыр икән? Полкка китсәм, ерак. Вакыт әрәм.

— Нигә полкка барып йөрергә,— диде кызый.— Моннан ике-өч километр ераклыкта, урман арасында бер авыл кисәге бар. Сумово дип атала. Хәер, авыллыгы калмаган инде аның. Немецлар яндырып киткәннәр. Шулай да ике йорт сыман нәрсә бар әле. Шуларның берсендә бер карт белән карчык тора. Бик ачык йөзле кешеләр... Сезне рәхәтләнеп, хәтта шатланып кундырып чыгарырлар. Ә иртәгә иртә белән килегез, рәхим итегез. Алдынгы кызларны күрсәтермен. Сөйләшерсез. Кирәк булса, үзем дә кайбер нәрсәләрне ачыклашырмын...

Мин аңа бу киңәшләре өчен рәхмәт әйтергә дә, әйтмәскә дә белмичә, уйланып торганда, лейтенант, әлеге аксак солдатка:

— Дядя Федя, иптәш капитанны озатып куй,— диде.— Ерак барма, олы юлга чыгарсаң җитәр.

Дядя Федя бау таккан винтовкасын иңенә элде, мин дә, лейтенантның киңәшен тотып, әлеге авылга китәргә әзер идем. Шул вакыт башыма бер уй килде: нинди милләт кызлары бар икән?

Соравыма каршы лейтенант:

— Отрядыбыз нигездә идел буе өлкәләреннән килгән кызлардан төзелгән,— диде.— Руслар да, татарлар да, чувашлар да, марилар да, удмуртлар да бар. Шулай ук башка милләт кызлары да... Кыскасы, бик чуар отряд. Әмма бик бердәм.

Минем өчен көтелмәгән хәзинә иде бу. Шатлыгымнан Павлова белән кул биреп күрешеп, әлеге авылга таба юнәлдем. Киләм, иртәгә иртүк киләм, килмичә калмыйм, редакциягә берничә сәгать соңга калып кайтсам берни булмас. Куначак урынымда лампа сыман берәр нәрсә булса, бәлки, алгы кырыйда җыйган материаллардан бер-ике хәбәр дә язып өлгерермен.

Күңелем күтәренке иде. Карт солдат та инде миңа ул чаклы бетерешкән булып тоелмый, Павловага булган үпкәм дә басылып бара.

Кер киптерә торган аланны уздык, машиналар белән тапталып, изелеп беткән юлга барып чыктык. Шул чак артымнан кемнеңдер: «Иптәш капитан, иптәш капитан!..» — дип кычкырганы ишетелде. Әйләнеп карасам, лейтенант Павлова, кобурасын уң кулы белән тотып, миңа таба йөгереп килә икән. Туктадым.

Янымa килеп җиткәч, ул хәрбиләр гадәте буенча бил каешын, пистолетын рәтләде, гимнастерка итәген тарткалап, артка таба җыйнаштырып куйды, хәтта юбкасын да сыйпаштыргалап алды.

— Сезгә бер үтенечем бар, иптәш капитан,— диде ул. Шактый араны йөгереп килгәнгә сулуы капкан, сүзләре өзек-өзек булып чыга иде, шулай да сөйләвендә дәвам итте.— Үтенечем бераз сәеррәк тоелыр, билгеле. Гафу итегез инде...

Мин зур игътибар белән тыңлыйм.

— Менә нәрсә, сез үзегезне татар газетасы корреспонденты дидегез шикелле. Шулаймы? Әгәр шулай икән, сез бездәге бер татар кызы белән бер четерекле мәсьәлә турында сөйләшә алмассызмы?

— Нинди кыз?

— Кире беткән бер кыз белән.

Кире беткән сугышчыларны, бигрәк тә кызларны, газетабыз битенә чыгара торган гадәтебез булмаса да, ризалыгымны белдереп, баш идем.

— Ни турында сөйләшергә соң аның белән?

— Хәрби дисциплина турында, үз өстенә алган бурычлар турында. Кыскасы, ничектер тәртипкә чакырасы иде аны.

— Үзегез генә сөйләшә алмыйсызмыни?

— Сөйләшә алам, билгеле, ләкин аңа тәэсир итә алмыйм. Шундый кыз ул...

— Гаебе нәрсәдә соң?

— Гаебеме? Менә нәрсәдә: алгы кырыйга качып китеп, отрядыбызны тәмам хур итте. Сугыш башыннан бирле берәүнең дә качканы юк иде. Ә ул качты. Бөтен дивизия алдында оятка калдырды. Әле ярый, тотып алып кайттылар үзен. Хәзер, җаным сизеп тора, тагын качарга җыена кызый. Бу юлы үзе генә түгел, бер төркем иптәшләре белән җыена шикелле. Башсызланмасын, үз-үзен харап итмәсен иде. Эшнең хәрби трибуналга барып җитүе мөмкин.

Лейтенанттан мин моны ачыграк сөйләп бирүен үтендем.

— Әйдәгез, дядя Федялар землянкасы янына китик. Анда эскәмия бар. Шунда утырып сөйләшербез,— диде кызый.— Теләсәгез, дядя Федя янында кунып та китәрсез. Дүртәү генә алар. Урын табылыр.

Бу какча гәүдәле лейтенант миңа кинәт матур, сөйкемле булып күренә башлады. Буе да зифа, әллә ни өлкән яшьтә дә түгел кебек. Бая ничектер буй-сынына игътибар итеп житкермәгәнмен, күрәсең.

Дядя Федялар землянкасы янында чыннан да ап-ак каен ботакларыннан ясалган эскәмия бар икән. Шунда барып утыргач, Павлова әлеге кире беткән кыз турында тәфсилләп сөйләп бирде. Отрядта татар кызлары бишәү. Шулар арасыннан Зөләйха Шәвәлиева дигәне лейтенантның канына тәмам тоз салган. Аның аркасында ул подполковник Орловтан каты шелтә алган. Кыз болай үзе тырыш икән, алдынгы да. Ул турыда сүз юк, диде Павлова. Нормасын да арттырып үтәп килә. Эшенең сыйфаты да начар түгел. Ул яктан бәйләнерлек урын юк. Тик отрядта кер юучы булып калырга теләми. Үлсә дә, үз сүзен итәргә ярата, кире беткән. Башта, алгы кырыйга җибәрүне үтенеп, командованиегә рапорт биргән, винтовкадан да, автоматтан да ата беләм, дигән, кирәк икән, пулемет расчетында да эшли алам, санитар да була алам, дигән әле тагын...

— Рапортын, хәрби тәртип буенча, дивизиянең медицина эшләре бүлегенә җибәрдем. Беләсез, аны мин үзем хәл итә алмыйм, анда карарга тиешләр аны. Подполковник Орловның характеры турында, бәлки ишеткәнегез бардыр,— диде лейтенант һәм җавап көткәндәй миңа карады.— Димәк, ишеткәнегез бар. Бу сүз, зинһар, үз арабызда гына калсын, бик формалист кеше ул. Хәер, командирымны тәнкыйтьләргә хакым юк минем. Шулай да моны сезгә әйтмичә булдыра алмыйм.— Павлова бу сүзне нигә әйттем икән, кирәкмәс иде дигән бер кыяфәт белән тынып калды, аннары тынычланыр өченме, әллә болай гынамы, пилоткасы астыннан тырпаеп чыгып торган чәчләрен ике кулы белән төзәткәләп алды.

Мин, аның бу хәлен күреп, тынычландырырга тырыштым:

— Мин сезне аңлыйм, бик яхшы аңлыйм,— дидем.— Борчылмагыз, барысын да сөйләгез... Рапорты ни белән бетте?

— Подполковник аны бик усал резолюция белән кире кайтарды. «Хәрби дисциплинаның нидән гыйбарәт икәнен рядовой Шәвәлиеваның башына бик ныклап тукыгыз! Юләрләнмәсен, кая куелган, шунда эшләсен. Сугыш беткәч тә егетләр янына барырга өлгерер». Шулай язган иде резолюциясен. Соңгы җөмләне язмаска кирәк иде аңа. Аннары мин дә гаепле. Резолюцияне Шәвәлиеваның үзенә күрсәттем. Шуннан соң кызый бер атна чамасы бик үпкәләп, хурланып, елаштыргалап йөрде. Бер көнне ялгызымны гына очратты да әйтте: «Иптәш лейтенант, үпкәләмәгез, минеге гаепләмәгез, мин барыбер кер юучылар отрядында калмыйм, качам», диде. Мин дә, юләр, янымa утыртып, аңа отрядтан качарга ярамавын яхшы гына, матур гына итеп аңлатып бирәсе урында, каты итеп әйтеп ташладым: башсызланма, Шәвәлиева, бу эш синең өчен бик начар бетәчәк. Исеңдә тот, дидем.

Кызый әйткән сүзендә торган, һөҗүм сугышлары башлану белән үк отрядтан юкка чыккан. Башта аның кая киткәнен белмәгәннәр, аптырап калганнар. Отряд өчен бу гадәттән тыш вакыйга, хәрби тел белән әйткәндә, ЧП булып әверелгән. Подполковник Орлов, отрядта дисциплина бик начар куелган, политик аңлату эше тиешенчә алып барылмый дип санап, Павлованы гаепләгән, аңа каты шелтә биргән, ә комсоргны сержант дәрәҗәсеннән ефрейторлыкка төшергән. Тик һөҗүм сугышлары беткәч кенә Шәвәлиеваның әллә кайда түгел, ә полкта, алгы кырыйда икәне беленгән. Кыз бәрелешләр вакытында санитар булып эшләгән, берничә яралыны ут астыннан алып чыккан. Шуңа карамастан, аны отрядка конвой белән алып кайтканнар, подполковник Орловның приказы белән биш тәүлек гауптвахтада ябып асраганнар. Лейтенант Павлованың әйтүенә караганда, аны полктан җибәрергә теләмәгәннәр, төрлечә яклаганнар, батыр, кыю кыз дигәннәр, үзләрендә бөтенләйгә калдыруны үтенгәннәр, әмма медицина эшләре начальнигы үзенекен иткән, әгәр без отрядта дисциплинаны йомшартсак, кызларга алгы кырыйга качарга ирек бирсәк, бер ай эчендә аларның барысы да полкларга күчеп бетәчәк, дигән. Ул чакта сугышчыларның кирләрен кем юар?.. дип, бик дулаган. Качкан кызларны гына түгел, алгы кырыйда аларны үзләренә алучы командирларны да каты җавапка тартырга тәкъдим иткән. Шуннан соң отрядта дисциплинаны тагын да катылата төшкәннәр. Безнең шикелле читләрне отрядка кертергә теләмәүнең бер сәбәбе шул икән.

— Эше ни белән бетте соң?— дип сорадым лейтенанттан.

— Ни белән бетсен, конвой белән кайтаргач, землянкага ябып куйдым үзен. Тик ике тәүлектән артык тота алмадым, чыгардым, чөнки кызый ашамас булды, ипине дә, суны да алмады, кертеп куйгач орынмады да, эшкә чыгаруымны таләп итте. Дөрес, бу кыланышы өчен аны тагын да катырак җәзага тартырга була иде, ләкин эшне зурга җибәрәсем килмәде, командованиедән яшереп булса да, эшкә чыгардым. Төннәрен шулай да ябылуда булды.

— Эшләдеме соң үзе?

— Ой! — дип кычкырып әйтеп куйды лейтенант.— Мин аның бу кадәр котырынып, җенләнеп эшләгәнен беркайчан да күргәнем юк иде. «Котырынып, җенләнеп» дип әйтүем дөрес булмас. Бик тырышып, бирелеп эшләде. Күрсәгез, үзегезнең дә исегез китәр иде. Шулай эшләп, гарьлеген, үпкәсен басмакчы булды, ахры. Качуы турындагы мәсьәләне отряд җыелышына куйдык, дисциплина турында, хәрби ант турында сөйләдек, алгы кырыйга качу булса да, отрядны рөхсәтсез ташлап китүне дезертирлык дип атадык, кыскасы, кызны оялтырга теләдек, гаебен тануны таләп иттек. Мин тагын бер акылсызлык эшләдем, башта аның белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе, күңел кылларын тартып карыйсы, контакт табасы урында җыелышта бөтен ачуымны чыгарып салдым, каты сүзләр әйттем, отряд кызларының күбесе аның ягында икәнен аңлап бетермәдем.

— Гаебен танудымы соң?

— Юк, танымады. Каршыбызга чыгып басты да сүзсез калды, бер сүз дә әйтмәде. Хәзер миңа бүре кебек карап йөри. Әйтерсең, мин гаепле. Шөкер, трибуналга бирмәделәр үзен. Бирсәләр, эше харап иде... Менә башыбызга шундый бәлаләр тудырган кыз ул. Үзсүзле, бик тискәре характерлы, кире беткән нәрсә. Тәмам теңкәмә тиде.

Мин, лейтенантның сүзен бүлеп:

— Аның белән сөйләшеп, мин нишли алырмын икән?— дидем.

— Сез бит аның якташы,— диде Павлова.— Журналист. Бәлки, мәкаләләрегезне дә укыганы бардыр. Без бит язучыларны, журналистларны бик ихтирам итәбез. Минем бер генә таләбем бар аңа: тагын кача күрмәсен, андый акылсыз уйны башыннан чыгарсын. Качса, бу юлы бик

начар бетүе мөмкин. Без дә фронт өчен бик кирәкле эш эшлибез. Хәер, боларны сез миңа караганда яхшырак беләсез...

Иртәгесен иртә белән мин кайбер мәгълүматларны лейтенант Павловадан алган идем инде, алдынгы кызларның исемнәре дә блокнотыма теркәлгән, репортажымны бизәр өчен әйләнә-тирә, табигать күренешләре, көзгедәй ялтырап яткан озынча күл, кер казаннары, ком гарәбедәй каралган йөзле, сылу буйлы япь-яшь кызлар турындагы тәэсиратларым ашыгып-ашыгып булса да сызгаланган... Кызларның берничәсе белән сөйләшеп, кайбер мәсьәләләр турындагы фикерләрен белешәсем генә калган. Шуны ачыклагач, редакциягә кайтып китәргә мөмкин, ләкин лейтенантның үтенечен җиренә житкермичә ничек кайтып китәсең?

Алан уртасында, утынлыкта, кер казаннарына ягар өчен китерелгән бүрәнәләр аунап ята. Шуларның берсенә барып утырдым. Элемтәче итеп билгеләнгән кыз кирәкле кешеләрне минем янга берәмләп чакырып килә башлады. Алар арасында татар кызлары да, руслар да, марилар да, чувашлар да бар иде. Барысы да алдынгы кызлар, ихтирамга лаеклы кызлар.

Лейтенант Павлованың сөйләвеннән чыгып, мин Зөләйха Шәвәлиеваны озын буйлы, таза гәүдәле, тупас йөзле бер кыз итеп күз алдыма китергән идем. Андый тискәре характер, үзсүзлелек, бераүгә дә баш имәү шундый кызларга хас сыйфат дип уйлый идем. Әмма каршыма уртача буйлы, мөлаем йөзле, оялчан бер кыз килеп басканч, бераз аптырап калдым, хәрби гадәт буенча үзенең Шәвәлиева икәнен әйтсә дә, гаҗәпләнүдән фамилиясен кайтарып сорарлык булдым.

Ул да, мин чакырткан башка кызлар кебек үк, эш киеменнән түгел, ә хәрби формадан иде. Өстендә юыла-юыла бераз төсен югалткан яшькелт гимнастерка, шундый ук юбка, башында йолдызлы пилотка, билен каеш белән каты итеп буган, шуңа булса кирәк, тал чыбыктай нечкә булып күренә. Бераз кыңгыр салып, чытлыкланып кигән пилоткасы да, өстенә ятып торган гимнастеркасы да бик килешле.

Башта мин аңа русча эндәштем:

— Утырыгыз,— дип, янымдагы бүрәнәдән урын күрсәттем.

Мин аңа җентеклэбрәк карап алдым. Барыннан да бигрәк күзләре игътибарны җәлеп итте. Матур булып, тирән кереп утырган зур зәңгәр күзләр иде алар. Тик ул күзләрдә сагыш дип әйтимме, борчылумы, шикләнүме, әллә таныш булмаган кешеләр арасында, бигрәк тә офицер белән солдат арасында була торган киеренкелекме, нәрсәдер бар иде. Нәрсә бу? Әллә ул мине аның эшен тикшерергә килгән хәрби трибунал кешесе дип уйлыймы? Минем газета корреспонденты икәнемне әйтмәделәрме икән әллә аңа? Әйтсәләр дә, ышанмаганмы икән әллә?

Икс арадагы киеренкелекне бетерергә теләп, бераз елмая төшеп, татарча эндәштем:

— Әйдәгез, таныш булыйк. Мин фронтыбызда чыга торган татар газетасы корреспонденты.— Исем-фамилиямне әйттем.

Кызның күзләре зур булып ачылып китте. Сөйләшә торгач, икебез дә Татарстаннан булып чыктык, хәтта берүк тирәдән дә икәнбез. Авылларыбыз бер-берләреннән ерак булса да, сугышка чаклы газета командировкасы белән йөргәндә алар авылында бернича тапкыр булганым бар иде, кайбер кешеләрне дә белә идем. Болар барысы да безне якынайтып җибәрде, уртак тел табарга ярдәм итте.

Кызның теле ачылып китте, үз авылына да, безнең авылга да бәйләнешле сораулар бирә башлады, аны туган ягыбызга кагылышлы бөтен нәрсә, бөтен хәбәр — яңасы да, искесе дә — бик кызыксындыра иде. Авылы турында ул минем белән сәгатьләр буенча сөйләшеп утырырга әзер иде шикелле. Шуның белән бергә күзләрендәге сагыш чаткылар да югалды.

Мин репортажыма кирәкле сорауларга күчтем: ничек эшлисез? Эшегезне яратасызмы? Норманы тутыра аласызмы... Шуның кебек трафарет сораулар иде алар. Бу сүзләрне ишеткәч, кызның авызыннан сүз чыкмас булды, соравымның берсенә дә төгәл җавап бирмәде:

— Эшләгән булабыз шунда... Яратам дип инде... Нормасын кем белгән аның...— Менә шундый бернәрсә дә аңлатмый торган җаваплар иде. Алар белән репортаж түгел, кыска хәбәр дә язып булмаячак. Хәер, нигә йөдәтәм соң мин аны? Ансыз да материалларым җитәрлек. Репортажның берәр җиренә исемен кыстырырмын да, шуның белән вәссәлам!

Күтәрелеп барган кояшка да, сәгатемә дә карап алдым. Я алла, сәгать ун булып килә. Хәзер үк олы юлга чыгып, кул күтәреп, берәр машинаны туктатырга да редакциягә кайтып китәргә кирәк. Бу чаклы соңга калуым өчен редактор рәхмәт әйтмәс. Шулай да лейтенант Павловага биргән вәгъдәмне үтәмичә урынымнан кузгала алмадым.

— Карагыз әле, Зөләйха сеңелкәй, сезне отрядтан качты дип сөйлиләр. Дөресме бу, әллә болай гынамы?— дип сорадым.

Кыз башын иеп, алдына караган хәлдә, бераз уңайсызланып, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп җавап бирде:

— Булды андый хәл, булды.

— Ник качтыгыз? Әллә монда эшлисегез килмиме яисә башка берәр сәбәбе бармы?

Зөләйха, башын күтәреп, миңа шундый итеп карады, аның күз карашы: «Әй, абый, абый, шуны да аңламыйсызмыни сез!» — дип әйтеп тора иде.

Бу юлы инде мин үзем, аның бу карашыннан бераз уңайсызланып:

— Әгәр мөмкин булса, сәбәбен әйтегез әле,— дидем.— Әллә ни өчен түгел. Болай гына... Профессиям шундый, кешеләр язмышы белән кызыксынам.

Гаҗәпләнүемә каршы, Шәвәлиева кыстатып тормады, акланырга теләгәндәй, бераз каушап, дулкынланып сөйләргә кереште:

— Качсам, мин бит, иптәш капитан, әллә кая түгел, алгы кырыйга качтым,— диде.— Монда эшлисе килмәгәнлектән түгел, зинһар, алай уйлый күрмәгез. Эшнең һәркайсы изге, кирәкле. Бигрәк тә монда, фронтта. Качуымның сәбәбе бөтенләй башка. Моны мин беркайда да аңлатып бирә алмадым. Әллә инде аңларга теләмәделәр. Кем белә, телем дә җитмәгәндер. Ни әйтсәң дә, рус теле бала чактан өйрәнеп үскән тел түгел. Яңа өйрәнеп киләм. Әгәр татарча булса, мин аларга, сезгә сөйләгән шикелле, чатнатып әйтеп биргән булыр идем.

Мин, аның сүзен бүлеп:

— Сәбәбе нәрсәдә соң?— дигән соравымны исенә төшердем.

— Сәбәбеме?.. Сәбәбе менә нәрсәдә,— диде ул. Һаман дулкынлана иде әле ул. Тынычланырга, дулкынлануын басарга теләп булса кирәк, я ике кулы белән чәчләрен төзәткәләп ала, я гимнастеркасын, я юбкасын тарткалап куя, яисә, кесәсеннән кечкенә генә кулъяулыгы чыгарып, кирәкмәсә дә борынын, ирен тирәсен сөрткәли, аннары аны яңадан кесәсенә тыга.— Мин алгы кырыйда, фронтта булырга телим,— дип дәвам итте ул сүзен.— Сәбәбе менә шул гына. Башка берни түгел. Анда миллионнар кан коялар, һәлак булалар, ә мин монда...

Ул нәрсәләр әйтергә теләп тә әйтеп бетермәде, мин дә кайтарып сорамадым, сүзен бүлдермәскә теләп, тыңлавымда булдым.

— Кыскасы, шул: мин анда файдалырак булырмын дип уйлыйм. Аннары, иптәш капитан, мине кер юарга дип түгел, ә сугышка дип алдылар. Иң кимендә зениткада хезмәт итәрсең яисә санитарка булырсың, диделәр. Мин винтовкадан да, автоматтан да ата беләм. Җитәрлек төз атам кебек, ирләрдән калышмыйм. Кирәк икән, башка эшләр-

не дә булдыра алам, тик алгы кырыйга җибәрсеннәр, рөхсәт итсеннәр генә... Аннары моннан китәргә теләвемнең тагын бер сәбәбе бар.

— Анысы нинди сәбәп тагы?

Кызый, ничек җавап бирим икән дигәндәй, бераз уйланып торгач, сүзен дәвам итте. Инде ул тынычлана төшкән, үзен беркадәр кулга алган иде.

— Бәлки, сәбәп дип әйтеп тә булмый торгандыр аны — чын сәбәп тә түгелдер ул,— диде.— Ничек дип аңлатып бирим икән сезгә?.. Менә нәрсә, иптәш капитан, тик сез, зинһар, миннән көлмәгез. Мин сезгә чынлап әйтәм: миңа кыз булып түгел, ә малай булып туарга кирәк иде... Мин солдатлар нәселеннән. Ата-бабаларым солдат булган кешеләр. Төрле сугышларда катнашканнар. Кечкенәдән үк миң сугышлар, батырлыклар турында ишетеп үстем. Аларның сөйләгәннәрен тыңлап то-ра идем дә батырларга, кыю кешеләргә кызыга идем. Минем дә алар шикелле буласым килә иде. Бабамның бабасы, Дәүләтша бабай, Николай солдаты булган, егерме биш ел хезмәт иткән. Кавказ сугышларында, Севастополь оборонасында катнашкан. Әйтүләренә караганда, Георгий тәресенең дүртесе белән дә бүләкләнгән. Шундый батыр булган ул. Безнең нәселне авылда Дәүләтша батыр нәселе дип йөриләр.

— Әтиегез кайсы сугышта катнашкан?

— Гражданнар сугышында.

— Хәзер кайда?

— Сугышта. Абыем да сугышта иде.

— Әллә үлдеме?

— Ийе. Мәскәү янындагы сугышта.

— Әтиегездән хат-хәбәр бармы соң?

Кызый бик моңсу җавап кайтарды: — Күптән юк...— Кулъяулыгы белән күз яшен дә сөртеп алды.

Без тынып калдык. Минем өстәмә сораулар бирәсем килми иде, бирсәм, тагын да кайгылырак җавап ишетермен кебек тоелды.

Зөләйха үзе сүз башлады.

— Әтием белән абыем өчен фашистлардан кем дә булса үч алырга тиештер бит?

Бу сорау миңа бирелгән иде, билгеле. Ләкин мин аны җавапсыз калдырдым. Әгәр: «Син үч алырга тиеш»,— дисәм, аны отрядтан качарга котырту булыр иде. Мин аның дисциплинаны тагын бозуын, хәрби трибуналга бирелүен һич тә теләми идем. Качса, шундый хәлгә дучар булуы мөмкин иде аның.

Шуңа күрә:

— Әллә тагын качарга телисезме?— дип сорадым.

Зөләйха башын кискен генә чайкады, пилоткасы астыннан бераз бөдрәләнеп чыгып торган коңгырт чәчләре җилфердәп куйды:

— Юк, исәбем юк. Аның нәрсә белән бетәсен яхшы беләм хәзер. Алгы кырыйга, сугыш эченә качкач, гаепләмәсләр дип уйлаган идем мин.

Эчке дисциплина, командирга мөнәсәбәт һәм башка шуның кебек нәрсәләр турында бераз сөйләшкәч, аңа, өлкән кеше буларак, кайбер киңәшләр бирдем дә урынымнан кузгалырга ниятләдем. Эшне тәмамларга бик вакыт, язгы кояш, җылы нурларын чәчеп, күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Урынымнан торып, саубуллашыр өчен кулымны суздым. Кызның әйтәсе сүзе бетмәгән икән. Ул, урыныннан кузгалмыйча, бераз оялган, уңайсызланган төс белән миңа карап басып тора иде.

— Абый, сезгә бик зур үтенечем бар,— диде ул, ниһаять, һәм, кемнәндер шикләнгәндәй, як-ягына карап алды.— Әгәр мөмкин булса, мәкаләгезгә исемемне дә, фамилиямне дә кертмәвегезне үтенәм.

— Нигә?— дидем мин, бик гаҗәпләнеп.— Мин бит сезне мактап телгә алам.

— Мактап телгә алсагыз да барыбер.

Мин соравымны кабатладым. Кыз җавабын көттермәде:

— Алгы кырыйда чакта мин әнигә дә, дус кызларыма да: «Мин окопта, сугышта», дип язган идем. Алар алдында ялганчы булып каласым килми.

Мин, аны тынычландырырга теләп:

— Борчылмагыз, сеңелем, газетабыз фронтта гына тарала,— дидем.— Алар кулына барып ирешмәс.

— Кем белә бит аны,— диде Зөләйха икеләнеп.— Берәр юл белән барып житеп, укулары мөмкин. Шулай да исемемнең кермәве яхшырак.

Фикере, алгы кырыйга китәргә омтылуы белән бу кызны ошатып өлгергән идем инде мин. Каршы килмәдем — репортажга исемен кертмәскә булдым.

Отрядтан китәр алдыннан Павлова белән саубуллашып чыктым.

— Тыныч булыгыз, качачак түгел, сүз бирде,— дидем.

Олы юлга чыгар өчен шактый барырга кирәк иде,— алда шул ук сазлы юллар, урман сукмаклары. Мин корырак, катырак җирләрне сайлап атлый-атлый, репортажымның планы турында уйларга тырышам, ләкин әлеге кызның сәер холкы, сөйләгән сүзләре, үтенече күңелемнән чыкмый, уйларга, планымны төзәргә комачаулый. Хәтта кайбер минутларда аның моңсу карашы күз алдыма килеп баса. Нигә репортажга исемен кертергә теләми ул? Әнисенә, дусларына: «Мин сугышта, окопта», дип язгангамы, әллә сугышчыларның керле, канлы күлмәкыштаннарын юуны кимсеткеч, түбән бер эш итеп санагангамы? Алай дисәң, нигә ул чаклы тырышып, бирелеп эшләр иде икән ул? Юк, эшләмәс иде. Лейтенант та, аңа никадәр каршы булуына карамастан, эше ягыннан аны яманламады. Киресенчә, алдынгы, булдыклы юучыларның берсе итеп атады, кулы кулга йокмый, хәтта кайбер чакларда «котырынып, җенләнеп эшли», диде. Юк, бу эшне ул түбән эш итеп санамый торгандыр. Шулай булса, сөйләшеп утырганда аның бу фикере тел төбеннән сизелмичә калмас, ничек тә ычкыныр иде бер. Киресенчә, ул бөтенләй икенче фикердә: кабәхәт дошманны җиңү, аны юк итү өчен сугышта булсын, тылда булсын, һәр эшнең изге, мөкатдәс икәнен аңлый, төшенә. Алайса, нигә ул эшен ташлап, алгы кырыйга качкан? Тукта, башта бит ул, устав кушканча, рөхсәт алып китәргә теләгән. Тик соңыннан аның кыз бала, юк, алай гына түгел, кешелек горурлыгын хурлаган резолюцияне укыгач кына куркынычлы юлга баскан. Анда да тылга түгел, ә алгы кырыйга, ут эченә, мәрхәмәтсез үлем давылы котырган җиргә качкан. Әгәр дөрес булса, батальон командирының әйтүенчә, ул анда тиз арада батырлык, кыюлык күрсәткән, каты сугыш барган сәгатьләрдә куркып, икеләнеп тормаган, ут эченнән бернечә яралыны алып чыккан, яраларын бәйләгән, аларны котылгысыз үлемнән саклап калган. Юк, бу кызның характерында, йөрәгендә, канында мин аңлап бетерми торган нәрсәдер бар. Аны шулай ук лейтенант та, подполковник Орлов та, башкалар да аңлап бетермәгәннәр булса кирәк. Кем белә, бәлки, ул аларга рус телен житәрлек белмәгәнгә теләген аңлатып бирә алмагандыр. Әллә аңларга теләмәгәннәрме? Ә мин аның уйларын, фикерләрен аңлап бетердемме соң?

Тылны ташлап, үз теләгең белән алгы кырыйга баруны, ут эченә керүне, курыкмыйча, шикләнмичә үлемнең күзенә карап баруны мин бөтен җаны-тәны белән илгә, халык эшенә бирелгән көчле характерлы шәхесләргә хас сыйфат итеп саныйм. Егермене дә тутырып өлгермәгән, күрер күзгә унҗиде-унсигездән арыны бирергә мөмкин булмаган бу бала, эрынсаң уалып китәрлек күбәләк-җан, кулына я автомат, я винтовка тотып, дошманга каршы барырга, сугышырга, ут эченә керергә омтыла. Сорап-сорап та максатына ирешә алмагач, һөҗүмнәр башлану белән алгы кырыйга кача. Аны тотып алып кайталар, гаупвахтага

ябып куялар, ипи белән суда гына тоталар, әмма кыз бөгелми, сыгылмый, үзен хаклы санап, башын югары күтәреп йөри, шуның белән кемнәргәдер протестын белдерә, гарьлеген, үпкәсен басарга теләп, башын күтәрмичә эшли, тырышлыгы белән иптәшләрен генә түгел, командирын да таңга калдыра. Каян килә аңа бу көч? Кайда чарланган аның бу характеры, бу ныклыгы? Әллә, үзе әйтмешли, Дәүләтша батыр нәселеннән булуының нәтиҗәсеме? Әллә инде тормышыбызның, социалистик җәмгыятебезнең, коммунистик тәрбиябезнең, ил алдындагы, халык алдындагы, ниһаять, бөтен прогрессив кешелек дөньясы алдындагы бурычларыбызны аңлауның матур бер күренешеме?..

Әле моннан берничә дистә еллар элек кенә аның әниләре, әбиләре дини-милли коллыкта, рухи коллыкта яшәгәннәр, атаклы бер татар әдибенең язуынча, туганда ук тереләй күмелергә хөкем ителгәннәр. Бүген ул бәхетле, азат, ирекле, тулы хокуклы. Бөек Октябрь революциясе яулап алып биргән бу хокукның, азатлыкның кадерен ул җаны тәне белән аңлый, төшенә. Шуңа күрә ул, кулына корал тотып, аны саклап калу өчен сугышырга, ут эченә керергә, үлемгә каршы барырга, явыз дошманны юк итәргә ашкына. Моңа мөмкинлек бирергә теләмәгән киртәләрне ватып, җимереп, таптап узарга тели. Бер ягы белән дә башкалардан аерылып тормаган бу кыз, гади татар кызы, үзенең зур, изге, тарихи эш эшләргә омтылуын беләме икән?... Аңлыймы икән?.. Юк, бу турыда ул бәлки бөтенләй уйламый да торгандыр, хәтта башына да китермидер. Ул моны тормыш таләп иткән, вөҗданы, намусы таләп иткән бурыч итеп саныйдыр...

Кире беткән кыз? Лейтенант Павлова аны шулай атый. Юк, мин аны алай димәс идем!

Миңа бу дивизиягә яңадан барырга, кызлар отрядына кереп чыгарга туры килмәде, җәйге һөҗүмнәр башланды, редакциядә эш артты, катлауланды, әлеге очрашулар, сөйләшүләр хәтеремнән дә чыкты диярлек. Хәер, кер юучы кызлар янына барып йөрүнең кирәге юк иде инде, репортаж басылган, план үтәлгән, алда яңа эшләр, яңа бурычлар, яңа темалар.

Көзгә табарак, сентябрьнең башлары, әллә урталары идеме икән, хәтеремдә калмаган, фронт юлында, алгы кырыйга бару өчен контроль-пропуск пунктында машина көтеп басып торганда, һич уйламаганда лейтенант Павлованы очраттым. Ул командованиенең кушуы буенча каядыр барган, хәзер шуннан кайтып килә икән. Без күптәнге танышлар шикелле кул бирешеп күрештек, гадәттәгечә исәнлек-саулыкларыбызны сорашканнан соң, отрядтагы хәлләргә күчтек.

Сүз арасында мин аңардан:

— Теге кыз нихәл? Зөләйха Шәвәлиева?— дип сорадым.— Тынычландымы инде? Алгы кырыйга китәм дип йөдәтмиме?

Павлова, миңа бик сәер елмаеп карап:

— Теге кире беткән кызмы?— дип кайтарып сорады һәм шундук башын чайкый-чайкый:— Әй, ул кыз! Әй, ул кыз! — дип сузып куйды.— Безгә караганда хәйләкәррәк булып чыкты ул. Тәки китте бит алгы кырыйга, үзенекен итте.

— Ничек китте?— дидем мин, бик гаҗәпләнеп.— Әллә тагын качтымы?

— Юк, качмады. Рөхсәт белән китте.

— Кем рөхсәте белән?

— Генерал рөхсәте белән.

— Ничек ала алган ул?— дип сорадым мин, төпченеп.

Юлда әле фронт ягына таба баручы машиналар күренми, вакыйганы тыңларга вакыт бар иде. Лейтенанттан мин моның ничек булуын

сөйләп бирүен үтендем. Ул карышмады, машиналар килә торган якка таба бер-ике тапкыр карап алганнан соң, сөйләргә кереште:

— Сез отрядка килеп киткәннән соң Шәвәлиева миңа булган мөнәсәбәтен бик үзгәртте,— дип сүзен башлады ул.— Яхшырды, сөйләшкәндә-ниткәндә үз итеп, елмаеп карый башлады. Мин дә аңа кырын каравымны ташладым. Бик тырышып эшләве, норманы һәр көнне арттырып үтәве өчен строй алдында үзенә бер-ике тапкыр рәхмәт тә әйттем, күңелен күтәрергә тырыштым. Чыннан да рәхмәткә лаеклы иде ул кыз. Нормасын кайбер көннәрне ике йөз процентка чаклы үти иде... Без һәр көнне отрядыбыздагы кешеләр саны, аларның ничәсе сәламәт, ничәсе авыру икәнне, частьлардан күпме кер килүе, күпмесен юуыбыз турында командованиегә мәгълүматлар биреп барабыз. Бу эшләрне мин медицина эшләре бүлегенә иртүк җибәрәм. Гадәттә ул мәгълүматларны безгә беркетелгән әлеге инвалидларның берәрсе илтә иде. Алар туры килсә, кер китергән машинага утырып китәләр, туры килмәсә, болай гына, җәяү генә атлыйлар. Ничек кенә бармасыннар, бүлегебез нинди генә ераклыкта булмасын, инвалидларыбыз аннан кич белән генә әйләнеп кайталар иде. Шәвәлиева моңа игътибар итеп йөргән булса кирәк. Бер көнне ул минем янга килде дә: «Иптәш лейтенант, нигә ул аксак-туксак картларны посыльный итеп йөртәсез?» — диде.— Ташбака кебек кыймылдыйлар ич алар. Медицина эшләре бүлеге ике-өч километр җирдә генә булса да, иртә белән китеп, караңгы төшкәндә генә кайталар. Дөресрәге, ашарга гына кайталар,— диде. Мин үзем дә алар белән йөдәп беткән идем. «Кемне җибәрим соң? Башка кешем юк бит», дидем. «Ә без? — диде ул.— Без нигә ярамыйбыз? Без яшь. Аякларыбыз җитез. Күз ачып йомганчы барып кайтырбыз. Ә ул картлачларга монда да эш җитәрлек». Дөрес әйтә, дип уйладым мин. Чыннан да нигә кызларны җибәрмәскә? Шундук мин аңа: «Алайса, иртәгә син барырсың»,— дип әйтеп ташладым. Кызый моңа бик шатланды. Безгә, кирәк булса-нитсә дип, берничә винтовка белән бер карабин бирелгән. Унлап гранатабыз да бар. Шәвәлиева кич белән карабинны, үз землянкасына алып китеп, бик тырышып чистартты, майлады. Мин аңа ике обойма патрон бирдем. Граната да сораган иде, бирергә теләмәдем, анысы нигә сиңа, дидем.

Ул арада бер-бер артлы машиналар килә башлады. Лейтенант Павлова китәчәк якка да бер-ике машина үтте. Ләкин мин танышымның тагын берничә минутка калуын, башлаган сүзен тәмамлавын үтендем.

— Иртәгесен иртә белән мин аңа әзерләп куйган мәгълүматларымны тоттырдым да бер юлы шунда отрядка килгән хатлар белән газеталарны да алып кайтырга куштым,— дип сүзен дәвам иттерде лейтенант.— Шәвәлиева, карабинын иңенә асып, шундук китеп барды. Әллә атлап барып, канатланып очып кайтты — анысын белмәдем, әмма сәгать ярым, ике сәгать дигәндә каршыма килеп басты. Честь биреп: «Заданиегызны үтәдем, иптәш лейтенант», диде. Медицина эшләре бүлеге бездән әллә ни еракта түгел иде болай, биш-алты километр чамасында гына. Шулай да аны шулай посыльный итеп йөрттем. Аннары сынар өчен башка кызларны да җибәргәләп карадым. Юк, берсе дә аның кебек тиз кайта торган булмады. Шуннан соң гел Шәвәлиеваны гына йөртә башладым. Йомышымны башкарып кайткач та ул башка кызлар кебек ял итеп тормый, шундук үз эшенә тотына иде. Нормасын да арттырып үти. Кыскасы, бик яратып йөрде ул посыльный буларак. Дөрес, бераз соңгарак калып кайткан көннәре дә булгалады, ләкин һәр юлы сәбәбен әйтә иде: я мәгълүматларны алмый торганнар, я почта килеп җитмәгән, шуны көтеп торган. Бер көнне аеруча шатланып, канатланып кайтып керде, авызы ерылган, күзләре ут шикелле яна. Кулыма бер пакет тоттырды. Ачып карасам, рядовой Шәвәлиеваны медицина эшләре бүлеге карамагына җибәрү турында подполков-

ник Орлов приказы. Исем-акылым китте. Шулай итеп, отрядтан китеп барды ул.

Мин аның сүзен бүлеп:

— Туктагыз әле, сез бит генерал рөхсәте белән китте дигән идегез түгелме соң?— дидем.

— Әйе, генерал рөхсәте белән китте,— диде Павлова.— Шәвәлиеваны алгы кырыйга җибәрү турында подполковник Орловка генерал үзе кушкан.

— Генерал янына ничек керә алган соң ул?

— Бөтен мәсьәлә дә менә шунда. Кергән, әйтәсе сүзен әйткән. Иптәшләренең сүзенә караганда, бу кыюлыгы өчен генерал аңа, аркасыннан сөеп, «Молодец!» дигән. Минемчә дә молодец кыз ул,— диде лейтенант Павлова һәм кабатлап әйтеп куйды:— Молодец кыз!

Мин соравымны кабатладым, чөнки Кызыл Армиядә кер юучы булып хезмәт итүче гади татар кызының генерал янына керә алуы кызыксындыра иде мине.

— Үзегез беләсез,— диде Павлова,— медицина эшләре бүлеге гадәттә дивизия штабы тирәсенә урнаша. Ә безнең хәйләкәр кызыбыз йомыш белән барган саен генерал янына керергә омтылып караган. Сакчылар якын да китермәгәннәр аны, билгеле. Шуннан соң кызый тактикасын үзгәрткән. Кайбер көннәрдә, бигрәк тә соңгарак калып кайткан чакта генералның землянкадан чыгуын яисә землянкага кереп баруын сагалап тора башлаган. Ниһаять, генералны очраткан, куркып-нитеп тормаган, янына барган да үтенечен әйткән.

— Димәк, аның медицина эшләре бүлегенә посыльный булып йөрүе бер хәйлә генә булган?

— Әйе, алдан ук бик оста уйлап әзерләнгән хәйләсе булган,— дип, лейтенант чыркылдап көлеп алды.— Шулай бик кызык итте ул безне.

— Хәзер кайда соң ул үзе?

— Батальонда. Соңгы һөҗүм көннәрендә пулемет расчетында булган. Әйтүләренә караганда, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләгәннәр дә икән инде үзен. Менә шулай,— диде лейтенант Павлова, сүзен тәмамлап.— Молодец кыз! Валлаһи молодец!

Ул арада машиналар тагын килеп туктады. Юл тәртибен саклаучы солдат кыз Павлова барачак юнәлешне кычкырып игълан итте.

Мин лейтенантны машинага чаклы озатып куйдым, менеп утырырга да булыштым.

Машина кузгалды. Павлова, минем белән саубуллашып кулын болгый-болгый, миңа нәрсәдер әйтеп кычкырды, машина тавышы аркасында сүзләренең барысын да ишетеп бетермәдем, әгәр рөхсәт итсәләр, мин дә алгы кырыйга бик рәхәтләнеп китәр идем, диде шикелле.

Озак та үтмәде, машина ераклашты, ахырда күздән дә югалды.

Рашат Низамиев

# МЕҢ АВАЗЛЫ ЗАМАН

## Серләр эзлим

Бер үк кояш яктыртса да шушы җирне —
Үләннәрнең яфраклары төрле-төрле.
Кара туфрак имеп үскән алмагачның
Алмалары нидән кызыл — шунсы серле.

Тузан баскан каберташлар күтәп тора
Яфракларның сыйпап-сыйпап киткән чагын.
Хикмәтле аш, хикмәтле җир, хикмәтле таш —
Серләр белән тулып ята тирә-ягым!

Кешеләрнең йөзләреннән серләр укыйм:
Берәү моңсу, ә берәү шат атлый юлдан.
Агач битле, таш бәгырьле җаннар гына
Мәхрүм була сагышлардан, елмаюдан.

Киң күкрәкле ир-егеткә караганда
Ун мәртәбә катлаулырак хатын-кызлар.
Серләрнең дә иң серлесе, иң нечкәсе —
Күз явыңны ала торган матур кызлар!

Серләр эзлим, серләр ачам — вакыт җиткәч
Сөйләр өчен оныкларга чын дөресен.
...Күзләремнән якты йолдыз яуган чакта
Мин үзем дә сердер әле кемдер өчен.

●

Нинди көчләр сәях җанлы итеп
Яраткандыр адәм баласын?
Хыялында ул җәяүләп уза
Йолдыз белән йолдыз арасын.

Күктә кояш, җирдә утлар яна,
Гүя тормыш — төсле маскарад,
Шампан булып ташый ак бәхетләр,
Сагыш кына төптә, астарак.

Көпә-көндез ай тәгәри күктә —
Тәмам, ахры, чиргә сабышкан.
Качыш-качыш уйнагандай итеп
Йөгерешә кырда арышлар.

Буранлый да, койма өсләреннән
Сикерә кыш — ап-ак көнгерә.
Чәчәкләрен кысып күкрәгенә
Кар астында язлар өлгерә.

Таңнар алсу, күкләр бик ямансу,
Урманнарны серле моң баса.
Кем сокланыр шушы матурлыкка —
Җирдә әгәр кеше булмаса!

## Бер халәт

Яшәү хакын даулый һәрбер үлән:
Авазлары чыңлый колакта.
Чәчәге дә, әрсез әреме дә
Тишелгәннәр бер үк туфракта.

Таянырга таяк юна бабай,
Кәләпүшен кырын «кундырган».
Ни могҗиза: орчык хәтле малай
Тәпи басып төшә болдырдан!

Фидаилар уза киләчәккә —
Максатына уза тау ярып.
Кара җанлы монафыйклар исә
Кабер ташын йөри аударып.

Офыкларга сыяр-сыймас булып
Ил өстеннән якты көн ага.
...Күктән иңгән яңа бер зат булып
Карап тордым әле дөньяга.

## Эзли вакыт

Нәрсә соң ул тарих? Офыклардан
Өр-яңа көн төшә ишелеп.
«Мин — тарихның үзе»,— дигән кебек
Аягүрә баса кешелек.

Тыеп булмый вакыт аргамагын —
Җилдерә ул дөнья буйлатып.
Һәйкәлләрнең намен укый-укый,
Илләр гамен йөри уятып.

Елъязмалар чорны яктырталар —
Еллар яна анда, шәм яна,
Чөйязуның ташлы тамгаларын
Сөртә-сөртә укый замана.

Уклар атып, илләр берсен-берсе
Үтерергә купме теләгән...
Җирдә һаман кара шәүлә йөри —
Ракеталар күкне тәрәгән!

Ә таллыкта, берни булмагандай,
Су коена сабый кондызлар.
Мәңгелектән бер кыйпылчык булып
Карап тора әнә йолдызлар.

Егерменче гасыр дөреслеген
Эзли вакыт, эзли чаң кагып.
Һәм ТЫНЫЧЛЫК сүзен өскә чөя
Ал байраклар җирдә чайкалып.

## Куркытылган поши

Җиле белән яфракларны чөеп,
Дулап чыкты урман эченнән.
Нинди язмыш аны эзәрлекли,
Качып бара кемнең үченнән?

Урманның ул, бәлки, йөрәгедер —
Дүрт аяклы, күзле, яралы...
Рәшәләрне айкап чаба җанвар,
Арышларда — кызыл кан табы.

Мәрмәр сыман шомарган ул җилдә
Кача-кача бүре күзеннән.
Авылгамы барып сыеныргга —
Сунарчылар килсә эзеннән?

Мәңгелеккә озата бара аны
Үлән исе, усак кайрысы.
Ул егылса — кара яңгыр булып
Түгелер төсле җирнең кайгысы!

Катлы-катлы урман өсләрендә
Зәңгәр төтен тора беленеп.
Чатлы мөгез, сорау билгесед әй,
Офыкларда калды эленеп.

## Кабатлану

Кылган эше, рухы, каны белән
Үз язмышын иҗат итә кеше.
Һәм бөртекләп җыйган хәзинәсен —
Җан байлыгын алып китә кеше.

Сокландыра иң беренче карлар,
Яңгырларның серле пышылдавы.
Акыл йөге авырая бара
Биегәйгән саен гомер тавы.

Вулкансыман бәреп чыга хисләр!
Еллар буе дөрләп яна-яна,—
Югалтулар, нәфрәт, алданулар
Меңнәр йөрәгендә кабатлана.

Мәхәббәтнең шашкын минутлары
Кабатлана олы шатлык булып.
Җыерчыклар баскан йөзләребез
Карап тора көләч картлык булып.

Гомер җебен ялгап ала сабый!
Һәм башлана бар да яңабаштан:
Юл алырга тора күпме хыял,
Алда дөнья — укылмаган дастан...

●

Җир белән күк арасында
Арыш кыры тирбәлә.
Шаулагыз! — дип сабакларга
Җил бәрә дә җил бәрә.

Җир белән күк арасында
Яши тургай яратып.
Канатлары ак болытка
Тиеп китә кайвакыт.

Җир белән күк арасында
Нинди серләр, нинди моң?
Галәмдәге сөйләшләрне
Җиргә ятып тыңлыймын.

## Ташландык кое

Үҗәтләнеп, җирне күләгәләп
Кычыткannar үсә балчыкта.
Тып-тын гына сулып ята кое
Күз яшьләре кипкән карчыктай.

Юлаучымы туктап чиләк сала,—
Шифа иде суы кемгә дә!
Төпләренә төшеп ак болытлар
Коена иде җәйге челләдә.

Суы киткән — каны кипкән инде,
Сагыш белән тулган бурасы.
Пәрәвездә чебен бәргәләнә,—
Шул аваздан тора дөньясы.

Куркуданмы — качыш уйнаганда
Читләп уза аны нәниләр.
«Суы йомшак иде»,— дия-дия
Сагынып сөйли булыр әбиләр.

Бардыр бит ул безнең йөрәктә дә
Онытылган, сулган чишмәләр...
Сулар эзләп чапкан аргамагым
Авызлыгын әнә тешләгән!

## Равил Мирхәйдәров

# БЕЗНЕ ОНЫТМАГЫЗ...

ПОВЕСТЬ

*Үги этиемә*



Көтелмәгән хат килеп төште.

Бакиров чираттагы ялга җыена иде, путевка — кулда, билетка заказ бирелгән. Фуат Мансуровичның җиде елга якын инде әнисеннән хат алганы юк иде. Бервакытны, циңгездән ял итеп кайтышлый, картларга телефон керттергән иде, шуннан бирле... Авылда телефон куйдыру, шәһәрнекенә карый, ул хәтле үк мәшәкатьле түгел. Аннары, җае чыкты: телефон бүлеге начальнигы мәктәптә бергә укыган дусты икән.

Дөресен әйткәндә, картлар телефонга һич кенә дә мохтаҗлык сизмиләр иде. Сәламәтлектән зарланмыйлар, ул-бу була калса поликлиника да урам аша гына. Телефон Фуат Мансуровичның үзенә кирәк иде — хат язышудан коткарды ул аны. Югыйсә, улыннан хат килсә, күрше-күлән саен йөреп, Миңсафа апаның ул хатны һәммәсенә укытуын да Фуат Мансурович бик яхшы белә. Күрегез, дия кебек әнисе, нинди укымышлы егет үстердем — инженер!

Ашыгыч эшем бар дип, Фуат Мансурович кабинетына кереп бикләнде, үзе белән хатны да, бүгенге газета-журналларны да эләктерде. Әмма аның бүген бернинди дә ашыгыч эше юк иде. Хәлбуки, зур гына трестның баш инженеры булып эшләүче Фуат Мансуровичның буш вакыты бөтенләй калмый диярлек, кайчакта тәүлеккә сыймаслык эшләр килеп чыга...

Бакиров хатны өч мәртәбә укыгач кына тынычланды. Әлеге хат шәмәхә карандаш белән язылган иде. Гадәттә, посылка салганда, мондый карандаш белән әнисе әрҗә тышына адрес яза. Шушындый ук карандаш белән этисе фронттан хатлар язып җибәрә иде. Өчпочмаклы хатлар...

Ярты сәгатьләп кабинетында утырганнан соң, Фуат Мансурович кухняга чыкты. Үзе белән хатны да алды. Мәктәптә йорт эшләре дәресләре керә башлаганнан бирле, улы ашлар пешерергә булыша, һәр көнне диярлек өстәл әзерләшә. Әлек тәлинкәйомры ватудан башы чыкмаган малай кытай сервизларын хәзер сак кына тота. Әнисенә башта бу яңалык — кытай сервизларын кузгаткалау ошап бетмәде. Фуат Мансуровичка, киресенчә, күңелле иде. Азактан күнектеләр, затлы савыт-сабалардан ашау-эчү гадәткә керде. Шаккаттылар: тузанга күмелеп яткан чынаякларга хәзер җан иңгәндәй булды.

Хатыны Фуат Мансуровичка чәй ясарга да өлгерә алмады, улы кинәт кенә сорау бирде:

— Әби белән бер-бер хәл булмагандыр бит, әти?..

Бакиров елмая төшеп, гаиләне тынычландырырга ашыкты: үзгәрешләр юк икән

анысы, бабай гына пенсиягә китәргә җыена, ди, тик хезмәт кенәгәсендә ниндидер буталчыклык тапканнар — исеме дөрес язылмаган, имеш. Әйе шул, татарларда шундый исемнәр очрап куя — катлы-катлы кәбестәләрең бер якта торсын, аларны язганда әллә нинди акыллы башларың да ялгышыр. Кайберләрен тутырып әйтә калсаң, сөяксез телеңне сындырырсың, кая анда хәрефләр буталу гына?! Пенсиягә китәр вакыты җиткәч, бабайның хезмәт кенәгәсендә дә хата табылган. Дөресен эзләтеп картны бер ишектән икенчесенә керткәннәр, мескенне тәмам хәлдән тайдырганнар. Ахырда бабай түзмәгән — үпкәләп барысына да кул селтәгән. «Аяк-кулларым сау чакта ялынмам,— дигән ул.— Пенсиясез дә үлмәм әле. Минем эш тир түгү булды, кенәгәгә мин үз кулым белән язмадым бит, кантур кешеләре язды»,— дигән.

Гаиләдә бабаларының холкын яхшы беләләр иде, әби хатында сурәтләнгән вакыйга бөтен ваклыклары белән күз алларына килде дә басты. Әлеге кәгазьләр инде менә ярты елдан артык хәрәкәтсез ята диелгән иде хатта. Бабай пенсия турында сүз дә кузгаттырмый, ди. «Карт кызганыч бит, гомере буе бил бөгеп эшләсен дә, хәзер үзенә тиешле пенсиясен дә бирмәсеннәр инде. Үпкәләмәслек тә түгел бит...»— дип тәмамлаган иде әби хатын.

Миңсафа апа улын кунакка чакырган, ял да итәрсең, әтиеңнең эшләрен дә кузгатып җибәрерсең, дигән. Ни генә әйтсәң дә, укымышлылыгың бар, законнарны да беләсең, аннан соң, мәктәптә бергә укыган шәриктәшләрең дә хәзер зур урыннарда эшлиләр, бәлки, ярдәм кулы сузарлар. Адәм хурлыгы бит, гомере качкынлыкта үткән диярсең. Гел шушы Бүләк авылында яшәде...

Фуат Мансурович бу ялын түземсезләнеп көтеп алган иде. Шулай булмыйни?!! Ел да тәтеми аңа ял итүләр: бер елны трест управляющие ялга чыкса, икенчесендә— Фуат Мансурович. Җәй айлары төзүчеләр өчен еллык планның дүрттән өч өлеше дигән сүз. Путевкасы да шәп иде — диңгез буена, Алуштага. Бу путевканы юнәтер өчен Бакировка шактый көч түгәргә туры килде.

Далада туып-үскән егет диңгезне беренче мәртәбә егерме җиде яшендә күргән иде һәм шул көннән башлап диңгезгә гашыйк та булды. Иртә таңнан кич караңгыга кадәр яр буенда диңгез киңлекләрен карап йөрергә ярата ул. Киткәнче үк аны сагына башлый, яңадан бирегә әйләнеп килер чакларын көнләп түгел, сәгатьләп-минутлап саный. Гаиләдә аның хисләре белән уртаклашучы булмаса да, хәлен яхшы аңлыйлар. Күрәсең, Белоруссиядә туып-үскән хатынына тын күлләр, җиләкле урман аланнары, алтын иген басулары якынрак тоеладыр. Әмма әти кешенең диңгезгә баруы өзелә икән, бу гаиләгә шатлык түгел. Хатыны үзе генә кайтып бөтен эшне җайга салырга теләк белдергән иде дә... Профессиясе — юрист, картларга ярдәм итәргә дә әзер, әмма Фуат Мансурович үзе кайтырга карар кылды.

Хатыны иренә юридик белешмә тоттырды, кайбер кирәкле битләренә кәгазь кыстырырга да онытмады. Бакиров эшен тиз әйләндереп ташлармын дип юанды, һәрхәлдә атна-ун көн эчендә мәсьәләне хәл итәр дә юлга чыгар, нигә кайгырырга?!

Бер күз ташлаудан ук Фуат Мансуровичның көчле кеше булуына ышанасың. Ләкин көчле кешеләр дә кеше бит әле, алар да тимердән ярат... ылмаганнар. Шуңа күрә алда көтелгән егерме дүрт көнлек ялы белән ләззәтләнеп бару Бакиров өчен дә бик табигый хәл иде.

Кояш кызуына әлсерәп яткан казакъ далаларына карап барганда, Фуат Мансурович уйлары белән яңадан үги әтисенә әйләнеп кайтты. Тәгәрмәчләрнең өзлексез тыкылдавы аңа кеше гомеренең кыска, ай-һай, кыска булуын исенә төшерде. Утыз җиде яшьлек Фуат Мансурович гомернең кыскалыгын болай да белә, тик йөрәкне бу хәтле чеметтереп алырдай итеп нәкъ шушы минутларда гына уйлады ул. Әле кайчан гына дөньяда гаме дә юк кебек тоелган төз гәүдәле ир, кирәк чакта онытылып кузналар уйнап йөргән кеше пенсиягә китә. Авылда иң күп орден-медальләре булган үткен һәм гаярь холыклы, гайрәтле һәм кешелекле иргә хәзер Фуатның ярдәме кирәк. Югыйсә, малай чакта Фуат үзен бөтенләй яраксыз кешегә исәпли иде, кая ул үги әтисе кебек көчле булу — андый бәхет төшеңә дә кермәс. Аны бит хәтта дошманнары да хөрмәт итә иде. Исмәгыйль абыйга кайчан да булса ярдәм кирәгер дип малай башың белән ничек уйлыйсың инде?! Юк, мең мәртәбә юк! Үзенә нык ышанган үги әтисенең вагон коридорында шаркылдап көлгәнен ишеткәндәй булды Бакиров.

Фуат Мансуровичны әнисе каршылады. Әнисе нык бирешкән, күрешмәгән биш ел эчендә нык үзгәргән... Соңгы араларда улы янына кунакка килүдән дә туктады. Бер дә сәбәпсез түгел инде, әлбәттә: карт-корының аяк-куллары да сызлар, аннары, поездларда йөрү дә, һай, мәшәкатьле эш. Вагонга кереп утырсаң, андагы халык... Дөньясы каядыр күчәнә диярсең.

Әмма шулай да төп сәбәбе шул иде: сыерны калдырып китәр кешесе юк... Элекке күршеләре балалары янына шәһәргә күченеп киттеләр. Ә яңалары — интеллигентлар. Кая ул кеше малын карау, үзләренең дә мал асрап караганнары юк әле. Сыерны бер генә көн саумасаң да, шундук ташлана, я сөте тәмсезләнә. Аннары утыр сөтсез чәй эчеп, майсыз бәрәңге ашап.

Еллары санаулы калган кеше өчен бик тә сизелеп үтә икән ул биш ел гомер... Чибәр иде Фуатның әнисе. Бу хакта аңа мәктәптә укыганда кызлар да әйтә торган иде. Соңрак, үсә төшкәч, инде кичләрен кызлар озата башлагач, култыклашып барган «алиһәләре» дә бу турыда телгә алгалыйлар иде. Сугыштан кайткач, күкрәге тулы орден-медальле Исмәгыйль абыйның да бер баласын иярткән Миңсафа апага өйләнүе гаҗәп түгел. Авылда кияүгә чыгарга атлыгып торан кызлар да аз булмагандыр, югыйсә. Бүләк авылыныкылар өчәү генә исән-сау әйләнеп кайтканнар иде сугыштан. Китүчеләр саны исә... Моны искә төшермәү хәерлерәк.

Фуат Мансуровичның туган йорты тәрәзәләренә кадәр җиргә сеңеп беткән иске генә өй иде. Исмәгыйль абый аларның ишегалдына үзенең «Диамант»ына утырып килеп керде. Элек бу урынны роза куаклары күмеп киткән иде. Юлдан эчкәрәк йорт салгач, роза куаклары ташландык хәлдә калды. Шунысы сәер: алар элеккегә караганда да матуррак булып утыралар. Тәрбия кылсаң, болай ук шау чәчәккә күмелә алмаслар иде әле. Койма буенда, эчтә дә, тышта да, утыргычлар эшләнгән иде. Пәкеле малайлар Бүләк авылында чибәрлекләре белән дан тоткан кызларның исемнәрен уеп яза иде бу утыргычларга. Элеп куйган ояңа сыерчык ояласа яки рәшәткә буендагы утыргычларыңда төне буе гашыйклар гөрләшеп чыкса, Бүләк авылында иң яхшы юраулардан санала бу. Фуатның да үз утыргычы бар иде — итекче Вася дәдәй йорты каршында...

Истәлекләр, истәлекләр...

Исмәгыйль абый яңа йортны моннан унбиш ел элек — Фуат институтны тәмамлаган елны салды.

— Билгеләнгән эштә срогым тулганчы гына эшлим дә бөтенләйгә Бүләккә кайтам,— дия торган иде ул. Әти-әнисе ышана иде аңа.

Йортны осталар яллап салдырдылар. Саман кирпечләрне чегәннәрдән сатып алдылар (җәйләрен чегәннәр Бүләк янында саман кирпече сугалар иде). Исмәгыйль абый ул елларны әле җегәрендә булса да, авыр эшкә ярамый иде инде. Әмма йортны ничек төзәтергә, төзегәндә нәрсәләр кирәк икәнлеген бик яхшы белә. Кемнең нинди эшкә кулы ятуын да аннан гына сора. Ул чакыргач, балтасын күтәреп Гани абзый килде. Үзе белән моңлы башкорт җырларын да алып килде ул. Миңсафа апа аны тыңлыйтыңлый кайчакта аш әзерләвен дә онытып җибәргәли иде. Вакытында төзеп калулары яхшы булды әле: хәзер, кем әйтмешли, балта осталары гап-гади борыс утыртып биргән өчен дә чамасыз хак сорыйлар. Тәрәзә яңакларының көлеп торуын гына кара син аның, өй кыегындагы төрле төсләргә буялган этәчене генә дә биш алтын бирерлек. Үткән бер кеше сокланмыйча калмый. Юкса, килешенгәндә мондый ваклыкларны телгә дә алмаган иде бит Гани абзый. Бөтенләй бушка ясап нинди матур истәлек калдырган.

Улын каршылаганда Миңсафа апаның эченә шатлыгы сыймады. Фуатны борчыганы өчен үзен азрак битәрләп алды анысы, тиккә бимазаламадымы икән, янәсе...

— Син инде, Фуат, әтиеңә пенсия турында ләм-мим сүз кузгатмаска тырыш. Яхшы түгел, яратмас. Болай да күңеле китек аның,— дип кисәтте ул Фуатны.

Эңгер-меңгер төште. Ишегалдына кайтып кергәндә күк читендәге шәфәкъ кызыллыгы да сүнеп өлгергән иде инде. Үги әтисе яшелчәләргә әле яңарак кына су сипкән, ахрысы, роза түтәлләреннән, ишегалдындагы тар гына асфальт сукмактан сизелер-сизелмәс кенә пар күтәрелә, дымлы һава поездда әлсерәгән тәннәргә салкынча рәхәтлек бирә.

Исмәгыйль абый җиз самавырга күмер салып маташа иде. Верандада ашамлык-

лары марля белән капланган әзер табын да, өйнең хуҗалары кебек үк, кадерле кунакны түземсезлек белән көтә иде.

Үги әтисе артык үзгәрмәгәнгә охшый. Тик керпе чәчләре генә агарып беткән. Исмәгыйль абыйның кечерәеп, суырылып калганлыгын Фуат Мансурович аңа якынрак килгәч кенә искәрде. Гәүдәсе шулхәтле утырган — хәтта Фуат Мансуровичның алтынчы класста укучы малае да бабасын буйга күптән узып киткән инде. Сөйләшүендә дә ниндидер үзгәреш сизелә: Фуат Мансурович әтисенең ясалма тешләр куйдыруын аңлады. Ниһаять, карт үз сәламәтлеген дә кайгырта башлаган, үзе турында уйларга да чират җиткән икән...

Фуат Мансурович әтисе белән кочаклашып күреште. Бер яктан ничектер уңайсыз да... Әмма җилкәсендә әтисенең көчле кулларын тою рәхәт тә иде аңа. Миңсафа апа өстәлдән нәрсәләрнедер алды, нидер өстәп куйды һәм ирләрне табын янына чакырды. Исмәгыйль абый исә колонка янындагы салкын сулы чиләккә утыртылган шешәне тартып чыгарды. Исән-сау кайтып җитү өчен берәрне күтәрделәр, артыннан җиңелчә генә тозланган кыяр каптылар. Сүз иярә сүз чыгып, әтисе шундыйрак сорау бирде:

— Озаккамы, әллә узып барышлый гынамы?

— Бераз торырмын әле,— диде Фуат Мансурович.— Туган йорт бик сагындырган. Һәм шулай әйтүе өчен шатланып куйды. Әнисенең җылы күз карашын, әтисенең туганнарча игътибарын тою рәхәт иде аңа. Самавырның пар бөркеп утыруы, тәнгә сихәт бирә торган авыл сөте — болар һәммәсе дә аның күңеленә якын. Сагынмаслыкмыни?! Бөтенләйгә монда каласы килде Фуат Мансуровичның. Ә бит заманында Бүләккә кайтырга хыялланып та йөргән иде ул. Үги әтисе, улының Төньяктан Урта Азиягә кайтасын белгәч, йортны да аның исеменә күчерткән иде. Менә, баксаң, йортның «чын хуҗасы» кайтып та төште.

Элек мондый өйләр Бүләктә юк иде әле. Киң, иркен, биек, якты, пыяла верандалы йортларны Бакировлардан күреп сала башладылар. Хәзер инде моннан да зуррак итеп төзиләр: верандалар җылытулы, өйләргә су кертелгән, өйне пар белән җылыту гадәткә әверелде Бүләктә. Яши белә хәзер кешеләр: ачлык, үзәккә үткән ялангачлык — барысы да онытылды. Фуат Мансурович Бүләкнең мондый муллыгында бөтенләй диярлек яшәмәде. Ара-тирә үтешли генә төн кунып чыгуларын исәпкә дә алырлык түгел. Матур тормыш биредә чирәм җирләрне күтәрүдән башланды. Беренче тапкыр өс бөтен, тамак тук чаклар илленче елларның ахырына туры килә. Бу вакытта Бакиров студент иде инде. Әти-әнисе Фуатка аз-маз акча җибәрәгли башлады — мул тормышның бер чагылышы иде бу. Күп түгел, әмма ул чордагы студент өчен җитә иде ул акчалар.

Картлар Фуатка йортның олы ягын бирергә уйлаганнар иде. Уртасында фикус гөле утырган иркен генә зал һәм ярымкараңгы йокы бүлмәсе... Килен төшүен дә шушы яңа йортта күрергә теләгәннәр иде. Фуат Мансурович та, узышлый гына кергән чакларында, монда кайтып яшәвен күз алдына китереп карый. Әй, рәхәт тә булыр иде соң! Әти-әнисе — янда, йорт төзек, хуҗалык әйбәт, сыер бар, яшелчә, җиләкҗимеш бакча тулы. Тагын нәрсә кирәк инде адәм баласына? Тик кирәк әйбернең иң мөһиме — эш урыны юк иде. Бөтен бәла дә шунда... Белеме буенча Бакиров — монтажчы инженер. Алтмышынчы еллар башында Төньякка эшкә билгеләнү бик гади күренешләрдән саналмый иде әле. Анда иң әйбәт студентларны гына сайлап җибәрәләр иде. Бакировка исә махсус заявка килде, аны өченче курстан ук Төньякка димли башлаганнар иде. Төньякта күнегелгән масштабны Бүләк авылында төшенә дә кертә алмас иден. Әнә бит, элеваторны да ике елга соңга калып төзи башладылар, аннары тагын туктатылды, җитмәсә, биш елга... Әйтерсең, элеватор төзергә шундый зур акыл иясе кирәк?! Егет бу хакта әти-әнисенә әйтмәде, көләрләр дип курыкты. Каян килгән зур инженер, янәсе, яңа масштаблы эш тапкан икән, имеш. Әти-әни исә бөтенләй башкача уйлый иде: СМУны соңга калып оештырдылар, аңа кадәр Фуат Урта Азиягә кайтып төпләнергә өлгерде, өйләнде, балалары туды.

Фуат Мансурович Ташкентта искәргәләп йөри: үзе кебек инженерларның күбесе авылда туып-үскән. Шундый зур шәһәрдә яшәп тә инженерлык сәләтең ачылмаган икән, бу — кызганыч. Андыйлар үзләренә җавапсызрак вазифалар тапканнар, төрле конторaларда эшләгән атлы кыланалар. Аларны туган якларына куып кайтарасы килә

башлый. Авылга бирәр файдалары тияргә мөмкин бит аларның! Безнең илнең кай төбәгенә барып чыксаң да, кая карама — төзелеш. Инде зур колачлы төзелешләрдә үзеңне күрсәтә алмагансың икән, кечкенәләренә рәхим ит. Авылны макта, шәһәрдә тор, дигән булып ялгышалар. Кайберләре гомер узды инде дип акланалар. Үзеңне табу яшьлеккә генә хас күренеш түгел, кеше үзен гомере буе эзләргә тиеш.

Фуат Мансурович иртән уянганда, үги әтисе промкомбинатка эшкә киткән иде инде. Чәйне верандада эчтеләр. Тәрәзәләре шар ачык. Әйбәт йоклаган иде, күңел дә күтәренке. Хәтта балачагы хатирәсенә охшашрак төш тә күрде әле ул. Фуатның кәефе яхшы икәнлеген белгәч, Миңсафа апа кош тоткандай куанды. Йөрәге кушкан-га түгел, бурычлы булганга гына кайткандыр кебек тоела иде Фуат аңа. Улының гамендә дә юк: бакчада уйнап йөргән кояш нурларына сөенеп-яратып карый, күрше ишегалдында сикергәләп биегән колынга елмая... Сагынган икән, сагынып кайткан икән!

Сөйләшеп сүз бетмәс сыман тоелган иде, шулвакыт күршедә яшәүче ике казакъ хатыны килеп керде. Ана белән улның сүзе бүленде. Миңсафа апа өлкәнрәгенә сүз кушты:

— Менә улым кайтты әле Ташкенттан. Анда бик зур инженер булып эшли,— диде ул горурланып.

Казакъ хатыны да җавапсыз калмады:

— Фуатны бик яхшы хәтерлим әле,— диде.— Кечкенә чагында гает бәйрәме белән котларга керә иде безгә. Тик ул чакта заманалар авыр иде шул, бик сыйлый да алмагандыр инде... Хәзер аллага шөкер. Илеңдә иркен булса, өеңдә милкең булыр ди бит. Керсәң, алла боерса, әйбәтләп кунак итәрбез, куй суярбыз, казан асарбыз, ачуын кайтарырбыз теге чакларның.

Фуат Мансурович чәен тиз генә эчте дә ахирәтләрне калдырып чыгып китте. Көне буе уйланып йөрсә дә, бәрхет жилет кигән әлеге казакъ түтәен хәтерли алмады ул. Кайда иде соң әле аларның өйләре? Юкса, элек ул хәтле зур да түгел иде бит Бүләк авылы. Хәзер әнә бер башыннан икенче башына чыгарга да күпме вакыт кирәк, үзәк урамнарына асфальт җәйгәннәр, иске йортлар урынына яңалары калка, саман кирпечтән салынганнарын ак кирпеч белән алыштыралар: болай матуррак, болай төзегрәк. Малай чакта үзе кереп йөргән бакчаларны караштыра-караштыра Бакиров собес урнашкан бинаны да узып китте. Собес бинасы искергән инде, түбә калайлары да күгәреп беткән. Элек РОНО да шушы бинада иде, кечкенә генә ике бүлмәсе бар иде аның. «Ярар, анда керергә өлгерермен әле»,— дип уйлады Бакиров һәм собеска соңрак сугылырга ниятләде. Әтисе утыз елдан артык эшләгән промкомбинат бинасына якынлаша төшкәч, адымнарын әкренәйтте. Урам аша чыкты да шул тирәдәге бер утыргычка чүгәләде. Сәрби куаклары ышыгына ясалган утыргычта тынычлап тәмәке тартып алырга да мөмкин иде. Әйе, Бүләк авылын эш белән тәэмин итеп торган промкомбинат үз вазифасын һаман да онытмый икән әле. Әтисе төн уртасына кадәр эшләгәндә, бирегә еш килә иде ул, әнисе төреп биргән ашамлыкларны китерә килә иде. Бәйрәм көннәрендә исә артельгә иртә таңнан йөгерә! Артель (авыл кешеләре промкомбинатны шулай атыйлар) бәйрәмне яхшы оештыра. Яңа ел бәйрәмнәрендә чыршылар алып кайталар, аны матурлап бизиләр. Хәтта иң битараф кешеләр дә, печенье-конфетларына кызыгыптыр, ахрысы, бәйрәмгә катнашып китәләр иде. Хәзерге мөмкинлекләрдән чыгып караганда да әйбәт үткән икән ул бәйрәмнәр.

Ишегалдында күккә ашкан цех биналарына күз салды Бакиров. Әнә тегесенең икенче катында аның үги әтисе эшли, палас тукый. Күзләрне камаштырырлык мондый паласларны районда кырылып алалар. Соңгы араларда өлкәдән дә сораталар, имеш. Эшләп кенә өлгерт. Исмәгыйль абый шундый савaплы хезмәт башкара. Бакировның әтисе янына керәсе килеп китте. Керергә иде дә янәшәсенә барып утырырга иде, комачауламыйча гына утырырга иде дә, төш вакыты җиткәч, авылның нәкъ уртасыннан икәүләшеп өйгә кайтып китәргә иде. Төш турына да озак калмаган югыйсә.

«Кая ашыгырга әле, өлгерермен»,— дип уйлады Бакиров, әтисенең пенсиясе турында башта промкомбинат парторгы белән киңәшеп карарга теләде. Әтисе коммунист түгел түгелен, аның каравы шушында утыз елдан артык үз көчен биргән, сугыш ветераны, орден-медальләр кавалеры...

Партком бүлмәсе бикле булып чыкты, хуҗасының кайда икәнлеген сораштырырга Бакиров җөрьәт итмәде. Парторгны эзләве әтисенә барып ирешсә?..

Фуат Мансурович тар гына коридордан чыгып бара иде инде, арттан аңа кемдер эндәште:

— Федя...

Бүләк авылында төрле милләт вәкилләре — рус, украин, татар, казакъ һәм башкалар яшәгәнлектән, бер-берләренә русча исем тагу гадәткә кергән. Тик менә эш документларга барып төртелгәч кенә төрле буталчык килеп чыга: ниндидер Гриша булып йөргән кеше паспорты буенча Гарифулла икән. Фуат Мансурович та кайчандыр Федя булып йөрде, үги әтисе — Алексей...

Борылып караса, элек урам аша гына яшәүче, гомер-гомергә артель бухгалтериясендә эшләгән Катя түтәй басып тора. Алар кочаклашып диярлек күрештеләр, ишегалдына да бергә чыктылар.

— Ничә ел очратканым юк иде инде сине, Федя?.. Ун еллап бардыр... Әле дә хәтерлим, Төньякта эшләгәндә өй туена кайткан идең. Минем ул чакта җырлап-биеп йөргән чаклар иде әле. Шәп йорт салдырды Алексей. Мактанган да иде әле, имеш, сине өйләндерәчәк, оныкларын караячак. Бала-чагаларың бармы соң?

— Берәү бар. Малай.

— Белмисеңдер дә әле, без бит хәзер казна йортында торабыз. Тимер юл артында. Безнең ише картларга йорт салу бик мәшәкатьле бит, акча да күп кирәк. Балалар да менә синең кебек таралышып беттеләр. Сирәк-мирәк кайткалыйлар болай. Әниең ничек яши? Карале, аны да ике ел рәттән күргәнем юк бит инде, гөнаһ шомлыгы... Бер авылда яшәп... Элек бит мин сезгә гел кергәләп йөри идем, җиз самавырыгыздан чәегезне аз эчмәдем. Шикәрләп тә, шикәрсез дә... Төрлесе булды инде. Күргәннәрне уйлап баксаң, куркыныч булып китә... Менә, безнең урамга да бәйрәм килде хәзер, без дә кешечә яши башладык. Нигә артельгә сугылырга уйладың соң әле, Федя?

— Парторгны очратып сөйләшергә уйлаган идем дә... Тик моны беркүк әтигә ишеттерә күрмә, яме, Катя түтәй.

— Авызыңнан җил алсын. Алексейны беләм мин. Собеска үпкә белдерүен ишеткән идем шул. Үзеңнең кайтып төшүең әйбәт булган әле. Вакыты шундый бит: бөтен эшне кәгазь белән алып баралар. Справка өстенә справка кирәк. Һәммәсе өчен ялынасың, ялварасың. Синең үги әтиең тумыштан шундый кеше инде ул, ачтан үләргә риза, әмма түбәнчелеккә төшмәс. Әниеңә генә авырга туры килә инде, андый баш бирмәс кеше белән яшәү җиңел түгелдер аңа. Әтиең дөрес яшәде синең, башкалардан да шуны ук таләп итте. Кешенең бит төрлесе бар. Син булышырга тырыш инде әтиеңә. Миннән эш калмады: бөтенесен исәпләп куйдым, өчәр тапкыр санадым. Әй, безнең вакытта акча артыннан куу бар идемени соң ул?!

Бакиров эндәшмәде.

— Менә бу папканы вакытлыча синең карамакка тапшырам, Федя, үзең карарсың шунда. Монда әллә нинди баш бетәрлек эш юк. Без бит гомер-гомергә Алексей белән бергә яшәдек, бергә үләрбез дә дигәндәй... Минем ирем Дмитрий да хәрби хезмәткә аның белән бергә китте, бергә сугышты, үлгәч, Алексей аны үз кулы белән җирләгән. Аерылмас ахирләр иде бит, волейбол ярышларында икәүләшеп катнаштылар. Районда беренче егетләр иде алар.

Әлеге юка гына папкага әтисенең эш хакларын күрсәткән гап-гади казна язулары гына түгел, анда гаилә язмышы теркәлгән иде. Алардан Исмәгыйль абыйның утыз ел буе промкомбинатта ничек эшләвен белергә мөмкин, саргайган кәгазь битләре Фуат Мансуровичка еракта калган балачак елларын хәтергә төшерде...

Бүлмәдәге язу өстәле артында утырганда аның янына еш кына әнисе кергәли, йомшак кына басып үтә дә саргайган кәгазьләрне кулына ала. Сакланып кына әйләндергәләп карый. Уку-язуга сәләте бигүк ачылмаган кешеләр генә шулай итә. Шәмәхә караның төсе уңа башлаган булса да, элекке күршесенең — Катя Панченконың укучылар каләме белән язган кулъязмаларын әнисе шундук таный. Юллар арасындагы санаулы гына тиеннәрне аңлаткан билгеләрне күрсә, шул җитә, иренең моннан егерме ел элек кем булып эшләвен әйтә дә бирә. Өй мәшәкатьләреннән бушаган ара-

ларда ерак еллар артына күмелгән моңсу истәлекләрне хәтергә төшерә. Үзе Фуаттан яшереп кенә яулык почмагы белән күзләрен сөртеп алгалый.

Утыз ел дәверендә үги этисе, бер үк оешмада эшләсә дә, үнлаган һөнәр алыштырган. Юк, Исмәгыйль абый һич кенә дә узгынчы булмаган. Аның сәләтенә сокланып, хезмәттәшләре: «Кулы алтын, акылы алтын!» — дияргә яраталар, һәм моны алар чын күңелдән әйтәләр. Фуат Мансуровичның моны дистәләгән тапкыр ишеткәне бар. Һөнәрен алыштырган икән, монда инде үги әтисенең бер тамчы да гаебе юк. Чөнки артель, әле оешкан гына елларны, плансыз-нисез эшли иде. Ел саен ниндидер яңа цех ачыла, икенчеләре ябылып тора иде. Тамак хакына эшкә урнашкан кеше нишләргә тиеш? Әлбәттә, ул бер буш урын табып, тиз генә яңа цехка җайлашу ягын карый. Бер ел узамы, юкмы, теге цехны тагын ябалар, ябылганын яңадан ачалар, тарау яткан коралларны җыялар да икенче өйрәнчекләрне эшкә кабул итәләр. Артель нинди эш белән генә шөгыльләнми иде: кондитер әйберләре дә пешерә, чаналар да ясый — җиңелен, урачәлесен, артлысын дисеңме... Ул чорларда өлкәдәге барлык председательләр дә Бүләк артелендә чыгарылган артлы чаналарга утырып йөри иде. Заманында Бүләк авылы оста куллары белән дан тотты: мамык шәл бәйләүме, тире иләп тун тегүме, итек басумы — һәммәсен сокланырлык итеп эшлиләр. Җил оясына басып хәтереңне еллар буе җиллатсаң да, боларны онытырлык түгел. Тик менә цехлар ябылу гына... Кешене уртак тормыштан читләштерүнең бер чагылышы түгелме бу?.. Бәйрәм саен орден-медальләрен тагып президиумда утырган Исмәгыйль абыйга артель начальнигы Иляхин, гафу үтенгәндәй, күзләрен идәнгә текәп әйтә торган иде: «Син ачуланма инде, Алексей, үзең беләсең хәлебезне. Яңа цехка өйрәнчек булып күчәрсең... Кайгырма, булдырырсың син аны». Ахрысы, фронтовик белән туры карап сөйләшергә оялгандыр. Фуат Мансуровичка ведомостьларның шундыйлары да очрап куя: үги әтисенең фамилиясе турысында 280—320 сумнар гына тора... Ә бит ул елларда шимбә көннәрне генә түгел, якшәмбедә дә ял итми иде халык, көнне төнгә ялгап эшли иде.

Миңсафа апа Фуат Мансуровичка мондый эчпошыргыч күңелсез хәлләрне генә түгел, шактый сөенечлеләрен дә сөйләде. Ул вакыйгаларның ире алган акчаларга бернинди катнашы булмаса да, Миңсафа апа ни өчендер сайлауларны сагынып искә төшерде. Төп агитпункт ул чакта мәктәптә урнаша иде. Сайлаулар башлануга бер ай кала агитпункт бүлмәсендә яңгыратып радиола сөйләргә кереша, аның тәрәзәләре еракtan ук балкып кичләрен кешеләрне үзенә чакырып тора. Фуат Мансурович әле дә хәтерли: сайлау көнне ул уянганчы ук әнисе белән үги әтисе агитпунктка китеп баралар иде. Алар аннан күтәренке күңел, якты йөз белән кайтып керәләр. Мөгаен, әтисе хезмәттәшләре, танышлары, дус-ишләре белән берәр чәркә тотып күйгандыр, әнисе исә әле рус гармунына, әле татар тальяны сыздырган көйгә «әйттергәндер»... Сайлаудан нинди дә булса тәмле әйбер алып кайталар: апельсин, хәлвә, арыш прянникедер, кипкән балык. Иртән ашап алгач, аннан-моннан гына киенеп ул үзе дә мәктәпкә йөгерә торган иде. Бәйрәмнең иң кызып кына килгән чагы. Яшьләр радиоладан яңгыраган музыкага мәктәп залында биеп яталар. Классларда гаипәләр баянга, гитарага, аккордеонга кушылып җырлыйлар. Буфетлар, кибетләр гөр килеп эшли. Бер почмакта шәһәрдән бәйрәм хөрмәтенә мул итеп кайтарылган сыра саталар. Ишегалдында исә райком секретарьларының җигелгән атлары тора. Чаналары, дугалары, бөтен сбруйлары шөлдер-кыңгыраулар, төрле төстәге сөлгеләр белән бизәлгән. Чаналарда — комач белән төрелгән кечкенә генә әрҗәләр. Бу әрҗәләрне урын өстендә ятучы карт-корыларга алып баралар. Бүләк халкы бердәм яклаган кандидатны сайлаганда аларны да читтә калдырырга теләмиләр. Иртәнге караңгыдан башланган сайлаулар төш җиткәнче тәмам да була, комиссия сайлауларның бертавыштан узуы турында шундук өлкәгә хәбәр итә. Әмма бәйрәм моның белән генә тукталмый, кич җитеп караңгы төшкәч тә өйләргә кучә.

Хатирәләргә бирелеп, Фуат Мансурович белән Миңсафа апа төш вакытына кадәр шулай утыралар. Берчакны хәтта Исмәгыйль абыйның өйгә кайтып кергәнен дә искәрми калганнар. Бакиров кәгазьләрен яшерергә дә өлгерә алмый калды, бәхеткә каршы, үги әтисе аларга игътибар итмәде бугай.

Кичләрен өстәл янында утырганда да, яшелчәләргә су сипкәндә дә Фуат Мансурович үги әтисе белән аз-маз гына сөйләшкәләде, анда да эшкә кагылышлы мәсьә-

ләләр турында гына... Олыгайган саен ирләр арасындагы мөнәсәбәт, хатын-кызларныкы белән чагыштырганда, катлаулана, кыенлаша гына бара икән. Еллар узган саен кызлар әниләренә якыная төшә, ата белән уллар арасында алай түгел... Бакиров моны бу кайтуында аеруча тирәннән тойды. Бәлки, Фуат Мансуровичның балачагы авыр елларга туры килгәнгәдер? Күрдемени соң алар буыны тиешле назны, иркәләүне?! Әти-әниләренең бөтен борчуы ничек тә балаларны ашату-киендерү булды, сөеп-иркәләп утырырга вакытлары да булмагандыр инде...

Исмәгыйль абый Миңсафа апага өйләнгәндә Фуатка алты гына яшь булса да, ул аны әткәй дип йөртмәде, үги әтисе аңа барыбер абый булып кала бирде. Чөнки Фуат үз әтисенең Мәскәү тирәсендә барган сугышларда үлеп калуын белә иде инде. Соңыннан да, үсеп җиткәч тә, әткәй дип эндәшмәде. Малайның мәхәббәтен яулап алыр өчен ниләр генә эшләп карамады Исмәгыйль абый: Фуатны үзенең хром утыргычлы зәңгәрсу «Диамант»ында йөрергә дә өйрәтте, чаңгы-чаналар да ясап бирде. Әмма Фуат авызыннан бер тапкыр да әткәй сүзе ычкынмады.

Буләк авылында күп кенә малайларның әтисе юк, алар Фуатка көнләшеп карыйлар иде: орден-медальләрен күргәч, Петька Васятюкның әтисеннән гәүдәгә кайтышрак булса да, Исмәгыйль абыйны авылда иң көчле кеше дип саныйлар иде. Әнисе өйдә юк чакта Фуат җиз калай белән бизәлгән кытай сандыгын ачып актарынырга ярата иде. Сандыкның бер тартмасында Исмәгыйль абыйның орден-медальләре саклана. Алар утыз! Иң беренче орденын Исмәгыйль абый утыз тугызынчы елны Хәсән күлендә ала. Фуат Мансурович әлеге бүләкләрнең дәрәҗәсен, кыйммәтен менә хәзер генә аңлады.

Кунаклар каршылаганда Исмәгыйль абый орден-медальләрен такмыйча йөрми иде. Сугыштан соңгы елларны аракы белән бик чуалмыйлар иде әле. Шешәле аракы сирәк-мирәк кенә, олы кунак килгәндә генә өстәлгә менә иде. Шуңа күрә хуҗа хатыннар кунакны каршыларга ике атна алдан әзерләнә башлыйлар — ачы бал куялар. Эчәргә йомшак булса да, ачы бал шактый куәтле. Аны һәр өйдә үзләренчә әчетәләр. Мондый нәмәрсәне куучылар аны сату белән шөгыльләнмиләр, шуңа күрә җирле власть та моңа игътибар итми иде. Мәҗлес көннәрендә Исмәгыйль абый орденнарның өчесен генә тага: менә хәзер, сандыкны актарып утырганда гына, Фуат Мансурович аларның Дан орденнары булуын аңлады. Үги әтисе дә Советлар Союзы Героена тиң кеше икән! Бу хәл күптән — Исмәгыйль абый үзенең әнисе Зәйнәп әбине ияртеп Миңсафа апаларга бөтенләй яшәргә дип килгән елларны ук булды шул. Фуатның аны вакытында аңламавы да бик табигый: малай чагы бит... Ул чакта әле Исмәгыйль абый да «Диамант»ына утыра да чыгып китә, станциянең «Локомотив» исемле волейбол командасының ярышларда ничек уйнавы белән бик кызыксына иде ул. Үзе дә сугышка кадәр шушы командада уйнаган.

Сугыштан соң Дан орденнары булган фронтовикларга эш хакына өстәмә түләү кертелгән иде. Бу хәл орденнарның дәрәҗәсен тагын да күтәрде, Исмәгыйль абыйга да горурлык өстәде. Ул әледән-әле орденнарын Миңсафа апаның хәтеренә төшергәләп тора иде. Өстәмә түләүне тиздән туктаттылар. Бу Исмәгыйль абыйдан кала Бүләк авылында башка кешеләргә кагылмады. Кайберәүләр өстәмә хак бетерелүне үзләренчә аңлатырга тотындылар: имеш, сугыш вакыты түгел бу сиңа күкрәк киереп йөрергә, анда син канга батып сугышкансыңмы, әллә иптәшеңә ышыкланып йөргәнсеңме — барыбер. Хәзер яңа заман башлана, син менә башкалар кебек эшләп күрсәт! Фуат Мансурович әле дә хәтерли, үги әтисе шундый сүзләр әйткән өчен Октябрь бәйрәмендә Оренбург ягыннан килгән бер вак спекулянтны кыйнап ташлаган иде.

— Провокатор, хәшәрәт,— дип кычкырды ул теге кешегә, җирән сипкелләре кан тамырларына охшап кызарып чыкты.— Синең кебекләрне мин стенага терәп атар идем. Корткыч! Спекулянт! — дип җикеренде ул Васятюкның көчле кулларыннан ычкынырга теләп.

Спекулянт аңа йодрык күрсәтеп ысылдады:

— Бигрәк узындыгыз. Монда да сугыш тәртибе кертмәкче буласызмы? Тот капчыгыңны! Менә эшләп күрсәтегез әле, карарбыз!

Шул вакыйгадан соң Исмәгыйль абый орденнарын сандыктан сирәк очракларда гына алып карарга гадәтләнде. Мондый җәнҗалларны Фуат Мансурович башка хәтерләми.

Өйгә кунак килүен балачагында Фуат өлкәннәргә карый ныграк ярата иде. Әтиәнисе күбрәк шул ук кешеләр белән йөрешә: Васятюк, Панченко күршеләр, ике-өч Оренбург татары (үги әтисе тумышы белән шул яктан), Миңсафа апаның таныш тол хатыннары, һәм, әлбәттә, гармунын аскан балта остасы Гани абзый... Бергә җыелышкан чакларда нинди генә җырлар яңгырамый — татар, рус, украин җырлары һич тә тынып тормый. Фуатка аларның шаулатып җырлап утырулары ошый иде. Өстәл янында утыручылар әледән-әле сугыш хәлләрен искә төшерәләр. Гадәттә болайрак башлана: «Германиягә бәреп кергәч...», «Польшаны коткарганда...» Әмма өлкәннәр тыныч тормыш турында күбрәк гәпләшәләр: кешеләрнең холык-фигыле, хәзерге көнкүреш, хуҗалык тоту, мал асрау... Тик сугышны, канкойгыч, җанкойгыч сугышны оныту мөмкинме соң?! Шул ук «Германиягә бәреп кергәч...», «Польшаны коткарганда...» аларның күпме дус-ишләре мәңгегә ятып калганнар бит...

Орден-медальләре хакында сүз чыкканда үги әтисе ике-өч исем әйтеп кенә җавап кайтара: «Днепрны кичкән өчен», «Киевны азат иткән өчен», «Брестны азат иткән өчен»...

Васятюк сөйли башласа, Исмәгыйль абыйның да күңеленә җылы иңә иде, ахрысы, ул да, кызып китеп, сугыш хәлләрен искә төшерә. Үги әтисенең сугышта күргәннәре бер-бер артлы күз алдыннан тезелешеп үтә. Хәзер, инде гәүдәсе бөрешеп калган картка караганнан соң, аның шундый фидакарь солдат булуына ышанасы да килми. Фуат Мансурович үсмерчакта ишеткән хикәялардән генә үги әтисенең нинди кыю разведчик булуын хәтерендә яңарта ала. Исмәгыйль абый разведчиклар отрядында сугышкан, дөресрәге, разведчиклар элемтәчесе булган. Немец-фашистларның тылына үтеп кереп, Исмәгыйль-солдат безнекеләр телефонын дошманнарның элемтә челтәренә тоташтырган. Безнекеләр ягында исә немец телен белүче офицер дошман ягындагы сөйләшүләрне тыңлап утырган. Ул бит сугышның башыннан ахырынача немецлар тылында йөргән, анда үтеп керүләре җиңел дисеңме?! Бәлки, үзенең немец милләтенә хас җирән чәчле булуы үги әтисен үлемнән коткарып калгандыр. Сугышта ул полк тегүчеләре әзерләп биргән вермахт формасында йөргән, илен сакларга дип күкрәгенә кысып тоткан автоматы да немец «Шмайссер»ы булган.

Фуат Мансуровичның балачагында хәтеренә иң нык уелып калган хикәяте дә бар әле. Бервакыт үги әтисе немецлар тылында, багана башына менеп, дошманның элемтә челтәренә чыбык ялгый икән. Коралы, кием-салымы, килеш-килбәте — барысы да немецчәкә. Әйтерсең, немец элемтәчесе. Ә иптәшләре якындагы куак арасында көтеп ята. Нәкъ шул мизгелдә генә унбишләп немец солдаты килеп чыкмасынмы!.. Совет разведчигы аларга игътибар итмәскә тырыша тырышуын да, тик кая ул, тегеләр шаярып ниндидер сүзләр кычкыралар, кул болгыйлар. Инде нишләргә?.. Разведчик чыбыкның очын тиз генә авызына каба, имеш, аның мәшәкате зур, сөйләшергә вакыты юк. Үзе барыбер тегеләргә «дустанә генә» рәвештә баш селки, кул изи. Күлмәге терсәккә кадәр сызганылган, беләге тулы җирән сипкел — яз бит! Нигә шикләнәсез инде, янәсе, мин бит шат күңелле, шаян холыклы батыр Ганс. Нечкә генә муенында «Шмайссер» атына, багана төбендә сары тун ята — ышанмасаң, кара, бөтенесе дә немецчәкә, хәтта тун өстендә аунаган авыз гармуны да немецчәкә!.. Фуат Мансурович үги әтисенең куркудан аяклары дерелдәвен, куллары ирексездән муенындагы «Шмайссер»га үрелүен күргәндәй булды. Тик атарга ярамый, ярамый! Йөзеннән салкын тир ага, һәм ул, күзләрен сертергә дә онытып, авызына чыбык капкан килеш салкын тир аша дошманнарга елмая...

Эшен җайга салырга бер атна да, хәтта ун көн дә җитмәслеген аңлады Бакиров, шулай да ул үзенең Алуштага баруын уена да китермәде. Хатыны шалтыратып хәтеренә төшермәсә, путевка хакында бөтенләй оныткан иде инде. Хатыны кайтып ярдәм итәргә теләвен әйтте, әмма Фуат Мансурович ризалашмады: «Мин монда барысының да эзенә төштем инде, хәзер Алуштага очарга әзерләнәм»,— диде. Чынлыкта исә Бакиров Оренбургка җыена иде. Юк, үзенең студентлык еллары узган шәһәрне күреп кайтырга гына түгел, Исмәгыйль абыйның туу турында таныклыгындагы әтисе исемен һәм туган елын дөресләп кайтыр өчен. Бу собес өчен кирәк иде. Собеста утыручы яшь кенә кызлар халык судьясы Бакирова биргән белешмәгә күз дә салмадылар. Мондагы кызлар шулкадәр битараф ки, аларны юмалап та, ачуланып та игә китерү

мөмкин түгел иде. Ниһаять, Фуат Мансуровичка килешергә туры килде һәм ул туу турында таныклыктагы хатаны төзәттерермен дип вәгъдә бирде.

Таң тишегеннән поездга утырып, Фуат Мансурович Оренбургка китеп барды. Ятакка урнашып бер-ике сәгать черем итеп алырга мөмкин булса да, проводник кызның чакыруына да карамыйча ул кешесез тамбурда баруны хуп күрде. Майлы тузан белән капланган пычрак тәрәзәне сөрткәч, йомылып калган станция һәм разъездларны күзәтеп бару яшьлек хисләрен уятты. Бу юлда ул аз йөрмәде, кайчандыр Бүләк белән Оренбург арасындагы һәр станция, һәр разъездның исемен яттан белә иде. Хәзер инде онытыла да башлаган,— Фуат Мансурович берничәсен генә таныды: Мартук, Яйсән, Акболак, Сагарчин... Кайберләрен танымаслык булып җурайган, истәлеккә атамалары гына калган.

Тәгәрмәчләр тыкылдавы кырык җиденче елгы күренешләрне кирегә әйләндерә башлады.

Фуат мәктәптә укый иде әле. Кыш ахырларында кинәт кенә Зәйнәп әби вафат булды. Ничек тавыш-тынсыз яшәгән булса, Зәйнәп әби дөньялыктан да шулай ук тыныч кына китеп барды. Гадәт буенча, мәрхүмәне шул ук көнне юып, җирләргә әзерләнделәр. Тик өйдә бер кисәк тә кәфенлек юк иде. Кәфенгә яраклырак җәймә кисәге дә табылмады хәтта. Андый елларда тукымалар кибетләрдә сатылмый да иде әле. Кышы да авыр килде җитмәсә. Ягулыкка ярты хезмәт хакы китә. Ул көнне Фуат мәктәпкә бармады. Әнисенең башы чуалган иде, кемгә әҗәткә керергә белмәде. Үги әтисе... Ул кемнән генә бурычка сорар икән, Васятюктанмы? Алар бит Исмәгыйль абыйлардан да фәкыйрьрәк яшиләр...

Исмәгыйль абый башын учлап озак утырды, ахырда җәһәт кенә торды да киенде, кышлыкка әйбәтләп майлап куелган зәңгәрсу «Диамант»ны — өйнең бердәнбер матурлыгын һәм горурлыгын, сугыштан кайткан бердәнбер трофейны алып буранга чумды. Ярты сәгатьтән әйләнеп тә кайтты. Аның кулында чәй-шикәр, бер шешә аракы иде, калган акчаны Исмәгыйль абый Миңсафа апага бирде. Фуат өйдән-өйгә йөреп, әбисенең үлгәнлеген әйтеп чыкты. Буран эченнән зиратка таба кешеләр тизелешеп үтте. Салкын булуга да карамастан, каберне тиз казыдылар. Каберне тиз тотсалар да, Миңсафа апа ак марляны төш турында гына таба алды. Фуат Мансурович еллар аша ишеткәндәй булды: «Әнә, орден тагып йөрүче Исмәгыйль үз әнисен марляга төреп гүргә иңдерде, ун метр бәз дә таба алмады...» — дигән гайбәт таралган иде ул чакта. Монысында Исмәгыйль абый берәү белән дә сүзгә килмәде, бөтен кайгы-хәсрәтен эченә йотты. Гайбәтләр тора-бара тынды, күңел яралары төзәлде. Язга чыккач «Диамант»ка кем утырып йөрер икән дип Фуат гаръләнеп тә, кызыксынып та көтте. Әмма «Диамант» Бүләктә бүтән күренмәде, җир йоткандай, башы-аягы белән юк булды...

Тар гына тамбурда әрле-бирле йөренгәндә, Бакиров әлеге тимер юл линиясенә бәйләнешле тагын бер вакыйганы хәтерләде.

Фуатның икенчеме-өченчеме класста укыган чагы, Зәйнәп әби дә, зәңгәрсу «Диамант» та юк иде инде ул вакытта. Яз җиткәч, итек басу цехын яптылар. Фуатның үги әтисе йомшак киез итекләр баса иде. Җил ыжгырып торган далаларда, салкынякларда киез итектән дә кадерлерәк нәрсә юк, аны бер аяк киеме дә алыштыра алмый. Итек басу цехында эшләнгән киезләрне казакълар келәм урынына йөртәләр иде. Бу шактый катлаулы һөнәргә әтисе барысыннан да тизрәк өйрәнгән һәм киез итекләрне барысыннан да остарак баса иде. Киез басучының эше бик авыр: көне буе тузан суларга, лычма су киезне көннәр буе тигезләргә, барысын да кулдан эшләргә кирәк. Калынлыгын, тыгызлыгын чамалый алмасаң, ОТКда утыручы саңгырау Шәйхи әйберeңне хәзер бракка чыгара. Үзе бернинди дә һөнәр белми, шул үҗәтлеге өчен генә артельдә тоталар иде аны, ахрысы. Ул кышны Миңсафа апа да киез итеккә тиенде, Фуатка да бик матур пималар алып кайтып бирде Исмәгыйль абый. Үзе чем-кара, йоп-йомшак, җып-җылы... Бераздан цехны яптылар, кайбер штатлар да кыскартылды. Дөрес, әтисен цехта калдырдылар, тик аңа да эш бирмәделәр. Иляхин бу юлы: «Өйрәнчек булып барырсың...» — дигән сүзләрен дә әйтмәде. Көннәрнең берендә эшсезлектән аптырап йөргән Исмәгыйль абыйга Гыймай абзый шундыйрак киңәш бирә:

— Менә мин үзем тире иләү цехында эшлим, тиредән калган майлардан, яры-

лардан рәхәтләнеп сабын кайнатып булыр иде. Содадыр, төрле химикаттыр табарга артельнең көченнән килә. Тотын син сабын кайнатырга!

Сабын кайнату иң дәрәҗәсез һөнәр булып санала. Әле утыз яшен яңа гына тутырган Исмәгыйль абый ике уйлап тормый, Гыймай абзый белән килешә.

Ул елларны өйгә сеңгән сабын исе Фуат Мансуровичның әле дә хәтерендә, кер сабыны күрсә, хәзер дә аның тыны буыла башлый. Хатыны бу хакта яхшы белә, кер сабыннарын ирена күрсәтмәскә тырыша, керне дә ул өйдә юкта юа.

Шулай итеп, Исмәгыйль абый сабын кайнату тәкъдиме белән Иляхин янына керә. Председатель сүзне кыска тота:

— Башта син миңа бер әрҗә сабын ясап күрсәт, аннары мин сиңа рөхсәт бирермен,— ди.— Миннән эш калмас.

Бүләк авылында сугышка хәтле дә, сугыштан соң да сабын кайнатып караучы булмый. Күңелгә коткы салучы Гыймай абзый да бу эшне нечкәләп белми икән. Шуңа күрә ул Исмәгыйль абыйга Оренбург якларын урап кайтырга куша.

— Анда,— ди ул,— Ырынбур татарлары сабын кайната беләләр, өйрәнеп кайт шулардан.— һәм, кирәге чыкса дип, бер танышы адресын да бирә.

Шул ук көнне Исмәгыйль абый вокзалга китеп бара. Сугыштан соңгы елларны бөтен узгынчы поездлар да, Бүләккә туктап, су алалар, паровоз мичләрен чистарталар иде. Җирдә май ае чәчәк аткан чак, җылы, рәхәт. Исмәгыйль абый, сыртын кояшка куеп, вагон түбәсендә Оренбургка тиз барып җитә. Тик менә Оренбургка җитәрәк поезд барган шәпкә сикерергә кирәк була. Вокзалга кадәр утырып барсаң, милиционерлар билетсыз пассажирларны шундук эләктереп алалар да түләп бетерә алмаслык штраф салалар. Исмәгыйль абый, кайчандыр разведчик булган кеше, бу сынауны да уңышлы үтә.

— Карале, бу өлгер егет җиңел генә сабын кайнатырга исәпләгән икән,— ди пеләш башлы кырыс старшина. Исмәгыйль абыйның фронтовик, җитмәсә, якташы икәнлеген белгәч, аңа сабын кайнатуның бөтен серләрен өйрәтә. Ярты капчык ниндидер химикатлар бирә.

Килгән юл белән үк кайтырга кирәк була. Тик потлы капчыкны вагон түбәсенә күтәреп менү җиңел түгел бит. Ничек итсә итә, әмма вагон түбәсенә үрмәләп менә бу.

Сугыштан соңгы елларда җылыга ияләнгән кесә карак лары ипигә бай Урта Азия якларына агыла иде. Алар да акча түләмичә генә вагон түбәсендә йөрергә яраталар. Әлбәттә, төрле шәһәрләрдә, авылларда туктала-туктала куна-төнә барган бу сукбайларны икмәккә бай Ташкент яклары гына кызыктырмагандыр. Андыйлар үтә гаярь була, юлда очраганны чишендерергә дә күп сорамыйлар. Әлеге сукбайлар хакында нинди генә хикәяләр сөйләнми иде.

Шундый бер төркем сукбай кайсыдыр станциядә вагон түбәсенә үрмәләп менә. Моны Исмәгыйль абый соңрак искәреп ала: борылып караса, вагон түбәләрендә нигәдер кешеләр сирәгәйгән... «һәрберсендә кимендә өчәр кеше иде бит әле, кая киткән болар?» — дип гаҗәпләнә ул. Күрәсең, тегеләр эшне койрыктан башлаган, үз әйберсен сакларга тырышып та көче җитмәгәннәрне түбәдән тәгәрәтә барганнар, ахры. Тегеләр якынлашырга өч-дүрт вагон кала Исмәгыйль абый алгарак — паровозның төтен бөркеп торган торбасына таба ук шуышырга уйлый. Инде алай да барып чыкмаса, тотарга да берәр вагон эченә төшеп утырырга. Әйдә, түләтсәләр түләтсеннәр штрафны... Исмәгыйль абыйның кузгалып паровоз түбәсенә таба атлый башлавын күргәч, карачаклар да аның артыннан йөгерергә тотына. Шунда аның тәне эссе借-суыклы булып китә: менә бу борылыштан соң йөз метр узгач, күпер чыгасы бит! һәм ул капчыгын вагон түбәсенә яткыра да карачакларга кычкыра: «Күпер! Күпер! Күпер...» Үзе дә түбәгә сеңеп үк ятарга чак кына өлгереп кала, поезд, тәгәрмәчләрен такылдата-такылдата, тимер күпергә ашыгып килеп керә. Баш очында күпернең кыршаулары чагылып уза. Күперне кичкәч, Исмәгыйль абый башын күтәреп карый, теге егетләр дә берәм-берәм кузгалалар. Йөзләреннән кан качкан, агарынганнар, үзләре Исмәгыйль абыйга тартырга тәкъдим итәләр.

— Әй, мужик, капчыгыңда нәрсә ул? — дип сорый «Казбек» папиросы сузганы.

— Алтын,— дип җавап кайтара Исмәгыйль абый битараф кына.

Сукбайлар кәлешеп алалар, битләренә бераз алсулык йөгерә. Башлыклары:

— Алай бик бай булгач, түбәдә кызык өчен утырып йөрисеңмени, миллионшик? — дип мыскыллы сорап куя.

— Вагонда һава җитми,— ди Исмагыйль абый.

— Шулай да капчыгыңның авызын ачып карыйк әле, шуның өчен чак кына үлмичә калдык бит. Елгыр кеше икәнсең, куркудан башың томаланмады, күперне онытмадың. Рәхмәт сиңа, мәңге онытмабыз.— Барысы да Исмагыйль абыйга яргаланып, бөгелеп беткән кулларын сузалар.

— Ай-яй сасы,— дип зарлана капчыкка башын тыгып караучысы.

Исмагыйль абыйга ни өчен Оренбург якларына баруы, Бүләктә ничегрәк яшәве турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирергә туры килә.

— Ташла син боларны, сасып бетәсең бит син сабын кайнатып. Бөтенесенә төкер дә киттек безнең белән, Ташкентта җаен табарбыз әле,— дип өнди аны атаман.

Исмагыйль абый, рәхмәт әйтеп, аның тәкъдимен кире кага. Барган шапкә генә берәвесе ресторанга төшеп аракы, капкаларга алып менә. Түбәдә бәйрәм итә-итә ул шулай Бүләккә кайтып төшә.

Оренбургта Фуат Мансурович дүрт көн тоткарланды. Исмагыйль абый дөньяга килгән Заһид хәзрәт мәхәлләсендәге архивның яртысыннан күбрәге граждannар сугышы вакытында юкка чыккан. Биредә Дутов бандалары торган. Аннары, архивны бер бинадан икенчесенә күчереп йөрткәндә дә кайбер төпләмнәр эзсез югалган икән. Миңсафа апаның моннан дүрт ай элек архивка язган хатын да Бакиров көчкә эзләп тапты.

Оренбург бөтенләй үзгәргән, өлкәдә газ чыганагы тапканнан соң, ул ике мәртәбә зурайган. Шәһәрнең кай тарафына барып чыксаң да, шырпы кабына охшаш бертөсле үк йортлар тезелгән. Хәер, бөтен шәһәрләр дә шундый йортлар хисабына үсә инде хәзер. Фуат Мансуровичның яшьлеге шушында узса да, ул аннан бернинди дә якты хатирә алып китә алмады. Шәһәр өчен Бакиров ят кеше иде инде... Оренбургта тапкан кечкенә генә ике белешмә кәгазе бердәнбер юанычы булды.

Ял көннәре уза торды. Фуат Мансурович үз бурычын үтәгән өчен генә түгел, әтиәнисенә, авылына, авыл халкына, аның табигатенә нинди дер якынлык тоеп яшәде, аның күңеле тыныч иде, Бакировның күптән инде мондый халәт кичергәне юк иде.

Документларны собеска илтеп тапшырганнан соң, ул я велосипедка утырып, я җәяүләп Илек елгасы буена барып чыга, су коена, кояшта кызына, балык тота. Тик әллә нинди шәп суалчаннарга да, махсус әзерләнгән җимнәргә дә вак балыклар гына эләгә. Кичкә таба ул өйгә ашыга, үги әтисенең эше бетүгә кайтып җитәргә тырыша. Өстәл янында әкрен генә сөйләшә-сөйләшә кичкелекне ашау аңа бик ошый. Аннары яшелчәләргә су сибәләр, каралты-кураны тәзәткәлиләр.

Катя түтәй биргән кәгазьләргә карап Фуат Мансурович үги әтисенең үз гомерендә нинди һөнәрләр үзләштерүен белде: ул кепкалар, бүрекләр, күнитекләр теккән, сабын гына түгел, конфет та кайнаткан, бер елны артельнең яшелчә бакчасында су сиптерүче механик та булып эшләгән, келәт мөдире авырып киткәч, ярты елга якын аны да алыштырып торган. Кыскасы, ни генә эшләмәгән ул. Бакиров уйлап куя: әгәр дә Бүләктә шахта ачылган булса, Исмагыйль абый күмер чабарга төшәр иде, завод-фабрика салсалар, станок янына басар иде.

Елга буенда йөргәндә Бакиров үги әтисенең үткән гомерен мең кат исәпләде, мең кат үлчәде. Элегрәк, Фуат я Ялтадан, я Сочидан, я Палангадан кайтышлый берике көнгә өйгә сугылып чыкканда, Миңсафа апа да, Исмагыйль абый да улларыннан исемнәре колакка ятышлы, күңелне иркәли торган әлеге төбәкләр хакында сораштыралар иде. Алар бу шәһәрләрне открыткаларга, шәраб этикеткаларына төшерелгән рәсемнәрдән күреп кенә беләләр. Ләкин бервакытта да: «Менә без дә эшләдек бит, ул шәһәрләрнең читен дә барып караган юк әле»,— дип ризасызлык белдермәделәр. Пенсиягә расчет ясаганда рәттән егерме бер графада «файдаланылмаган отпуск өчен компенсация» дигән язуны укыганнан соң, Бакиров шуларны хәтерләде. Башта ул сүзләрнең мәгънәсен дә төшенмәгән иде, кинәт аның акылы яктырып киткәндәй булды: кеше егерме бер ел буе ял итмәгән! Ни өчен болай булганлыгын Фуат Мансурович әнисеннән дә сорарга уйлаган иде, аннары аңлады: нигә әле әнисенең исенә авыр елларны әйләндереп кайтарырга?! Бу хәлгә ышанмыйча Бакиров кәгазьләрне күп тапкырлар актаргалады, барысы да дөрес, төп-төгәл егерме

бер ел! Мена сиңа кирәк булса... Ике елга бер генә мәртәбә ял итәм, бик арыдым дип Фуат Мансурович әти-әнисенә һаман саен зарлана иде. Ә мескен картлар үзләре турында авыз ачып ичмасам бер сүз дә әйтмиләр, икенче ел ял итмәгән улларын кызганып тик утыралар иде.

«Шушы картларга зарланганмын икән...» — дип, ояла-ояла үкенде Бакиров. Һәм ул уйлары белән Ташкентка — ун мең кешелек үз оешмасына әйләнеп кайтты: анда да Исмәгыйль абый кебек кешеләр аз түгелдер. Беләме соң ул аларның ничек эшләүләрен, ничек ял итүләрен, пенсиягә киткәндә алар белән дә мондый буталчык, аңлашылмаучылык килеп чыкмый микән?.. Юк, боларны Фуат Мансурович белми. Аларның да Ялтаны, Сочины күргәннәре бармы икән... Дөресен әйткәндә, Фуат Мансурович андый хәлләр белән кызыксынмый иде.

Илек буена Бакиров атка атланып кичләрен дә килгәләде. Күрше Мостафа агайның улы Мукаш колхозда бригадир булып эшли, тәнендә казакъ каны уйнаган бу егет атларны үлеп ярата, хәтта үзенең бәйгеләрдә генә катнашырга дип саклап тота торган Каракүз кушаматлы чаптары да бар. Өлкә бәйгесендә җиңгәннән соң очар Каракүзгә чабаннар «Жигули»лар да тәкъдим итеп карадылар. Мукаш, чаптарга менгән килеш, «Жигули»лар рәтенә өстән генә карады, ризалашмады. Җәйге урак өстендә Мукаш көне буе кырда, төнгелеккә дә өйгә кайтмый, кырда куныл кала. Мостафа ага Каракүзне Фуат Мансуровичка бирә, рәхәтлән, янәсе, Мукашның атта кайгысы юк. Бакировның китәр вакыты җиткәч кенә Мукаш Мостафа ага турында авыр хәбәр җиткерде. Иртүк йокысыннан уянган Фуат Мансурович, әз булса да әнисенә булышырга теләп, сыерны көтүгә куарга җыена иде.

Ишегалдында кинәт кенә пәйда булган Мукаш:

— Әти үлде, Мостафа агагыз вафат...— дип кычкырды. Чибәр егетнең йөзе кара коелган, этисенең көтелмәгән үлеме көлачлеген юып алган.

Миңсафа апа тиз генә Исмәгыйль абыйны уятырга йөгерде. Фуат Мансурович көтү куып кайтканда, Исмәгыйль абый көрәкләрнең какшаган сапларын ныгыта иде, янәшәсендә лом да ята. Мостафа агайга кабер казышырга Фуат Мансурович та барырга булды.

— Бар, бар, улым,— диде аңа әнисе, өйдән әчлектер, берлектер җыеп җәмгысе егерме сум акча сузды.— Безнең соңгы аксакалларны күреп кал, син аларны онытмаска тиеш. Әтиеңнең яшьтәше ул. Киләсе кайтуыңда барысының да бәхиллеген алып китәрсең... Акчаларны өләшерсең, горефе шулай... Мостафа агайга багышлап дога кылсыннар, урыны җәннәттә булсын, әйбәт күрше иде, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын...— Миңсафа апа улын капка төбенә кадәр озата чыкты.

Халык урам буйлап чокыр артындагы зиратка агыла. Ак сакаллы бер карт зиратта Мостафа агайның төп йорты урынын билгеләп куйды. Картлар иртәнге намазны укып бетергәнче, кабер казучылар бер читтә көтеп торды.

Кайчандыр кара эшчеләр — итек басучылар, сабын кайнатучылар, мич чыгаручылар, йорт салучылар, чана ясаучылар, көтүчеләр булып эшләгән бу картлар, ай-һай, алланың барлыгына ышаналармы икән?.. «Мулла» аты күтәреп йөрүче Миңлегали агай да кайчандыр ятлап алган бер-ике дога гына укый белә, халык сораганга гына шундый вазифаны үтәргә риза булгандыр, мөгаен. Тик алар борынгылар горефенә тугрылык саклап, Мостафа агайны бөтен шартына туры китереп җирләргә тырыштылар.

Кабер казырга кеше күп җыелган иде, эшне тиз тоттылар. Рәвешенә китереп картлар да берәр көрәк балчык алып ташлагандай иттеләр. Исмәгыйль абый азакка кадәр көтеп тормады, эшенә барыр вакыт җиткән иде. Ул Фуатка көрәкләрне алып кайтырга кушып, сиздермичә генә төркемнән аерылды да артель ягына таба атлады.

Бөтенесе таралышып беткәч тә, Фуат Мансурович кайтырга ашыкмады, зиратта йөрде. Каберләрдә чәчәкләр дә юк, аларда яшел чирәм, сары кылганнар гына үсә. Бакиров кабер ташларына уелган язуларны укып йөрде, күбесенең исемнәре таныш иде. Инде зираттан чыгып барганда ул кыйшайган кабер ташына игътибар итте, аны турайтып куярга теләде. Бәлки, бу кабер караучысыз калгандыр...

Шактый ук авыр кабер ташын турайтып куйганнан соң Фуат Мансурович анда язылган сүзләрне чак-чак укый алды: «Кашаф Вәлиев. 1923—1949 еллар». Астарак та-

гын язу: «Безне онытмагыз...» Утыз ел аша Фуат Мансуровичка егерме алты яшьлек егет эндәшә иде: «Безне онытмагыз... Безне онытмагыз...»

Кашаф Вәлиев... Кашаф. Аның бит Бакировлар өендә бернична мәртәбәләр булганы бар иде. Сугыштан исән кайткан өч егетнең берсе. Яши алмаган, матур еллар килгәнче яши алмаган икән якты дөньяда... Димәк, өч егетнең хәзер икесе исән: үги әтисе һәм Васятюк. «Безне онытмагыз... Безне онытмагыз...»— дип дәшә кебек иде моңсу күзле Кашаф.

Кичләрен Бакиров үзбәкчәләтеп ясаган айманда үги әтисе белән утырырга гадәтләнде. Айманга әтисе дә, әнисе дә бик сөенделәр. Исмәгыйль абый әле нык булса да, эштән арып кайта, көне буе аяк өстендә бит... Әтисе терсәк турына мендәр куя да шарыкчәләтеп кырын ава, «Прима» сигаретын ирен читләренә кыстыра. Мондый хәлләрдә Фуат Мансурович күңеленә ниндидер яңа дулкын, җылы дулкын кагылганын сизә, әтисенә ягымлы итеп эндәшәсе, берәр яхшылык эшлисе килеп китә.

Үги әтисенең ничек итеп горур, ирләрчә, түбәнсенмичә, үз дәрәҗәсен шушы озын гомерендә дә саклап калган хәлдә яшәвен Фуат Мансурович элегрәк аңлап бетерми иде әле. Шәйхи белән булган бер вакыйга Фуат Мансуровичның күңелендә нык уелып калган.

Исмәгыйль абый белән Шәйхи арасында яшерен көрәш барганлыгын ул белә иде. Әйе шул, аларның тормыштагы урыннары да төрлечәрәк. Шәйхи, Исмәгыйль абый кебек башлангыч белем генә алган булса да, начальникларга яраша белгәч, җылы урында гына эшләде. Үзенең бер эш рәтен дә белмәвенә ачуы килеп, оста куллы Исмәгыйль абый ясаган әйберләрдән гаеп табып, һәрвакыт аңа бәйләнеп яшәгән. Гомере буе өйрәнчеклектә йөргән Исмәгыйль абый бу шөгыльдән туяр, көннәрнең берендә барысына да кул селтәп, эчкечегә сабышыр, эшкә йөри алмас. Аннары инде эш калдыручының артына да тибәргә мөмкин. Шундыйларны тикшерүчеләрнең комиссия председателе дә булып йөргән әлеге надан саңгырау карт. Әмма солдат бирешмәгән, баш та имәгән, ярдәм дә сорамаган. Шуның өчен дә Исмәгыйль абыйның йөзләгән кепкасы, ничәмә пар итеге я өченче сорт булып киткән, я бракка чыгарылган. Көннәрнең берендә бу хәл карт солдатның теңкәсенә тияр, барыбер алдыма килеп тезләнер дигәндер Шәйхи. «Кызган, Шәйхи, алла хакына кызган хәләл көчемне!» — дигән сүзләрне ишетергә теләгәндер ул. Юк, аның өмете акланмаган, Исмәгыйль абый килмәгән, тезләнмәгән. Шул ук «брак» кепкаларны, бүрекләрне, киез итекләрне Шәйхинең дуслары киеп йөргәнен дә күргән ул югыйсә. Тик Исмәгыйль абый бервакытта да Шәйхигә: «Карак! Булдыксыз!» — дип тә кычкырмаган. Әмма Шәйхи Исмәгыйль абыйның көне буе эшләп арыган-кызарган күзләреннән барыбер шул сүзләрне укыган: «Карак! Булдыксыз!» Шуңа күрә дә аңа һәрчак бәйләнеп яшәгән.

Шулай да бер мәртәбә Исмәгыйль абый Шәйхине төп башына утырта. Аның тегермәндә эшләгән чагы була бу. Онны колхозга да тарталар, кирәк оны хакына аерым хуҗалыкларга да тартып бирәләр.

Вакыйга Яңа ел бәйрәме алдыннан була. Шәйхи үзенең улларын ияртеп тегермәнгә килә. Әлбәттә, берәүгә дә ни сәлам бирми, ни күтәрелеп карамый. Тезелеп торган чиратны күрми дә. Чираттагылар һәркайсы үз икмәген башта үлчәтә, тиешле процентны түләве хакында квитанция яздырып ала, аннары илтеп мөшкәгә сала, улактан аккан онны капчыгына тутыра. Исмәгыйль абый онның ничек тартылуын тикшерә, тегермән ташын әле күтәртә, әле төшертә, квитанцияләр язып бирә, тарттырган өчен тиешле процентны казна әсәгенә күчертә. Кемнеңдер оны тартылып беткәч, Шәйхи бер казакъны чираттан төртеп чыгара, икмәген малайлары мөшкәгә илтеп салалар. Кая ул үлчәтү, квитанцияләр яздыру — ул турыда уйламый да! Боларны күзәтеп торган Исмәгыйль абыйның ачуы кабара. Он әйбәт тартыла, мөшкәдән йомшак он агылуын күреп, Шәйхи дә, малайлары да куана, шатлыклары масаюлы йөзләренә чыга. Малайлар капчык авызын тотып торалар, Шәйхи лардагы онны чумырып тутыра да башлый. Исмәгыйль абый үзенең көчсезлегеннән, чираттагылардан ояла. Әмма ул ачудан кара янган йөзен күрсәтмәскә тырыша, кинәт кенә өстәле янынннан кузгала да кемнеңдер капчыгын үлчәүгә куйдыра, аннары өскә менеп китә. Нәрсәнедер боргалый, төзәтә. Он тагын да әйбәт тартыла башлый. Кинәт нәрсәдер шатырдап куя, он урынына ниндидер ләпек нәмәрсә агарга кереша.

Шәйхи акырырга, зыянны түләтәм дип җикерергә тотына. Исмәгыйль абый тыныч кына килешә.

— Мин,— ди ул,— синең икмәкне түләргә риза. Тик башта күрсәт әле миңа квитанцияңне, карыйк әле, тегермәнгә ничә пот ашлык алып килдең икән?

Шулай итеп Шәйхи беренче мәртәбә отыла. Әмма соңыннан Исмәгыйль абыйга тегермәнне үз хисабына төзәтергә туры килә.

Китәсе вакыт килеп терәлгәч тә Бакиров ашыкмады, пенсия хәл кылынуын көтте. Бер-ике көнгә тоткарлануы хакында эш урынына телеграмма да сугарга уйлаган иде инде. Нәкъ шул көнне Исмәгыйль абый төш вакытында ук кайтып керде.

— Булды,— диде ул куанычлы тавыш белән.— Әле генә кадрлар бүлегенә чакырттылар...— һәм ул һәр айның икенче числосында пенсия алачагы турында сөйли башлады.— Җитмеш ике таңкә, әнисе, Шәйхинең күпме әле, алтмыш сигез генәме? Җитмеш ике таңгә безгә җитәчәк ул, әнисе, шулай бит. Безгә күп кирәк түгел, дөрес әйтәмме?

Миңсафа апа башта ышанмыйчарак торды, аннары, шатлыгын яшерә алмаган хәлдә, тыз-быз йөреп табын әзерләргә тотынды.

— Хәзер тынычлап ял итәрсең инде,— диде картына.

— Һы, мин бит сине шатландыру өчен генә әйтүем. Үземә нәрсә... Гомер буе эшләгәнне, хәзер генә тик ятмам инде, пенсия дигән булып...

Миңсафа апа мондый шатлыклы көндә ире белән бәхәскә кереп тормады, кичен кунаклар чакырырга дип җыена башлады.

...Иртәнге салкынча һавага алар өчәүләшеп чыктылар. Капканы ябарга да өлгермәделәр, урамны иңләп-буйлап бер төркем велосипедчы узып китте. Итальяннарның төрле төстәге лак белән буялган никельле «Феррари»ларын күргәч, Фуат Мансуровнч балачак илендә калган зәңгәрсу «Диамат»ны хәтерләп куйды.

Поезд тиз килеп җитте. Бүләк станциясендә өч кенә минут туктап торырга тиеш булганлыктан, Бакировка үз вагонын шундук табып бирделәр. Тамбурга ул берүзе күтәрелде һәм картларга борылып карады. Үги әтисе янәшәсендә Миңсафа апа гәүдәгә калкурак, яшьрәк, чибәррәк күренә. Малайлар свитеры кигән Исмәгыйль абый яшүсмер гәүдәле генә. Ничектер кызганыч, таянычсыз булып тоелды ул Фуат Мансуровичка. Һәм аның тамагына төер килеп утырды...

Иске гадәт буенча поездның китәчәген белдереп станция кыңгыравы яңгыраса да, состав кузгалмый торды. Нәкъ шул вакытта каяндыр зират ягыннан моңсу күзле Кашафның тавышы ишетелгәндәй булды: «Безне онытмагыз... Безне дә онытмагыз...»

Поезд кинәттән тартылып кузгалды да тизлеген арттыра башлады. Фуат Мансурович, тоткага ябышып, ишектән башын тыкты да тәгәрмәчләр тавышы аша, үги этисен соңгы мәртәбә күргәндәй, ачынып кычкырып җибәрде:

— Әткәй! Әткәй!..

Русчадан **Хәйдәр ГАЙНЕТДИНОВ** тәрҗемәсе.

## Рәфикъ Юнысов

### Очыш

*Мәскәүдә, Югары Комсомол мәктәбе ишегалдында, тавыш барьерын үткән беренче самолет — Г. Мосолов сынаган Миг-17 истребителе тора.*

Сүнгән яшен минем алда.
Фюзеляжын сарган тузан.
Үзе тузган, хуҗасы — карт.
Бар да узган?

Әйе, узган. Нәрсә шуннан?!
Бөек мизгел булган, булган!..

Бер көнне ул тагын килер.
Канатына кулын салыр.
Тагын — очыш, тагын — давыл!
Сызып-сызып янар йөрәк —
Җанда бар да кабатланыр!

Хәтер — бензин, хәтер — дары!

Еллар гына аеры бары:
Сөрән салып, кылыч айкап
Революциягә очкан
Илнең кызыл җайдаклары!

Атың үлсә — йөгән кала.
Җанның утлы тулпарлары —
Истәлекләр исән кала.

Нинди бәхет — күңелеңдә
Ат чабышлы җыр булуы,
Хыял барьерларын үтеп
Киләчәккә ыргылуы!

### Аерылмамын

Мең-мең чишмә тибә булыр җанда.
Ә мин белмим аның йөзен дә.
Мин — елга.
Тик кая агасымны
Әйтә алмыйм әле үзем дә.

Белмим әле нинди буласымны
Чикләп алса кайгы, боегу...
Күңел иркенәйгән чаклар булыр.
Тирәнәю булыр, саегу.

Борылмалар булыр. Ләкин беләм,
Борылмасым беләм яманга.
Дулкынланмый, әйе, яши алмам,
Диңгез булып шауламасам да!

Тагын шуны беләм! Ахыргача!
Тартсалар да кырык ягымнан,
Елга җирдән аерылмаган кебек,
Аерылмамын туган халкымнан!

●

Кеме генә юк бу яшәешнең!
Бүгенгене кара, үткәнне.
Королевлар, Бахлар белән бергә
Мин дә кирәк булдым микәнни?

Чакырган бит — үги түгелмендер,
Урыным бар бугай дөньяда.
Цезарьларга карап көлгән кояш
Миңа да бит әнә елмая!

Тормыш җыры. Күптән башланган ул.
Өзелмәскә тиеш, тынмаска.
Дирижеры була алмам, ләкин
Тырышырмын көйне бозмаска.

«Бәлкем син дә эзсез югалмассың —
Чагылышың яшәү күгендә
Шәфәкъ булып бераз янар, бәлки». —
Дип пышылдый хыял күңелгә.

## Орлыклар

Суны тапкан балыклардай
Буразнага сикерәсез.
Күкрәк эзләгән бәби күк
Җир дымына үреләсез.
Сез беләсез,
Барысын да сез беләсез!
Башак шавы, кояш назы —
Сездә бар да тамгаланган.
Тоныкк хәтер килә сезгә
Сезнең ерак бабалардан.
Беләсездер кем чәчкәнен
Җиргә тәүге орлыкларны.
Без — аларның оныклары!
Зәңгәр күкле бу йолдызга
Бүләк итеп бирелгәнбез,
Гөлнең ике сабагы күк
Бер язмышта үрелгән без!
Безнең уртак бәхет булып
Яңгыр килгән, кояш көлгән.
Килсә кайгы сезнең илгә
Безнең йөзләр кара көйгән!
Еракларга барырбыз без,
Үтеп бергә хыял чиген.
Хыялымда Галәм тулып
Уйный серкә, шаулый иген!..
Мәңге бергә! Сизәсезме:
Җиңеләя бара юллар?
...Нәни йөрәкләр типкәнен
Тоя кебек минем куллар.

## Без күрәбез сезне

*Күпме «бүген» күчкән «кичә»гә —*
*Күк томанга көннәр төренә.*
*Ачыла да томан, үткәннәр*
*Тарих булып кабат терелә.*

Күреп торам «Бүген» тавында
Киләчәккә илткән эзләрне...
Аермачык булып алдымда
Изрәп ята «Үткән» үзәне.

Каушый күзләр: ниләр генә юк!
Ут белән боз бергә йөрәктә.
Кайный тормыш янда гына ук!
Бераз ары! Ерак-еракта!

Морза кызы бизи калфагын.
Лашманчылар урман кисәләр.
Хәрабәдә ята Карфаген.
Дарданеллны кичә Искәндәр [1]...

Упкын кебек урта гасырлар:
Йоклый илләр, төнне кочаклап.
Дөрли бары бөркет җанлылар —
Жанна, Ян Гус [2] янган учаклар!

Аерылган күпме гасырга
Гадиләрдән ялгыз галиләр:
Ачышларны кемгә ачарга?! —
Уй-газапта Әбү Галиләр [3].

Йотылып карый, карый Бруно,
Тоткан килеш ялкын пәрдәсен.
Кемнән алсын соңгы җылыны,
Соң карашын кемгә төбәсен?!

...Ярдәм генә кыла алмыйбыз:
Киләчәктә — биек үрдә без.
Нык булыгыз, газизләребез,
Без күрәбез сезне, күрәбез!

●

Җир өслэтеп барасың син —
Гомеркәең ничә атлам?
Үткән генә, сүнгән генә —
Аста тормыш катлам-катлам!

Аста «сөям», «сагынам»нар...
Җир шуңа да җылы бит ул!
Болын булып көлсә дә Җир,
Чишмә булып елый бит ул!

---

[1] Искәндәр — Александр Македонский
[2] Ян Гус, Жанна д Арк — инквизиция корбаннары
[3] Әбү Гали — Әбугалисина

Мансур Вәлиев

# ЗИЛӘ

НОВЕЛЛА



Ул арып, йончып ерак командировкадан кайтып килә иде. Башында бер генә уй: тизрәк өйгә кайтып җитү, тизрәк урынга аву һәм йоклау... Берни уйламыйча, бернигә карамыйча озаклап, рәхәтләнеп йоклау. Ял итү, ял итү...

Шуңа күрә яшьләр белән тулган шау-шулы кечкенә трамвайда да һичбер нәрсәгә игътибар итми генә барды ул. Тәмам алҗыган бу кешене бүген инде дөньядагы бер генә әйбер дә үз-үзенә каратмас, дикъкатен җәлеп итә алмас кебек иде. Аяк өсте кайтса да, күзләре йомылып-йомылып китәләр.

Командировкага барган шәһәрдә ничә көн буе өешмәдән өешмәгә чабу, аннары шыгрым тулы поездда шулай ук ярым утырып, ярым басып диярлек кайту — болар барысы да менә хәзер, ял итү сәгатьләренә бик якын калгач, үзен нык сиздерә башлады. Аның бөтен гәүдәсе менә-менә авар да, шул ауган урында ук күптән татылмаган озак йокыга талыр сыман.

Үз тукталышын ниндидер аңлашылмаган билгеләр буенча сизеп, ул башкаларга ияреп кенә вагоннан төште. Аннары нәрсәдер уйлаган төсле, салкын урам уртасында бераз басып торды да, авыр гына атлап, үз ягына таба китеп барды. Аңа хәзер җир асты юлыннан урамның теге ягына чыгарга кирәк иде... Анысы да чыгылыр, автобусы да килер. Өенә дә әкренләп кайтып җитәр ул...

Бу уйлар үзләреннән-үзләре адымнарын ашыкмас, салмак җайга көйләделәр. Аның арыганлыгы, дөньяга битарафлыгы бөтен хәрәкәтенә чыкты.

Сак кына басып җир асты юлы баскычыннан аска таба бер-ике адым атлау белән, аның игътибарын янәшә төшеп килүче берәү җәлеп итте. Нәрсәсе белән, ничек? Ул моны үзе дә белми. Кайчагында шулай серен аңлата алмаслык нәрсәләр була бит. Ниндидер билгесез тойгы аларны бер-берсенә тартты. Тартты һәм әкренләп телгә сүзләр иңде. Алар әллә нинди тыныч иплелек, баштан ук бер-берсенә карата туган ышаныч һәм эчке ихтирам хисе белән сөйләшеп киттеләр.

Башта Кәрим:

— Кара әле, тайгак икән монда... — дип куйды.

Баскыч чынлап та бозланып каткан иде. Мондый караңгырак чакларда аннан төшүе дә шактый кыен иде.

Аннары ул йомшак-тыныч тавыш белән:

— Әйе шул...— диде бугай.

Йокымсырап кайтучы Кәримнең күзләре ачылып, зиһене шунда гына уянып киткәндәй булды. Әллә инде «егылып хурлыкка калмыйм тагы...» дигән уй аның йокысын ачты, әллә янәшәдә бик якында ишетелгән әлеге йомшак аваз Кәримгә шулай тәэсир итте — ул бик тиз исенә килде. Әллә каян гына сүзләр дә табылды.

— Сез каранғыда ялгыз йөрергә курыкмыйсыз икән...

— Ялгыз түгел ич.

— Кая, тагы кемегез бар?

— Менә сез бар.

— Мин?

Кәрим шаянрак тонда, елмаебрак сөйләшкән жиреннән, бу сүзне ишеткәч аптырап китте. Үзе белән рәттән атлаучы бу ять-яшь кызның аңа һич көтмәгәндә «менә сез бар» дип әйтүе бик тә гажәп кебек иде. Бу — Кәрим өчен бик яңа, таныш түгел нәрсә иде. Шуңадырмы, ул сүзне баштагыча шаянрак рухта дәвам итү мөмкинлеген бөтенләй исеннән чыгарып жибәрде. Сөйләшүеннән ук тукталып калды.

Күбрәк үз эченә бикләнеп яшәүче, кешеләргә караганда ешрак үз уйлары белән аралашып, шул дөньяда гомер итүче Кәрим — үзе турында сүз чыкканда, игътибар үзенә юнәлгәндә, һәрчак диярлек югалып кала иде. Мондый вакытта аның бөтен фикер агышы салмаклана, ә сөйләвен инде әйтәсе дә юк... Гомумән, ул бик мавыккан чакларында гына әйбәт гәпләшә ала сыман — бу вакытта ул әллә нинди нечкә мәгънәле матур сүзләр табып, онытылып сөйли. Ә болай — гадәти, тыныч сөйләшүләргә кушылып китү аңа бик кыен.

Әле ярый, сүзне кыз дәвам итте.

— Мин сез кайткан трамвайда идем... Сез уртада басып бардыгыз. Беркая карамыйча, беркемне күрмичә. Тәрәзәгә генә текәлеп. Ә мин, әллә нишләп, гел сезне күзәтеп бардым... Вокзалдан бирле. Озак күзәткәннән соң сез ышанычлы кеше дигән фикергә килдем.

— Алайса, минем белән жир асты юлыннан үтәргә дә була дип санамыйсыз инде?

Инде хәзер кыз тукталып калды.

Ул бу сүзләргә җавап бирмәде.

Кәрим бөтен уйлаганын шундук әйтеп биреп ялгышлык ясадымы — ничектер җайсызрак килеп чыкты... Хәер, сүздә җорлык житмәгәнен Кәрим моңарчы да еш кына искәреп ала иде. Башкалар төребрәк, яшеребрәк, һич югы әз генә хәйлә кушып, матурлабрак белдергән фикерләрне ул, алдын-артын уйлап тормыйча, үзе тойган бөтен дөреслеге белән әйтеп ташлый шул! Күп чагында, теге яки бу очрак өчен бик үк кирәк булмаган сүз дә ычкынгалый. Аннары инде, үзенең үтә тәрбияле саналган иптәшләренә ул сүзләрнең ничегрәк тәэсир иткәнлеген чамалап алгач, ул бик уңайсызлана. «Бу юлы да шулайрак килеп чыкты, ахры»,— дип уйлады Кәрим. Ләкин кыз эчтән үз-үзен телгәләргә тотынган Кәримне бераз тынычландыргандай итте.

— Иптәш кызларыма барган идем. Бергәләп семинарга әзерләнеп утырдык та, соңга калынды...

Бу инде сүзнең Кәрим теләгән якка борылуы иде. Шуңа күрә ул, жил чыгуын көтеп алган тегермән кебек, акрын гына булса да яңадан кузгалды.

— Әле сез студентка да мыни?!

Әмма, теле ул сүзләрне әйтү белән, башында шундый уй ялтырап узды: «Арудан әллә баш тәмам эшләми башлаган инде минем? Ничек инде ул — студентка да мыни? Сез минем турыда тагын нәрсәләр беләсез соң, дип сораса? Ул чагында көймәң комга терәлә бит, картая баручы яшь иптәш...»

Ә-ә, юк, бусында дөрес әйтелгән икән!

Кәримгә чыннан да аның турында бик күпне белә кебек тоелды.

Бергә атлап барган шушы ничәдер минут эчендә Кәрим аңа күңеленнән бөтен әйбәт сыйфатларны биреп куйган, үзе өчен кызның образын тудырып өлгергән иде инде. Аның ак якалы озын пальто кигән зифа буе, төнге урамда да матурлыгы сизелеп торган озынча йөзе, барыннан да бигрәк, кыш салкынлыгын онытгырырлык җылы тавышы — һәммәсе дә кызны Кәримнең идеалы булган тәрбияле дворян кызларының берсенә әйләндергән иде инде. Ә дворян кызлары аның күңеленә күбрәк рус художникларының картиналарыннан, декабристларның легендар хатыннары аша кереп калган, күрәсең... Алар — сын һәм йөз чибәрлегенең җан, күңел матурлыгы белән тулыландырылган бердәнбер чагылышы сыман иде.

Янәшәсендә атлаган әлеге чибәргә тагын бер сыйфат өстәлгәнгә күрә ул: «Әле сез студентка да мыни?» дип сорады бугай инде... Чөнки, Кәрим уйлавынча, хыялга якын торган яшь матурлык бары тик студенткаларда гына була иде сыман. Башка кызлар аның өчен артык гадәти кебек.

Кәрим белән кыз әкрен генә атлый-атлый тагын әллә ниләр сөйләштеләр. Әмма бу инде алар өчен үзенең чын мәгънәсен югалтты төсле. Сүзләр — бу ике йөрәк арасында җәйрәп аккан кичерешләр дәрьясының маяклары гына кебек иде.

Төнлә белән зур елга ярына басып карап торганда да күзгә бары тик әнә шул маяклар гына күренә. Ә елга үзе, күзгә күренмәс олы, көчле ташкын булып, серле караңгылык эчендә, бары аның үзенә генә билгеле дөньясы белән агып ята... Аны бары тик күңелең белән генә тоеп, сизеп була...

Алар инде бүтән баскычтан өскә, урамга чыктылар.

Мөнда — зур шәһәрнең зур урамында — яктырак та, хәрәкәт тә күбрәк. Алар арасында пәйда булып, икесен дә бер-берсенә серле көч белән тартучы әлеге күзгә күренмәс агымга бирелә кыен иде.

...Әйе, дөнья кешеләр арасындагы мондый кабатланмас садә мизгелләрне саклауны үзенең төп вазифасы итеп санамый шул... Дөньяның да, кешеләрнең дә бүтәнрәк максатлары бар....

Менә бүген алар арасында эчкерсез саф дөнья туды. Ләкин ул — әлеге ике кешелек мохит — шушы зур тормышта яшәргә тиеш бит! Әлеге кечкенә дөнья зур дөнья белән килешә алырмы соң? «Егерменче гасыр» дип аталган көчле хәрәкәт эчендә ул үзенең бөтен нечкәлеге, сафлыгы белән исән, тере кала алырмы?..

Кәрим — инде күптән гаилә корып караган һәм барып чыкмагач (ул моны үзенең ашыгуыннан күрә иде), барысын онытгыра ала торган бер көчле ярату очраганчы өйләнмим дип үз-үзенә ныгытып сүз биргән, хәзер буйдак тормышына күнегеп килүче утыз биш яшьләрдәге кеше — мондый сорауларга җавап бирердәй хәлдә дә түгел иде инде. Аның өчен хәзер дөнья ачыграк бәйләнешләрдән торган шактый нык төшенчәгә әйләнгән иде. Ул аның әнә шул ныклыкларын гына күрә һәм аңлый башлаган иде. Ә нечкәрәк һәм нәфисрәк нәрсәләр — аякка уралып еш кына комачаулык тудыручы вак-төяк кебек иде аның өчен. Олы эшләр вакытында мондый чүп-чарның гел булуын һәм аларның санга сугылмавы, искә алынмавы ниндидер мөһимрәк күренгән максатлар аркасында акланганны да белә иде Кәрим.

Шундый уйлар белән яшәп, ул үзендә барган эчке үзгәрешне дә олы, җаваплы эшенә бәйләп аңлатырга ияләнеп китте.

«Мин үз гомеремдә берәр зур эш эшләп калырга тиеш,— дип уйлый иде ул.— Ә нечкәлекләр, кешегә хас йомшаклыклар — минем ул эшемә комачаулаячак кына. Алар белән мин гап-гади, әзергә-бәзер килеш, хәлиткеч үзгәрешләр ясауга сәләтсез кеше булып кына яши алам. Дөньяның әзер матурлыгына куанып, шуны татып, шуннан тәм табып йөрүче кеше буларак кына... Ә мин моннан гына канәгать түгел. Бу — ми-

нем өчен бик тә аз. Дөньяның бер почмагын гына булса да үзем дөрес дип санаганча төзисем, төзәтәсем килә минем. Күңелем шунсыз канәгатьләнмәячәк... Күңелдәгенең чынга ашуын, күзгә күренерлек чынбарлыкка әверелүен күрү кирәк.

Гомумән, ниндидер үсешкә ирешкән һәрбер рух һәм күңел үзенең реаль эшен, реаль матурлыгын тудырып, җир йөзендә калдырып китәргә тиеш. Ул аны үзенә тиң тәрбияләнгән баласы рәвешендә калдырамы, эшләгән зур эше янсә иҗат җимеше итепме — барыбер. Әмма матур күңел, көчле рух үзеннән бер эз калдырырга тиеш!»

Әйе, ул үзен күбрәк әнә шундый уйлар белән юатып йөри башлаган иде соңгы вакытта. Ә эшендәге бер-бер артлы килеп торган уңышлары аның бу фикерләрен, басып тору җирлеген тагын да ныгыталар, дөресләгән раслыйлар иде. Ул үз өлкәсендә инде күпләр тарафыннан танылган, нык хәзерлекле, көчле белгеч санала. Эш стихиясендә ул үзен судагы балык кебек — иркен, ышанычлы сизә. Иң мөһиме — көчен, нык адымнар белән алга баруын тою аңа тагын да күбрәк нык лык, үз-үзенә ышаныч бирә иде.

Әйе, моңа кадәр шулай иде.

Ә хәзер?

Хәзер, менә шушы минутта Кәрим үз-үзенә, үзенең һәр яктан килгәнлегенә, яхшылыгына, камиллегенә эшендәге кебек, эш дөньясындагы сыман тулысынча, ныклап ышана аламы? Ул үзен андагыдай көчле сизәме? Кешелек тойгылары тулы икәнен, шикләнмәслек дөрес яшәвен һәм моңарчы да шулай яшәгәнлеген сизәме ул хәзер? Шуңа иманы камилме аның?

...Яп-якты автобуска кереп, кыз белән янәшә утырып бара башлагач, аны адашуын сизенү тойгысына охшаган ниндидер халәт били барды. Әлек адашканлыгыңны хәзер генә аңлау идеме бу, әллә менә хәзер, шушы вакытта адашып йөрүеңне сизенүнең күңелне сүлпәнәйтүче тәэсире идеме — Кәрим моны аера алмады.

Яп-якты автобус эче үзе дә Кәримне тыңлаячак, аны хөкем итәчәк бер суд залы сыман тоелды. Аның яктылыгы — кискен, катгый, һәммә нәрсәдән, һәммә кешедән ачыклык, аныклык таләп итүче яктылык иде һәм ул нәрсәсе беләндер аны куркыта да, ни өчендер шикләндерә дә. Әле генә үзендә ниндидер күңел талпынуы сизгән, һич көтмәгәндә билгесез ашкыну, каядыр, кемгәдер тартылу, ымсыну тойган кеше — ул идеме соң? Кәрим үзе идеме? Әгәр чынлап та шулай булса — хәзер ул нишли, ни хәлдә бара? Янәшәдәге яшь кыз үзенең бөтен барлыгы белән аннан әнә шуңа җавап көтә иде кебек.

Җиңелүләргә күнекмәгән, эшендәге гайрәтне, өстен булуны гомумән тормыштагы көчлелек дип санарга ияләнгән, аларны үзара тигез күрә башлаган Кәрим экренләп кызаруын тойды. Югарыга менеп барганда әйтерсең лә ул аягы белән басарга тиешле ниндидер басманы таба алмаган да, шуңа күрә хәзер бушлыкта түбән таба оча, каядыр түбәнәя бара...

Кәрим инде автобус урыныннан кузгалып киткәннән бирле күңеленнән бу яшь гүзәлгә тиң сүзләр эзләп килә. Ул үзендә шундый көчле сихри сүзләр тудырырдай моңарчы тоелмаган ашкынулы хәрәкәт, дулкынлану, кичерешләр табарга тели. Үз күңелендә шундый — тел белән әйтеп булмый торган нәрсәләрнең акылга буйсынмаган шашкын агышын табасы, аңа юл бирәсе, ул ташкынны тышка, дөньяга чыгарасы килә. Шушы ташкында үзенең дә кинәт кенә югалып каласы, иярен агасы, күңелне ымсындырган шул стихиядә бер яшәп аласы килә.

Әмма никтер — бер сүз эндәшмичә яисә, юк-бар сүз сөйләшкәләп, күпме генә көтмәсен — аның күңеленнән ургылырга тиешле әлеге ташкын үзен сиздермәде. Кәрим кызның матурлыгын күзләре белән күрде

акылы белән аңлады, ләкин ничек кенә тырышса да, көч куйса да шуннан ары уза алмады.

Бу — Кәрим өчен гаҗәп һәм яңа ачыш иде.

Бу — моңарчы бер дә уйланмаган нәрсә иде.

...Кәрим аны өйләренә хәтле озатып куйды. Кыз, саубуллашып, биш катлы йорт ишегеннән кереп югалгач, ул инде арудан түгел, ә бөтенләй башка уйлардан салмакланып, акрын гына үз өенә таба китте.

Төнге аулак урам шушы кыска гына арада да байтак нәрсә турында уйландыра иде. Кәримнең үзенең дә бик ашыгасы килмәде. Өенә кайтканчы, иялэнгән мохитына яңадан кереп киткәнче, аңа нәрсәнедер аңлап бетерәсе бар иде кебек. Һәм ул теләк алдагы тормыш өчен бик мөһим дә кебек.

Ә ике көннән ул хат алды. Һәм аны төшендәге кебек укыды. Бу хәл һич тә өнгә, чынга охшамаган иде.

«Сез мине ачуланмагыз, мин — Зилә, теге кичне сез озатып куйган кыз. Адресыгызны каян белүемә дә аптырамагыз. Ул кичне сездән соң мин өйгә кермәдем. Сезнең кайда яшәгәнегезне бик беләсем килде. Һәм мин әкрен генә артыгыздан бардым. Өегезне, подъездыгызны күрдем. Хәтта, почта ящигыннан газеталар алуыгызны карап торып, ничәнче квартирада яшәвегезне дә белдем. Ә бу хатның чит кеше кулына эләгүеннән курыкмыйм мин. Чөнки теге чакта сез күпме көннәр җыелып торган почтаны алдыгыз — димәк, өегездә ящикны сездән башка ачмыйлар. Логика шәпме?! Ярый, бусын калдырып торыйм әле.

Сезне борчып нигә бу хатны язарга булдым соң әле мин? Һич кирәкмәгәнгә аптыратып... Беләсезме, минем бер үзгәрмәс кагыйдәм бар: кеше үз күңеленә хыянәт итмәскә, аны беркайчан да алдамаска, хәйләләмәскә тиеш. Менә хәзер сезнең каршыгызда шуның белән акланам. Мин хатны шул кагыйдәм кушуы буенча яздым. Ә ни өчен яздым? Сезне ошаттым бугай мин... Ул кичне трамвайда юл буе сезне күзәтеп кайттым. Сез кереп басу белән үк. Йөзегезнең һәр хәрәкәтен, кашларыгызның, иреннәрегезнең һәр кыймылдавын күреп, күзәтеп бардым. Килеп җиткәндә сез инде миңа бик таныш, бик якын кеше идегез. Әллә шуңа күрә инде, баскычтан да янәшә төшә башладым. Юллар да бер якка булып чыкты, минем бәхеткә. Бары тик сөйләшә башлагач кына мин үземнең хыялымда чынбарлыкны әзрәк узып киткәнемне аңладым. Чөнки тавышыгыз — минем өчен яңа, ят тавыш иде.

Ә бәлки мин бу хат белән сезнең кәефегезне кырамдыр?

Бәлки сез башка берәүне бик ярата торган бәхетле бер кешедер? Мин сезне бу хатым белән борчыйм гынадыр? Ләкин минем сезгә бик тә, бик тә хат язасым килде. Шуны язып мин хәзер үз-үземне ачам кебек. Күптән көткән үземне. Хат язганда гына булса да, үземнең хәзерге чынлыгымны матурайтам, матуррак яшәп алам кебек. Миннән тагын хат алсагыз, аптырамагыз, яме... Хәзергә сау булыгыз! Зилә».

Кәрим хатны бер укып чыкты, яңадан укыды. Андагы сүзләрне тагын-тагын күңеленнән үткәрде. Әмма аңа шактый вакыт бер фикер дә килмәде. Ул берни уйлый, берninди хәрәкәт кыла алмаслык сәер бер халәттә, хатка текәлгән килеш, кыймылдый да алмыйча басып торды. Билгесез бер вакытка ул үзенең эшкә чыгып баруын да, бүтән көнне өй бусагасыннан атлау белән хәл кыла башлый торган эреле-ваклы мәсьәләләрен дә онытты. Бер генә минутны да бушка, юк-барга уздырырга яратмавын да, гомеренең һәр минутын диярлек эш өчен генә файдаланып килүен дә — барысын-барысын да үзе дә сизмәстән исеннән чыгарды ул. Әйтерсең, бу минутларда шул хәтле көч куелып үткән гомер бөтенләй булмаган да.

Сәер онытылу халәтеннән соң килгән беренче хис, теләк шундый иде: кинәт кенә аның бу хатка бик нык ышанасы килеп китте. Аны күптәннән зарыгып көтелгән нәрсә дип кабул итәсе килде. Кәрим үзен түзем-

сезлек белән хат көткән, хат язарга тиешле кешесен бик тә, бик тә сагынган итеп тоярга теләде.

Һәм бу теләк, бу омтылыш — әллә нинди бер көч табып, җиңеләеп, күккә күтәреләсе килү теләге кебек иде. Ул күтәрелү чынга ашса, моңарчы яшәлгән тормышның бик күп ягын аста, түбәндә калдырачак иде. Аларны вак, кирәксез, артык мөһим түгел нәрсәләргә әвереләдерәчәк иде. Кәрим үзе дә, ирексездән, шуның белән килешер төсле иде.

Кызганычка каршы, ул бу халәтендә озак басып тора алмады. Икенче каттан төшеп килүче ир-ат, очрашканда эндәшми китүне зур начарлык дип санаучы танышы:

— Нәрсә, авылдан язалармы? — дип аны, бер хат — бер канат белән каядыр күтәрелергә омтылган адәм баласын, үзләренең баскыч төбенә үк, Кәримнең басып торган урынына китерде дә куйды. Кәрим ничек җавап биргәнен үзе дә аңлый алмастан:

— Ә, әйе...— дип кенә әйтә алды.

Шуннан соң инде әкренләп күнегелгән, иләнелгән җир тормышы, көн итү башланды.

Автобус көткәндә дә хат тәэсиреннән арынып җитмәде әле ул. Ә эчкә үтеп җайлырак бер урынга баскач — ул эшенә бәйле уйларга бирелде. Аның һәр көнне ашыгыч мәсьәләләр хәл итәсе була. Ә аларны исә алдан уйлап кую, һәр яктан үлчәп карау, бөтен шартларны искә алу кирәк. Ул һәр көнне юлдагы вакытын тулысы белән әнә шуңа багышлый. Һәммәсен уйлап, тикшереп карый, төрле варианттагы чишелешләрне күңеленнән үткәрә...

Ә эш дигәнең кешегә, аның яшәү рәвешенә, холкына нык кына йогынты ясый икән бит ул. Кәрим дә моны вакыт-вакыт, күңел күзе ачылып киткәләгән сирәк минутларда бик ачы хакыйкать итеп сизә...

Эш белән ничек кенә мәшгуль булмасын, соңгы елларда көн-төн шуның белән генә яшәүгә күнегеп җитмәсен — Зиләнең хаты Кәримне нык кына уйландырды. Үзенә шулай эчкерсез ышана алган кызны теләсә ничек эзләп табасы, аңа чын күңелдән сокланасы, рәхмәт әйтәсе килгән чаклары да булгалады аның. Сөйләшәсе, якыннан аңлашасы да килә иде. Бу очрак, бу кыз аңа кайвакыт тормышында бердәнбер булып тә күренә. Зилә аны яшьлек белән һәм аңа хәзер бик тә тансык булган ниндидер бер мөһим нәрсә белән очраштырыр кебек иде.

Ә кайчагында аның Зилә кебек онытылып хат язасы да килеп китә иде. Бернидән кыенсынмыйча, барысын, барысын әйтеп, ачып салып. Бердәнбер мәртәбә кемгәдер тулысынча ышанып. Ни уйлап, ни кичереп яшәгәннәрен барысын шул хатка түгеп салып. Үз тормышының бердәнбер һәм иң ачык хаты итеп...

Ләкин бу талпынулар ничек кенә көчле һәм ихлас йөрәктән чыкмасын — алар Кәримне ниндидер бер адым ясарга этәрмиләр иде. Анда «Зиләне һичшиксез эзләп табарга» яисә «тиз арада хат язып, аңа барысын да аңлатырга» дигән көчле бер уй тумый иде. Ныклы бер теләк аны үзенә буйсындыра да, конкрет адым ясата да алмый. Ул, һәрвакыт диярлек, Зилә турындагы уйлары белән генә чикләнеп кала килде. Күпмедер вакыттан соң Кәрим бу уйларына иләнә, күнегә башлады сыман. Алар беренче көндәге кебек бөтен күңелне кузгатмый, бар акылны биләмиләр дә төсле иде...

Соңрак, Зиләдән тагын бер хат килде.

Кәрим бу юлы аны тынычрак, ниндидер тиешле бер нәрсә кебегрәк кабул итте. Кызның хәленә кергән төсле, түбәнчелекле илтифат беләнрәк укыды бугай ул хатны.

Зилә үзе дә Кәримгә әллә ни зур нәрсә әйтми, ул күбрәк кичерешләрен, эчке тормышын яза. Кәрим исә моңа каршы ничек дип әйтергә дә, үзенең нишләргә тиешлеген дә белми. Ләкин ул бер нәрсәне һичшиксез

төшенә: Зиләнең дөньясы анықыннан матуррак һәм Кәрим тиз генә менеп житә алмастай жирдә — кайдадыр биектә, югарыда, өстә иде.

Ә бер көнне Зилә Кәримне очрашуга чакырды.

«...Ял көнне кичке сигездә мин сезне телефон-автомат янында көтәм»,— диелгән иде аның хатында.

Бу сүзләрне укыгач, Кәрим күптән югалткан кадерле әйберсен тапкан шикелле куанды. Тиздән, бик тиздән гомер күрелмәгән могжиза булыр кебек иде. Ул, әйтерсең, үзенең яшәү дәверендәге иң олы бәйрәмгә әзерләнә, бөтен барлыгы белән шуны көтә иде.

Әмма... Әмма ул сәгать якынлашкан саен Кәрим үз күңелендә бөтенләй икенче халәт урнаша баруын сизде. Аның бөтен бәхетле уйлары каядыр таралып бетте.

Күзгә каршында тырыша-тырыша киенгәндә ул инде һич тә бәхетле түгел иде. Ниндидер көч житмәслек, хәленнән килмәслек авыр эшкә барган кешегә охшаган иде ул хәзер.

«Әллә бөтенләй бармаска гынамы соң? — дигән фикер дә бик еш кереп чыга иде башына.— Бу хатларны да, каяндыр килеп чыккан Зиләнең үзен дә онытырга һәм элек ничек яшәлгән булса, шулай яшәүне дәвам итәргәме әллә? Бер нәрсә дә булмаган төсле!»

Ләкин Кәрим буйсынып өйрәнгән әхлак кануннары аңа инде артка чигенергә рөхсәт итмиләр иде. Ул очрашуга бармый кала алмый.

Ишектән чыкканда да, лифт белән сигезенче каттан түбәнгә төшкәндә дә ул үзен бәхетле кеше итеп тоярга тырышып карады. Бик-бик тырышты! Әмма бу һич кенә дә барып чыкмый иде. Кәрим үзен ниндидер бер кысага китереп керткән көчтән һичничек ычкына алмый...

Телефон автомат аның өеннән ерак түгел. Кечкенә генә бакча аркылы чыксаң, каршыдагы биш катлы йорт почмагында.

Тик Кәрим ул бакчага кермәде. Билгеләнгән урынга ул әйләнечрәк юлдан, йортлар арасыннан барырга булды. Алай иткәч юл шактый озыная. Нәрсәнедер тагын бер кат уйларга вакыт күбрәк кала кебек иде.

Зилә ерактан ук күренде.

Телефон будкасыннан ике-өч адым гына читкәрәк баскан да, бакчага таба карап, аны көтә иде.

Әйе, бу — бер гөнаһсыз, саф күңелле яшьлекнең үзе иде! Көткән кешесе һичшиксез әнә шул яктан килер дип ышанган, аның башка яктан килеп чыгуын башына да китермәгән яшьлек иде бу! Күзләрен талдырыталдыра, игътибарын бер генә секундка да читкә юнәлтмичә, зарыгып көтеп ала торган яшьлек иде бу. Аның каршысына килүче дә әнә шундый — көтә-көтә зарыккан, сагынган булырга тиеш иде. Моның кадәр бирелеп, онытылып көтү, һичшиксез, шуны таләп итә.

Ә Кәрим бу бәхетле кеше роленә һич кенә дә туры килми бит... Юк, туры килми! Хәтта ул менә хәзер Зилә янына барып ничек дәшәргә, ни турыда сөйләшергә дә белми. Ниндидер бер кыз өчен шулай баш ватып, унайсызланып торуга караганда күнегелгән тормышы күпкә рәхәтрәк тә, тынычрак та тоела иде аңа. Ул — Кәримнең үз дөньясы, үзенчә яшәве иде, ичмаса: анда барысы да ачык һәм бөтен нәрсәне дә акыл белән, тырышлык белән хәл итеп була.

Зиләгә карап Кәрим озак басып торды. Кыз исә вакыт үткән саен ул киләсе якка һаман бирелебрәк, һаман текәлебрәк карый. «Күрмичә үткәреп җибәрмәгәем» дигән шик, әйтерсең аның күңелендә бүтән берникә дә урын калдырмаган.

Кәрим урыныннан кузгала алмый...

Кәрим аңа таба барырга, сүз әйтергә көч таба алмый...

Ул Зиләнең яшьлеген, чибәрлеген күрә. Мондый матурлыкка һәрбер тере җанның тартылганын, омтылганын белә. Әмма... Әмма ул үзендә бу очракта һичшиксез булырга тиешле, тиреннән килергә тиешле дулкынны никтер тоймый, сизми. Каядыр китеп югалган шул хис кушыл-

маганга күрә, акыл үзе генә Кәримне кузгата алмый. Моңа кадәр әле киләчәктә дип уйлап йөрелгән бәхет, менә хәзер, шушы очракта инде булырга тиешле бәхет Кәримгә никтер елмаймый.

...Акрын гына атлап Кәрим кирегә китте. Нәкъ килгән юлыннан китте ул... Ә үзенә нидәндер курыккандай кача, кызу-кызу йөгерә кебек тоелды.

«Нәрсә бу? — дип бу хакта соңыннан да кат-кат уйланды Кәрим.— Картая башлаумы? Әллә инде күп эшләү аркасында туган вакытлы гына бер хәлме? Үтәрме ул?.. Әгәр дә миңа бу җан өнәмәгән нәрсә бөтенләйгә килсә? Ул чагында миңа нишләргә кала?!!»

Ул күпме генә баш ватмасын, үзенең бу уйларына, бу сорауларына төпле җавап таба алмады.

Аның бу чактагы халәте — кемнәндер зур бүләк көтеп алданган һәм шуңа бик тә үпкәләгән бер сабыйны хәтерләтте.

Зиләнең, әлбәттә, монда бер гаебе дә юк иде.

Ул Кәримгә бары тик нәрсәнедер аңларга гына ярдәм итте бит.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Гарәп мәкальләре һәм әйтемнәре

*Минем күңел болгана дип, бүтәнгә дә лимон бирә.*
*Мулла белән очрашудан шайтанны күрү артык.*
*Йомыркасын урлаучы тавыгын да калдырмас.*
*Үзе алтын ташый, үзе салам ашый.*
*Күләгәсендә утырган агачыңны ник кистең?*
*Үгезнең үз коерыгыннан чыбыркы эшләгәннәр.*
*Башлыкның балы әче дип кем кайчан әйтә алыр?!*
*Бер башны ике кул тыңлый.*
*Арысланны ишәк дисәң — син аңа йөгән кидер.*
*Ике кешелек запас өч кешегә дә җитә.*
*Йомырка кабып йоту — тавыкны да ашау ул.*
*Аз ашасаң, күп чир бетә.*
*Су агып беткәч, тегермән тартмый.*
*Телең муеныңны өзмәсен.*
*Аклану ялгансыз булмый.*
*Әгәр акыл күрмәсә, күзләрнең файдасы юк.*
*Яман эшне мактасаң, өстеңә гаеп аласың.*
*Тәрбиясез кеше — җансыз тән.*

# Виктор Гончаров,

рус шагыйре

## Куликово кырында

Ак аргамак кешнәмәде төнлә,
Камыл таптамады тояклары.
Кызлар казып киткән ур туфрагын
Тупчы Петров өнсез кочаклады.

Өнсез ятты килеп матрос Мирза —
Килеп ерак Казан җирләреннән.
Җиңү көтеп талган керфекләрен
Тибрәталмас дала җилләре дә.

Күпме дошман алар кодрәтеннән
Борын төрткән иде Непрядвага!

Әле булса «Тигр» колагасе
Чайкаладыр бәрелеп ташлы ярга.

Уздырмаска шуны бирге якка
Кирәк булды ике дусның гомере.
Алар каны белән сугарылды
Килер уңыш, Куликово кыры.

Тукта, ял ит, кая ашыгасың?
Тик бул, туган, мөмкин чаклы кырыс
Алар кочаклаган тын зурлыкны
Вак шау-шудан син сакларга тырыш!

## Елга зары

Кичке, таңгы шәфәкъ аша
Инешем миңа дәшә:
— Үзеңне харап итәсең,
Мине түгел, ләбаса.

Тугаемда күрми арба,
Күрми печән әсәрен.
Камыш шаулаган күлләрдә
Сазлык ята мәсәрәп.

Элекке урман урнында
Чаука да юк икән лә.
Өянкеләр тирәсеннән
Җиканнәр дә киткәннәр.

Тик мин мескен үз юлымны
Бутамый ага бирәм.
Су корткан йонлач җупны да
Сукранмый юа беләм.

Игелексез куллы адәм,
Тын калуың урынлы.
Без югалсак, кораб йөрткән
Зур дәрьягыз булырмы?

Уйсыз гына син аръякка
Күпме чыгарсың сөткә?
Син сөткә дә... ә мин һаман
Тиранга — төпкә, төпкә.

●

Бер-береңнән яшәү читтә
Бик тә озакларга китсә,
Җил-буран үтә үзәккә,
Тәнне суык уттай өтә.

Безнең хикмәтле елларда
Яңа хикмәтләр туганда,
Көннәр тыныч, әйбәт тора
Без бары берга булганда.

**Әхсән БАЯНОВ** тәрҗемәләре

Анатолий Емельянов,
чуваш язучысы

# СЫБЫЗГЫ

ХИКӘЯ



Көньякта чакны ял көннәрнең берсендә бөтен ял йортыбыз белән жыелдык та җирле рәссамнар һәм скульпторлар күргәзмәсенә киттек. Картиналар мине әллә ни кызыксындыра алмады һәм мин, аларга күз йөртеп чыккач, скульптуралар залына кердем. Үзем дә бу эшкә күпмедер якын кеше — буш вакытларда ни дә булса чокырга, әвәләргә, уеп ясарга яратам. Кергәч тә игътибарымны гипстан ясалган скульптуралар җәлеп итте, аларның да «Печән чабучы хатын» дигәне. Хатынның буй-кыеме, буй-сыны шул кадәр таныш һәм якын иде ки, чак кына: «Бу бит чуваш хатыны, минем якташым!» — дип кычкырып җибәрмәдем. Шулай да иң гаҗәбе «Мәхәббәт елый» дип аталган скульптура иде. Кызның йөзендә сагышәрнү шулай сурәтләнгән, аңа күз салу белән әллә нишләп китәсең. Кешенең эчке халәтен шулай бирә алгач, сәләтле скульптордыр, күрәсең. Кайгыга сабышкан бу кызда да мин чувашларга хас төсмерләр таптым. Сын астына «Н. И. Хурашов» дип язылган иде.

Фамилиясе дә чувашка охшаган. «Хура» — чувашча «кара» дигән сүз. Экскурсоводның сөйләвенә караганда, Хурашов — отставкадагы полковник, фәлән җирдә тора, ә менә нинди милләттән икәнен экскурсовод белми икән.

Мин шул көнне үк скульпторның өен эзләп таптым. Таныштык. Әйе, мин ялгышмаганмын. Никита Иванович чыннан да минем якташ, чуваш икән. Ике ел элек отставкага чыгуы да дөрес.

Никита Ивановичның эшләрен карап йөргәндә мин аны гомере буе скульптура белән шөгыльләнгәндер, дип уйлаган идем. Әмма ул күргәзмәдәге әсәрләрнең ел ярым вакыт эчендә эшләнгәнен әйткәч, аптырашта калдым. Скульптор сөйләп китте...

— Балчыкның чикләнмәгән мөмкинлекләрен мин сигез яшь тулмас ук сиздем.

Язлар житеп, табигать кышкы йокысыннан уянгач, беренче булып таллар бүртенә. Бер туры ботакны кисеп алып, сак кына суккаласаң — кайрысы тоташ килеш куба да чыга һәм кулыңда шыпыр[1] ясарлык менә дигән көпшә кала. Бакчалар артындагы тирән чокыр куаклар белән сырып алынган. Кулыңа пәке тотып, шунда йөгерәсең, туры чикләвек таягы кисеп аласың да каерысын каезлыйсың. Аннан әлеге йомшак каеры белән теге көпшәне шәпләп чорныйсың һәм... инструмент әзер. Инде көпшәгә берничә тишек кенә уясы кала. Мондый инструмент белән әллә нинди көйләр чыгарып була.

Безнең авыл көтүен каяндыр килгән Захар исемле бер егет көтте. Озын буйлы, какча гәүдәле бу егет чегәнгә бик охшаган иде. Хәзер инде аның төсе-бите онытыла язса да, күзләре хәтердә: кечкенә генә кара күзләрендә ниндидер әремәс боз салкыны бар иде аның. Гадәт буенча Захар өйдән өйгә йөреп туена һәм шул йортта кунарга да кала иде.

[1] Шыпыр — курайга охшаган музыка коралы.

Безнең чират җиткән көн истә калган. Ул безгә кояш батар алдыннан гына килеп керде, ишегалдында яткан төп өстенә утырды да аягын чишенә башлады. Шактый таланган чабатасын салды, какты, аннан чолгауларын сүтеп кибәргә элде. Мин тын да алмыйча аны күзәтәм, ә авызымда бүген генә ясалган сыбызгы. Захар да сиздермичә генә мине күзәткән, күрәсең, кулымдагы сыбызгыга ымлап:

— Болай булгач, синең колагыңа аю басмаган инде,— дип куйды.

— Ничек бассын, аю урманда бит ул,— дидем мин.

Көтүче көлеп куйды, шул мизгелне бозлы карашы җылынгандай тоелды.

— Карале, музыкант, син Авсюта чокырын беләсеңме? Аның кырыенда балчык базлары бар, ә иң өстәгесендә ак балчык та була. Бар, йөгер шунда, баш хәтле ак балчык алкайт.

— Юк, бармыйм. Альдонна кыйный.

— Кем ул Альдонна?

— Кем булсын. Бер кыз.

Көтүче тагын көлеп алды, аннан шелтә белән башын чайкап:

— Эх син, музыкант, әллә чыннан да кызлардан куркасыңмы? Алайса, кулыңа таяк тот. Тисәләр — таяк белән. Аңладыңмы? Таяк белән! Ну, бар, йөгер, ир затын хурлыкка калдырып йөрмә болай. Бар!

Захарның күзләрендә кинәт салкын очкыннар кабынып китте, һәм ул онытылып, карашы белән каядыр еракка-еракка текәлде.

Ә мин, әбинең чикләвек агачыннан ясалган таягын эләктереп, чыгып йөгердем.

Бәхеткә каршы, Альдонна бу юлы очрамады. Ул өй эшләре белән мәшгуль иде — чокырга төшәм-төшәм дип торган өйләренең ишегенннән тотен чыга иде.

Бу моржасыз өйнең стенасына, түшәменә калын булып корым утырган. Килеп җитәр-җитмәс борын өйдән мунча исе аңкый башлый. Җирән сакаллы этисе — Пурхиль абый белән Альдонна шушында тора. Үземнән өч кенә яшькә олырак Альдоннаның кыерсытуы сәбәпләме, мин Пурхиль абыйдан да куркам һәм аны сөйми идем. Альдоннаның кушаматы «Алтуни» иде, ә Пурхиль абыйны без, малайлар, «комбед» дип йөртәбез. Соңгысын мин еллар үткәч кенә белдем: авылда оештырылган ярлылар комитетының беренче председателе ул булган.

Чокырдан тиз генә ак балчык алдым да өйгә кайтып киттем. Әбинең таягы бу юлы кирәк булмады.

Кичке аштан соң Захар кулына пәке алды да агачтан кечкенә генә көрәк ясады, аннан берничә чыбык кисте. Бер уч балчыкны тагарактагы суда чылатты, изә башлады. Берничә минуттан ул балчык матур кошка әверелде. Захар аны берничә җирдән тиште, аннан иреннәренә китереп өреп карады. Ишегалдында чын кош сайравы ишетелде кебек. Көтүче тагын ике шундый ук кош ясап ишек өстенә куйды.

— Ике көн кипсеннәр, кагылма!

— Захар абый, мине дә өйрәтче!

— Иртәгә көтүгә кил, балчык та алып кил, өйрәтермен.

— Үзем генә килимме, әллә Арнашканы да алыйммы?

— Башта үзең өйрән, үзеңне кайгырт,— диде көтүче коры гына. Аннан дәшми-нитми генә ишегалды уртасындагы арбага менеп ятты. Әниң аңа өйдән мендәр һәм ике чикмән чыгарган иде.

Төнне мин начар йокладым. Әллә нинди төшләр керде. Захар ясаган уенчыкларымны Альдонна чәлдергән, имеш. Мин әбинең теге таягы белән аны куам. Ә ул һаман саен тизрәк чаба, мин артта калам. Менә ул инде күздән дә югалды. Мин гарьлегемнән елап җибәрәм һәм уянып китәм. Берни аңламаган килеш сарайга йөгереп чыгам. Сыбызгыларның өчесе дә элекке урында иде.

Мин хәзер иртә саен Авсюта чокырына йөгерәм, кичләр сумкага балчык тутырам да чеби чыккан аякларым белән атлап тегермән янына китәм. Бераз сулга сугылуга, тузанлы юл мине Цивиль ярына алып төшә.

— Покы симертәсең, музыкант. Күрәсеңме, сарыклар инде ашап та туйды, тиздән тугаулауга төшерәсе, ә син әле килдең генә. Сыбызгы ясарга шулай өйрәнмәкче буласыңмы? — дип, Захар мине орышып ала.

— Ә хәзер өйрәтмисеңме? — дим мин куркуга калып.

— Өйрәтермен, тик син башта бераз көтүгә күз-колак булып тор, мин черем итеп алам. Азрак йөргәч, туплауга куарсың.

Захар, тау башына менеп, карт өянке күләгәсенә сузылып ята. Күзен йому белән, ул дөнья яңгыратып, гырларга керешә. Ә мин, котырган көчек шикелле, көтү әйләнә чабам. Тәмам хәлем беткәч кенә сарыклар, мине кызгангандай, кояштан котылырга теләп, башларын бер-берсенең корсак астына яшерәләр. Миңа шул гына кирәк тә: көтүне Цивиль буена куам.

Туплау — су тегермәне урынында. Буаның һәр ягына киң ябалдашлы өянкеләр тезелгән. Иске тегермән җимерелгән инде. Сыгылып төшкән түбәсендә һәм чарлагында ала-бута үсә, ә ватык тәрәзәләре белән ачык ишеге — буш күзләр сыман. Әйләнә-тирәне үтеп булмаслык куе кычыткан баскан. Бу урын мине гел куркыта, тегермән эчендә еланнар һәм шуның кебек нәрсәләр мыжлап тора кебек. Захар булып Захар да монда сирәк керә, ә кире чыккач, котымны алып:

— Чак кына җеннәр тотып калмады, — ди.

Шуларны күз алдыма китерәм дә йоклап яткан Захар янына бар көчемә йөгерәм. Ул шундук сикереп тора, ялт-йолт итеп тирә-юньне караштыра башлый.

— Әйдә, сыбызгы ясарга өйрәт инде.

— Син үзең дә мена дигән сыбызгы, ә өйрәтсәм, аннары, беләсеңме, нинә сыбызгычы була?

— Ике, — дим мин.

Захар йокысыннан тәмам айнып көлә башлый, аркамнан сөеп ала.

Без аның иске пинжәген җиргә җәеп утырабыз. Захар бер кисәк балчык каерып ала, мин аның артыннан кабатлыйм. Ул аны киң учында тырышып-тырышып изә һәм балчык тиздән кабартмага әверелә. Ә минем балчык һич кенә дә бирешергә теләми.

— Син һава куыкларын калдырмаска тырыш — юкса кипкәндә бөтен сыбызгыларың ярылып бетәчәк, — ди Захар, кулларымны учына алып, һәм минем балчыкны да йомшарта. Берничә минуттан балчыктан кош хасил була. Захарның бөтен кошлары да бер төрле: киң түшле, үткер томшыклы. Мена ул кошның түшендә куышлык ясый, койрык очын чыбык белән төртеп тишә. Шундый ук тишекләрне канат урыннарында да ясый. Аннан кошны кулында сак кына тотып сызгыртып карый. Кош матур итеп сайрап ала. Тишекләрнең берәрсен бармак белән томаласаң — тавыш үзгәрә, сыбызгы елый, ә икесен дә берьюлы томаласаң, тагын үзгәрә. Шулай итеп төрле көй чыгарып була.

Берничә сыбызгы ясый да Захар тагын сузылып ята. Ә миңа көтү кузгала башлаганчы күз-колак булырга кала.

Мин Захарга ай буе шулай балчык ташыдым — кошларым хәзер аныкы шикелле үк матур чыга башлады. Ишек өсләре, чоландагы шүрлекләр сыбызгы белән тулды. Кем белә, бер вакыйга булмаса, сыбызгы ясауны мин, бәлки, дәвам да иткән булыр идем.

Укулар башланганга икенче генә көн иде. Дәресләр бетү белән өйгә йөгерәбез.

— Карагыз әле, малайлар, көпә-көндез көтү кайткан?!

— Юк, алар көтүдән качкандыр, — ди арабыздан берәү.

Ләкин барган саен урамда сарыклар күбәя генә. Күңелем нидер сизенә: «Әллә Захарга бер-бер хәл булганмы?»

Авыл советы янында барысы да ачыкланды. Монда ике арбаны халык урап алган, шундук ике милиционер. Берсенең кулы марля белән бәйләнгән, учыннан кан саркый. Шунда мин арбаларның берсендә кара чәчле кешене күреп алдым. Бу — Захар иде. Кысыла-кысыла алга уздым. Захар минем якка борылган килеш ята. Иреннәре күгәргән, йөзендә балавыз сарысы. Ә күзләре ачык. Карашы каядыр маңгай астына яшеренгән һәм бу килеш ул бик тә куркыныч иде. Йөзендә кан эзләре дә бар.

— Захар! — дип кычкырып җибәрдем мин һәм үле гәүдәгә ташландым. Ләкин кемнеңдер көчле куллары мине халык арасына этеп кертте.

— Шул кирәк аңа, явыз бүрегә, — диде Пурхиль абый.

— Үзеңә шул кирәк! — дидем мин яшь аралаш һәм, стена булып баскан халык арасыннан чыгып, өйгә чаптым. Печәнгә капланып туйганчы елагач, Захарны үтерүчедән үч алырга ант иттем.

Иртәгесен ике милиционер белән авыл советы председателе мине көтү көткән җиргә алып киттеләр. Көтүченең кайда йөргән, кайда ял иткән сораштылар. Белгәнемне сөйләп бирдем. Тынлап бетергәч, алар, тиз-тиз атлап, тау башындагы өянке янына юнәлделәр. Аның куләгәсендә Захар ял итәргә ярата иде. Өянкедә яшерен куыш табылды. Милиционерлар аннан берничә винтовка, бер капчык патрон һәм тимерче ясаган зур пычак тартып чыгардылар.

Кичен мин этидән:

— Захарны нигә утерергәннәр? — дип сорадым.

— Ул кулак малае,— диде эти.

— Бөтен кулак малайларын да утерергәме?

— Нигә алай булсын. Ул бит Себердән качкан.

Әбидән ишетеп, мин Себердә бик зур төрмә барлыгын, анда бик күп явыз кешеләр — караклар, кеше үтерүчеләр, җинаятьчеләр утыруын белә идем... Моңысын мин белә идем. Шуңа күрә соравым беркатлы килеп чыкты:

— Захар төрмәдән качканмыни?

— Әйе,— диде эти.— Әйе! — дип кабатлады, җитдиләнә барган күзләре белән миңа төбәлеп.— Качып кына калмаган, коммунистларның, комсомолларның өйләрен яндырып йөргән.

— Утны нигә төрткән соң?

— Үч алу өчен. Күрә алмаганга. Ерткыч ул Захар...— һәм эти тынып калды.

Мин Захар турында сораша башласам, эти һәрвакыт тавыш күтәрә, чыгырыннан чыга, «башсыз чебеш» дип миңа кычкыра башлый, синең аркада миңа Пурхиль абыеңнан эләгә, онЫт аның исемен, өйдә дә, мәктәптә дә искә аласы булма, дип дулый иде.

Захар юк... Әмма төннәрен безне барыбер чаң тавышы уята: әле бер, әле икенче урамда янгын чыга. Халык йөгерешә башлый, минем эти дә алар арасында. Әни, мине кочаклап:

— Я ходай! Тагын ут төрткәннәр. Кайчан бетәр бу...— ди.

— Захар юк бит. Кем яндыра соң? — дим мин, олыларча җитди итеп.

— Явыз адәмнәр бер Захар гына түгел...

Ул көннәрне авылда сүз гел милиционерларның батырлыгы хакында барды.

Захар совет власте вәкилләренә каршы чын сугыш ачкан. Милиционерлар аны йокылаганда тотмакчы булганнар, ләкин ул сизеп алган да иске тегермәнгә кереп яшеренгән. Атыш башланган. Бер милиционер үлгән, икенчесе — яраланган. Әмма үзен дә кайнар пуля читләтеп узмаган.

Кабат берәр янгын чыга калса янсә олылардан ниндидер корткычлык хакында ишетсәм, мин кешеләрнең явызлыгын уйлап баш вата идем. Ни җитми аларга? Захарның явыз кеше булуына мин байтак вакытлар ышана алмый йөрдем. Ул бит мине сыбызгы ясарга гына түгел, батыр булырга — Альдоннадан курыкмаска да өйрәтте. Юк, Захар явыз түгел. Тәҗрибәсез күңелемдә кызгану хисе кузгалып торса да, бу турыда мин инде этигә дә, әнигә дә әйтми идем. Алар үзләре дә мине борчымадылар. Тик бер көнне укытучы апа гына Захар дошман, ярлы балаларында сыйнфый сизгерлек булырга тиеш, дип сөйләгәндә текәлеп миңа карап алды.

Вакыт үтә. Мин инде бердәнбер теләк — тизрәк үсеп җитү теләге белән яши идем. Захар үлгәч, балчыктан сыбызгылар ясауны ташладым гына түгел, бөтенләй онЫттым. Бер вакыйга булмаса, ул һөнәргә гомумән әйләнеп кайткан булыр идем микән?

Ул чакны миңа инде унбиш яшь тулды. Күрше авылда җиде классны тәмамлагач, инде нишләргә дип баш ватам. Уйлануларыма эти чик куйды.

— Ну, җитәр, прохвессор,— диде ул көннәрдән бер көнне.— Мин мәктәпкә бер генә кыш йөрдем, шулай да бригадир булып эшлим. Синең җиде классың белән хәзер РИК председателе булырга да ярый. Хәзергә укуыңны шуның белән тәмамлап торыйк.

Нишлисең, тәмамларга булгач, тәмамларга... һәм мин эти бригадасына эшкә йөри башладым.

Бервакыт миңа ниндидер эш белән Канашка барырга туры килде. Кара төндә генә әйләнеп кайттым, атны тугардым да, караңгыда көтүне барыбер табып булмас дип, атны ишегалдында калдырдым. Арбага бераз печән салдым да шунда сузылып яттым.

Шул вакыт безнең бакчада сандугач тавышы ишетелде. Бу сайрауны мин хәзер дә берни белән чагыштыра алмыйм. Аның тавышы шундый гүзәл иде, әле дә булса ишетелеп тора кебек. Әллә инде безнең якларга сандугач сирәк килгән, әллә концертлары башланганчы йокыга китә торган булганмын, кыскасы — моңа кадәр минем сандугач тавышын рәтләп ишеткәнем юк иде. Кошны куркытмас өчен мин, суларга да кыймыйча, кымшанмыйча ята бирдем. Ә ул һаман саен матуррак, моңлырак итеп сайрый. Аның жырын бәхетсез кеше тыңласа, аркасына канат үсеп чыгар кебек тоелды. Минә жыр туктады, ә колагымда һаман аның концерты яңгырый. Жыр минем йөрәгемә генә түгел, һәр күзәнәгемә үтеп керде шикелле.

Бу халәттән мине атның тәнемә тиеп киткән салкын иреннәре чыгарды. Ат тырышып печән ашый, пошкыргалап та куя иде. Минем жырчымны ул куркыткандыр, мөгаен.

Әмма сандугач алай ук куркак булып чыкмады. Минә аның тавышы кабат яңгырады һәм мин, шул жырга бирелеп ята торгач, йоклап киткәнемне сизми дә калганмын. Уянып киткәндә дә күңелемдә шул жыр тирбәлә иде. Ат, астымдагы печәнне йолкый-йолкый, иреннәре белән мине буяп бетергән. Ә хәзер, сабый бала кебек, су эчергәнне көтеп, арба янында басып тора.

Иртәнге салкын бөтен тәнемә үткән, ләкин мин үземне гаҗәп бәхетле хис итәм. Шул вакыт хәтеремә сыбызгы ясаулар килеп төште һәм мин, артыгын уйлап тормыйча, Авсюта чокырына чаптым.

Минә тагын кулымда балчык жырлый. Мин, нидер югалтып, кабат тапкан кеше кебек, сарай буендагы эскәмиядә утырам. Монда минем «остаханәм» — балчык кошлар белән тулган ике эскәмия.

Минем кабат бу эшкә тотынуымны, өйдәгеләрдән кала, Альдонна да белә иде. Ул инде минем белән сугышмый, бары тик әрләшә генә. Пурхиль абый да үзенең кечкенә өен сүтеп, яңаны — яктыны һәм морҗалыны салды. Ул хәзер колхоз председателе. Авылда аны хөрмәт итәләр. Кешедән гел читләшеп яшәгән безнең эти дә аның белән хәзер еш сөйләшә, бәйрәмнәрдә кунакка чакыра, түргә — кырыс карашлы алла сурәте ясалган иконалар астына утырта.

Альдонна, кыю булса да, усал кыз түгел иде. Ул безгә әле бизмән, әле гөбе алырга керә. Артыннан ишек ябылуга безнең әби, ризасызлык белдереп, сукрана башлый:

— Кара инде боларны, сыер тикле сыер асрыйлар, гөбе юнәтергә хәлләреннән килми.

Альдонна минем кабат сыбызгылар белән мавыгуымны ничек сизгәндер — белмим, ләкин мин балчыкка тотыну белән, ул безнең бакчага килеп керә һәм бер сүз дәшмичә кулларыма карап утыра иде. Нишләптер йөзе моңсу, вакыт-вакыт авыр итеп сулап та куя, яки көтмәгәндә:

— Сызгыртырга биреп тор әле,— дип миннән сыбызгы сорый.

— Сызгыртырмын менә колагыңа берне! Кипмичә кагыласы булма! — дип мин кабынып китәм.

Миңа сыбызгы жәл түгел, мин аңа инде дистәләпне бүләк иттем, ләкин Альдоннаның сызгыртуын сөйми идем. Ул көй чыгара белми, әллә нинди ямьсез, колак пәрдәләрен ерта торган тавыш чыгара.

Бераз шулай тарткалашкач, мин барыбер аңа сыбызгы бирәм, әмма безнең концерт моңа да карамастан сугыш белән тәмамлана. Альдонна башлап жибәрә: сиздерми генә килә дә, колак төбен яңгыратып, сызгыртып ала, яисә авызына бармагын тыгып:

> Мик, Мик, Микиток,
> Сыбызгылы Микиток.
> Микитокның сыбызгысын
> Алып шылган аксак эт...

— дип мине үрти.

Мин, пыр туздырып, аны куарга керешәм, куып житәм дә дөмбәслим. Дөрес, мондый «бәрелешләрдән» соң үз колакларым да тәүлек буе сызлый. Чөнки барысын да күреп торган әби этигә шундук житкереп тә өлгерә.

— Улым, ишетәсеңме,— ди ул,— безнеке тагын Пурхильның кызын кыерсыта.

Һәм әбинең улы, ягъни минем эти, улының үзе хәтле булуына карамастан, ике колагымнан тотып «Мәскәү күрсәтә» башлый.

Шундый сабак алгач, өйдән ук булып атылып чыгам.

Боларның барысына да шул Альдонна гаепле. Аның аркасында көн саен әтидән сабак алу гына җитмәгән, өстәвенә мин гомергә салпы колаклы булып калдым.

Ә кызыйның исе дә китми, берни булмагандай, ул тагын ишегалдына яки бакчага килеп керә.

— Мик, әйдә сызгырт әле,— ди.

— Юк инде, үзең сызгырт, синең аркада әле дә колаклар яна.

Бер минутка тынлык урнаша. Аннан шул ук сүз:

— Ну, Мик, сызгырт инде.

— Җитәр! Бәйләнмә!— дим мин, кырт кисеп.— Тик утыра алмасаң, әнә Авсюта чокырына йөгер.

Альдонна сикереп тора да сарай ишегенә кереп югала. Күр дә тор — кабат котырта башлаячак. Әйттем бит:

Мик, Мик, Микиток,
Мик Розаның кияве...

— Роза өчен сандугач булып сайрыйсыңдыр әле,— ди ул, үпкә белдереп. Бу сүзләрдән соң кызыйны озын сыйраклары гына коткара. Розаны телгә алуны гафу итмәячәгемне Альдонна яхшы белә.

Роза!.. Ул авылга әти-әнисенә ияреп килде. Алар Себергә күчеп киткән Хрисан абыйлар өендә урнаштылар. Хрисан абый безнең күрше иде. Розаның әтисе — мәктәп директоры.

Яңа хуҗалар кереп урнашкач Хрисан абыйның өе бөтенләй үзгәрде: салам түбә такта белән ябылды, каралты-кура да яңартылды. Әмма иң кызыгы — кич саен ачык тәрәзәләрдән ишетелгән музыка иде.

— Күр, тагын музыкаларын җибәрделәр,— дип сукрана иде әбекәй.— Гармунда гына уйнасалар соң...

Музыканы ишетү белән минем колакларым тора. Ул гына да түгел — сыбызгымны алып, әлеге билгесез аһәң белән ярыша башлыйм. Мин хәзер сыбызгыны Захардан да остарак ясыйм, үзем белгән шактый көйләр чыгара алам. Әмма минем концертларым еш кына «Мәскәү күрсәтү» белән тәмамлана.

— Кемгә генә охшагансыңдыр инде, аптырагач. Кулың бер генә кирәк эшкә дә ятмый,— дип сүгә иде әти.

Роза миннән ике яшькә бәләкәйрәк. Мин аны еш кына бакчаларында күрәм. Бер генә килешмәгән җире юк үзенең: зур зәңгәр күзләр, алтын чәчләр, өсте-башы пудра тартмасына төшерелгән кызныкы шикелле.

Безгә беренче керүендә үк мин аңа иң шәп сыбызгымны бирдем. Ул аны кулында әйләндергәләде дә сызгыртып карады, аннан кире сузды.

— Инструмент мыни бу? Безнең пианино бар...

Мин тыңлап бетермәдем, шул сыбызгыда яраткан көемне уйнап күрсәттем. Ә ул киреләнеп:

— Безнең әни барыбер матуррак уйный,— диде.

— Кем соң синең әниең?

— Укытучы.

Иртәгесен Роза милиционер сыбызгысы алып керде.

— Бу синекеннән яхшырак,— диде.

— Каян алдың моны?

— Әти сатып алды.

Өч көн интеккәннән соң мин, ниһаять, милиционер сыбызгысыннан яхшыракны уйлап таптым, эченә бер борчак урынына өчне салдым. Кире кызны акылга утырту өчен сыбызгыны аңа бүләк иттем. Ә ул рәхмәт әйтәсе урынга:

— Минем сыбызгы барыбер шәбрәк,— диде.— Ул бәләкәй, үзе тимердән ясалган.

Альдонназы тукмаган кебек аны да тукмыйсым килеп китте. Ләкин кызыйның матур зәңгәр күзләренә күтәрелеп каравым булды, йомшардым да төштем.

— Ярар, синеңчә булсын. Тик син монда башка килеп йөрмә, ямe? Ишетәсеңме, тел бистәсе!

Шул көннән мин сыбызгыларымны ташладым, көннәрем хәзер Цивиль буенда үтә

иде. Хәтта үткен Альдонна да күпмедер вакыт минем кайдалыгымны белми йөрде. Балык тоту белән мавыгып киттем: әнинең эремчек сөзә торган марлясыннан ятьмә ясап, сәгатьләр буе камыш арасында чабак белән шамбы тотам. Ә Цивильнең кечкенә бер инеш кушылган җирендә, кыяклы үләннәр арасында елан-балык та эләгә иде. Кыскасы, барлы-юклы өч литрлы бидоным балык белән тула. Шулай да болай йөрүләрем әтигә ошап бетми.

— Балык тоту белән аучылык — ялкаулар эше,— ди торган иде ул.

Әби мине яклый.

— Тимә, тота бирсен. Бу елан балык дигәннәре бигрәк шәп нәрсә булып чыкты. Шуны ашый башлаганнан бирле буыннарым сызлаудан туктады.

Шулай да ялкау дигән исем минем өстән шактый вакыт төшми йөрде. Миңа барыбер иде. Өйдән мин таң ату белән үк чыгып китәм, киндер сумкамда — суган да бәрәңге. Өч дистә чамасы чабак тоткач, учак ягып җибәрәм, уха пешерәм. Ә соңыннан чалкан ятып урман авазларын тыңлыйм. Берәр кош сайраса — шуны кабатлыйм. Агач куышыннан тиен баласы килеп чыга — тын да алмыйча аны күзәтәм. Бу чытырманнан табып кара син хәзер мине...

Шулай да Альдонна белән Роза мине таптылар. Артымнан барганнар, күрәсең. Ятьмәмне ташлаган гына идем, яр буенда алар күренде.

— Безне дә балык тотарга өйрәт әле! — дип кычкырдылар алар яр өстеннән.

— Монда төшегез. Син, Роза, туфлиләреңне сал, су кермәсен. Альтуни балык кусын.

Мин эремчек капчыгын агымга каршы куйдым. Бидон бик тиз тулды. Шунда минем мактанасым килеп китте: бидонны муены бәйләнгән күлмәккә бушатып, тагын, тагын тотам. Эш беткәч, кукрәк киереп:

— Ну, чебен гөмбәләре, хәзер — өйгә! — дидем.

Иңгә балык тутырган күлмәкне астым, кулга сумка тоттым. Кызлар исә бидонны алмаш-тилмәш күтәрделәр.

Безнең бакча башына утырып балыкны бүләргә керештек.

— Миңа кирәкми,— диде Роза.

— Ник?

— Безнең әти кибеттән ала. Анда эрерәк тә.

Розада мине кыерсыту нияте юк иде шикелле, шулай да ачуым килде. Бу, минемчә, хезмәтемне аяк астына салу гына түгел, мине хөрмәт итмәү дә иде. Айканып берне яңагына кундырдым. Ул зәңгәр күзләре белән бер мизгел миңа карап торды, аннан ике эре тамчы сытылып чыкты.

— Кыргый! Культурасыз! Ахмак! Кызлар янында үзеңне тота белмисең! — дип үтә дә чиста рус телендә әйтте дә салды Роза.

— Күрсәтермен мин ахмакны! — дидем мин кабарынып, ләкин кабат сугарга кулым күтәрелмәде. Ачудан бөтен балыкны Альдоннага бирдем. Ул ялындырып тормады, алды да сызды.

— Моннан соң безгә аяк атлама! — дип кычкырдым мин Розага.

— Һәм атламам да,— диде ул горур гына һәм, күз яшьләрен дә сөртеп тормыйча, китеп барды.

Көз житү белән әти мине ФЗӨ мәктәбенә урнаштырды. Һәм мин, бәхеткә каршы, лепщик һөнәрен үзләштердем. Хәзер мин балчык белән түгел, гипс белән эш итәм, минем кулда ул гаҗәп фигураларга әверелә. Яхшы мастер буларак, җаваплы эшләргә мине җибәрәләр иде. Кайвакытта икешәр смена да эшлим. Акчасы да шәп төшә.

Ял вакытында авылга кайттым. Бервакыт көн саен диярлек тавышсыз фильмнар күрсәтелә. Билетлар алам да кызларны киногә алып барам. Бер көнне иптәшләре белән Роза да килде. Әллә инде теге вакытта яңагына биргүне онытмаган, әллә үзенең беркатлылыгы аркасында, килеп житү белән:

— Синең акчага киногә йөрергә мин хәерче түгел,— дип әйтте дә салды бу.

Кара син аны, үзе тугызынчы класста гына, әллә кем булып кылана! Без дә ялына торганнардан түгел. Альдонна мин кайтканнан бирле бездән чыкмый диярлек, киногә барганда да ул миннән калмый, аны конфетлар белән сыйлыйм. Ә бер көнне, өйдә әби

генә калгач, хәтта шәраб та эчтек. Беренче рюмкадан соң ул исереп китте, авылда кемнең кем белән йөрүен сөйләргә кереште.

— Ә үзең соң кем белән йөрисең? — дидем мин көлеп.

— Минме? Беркем белән дә йөрмим... Мин менә сигезенче класска күчтем. Әти укы ди...

— Димәк, прохвессор булмакчы,— дим, әти кебек төрттереп.

— Юк, мин врач булам.

— Алайса, укы, авырып китсәм, синең янга килермен.

Ял үтеп тә китте. Мин кабат Мәскәүгә әйләнеп кайттым.

Сугыш башланыр алдыннан әти, йорт-җирен сатып, нигәдер Себер якларына күчеп китте.

Буш вакытларда мин скульптура белән шөгыльләнә идем. Кулымдагы гипсның төр ле сыннарга әверелүе бик тә ошый иде. Һәм, күрәсең, миндә берникадәр сәләт тә булгандыр — «Лепщик» һәм «Штукатур» исемле ике эшем премиягә лаек булды. Газеталарда аларның фотографияләрен һәм комментарий урнаштырдылар. Түзә алмадым, ул газеталарны Розага салдым, ләкин җавап килмәде. Тагын яздым — шул ук хәл...

Сугыш безнең бөтен хыялларыбызны, планнарыбызны бутады, бүлде. Бәлки миннән скульптор һәм композитор чыккан булыр иде, әмма кулга корал тотып Ватанны саклаdensiарга туры килде. Дүрт ел сугышта булдым. Әтинең Мәскәү янындагы сугышларда һәлак булуын белдек, соңрак әби үлде, каты авырудан әни дә аякка баса алмады...

Кырык сигез яшьтә отставкага чыктым. Чирек гомерем хәрби хезмәттә үтте, хәзер менә илдә. Утыз биштә хәрби академияне тәмамладым. Картаюны сизми дә калганмын...

Хәзер минем вакыт күп. Хатынны эшкә, улымны техникумга озатам да элекке шөгылемә керешәм. Гипсны больницадан алам. Теге сыбызгыларны ясап карамакчы идем, барып чыкмады — балчык кирәк, гипстан булмый. Монда ком, балчык бөтенләй юк. Күңелемдә көннән-көн сагыш, юксыну арта — нишләргә дә белмим. Көнен дә, төнен дә күз алдымда туган авылым тора. Булыр да — анда кайтмаганга инде чирек гасыр бит. Һәм нигәдер еш кына Захар белән көтү көткән чаклар искә төшә...

Шулай өч атналап азаплангач, түзмәдем — юлга җыендым.

Ике тәүлектән үзебезнең станциядә идем инде. Бирерә күп нәрсә үзгәргән, ике-өч катлы яңа йортлар үсеп чыккан.

Авылга мин туры юлдан түгел, әйләнеч сукмактан кайтырга булдым. Күп тә үтмәде, ул сукмак мине Цивильнең борылган төшенә алып чыкты. Иске дустым каршысына ашыккан шикелле, куе үлән ерып мин яр буена атлыйм.

Менә ул Цивиль, мең чишмәне үзенә туплап, ашыкмый гына, вәкарь белән генә агып ята. Аның суы да күз яше кебек саф. Төптә балыклар уйнаганы күренә. Менә, кояш нурларында ялтырап, бер көтү чабак үтте. Минем аларны куркытасым килми, үтеп киткәннәрен көтәм, аннан соң гына яр кырыена төшәм. Агымга каршы берничә адым атлагач, тезләнәм дә теш сындырырлык салкын чишмә суы эчәм. Һәм шул вакыт ярга төшкән җирдә балчык күреп алам. Кемдер бу хәзинәне миннән тартып алыр төсле, кулларым белән балчык казыйм, авыртуны тоймыйм. Балчык бала башы хәтле булгач, бераз тынычланам, кулларымны юып, бер тал чыбыгы кисеп алам. Биш минуттан кулымда сыбызгы хасил була, балачак музыкасы ишетелә башлый. Тансыклаган куллар калган балчыктан да берничә сыбызгы әвәлиләр. Бала-чага кебек шатланып, мин аларны кояшта кибәргә куям.

Инде тегермән тирәсендәге карт өянкеләр янында да булдым, сарык көтүен күрәсем килде. Ләкин... иске тегермән йортын таба алмадым. Анда хәзер котырып кычыткан үсә иде. Өч өянке картаеп корыган, аларны кызганып куйдым. Чуваш авылларын бизәүче бу агачлар кешеләрсез яши алмый шул. Бала чактан истә калган: өянкеләрнең корыган ботакларын кисеп торалар, алар урынына яңалары үсә иде. Ә бирерә караучы булмаган. Элекке туплау урынында куе булып үлән үскән, Захар корал яшергән агачтан да бары тик черек төп кенә утырып калган...

Бирерә үземнең балачагым, үсмер елларым искә төшә. Мин инде яхшылык белән

явызлыкны аерырга өйрәндем. Кулга корал тотып, явызлыкка каршы үзем көрәшкән кеше. Бүгенге көнгә сугыш сөреме белән томаланмавында минем дә бераз өлешем бар. Һавалар бозылганда яраларым сызлый, үпкәмдә утырган миңа кыйпылчыгы сугышны онытырга бирми.

Фронтта, сугышлар тынып торган арада, мин үткәннәрне уйлый идем. Захар утны безнең авылда гына төртмәгән, егерме сигез чакрымдагы үз авылларында да өйләр яндырып йөргән. Бер төн эчендә шундый араны теләсә кем үтә алмый. Ул әлбәттә, арыган, ә мин аңа көтү көтешеп ярдәм иткәнмен. Менә шул сәбәпле Пурхиль абый мине яратмаган, эти дә бала дип кенә түзгән, ә укытучы апа дәрес юлга бастырырга тырышкан.

Мин авылга менә инде иң шәп сыбызгы да алып кайтам.

Безнең өй авыл кырыенда, урманга төртелеп үк тора иде. Күпме карансам да, өй тирәсендә яраткан өянкеләремне күрмәдем. Безнең нигездә, дүрт тәрәзәсе белән урам якка карап, яңа йорт тора. Түбәсендә — телевизор антеннасы. Буяуга буялган урыс капка да шәп, сарай түбәсенә хәтле шифер белән ябылган. Сарай артында — бакча. Капка төбендәге урындыкка килеп утырдым, тәмәке кабыздым.

Кинәт капка шыгырдап куйды, ак күлмәкле малай күренде. Мине күрмичә сикерә-сикерә ары узды. Аннан кинәт миңа борылды да катып калды.

Мин чак кына кычкырып җибәрмәдем — каршымда өзелгән дә төшкән Роза тора иде. Шәфкатьле зәңгәр күзләре кызыксынып карый. Малайны минем мундир куркыткандыр, күрәсең, ул инде кереп шылырга җыена иде, ахрысы.

— Туктале, үскәнем,— дидем мин.— Синең әниеңнең исеме Розамы?

— Роза Петровна,— диде ул, бәясен белгән кебек.

— Ә синең исемең ничек?

— Славик.

— Әниең өйдәме соң?

— Юк, ул бакчада, кура җиләге җыя.— Ул, минем кулдан ычкынып, капкага кереп югалды.

Мин исә, балачак истәлекләренә бирелеп, сыбызгыда көй чыгара башладым. Дәрес, көй элекке шикелле чиста түгел иде, әмма күңелемдә бу минутта җыр уянды. Уйный-уйный күзләремне дә кысып йомганмын. Ачып җибәрсәм, каршымда Роза тора иде. Әйе, мин ялгышмадым — ул. Зифа буйлы чибәр ханым. Шулай басып торабыз, икебезнең дә битләр яна, икебез дә ләм-мим. Ниһаять, Роза якынрак килде, кулын сузды, һәм бала чактагы кебек — көйләп алды һәм тагы да кызарды:

Мик, Мик, Микиток,
Сыбызгылы Микиток.
Микитокның сыбызгысын
Аксак эт урлап киткән.

— Ну, исәнме, Роза! — дидем мин.

Өйгә кердек.

Бераз вакыттан ире дә кайтып җитте. Роза безне таныштырды. Ул мәктәп директоры икән. Мефодий Петрович улына сумка тоттырды да кибеткә озатты. Мин дә, чемоданнан чыгарып, өстәлгә бер шешә шампанское куйдым.

Мефодий Петрович эше турында байтак нәрсәләр сөйләде, директор булуның авырлыгыннан зарланды, уку елы тәмамлангач та ял күрмисең, диде. Зарлана-зарлана рюмкага да кагыла торгач, шактый йомшады ул. Утырган килеш йоклап ук китте. Роза белән икәүләп аны диванга илтеп салдык. Сөйләшәбез дә сөйләшәбез. Славик — урамда.

— Син дә гаилә коргансың икән,— диде Роза.

— Әйе, малай техникумда укый.

— Өйләнүен яратып өйләнгәнсеңдер инде,— дип куйды ул, әллә чыннан да беләсе килеп, әллә инде үзен тынычландыру өчен.

Мин аңа җыр юллары белән җавап бирдем:

Яратканны яратучы була,
Мәхәббәтсез кем соң бәхетле?

Розаның йөзеннән күләгә узды, мин хатамны төзәтергә тырыштым:

— Мин өзелеп сөйгән берәү хатларыма да җавап бирмәде. Менә хәзер ана карыйм да йөрәгем, унҗиде яшьтәге кебек, сулык-сулык килә.

Роза беравык миңа карап торды, йомшарган карашында сагыш күренде. Елап җибәрүдән ул чак кына тыела алды.

— Эх, Мик, Мик, син берни дә аңламадың, хәзер дә аңламыйсың. Мин бит синең аркада чак кына утырып калмадым. Ә Альдонна хәзер дә япа-ялгызы яши, сине сөя. Ул бит хәзер профессор, Казанның медицина институтында. Эх, Мик, Мик! Аның сине ничек сөйгәнен, ничек көткәнен белсәң иде. Андый мәхәббәт, беләсеңме...

Роза бүтән тыелып тора алмады, елап җибәрде. Аны тынычландыру өченниләр генә әйтмим, ә күңелдә һаман бер уй: «Әх, Роза, кем белгән бит аны...»

Карангы төште. Өйдә бөркү. Урынымнан тордым да ишегалдына караган тәрәзәне ачтым. Өйгә яңгыр исе керде. Менә яшене дә сызып үтте, аннан гөрселдәп күк күкрәде. Тәрәзә пыялалары зеңләп узды. Мин Розаның авыр көрсенүен ишеттем. Тәрәзәне ябып, янына килеп утырдым һәм күз яшьләреннән тозланган иреннәреннән үптем. Аннан, чемоданымны алып, коеп яуган яңгыр астына чыктым.

Солтан ШӘМСИ тәрҗемәсе.

Рәис Сабиров

# УЛЬЯНОВЛАР

Владимир Ульяновның укуын дәвам иттерү өчен Казанга килүе очраклы хәл булмый. Һәм эш, әлбәттә, патша галиҗәнапларына һөҗүм итүдә катнашкан Александр Ульяновның энесе өчен башкала университетының ишеге ябык булуда гына түгел.

Идел буендагы бу борынгы шәһәр шактый вакыттан бирле Ульяновлар гаиләсе тормышында зур роль уйнап килә. Сүзне 1850 елның җәендә бирегә булачак юлбашчының әтисе Илья Николаевич Ульяновның Әстерханнан килүеннән башлыйк. Крепостной крестьян оныгы, тегүче малае Илья үзенең тырышлыгы һәм сәләте аркасында гимназия тәмамлый, Казан университетына алуларын сорап гариза бирә. Әмма аңа биредә укуы җиңел булмый. Әстерхан гимназиясе директорының тормыш итәр өчен беркинди килере булмаган бу сәләтле малайга стипендия билгеләүне сорап җибәргән кәгазенә Казан уку-укыту округы попечителенең җавабы катгый була: стипендия балаларын тәрбияләүдә ярдәм йөзеннән тик чиновникларга гына билгеләнә торган нәрсә ул, янәсе. Шуңа күрә мещан гаиләсендә туып үскән Ульяновны стипендия алучылар исемлегенә кертү өчен нигез күренми.

Шулай да Илья Ульянов укуын өзми. Аның тырышлыгын, белемгә омтылуын тиздән профессорлар да, ул вакытта инде ректорлыктан китеп, попечительнең ярдәмчесе булып эшләп йөргән бөек геометр Николай Иванович Лобачевский да күреп алалар. Физика-математика факультеты студенты Илья Ульянов, Лобачевский киңәше белән, дәрестән соңгы буш вакытларында әле яңа гына төзелеп беткән астрономия обсерваториясендә күзәтүләр алып бара башлый, туфракның температурасын үлчи. Атаклы галим Илья Николаевичның моннан соңгы язмышында да зур роль уйный. 1885 елда кулына яңа диплом алган кандидат Илья Ульяновны ул Пенза дворяннар институтына югары сыйныфларда математика укытучысы итеп җибәрә һәм шуңа өстәп тагын аңа бу шәһәрдә метеорология станциясе эшен җайга салу бурычын да йөкли. Сембер губернасында халык училищелары инспекторы, ә соңрак директоры булып эшли башлагач та, губернадагы уку йортлары Казан уку-укыту округы карамагында булганлыктан, Илья Николаевич безнең шәһәргә еш килеп йөргән.

Юлбашчыбызның әнисе Мария Александровнаның балачагы һәм яшьлеге дә Казан һәм аның тирәләре белән, аерым алганда Лаеш өязенең Кокушкино авылы белән тыгыз бәйле. Аның әтисе Александр Дмитриевич Бланк, врач кеше, 1847 елда отставкага чыга, нибары ике дистә хуҗалыгы булган бу кечкенә генә авылда, Ушня елгасы буенда утар сатып ала һәм бөтен калган тормышын әнисез калган алты баласын — Анна, Любовь, Екатерина, Мария һәм Софья исемле кызларын, Дмитрий исемле улын тәрбияләүгә багышлый. Мария Александровна бу авылда уналты ел гомерен үткәрә, Пензага олы апасы Анна янына кунакка баргач Илья Николаевич белән танышып, 1863 елда Кокушкиноның күршесендәге авыл чиркәвендә аның белән никахлануга кадәр шунда яши.

Казан һәм Кокушкиноның Илья Николаевич белән Мария Александровналарның

балалары тормышында тоткан урыны да зур. Александр Дмитриевич Бланк үлгәннән соң аның Кокушкинодагы утары биш кызына мирас булып кала. Алар аны бүлешеп тормыйлар, аңардан уртак файдаланырга булалар. Шулай итеп, әлеге авыл алар өчен җәйге ялны бергәләп үткәрү урыны булып китә. Һәр җәй диярлек Сембердән Казанга кадәр пароход белән, ә аннары ат белән бергә Ульяновлар килә торган була. Килешли алар шәһәрнең Профессор тыкрыгында яшәүче Анна Александровна Веретенниковаларда берничә көн кунак булалар. Кокушкинога ирләре һәм бала-чагалары белән Мария Александровнаның бүтән апалары һәм сеңелләре дә килеп төшә. Утар балалар шау-шуы белән җанлана. Ульяновларның барлык балалары Кокушкинода үткәргән бу көннәрне үзләренең истәлекләрендә бик яратып һәм сагынып искә алалар.

Владимир Ильичка укуын дәвам иттерү өчен кая бару мәгъкульрәк булыр икән дигән сорауга җавап эзләгәндә Ульяновларны Казанны сайларга мәҗбүр иткән тагын ике мөһим нәрсәне искә алмый мөмкин түгел. Владимир Ульянов Сембер гимназиясен тәмамлаган елларны аның әнисенең ике апасы — Анна Александровна Веретенникова һәм Любовь Александровна Ардашова-Пономаревалар Казанда торалар. Аларның беренчесе Профессор тыкрыгындагы Завьяловлар йортында, ә икенчесе Беренче тау урамында Ростова йортында (хәзер Ульяновлар урамы, 24) яши. Белүебезчә, туганнарның бер тирәгәрәк, бер-берсенә якынрак оешырга омтылуы бик табигый хәл. Икенче сәбәп исә — мөһимрәк. Билгеле булганча, патшаны үтерергә теләп, аңа һөҗүм ясауда гаепләнгән Александр Ульянов белән бер үк вакытта, шул үк эш буенча аның апасы, Петербургтагы Бестужев курсларының соңгы сыйныфы тыңлаучысы Анна Ильинична да кулга алына. 1887 елның апрелендә аңа Көнчыгыш Себергә сөргенгә китәргә кушыла. Шулай итеп, Ульяновлар гаиләсе һәм, беренче чиратта, Мария Александровна, бик тә катлаулы мәсьәлә алдында кала. Ул кызы Аннаны шундый ерак җиргә бер ялгызын гына җибәрә алмасын аңлый. Сембердәге йорт-җирне сатып, Анна Ильинична белән бергә Себергә китү — аның өчен хәл ителгән нәрсә. Тик менә Володя мәсьәләсе борчый. Аня да үз янында булсын, Володя да университетка керә алсын өчен нәрсә эшләргә соң? Себерме, әллә Казанмы? Билгеле, соңгысы әйбәтрәк. Ләкин әгәр Казанда эш барып чыкмаса, аңарга бердәнбер юл кала: Аннаны сөргенгә Көнчыгыш Себергә түгел, һич югында Томск шәһәренә җибәрүләрен сорарга. Ә нигә Томскига? Чөнки алай иткәндә Володяның укуы мәсьәләсе дә хәл ителә: Томскида университет ачылырга тиеш.

Һәм бик озак йөргәннән соң, зур мәшәкать-тырышлыклар белән, Мария Александровна кызы Аннага сөрген урыны итеп Казан губернасын билгеләүләренә ирешә. Бу үтенечен канәгатьләндерүдә аңа апаларының бу авылда яшәүләре ярдәм итә. Нәкъ менә шундый шарт — үз өсләренә поручительлек вазифасын алган туган апалары яныннан беркая да китмичә, алар белән бергә яшәү шарты белән Анна Ильиничнага сөрген вакытын Кокушкино авылында үткәрергә рөхсәт итәләр.

Менә шундый шартларда Ульяновлар гаиләсе, Сембер шәһәрендә булган бар мал-мөлкәтне сатып, 1887 елның июнендә Казанга күчеп килә. Җәйне һәр вакыттагыча Кокушкинода үткәрәләр, ә көзен, төгәлрәк итеп әйтсәк, сентябрь азакларында, шәһәргә әйләнеп кайталар. Тик менә кайда торырга? Ульяновларның истәлекләреннән без шуны беләбез: Кокушкинодан кайтканнан соң Казанда алар яшәгән беренче фатир инде без телгә алган Беренче тау урамында, Ростова йортында була. Бу истәлекләрне җентекләбрәк укыганда үзеннән-үзе бер сорау туа: «Нигә бу йортта?» Анна Ильиничнаның хатларыннан укып белгәнебезчә, бу өй салкын һәм юеш булган бит. Өстәвенә, без инде шулай ук белгәнебезчә, бу өйдә Мария Александровнаның апасы Л. А. Ардашева-Пономарева гаиләсе яшәгән. Ике гаиләгә, гәрчә иң якын туганлык җепләре белән бәйләнгән булсалар да, бер өйдә торуы кыен-кысан буласын, ни генә әйтсәң дә, ерактагы кояшның ныграк җылытуын алар белмәгән дип әйтә алмыйбыз. Әлбәттә, белгәннәр, шулай да моңа барганнар. Эш нәрсәдә соң? Бу сорауга җавап соңгы елларда гына табылды. Мондый корбанга, мондый кыенлыкка Мария Александровна аңлы рәвештә риза булган икән. Ардашева-Пономарева белән бер өйдә яшәгән очракта,— ә бу ханым, инде әйтеп үткәнебезчә, Анна Ильиничнаның поручителе,— ул сөргендәге кызына кышкы айларда гына булса да Кокушкинодан Казанга күчеп торырга рөхсәт итүләрен сорап мөрәҗәгать итәргә

нигезе күчләрәк булачагын яхшы аңлаган. Бу үтенеч уңай хәл ителгән очракта Анна Ильинична энисе янында гына түгел,— монысы аерата мөһим,— туган апасы Любовь Александровна, ягъни үзенең поручителе янында да яшәү мөмкинлеген алачак.

Ләкин Мария Александровнаның тырышлыгы бу юлы нәтиҗә бирми. Анна Ильиничнага вакытлыча гына булса да Казанга күчеп торырга рөхсәт итмиләр. Полиция департаментыннан шундый җавап алынганнан соң ук (ә ул җавап, хәзер ачыкланганча, 1887 елның 29 октябрендә алына) Ардашева-Пономаревалар белән бер өйдә кысылып яшәүнең хаҗәте калмый. Ульяновлар үзләренә икенче фатир эзли башлыйлар һәм аны тиздән Яңа Комиссариат урамында (хәзерге Комлев урамы, 15) табалар.

В. И. Ленинның Казандагы тормышын тикшерүдә соңгы елларда шактый эш башкарган Г. Хаитның ачыклавынча, алар бу йортка 1887 елның 3—4 ноябре белән 10 ноябре арасында күчкәннәр. Чөнки Яңа Комиссариат урамындагы М. Н. Соловьева йортындагы буш квартираларга кеше кертелүе турындагы игълан «Волжский вестник» газетасында шул елның 2 ноябрендә басылып чыга. Ә 10 ноябрьда Ольга Ильинична үзенең дус кызына язган хатында: «Миңа Яңа Комиссариат урамы, Соловьева йорты адресы белән яз»,— ди. Моның шулай икәненә ышансак, Ульяновлар Беренче тау урамындагы Ростова йортында, бүген аның стенасына куелган истәлек тактасында язылганча, 1887 елның август-сентябрь айларында түгел, шул елның сентябрь азагыннан ноябрь башларына кадәр яшәгәннәр булып чыга.

Казанга килгәч Владимир Ильич император университеты ректоры исеменә гариза яза. Әмма аны бирергә кочак җәеп үк каршы алмыйлар. Ректорның беренче резолюциясе менә мондый була: «Характеристика алганга хәтле кичектереп торырга». Бары тик Сембер шәһәреннән тел-теш тидергесез әйбәт характеристика алынганнан соң гына университет түрәләре аны студент итеп алырга риза була.

Әмма Владимир Ильичка барыбер аны тәмамларга мөмкин булмый. Университетта 1887 елның 4 декабрендә булган студентлар сходкасы турында, анда Владимир Ульяновның актив катнашуы, катнашуы гына түгел, аны оештыручыларның берсе булуы, шуның өчен аның университеттан чыгарылуы, Кокушкинога сөргенгә җибәрелүе турында барыбыз да беләбез. Ул сөрген срогын тутырып янә Казанга кайтканнан соң — 1888 елның сентябреннән башлап 1889 елның маена кадәр — Ульяновлар гаиләсе безгә инде мәгълүм булган Беренче тау урамындагы Орлов йортында (хәзер Ульяновлар урамы, 58) яши. Бу урында тагын бер кечкенә детальгә игътибар итәргә кирәк. 1888 елның көзендә патша хөкүмәтенең мәгариф министры И. Д. Деляновның Казанга килүеннән файдаланып, Мария Александровна аның исеменә чираттагы гаризасын җибәрә: «Әгәр сез галиҗәнаблар,— диелә анда,— минем улым Владимирга яңадан Казан университетына керергә мөмкинлек бирүне уңайсыз дип тапсагыз, аңа Россия университетларыннан берсенә: Мәскәү, Киев, Харьков яисә Дерпт университетына керергә рөхсәт итегез». Җавап кыска була: «Министр үтенүче ханымның юллавын кире кагарга булды». Ләкин хәзер сүз бу җавап турында түгел. Ильич әнисенең әлеге гаризасының ахырында «Казан шәһәре, Грузин урамы, Опехтин йорты» (хәзерге Карл Маркс урамы) дигән адрес куелган. Эш нәрсәдә соң? Без бит әле генә, 1888 елның сентябрендә Ульяновлар инде Беренче тау урамында, Орлов йортында яши башлаган дигән идек. Моның аңлатмасын без әлеге дә баягы Ольга Ильиничнаның дус кызы А. Щербога язган хатыннан табабыз. «Без әнием белән бөтен Казанны әйләндек,— дип яза ул,— бу квартирага тукталган идек (ягъни Грузин урамындагы йортка — Р. С.), ләкин ул юеш булып чыкты һәм без анда калмаячакбыз. Бу квартиралар белән бәла!

...Менә әле генә әнием кайтты — квартир белешкән. Беренче тау, Орлов йорты. Хатыңны яңа өйгә җибәр, без ике көннән күчәбез».

Ульяновлар Орлов йортына 4 сентябрьдә күчкәннәр булып чыга.

Бу дус һәм бердәм гаиләнең истәлеген һәм гүзәл революцион традицияләрен хөрмәт итү йөзеннән Казан хезмәт ияләре Беренче тауга Ульяновлар урамы дигән исем бирделәр, ә бу гаилә 1888 елның сентябреннән 1889 елның маена кадәр яшәгән 58 нче йортта В. И. Ленин музее эшли. Бу йортның торак бүлмәләре В. И. Ленин туганнарының истәлекләре буенча, Мария Ильинична, Дмитрий Ильич, шулай ук

аларның туганы Н. Веретенниковның актив катнашында җиһазланыла. Музей 1937 елда ачылды. Зур мәхәббәт белән җыйналган, зур зәвык белән урнаштырылган экспонатлар юлбашчының һәм аның туганнарының Казанда яшәгән чоры турында, аларның үзара мөнәсәбәтләрендәге дуслык, иптәшлек рухы турында сөйлиләр.

Музейга килгән һәр кешене беренче чиратта таңга калдырган нәрсә — гадилек. Күп кулланыла торган бу сүзнең әлеге очракта үзенә хас ниндидер аерым бер мәгънәсе бар. Ул — әлеге гадилек — бүлмәләрдәге җиһазларда да, аларның кеше күзенә бәрелеп торсын дигән мещаннарча омтылыш белән куелмаган булуларында да, китаптан башлап гади генә юк-бар нәрсәгә кадәр һәр әйбернең нинди дә булса бер максатка хезмәт итүендә дә чагыла. Аларның барысын да карап йөри торгач, экскурсоводларның сүзләрен игътибар белән тыңлый торгач, үзеннән-үзе шундый бер нәтиҗәгә киләсең: югары әхлак сыйфатларына ия булган һәм үз тормышларын халыкка хезмәт итүгә багышлаган кече Ульяновларның чын кеше булып үсеп җитлегүләре нәкъ менә шундый шартларда гына, нәкъ менә шундый гаиләдә генә мөмкин булган. Биредә тупланган бай материал белән танышып йөргәндә ирексездән хәтергә КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежневның В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны бәйрәм иткән вакытта әйткән сүзләре килеп төшә: «Ленинның тормышта шундый юл сайлавында Ульяновлар гаиләсе шактый зур роль уйнаган. Илья Николаевич белән Мария Александровнаның барлык алты баласының да революционер булып китүе очраклы хәл түгел. Аларның гаиләсе рус демократик культурасының иң яхшы традицияләрен үзенә сеңдергән».

В. И. Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле булган бүтән урыннар кебек үк, Казандагы музей да күп меңнәрчә кешенең чын йөрәктән яратып караган, изге итеп санаган урыны ул. Сөекле юлбашчыбызны хәтерләткән һәр нәрсәгә үефикере, җаны-йөрәге белән якын булырга теләүчеләрнең агымы һич өзелеп тормый биредә. Музей ачылганнан соң үткән еллар эчендә анда инде 4 ярым миллионнан артык кеше булган.

Сүзнең ахырында тагын бер фикер белән уртаклашыйк. Мәгълүм булганча, Ульяновлар Беренче таудагы йорттан һәм, гомумән, Казаннан 1889 елның 3 маенда китәләр. Әдәбиятта аларның шәһәребездән китүләренең төп сәбәбе итеп гадәттә Мария Александровнаның Самара губернасындагы Апакаево авылы янында утар сатып алуы күрсәтелә. Бу дәлил белән бәхәсләшүе кыен. Тик менә Казандагы В. И. Ленин музее хезмәткәрләре моңа шактый ук җитди бер нәрсәгә игътибар итәргә киңәш бирделәр. Сүз Мария Александровна Ульянованың кызы Мариягә кызлар гимназиясенең икенче сыйныфына керү өчен имтихан тотарга рөхсәт итүен сорап директор исеменә биргән гаризасы турында бара. Бу кәгазь 1889 елның 22 апрелендә язылган. Үзеннән-үзе шундый бер нәтиҗә сорала: Ульяновларның ун яшьлек Маняшаны Казанда ялгызын калдырырга җыенган булулары икеле. Шул ук вакытта кыз Казанда укырлык булмагач, китәргә ике атнадан да кимрәк вакыт кала нигә мондый гариза язып торырга иде? Бәлки бу гаризаны биргән көн белән гаиләнең Казаннан китү вакытын аерып торган уникe көн эчендә бу китүнең төп сәбәбе үк булмаса да, аны тизләтүгә китергән бер-бер хәл булгандыр? Бәлки бу бер-бер хәл дигәнебез ул вакытта Владимир Ильичның баш өстендә болытларның яңадан куера башлавы, ягъни кулга алыну куркынычының яңадан янавыдыр? Бик ихтимал. Н. Е. Федосеев истәлегенә багышланган мәкаләсендә В. И. Ленин үзе болай дип яза: «1889 елның җәй азагында Федосеевның һәм Казандагы түгәрәк,— сүз уңаенда: мин катнашканының да,— членнарының кулга алынуы турында ишеттем. Ул җәйдә Казанда калган булсам, шулай ук бик җиңел кулга алынган булыр идем, дип уйлыйм».

Кыскасы, уйланыр нәрсә, эзләнер-тәпченер нәрсә бар әле монда.

# ЮЛБАШЧЫНЫҢ ГОМЕРЛЕК ЮЛДАШЫ

Гаять киеренке тормыш белән яшәгән, көрәш уртасында кайнаган даһи акыл иясе Владимир Ильич Ленин узган юлга күз төшергәч, миллионнар йөрәгендә искиткеч зур соклану хисләре уяна: шундый бөек эшләрне башкарып чыгу өчен ару белмәс көч-куәтне кайдан алган соң ул?

Ильичның бала һәм үсмер чагыннан ук физик яктан чыныгып үсүе аңа профессиональ революционер тормышына төшкән авыр сынауларны уңышлы үтәп чыгарга ярдәм итә. Көн саен күнекмәләр ясау, чыныгу, эш һәм ял режимын төгәл саклау аңарда корычтай нык ихтыяр көче тәрбияләгән. Шуңа күрә дә ул авыруларны (яраланганнан соң авырганын исәпләмәгәндә) бөтенләй диярлек белмәгән. Ленин гимнастика белән шөгыльләнгән, тауларга менәргә яраткан, рәхәтләнеп тимераякта һәм чаңгыда шуган, велосипедта йөрүне хуш күргән. Ул искиткеч оста йөзүче булган, ауга йөргән, крокет һәм городки ише уеннар уйнаган. Теләсә нинди шартларда да: гаиләдә, сөргендә, төрмәдә, эмиграциядә, хәтта совет дәүләтенең җитәкчесе булгач та физик күнекмәләр ясауны бер генә көнне дә онытып тормый. Апасы А. И. Ульянова-Елизарова, сеңелесе М. И. Ульянова, энесе Д. И. Ульянов, хатыны Н. К. Крупская һәм шулай ук көрәштәш иптәшләренең бик күп истәлекләре моның шулай булуын бик ачык раслый. Ильичның хатларын өйрәнү дә аның физкультура белән даими шөгыльләнүен исбатлый. Ул бу турыда үзенең 140 тан артык хатында теге яки бу дәрәҗәдә телгә алып уза.

Апасы Анна Ильинична: Владимир Ильич беркем эшләмәгәнчә эшли дә, ял да итә белә иде, дип искә ала. Ә сеңелесе Мария Ильинична: теоретик хезмәт белән нык-лап шөгыльләнү Владимир Ильичны коры кеше итмәде, дип яза. Ул ничек ялкынланып эшләсә, шундый ук ялкын белән ял да иткән, һавада йөргән, бер генә минутка да тормышны яратудан туймаган.

Даһи юлбашчының физкультура белән нык-лап кызыксынуы турында Н. К. Крупская истәлекләреннән дә укып беләбез. Ул баш миен өйрәнү институты анкетасына җавап биргәндә болай дип яза: «Һавада озак йөргәндә дә әрмый иде. Бик хәрәкәтчән, ятып торуны яратмый... Городки уйный, йөзә, тимераякта яхшы шуа, велосипедта йөрергә ярата иде. Ул — гөмбә җыюның искиткеч остасы, мылтык асып ауга чыгарга, урманда булырга бик ярата... Үткен күзле иде ул — төз ата торган иде... Табигатьне, тауларны, урманны һәм шәфакъне сокланып күзәтә иде. Биеклектән курыкмый — тау түбәләренең «иң читенә» үк килеп, аска карый ала... Суга беренче булып, һичбер икеләнүсез, һичбер куркусыз керә. Ленин курку белмәс, кыю һәм батыр кеше булды» (В. И. Ленин турында истәлекләр, 1 том, икенче басма, М., Политиздат, 1979, 603—609 битләр).

Совет хөкүмәтенең Сәламәтлек саклау халык комиссары Н. С. Семашко да Ильичның физкультура белән чын-чыннан шөгыльләнүен искә төшерә. «Ленин мөмкин булганча үз сәламәтлеге турында кайгыртты... Ул эчми, тартмый иде. Ленин бу сүзнең иң төгәл мәгънәсендә физкультурачы иде» (шунда ук, 2 том, 282—283 битләр).

Ильичның балачак һәм үсмер еллары Идел буенда, Сембердә, Кокушкино, Казан, Алакаевка һәм Самарада уза. Аның әтисе белән әнисе балаларын тәрбияләүгә бик зур көч куялар. Алар балаларының рухи һәм физик мөмкинлекләрен гармонияле үстерү, сәламәтлекләрен ныгыту, характерларын чыныктыру турында кайгырталар. Володя кечкенәдән үк хезмәтне яратып, бөтен нәрсә белән кызыксынучан булып үсә, күп укый, укуында гел өлгереп бара, дусларына һәрчак булыша, рояльдә уйный, җырларга ярата. Абый-апалары, эне-сеңелләре белән берлектә өйдәге бөтен эшне башкара. Балалар өлкәннәргә коедан су ташырга, чәчәкләргә су сибәргә, җиләк җыярга булышалар. Әтиләре Илья Николаевич өйдә булган чакларында вакытын балалары белән уздыра: алар белән крокет, шахмат ише төрле уеннар уйный, бергәләп урманнарга чыгалар, Зөя елгасында коенып кайталар. Володя башка балалардан шат күңелле, тере җанлы булуы белән аерылып тора. Ул сабый чагыннан

диярлек төрле физик күнекмәләр ясауга, эш һәм ял режимын саклауга гадәтләнә. Шушы гадәтенә гомере буе тугры булып кала.

Балалар нинди генә уеннар уйнамыйлар! Кайчакта аларны үзләре дә уйлап чыгаралар. Володя бигрәк тә аучылар һәм индеецлар булып уйнарга ярата, шушы уен өчен ул җәя-ук ясый... Гимназиядә укыганда башкалардан җитезлеге, елгырлыгы белән аерылып тора, гимнастика белән шөгыльләнә, аркан һәм колга буйлап үрмәләп менәргә ярата. Ульяновлар гаиләсенең һәр җәйне Сембердән Кокушкинога ялга кайтып тору сәяхәте аларның балаларына әйтеп бетергесез сөенеч китерә. Әти-әниләре һәр баланың сәламәт булып үсүен кайгырталар, аларны һәр яклап чыныктырырга тырышалар — саф һавага, табигать кочагына бик еш алып чыгалар, коенырга өйрәтәләр.

Кокушкинода чагында Володя үзенең буш вакытын энеләре һәм сеңелләре белән үткәрә, шулай ук башка балалар белән дә уйный. Балалар урманга баралар, Үшнә суында коеналар, көймәдә йөриләр. Бу хакта Ильичның якын туганы Н. Веретенников искә төшерүенчә, Володя һәр уенга бик җитди карый. Ул уенда җиңел отуны яратмый. Бервакыт аңа чын-чыннан көч сынашырга туры килә. Ул үзеннән бер яшькә олы һәм гәүдәгә бер башка озын малай белән көрәшә. Ектырса — ектыра, әмма алдан ук, бу малай миннән көчлерәк, дип, көрәшүдән баш тартмый.

Балалар «Иректе казак» дигән уенда үзләре яраткан әсәр геройларын сайлыйлар. Володяга Тарас Бульба булу ошый. Озын агач сөнге күтәреп, үз «атына» атланып, башка малайлар белән бергә, ул болыннар, үзәннәр буйлап чабып йөри.

1887 елның декабренда Владимир Ильич студентлар чуалышында катнашканы өчен Казан университетыннан чыгарылып, Кокушкинога сөргенгә озатылгач, яшь Ульянов анда үзенең бер генә минутын да әрәм уздырмый: гаять күп укый, күп төрле физик күнекмәләр дә үти.

Тагын ике елдан соң Ульяновлар гаиләсе Казаннан Самарага күчеп килә. Җәйләрен Ильич үзенең туганнары белән Алакаевка авылына кайта. Бирелә ул, куе булып үскән юкә агачлары арасына өстәл белән урындык куеп, көннәрен китап укып уздыра. Ел ярым вакыт эчендә Петербург университеты юридик факультетының тулы курсын уза һәм 1891 елда имтиханнарны уңышлы тапшырып кайта. Имтиханга әзерлек һавада йөрүләр, ауга чыгулар, коенулар һәм гимнастик күнекмәләр ясау белән чиратлаштырып алып барыла. Владимир Ильич Самарада яшәгән чагында иптәшләре белән Идел буйлап көймәдә сәяхәт итәргә аеруча ярата. Мондый сәяхәт, әлбәттә, аның сәламәтлегенә һәм физик яктан чыныгып үсүенә уңай тәэсир ясый.

Казанда һәм Самарада яшәү елларында В. И. Ленин чын-чынлап революционер-марксист булып формалаша һәм үзенә гомерлеккә хезмәт иләрен изелүдән, коллыктан азат итү өчен революцион көрәш юлын сайлый. Революция, дип яза соңыннан В. И. Ленин, массалардан һәм шәхестән көчләрне туплауны һәм җигелеп эшләүне таләп итә (В. И. Ленин турында истәлекләр. 1 том, 2 нче басма, М., Политиздат, 1979, 94 бит).

Ул, идея ягыннан чыныгу белән беррәттән, физик яктан чыныгу революционер өчен аеруча зарур дип исәпли. Революционер кыюлыкка һәм батырлыкка даими күнекмәләр үткәрү нәтиҗәсендә генә ирешә ала. Ленин балачагында үзләштергән гадәтләрен олыгайгач та онытмый. Ильичка ачык һавада йөрү, табигать кочагында булу әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә. Кайда гына булмасын, ул иң элек шул урынның табигате белән таныша. Бөек революционер өч ел Себердә һәм Шушенскоеда сөргендә яши, унбиш елга якын гомерен эмиграциядә үткәрә. һәм ул һәркайда көненә бер-ике сәгать кенә булса да һавада йөреп керү өчен вакыт таба, кайчакларда туристик экскурсияләргә дә чыга.

Шулар хакында Владимир Ильич еш кына туганнарына да язып тора. 1898 елда ул Себердән әнисенә җибәргән бер хатында: «Монда һавалар әле һаман да суык. Себер кышы һәрхәлдә үзен танытырга тели. Ләкин мин салкынга беркадәр күнектем шунда, һәркөнне озаклап һавада йөри бирәм» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 37 том, 93 бит).

Лондонда яшәгәндә Владимир Ильич хатыны Надежда Константиновна белән еш кына шәһәр читенә чыга. Алар парклар буйлап ҳозурланып йөриләр. Бу урын

аларны шул ягы белән дә үзенә тартып тора: биредә Карл Маркс күмелгән кабер була. Ленин Лондоннан әнисенә мондый эчтәлекле хат юллый: «Күптән түгел без Е. В.[1] ны да алып бик зур прогулкага чыктык, төшке аш урынына бутербродлар алдык та... көне буена киттек. Бик шәп ял иттек, саф һава сулап барыбыз да, балалар кебек шатланып йөрдек, соңыннан мин, Себердә аудан кайтканнан соң ятып ял иткән кебек, озаклап ял иттем. Гомумән, без чыгып йөрү ягыннан алдатмыйбыз. Мондагы бөтен иптәшләрдән шәһәрнең бөтен тирә-юнен өйрәнүчеләр — бер без. Төрле-төрле «авыл» сукмаклары табабыз, якын-тирәдәге урыннарны беләбез, еракларак та китеп йөрергә җыенабыз. Соңгы вакытта мин үземне яхшы сизәм, вакытында эшлим, тынгысызлыктан интекмим» (шунда ук, 294 бит).

1894 елның җәендә Владимир Ильич Петербургтан Мәскәү янындагы Люблино станциясендәге дачада яшәүче туганнары янына ялга кайта. Беренче тапкыр ул шунда велосипедта йөрергә өйрәнә. Соңыннан да Ильич велосипедны үз итә. Швейцариядә чагында ул хатыны белән икесенә велосипед сатып ала. Бу хакта Ленин хозурланып болай ди: Велосипед — «ял һәм прогулка өчен менә дигән нәрсә» (шунда ук, 331 бит). Ул Крупская белән дә, шулай башка иптәшләре белән дә Швейцария, Германия, Польша һәм Франция юллары буйлап велосипедка утырып йөри.

Әйткәнебезчә, Ленин табигатьне бик яраткан. Әмма таулар аны үзләренә аеруча нык тарткан. Ул Швейцариядә чагында Альп тауларының карлы түбәләренә күтәрелгән, Пилат һәм Ротхорн тауларының иң биек түбәләренә (2122 м, 2300 м) менеп караган, Польшада чагында Татры тауларының гүзәллегенә сокланган.

«Тауларга сәяхәтнең төп матурлыгын Ленин аларга менгәндәге кыенлыкларны җиңүдә күрә... Ул искиткеч чыдам турист иде. Мин аңардан ун яшькә яшьрәк булсам да, аның артыннан көчкә җитешә идем»,— дип искә ала үз хатирәләрендә С. Ю. Багоцкий (В. И. Ленин турында истәлекләр. 2 том, икенче басма, М., Политиздат, 1979, 325 бит).

Шулай бервакытны Ленин революцион көрәштәш дусты Багоцкий белән бергә бик хәтәр тауга мениләр. Чак кына ялгыш адым ясасаң да, аска мәтәлеп төшүеңне көт тә тор. Тау түбәсенә менеп җиткәч, алар үзләре алдында ачылган матурлыкка таң калып карап торалар.

Таудан кире төшкәндә Багоцкий үзенең юлдашына: Әйдәгез, мин сезгә тагын да матуррак урыннарны күрсәтәм, дигән булып хәвефсезрәк бүтән юлдан кайтырга тәкъдим ясый. Ленин аның хәйләләвен бик тиз сизеп ала һәм кискен итеп: «Кыенлыклардан качарга ярамый! Аларны җиңә белергә кирәк!» — ди дә, үзләре менгән юлдан атлый. Тиздән алар үз сәяхәтләрен исән-имин тәгәллиләр (шунда ук, 328—329 битләр).

Тауларга сәяхәтләре турында шулай ук Н. К. Крупская да еш искә ала. Ул 1904 елда Ленин белән икәүләп, аркаларына биштәрләр асып, бер айга тауларга ял итәргә барулары турында яза. 1903—1904 елларның кышы Ильичка аеруча мәшәкатьле һәм киеренке булган, көннәр-төннәр буе эшләү аркасында нервлары шактый какшаган. Менә шул чагында аны бу халәттән таулар коткарган. Табигать кочагында туган яңа тәэсирләр, тау һавасы, арганчы йөрү һәм туйганчы йоклау аның сәламәтлегенә уңай тәэсир иткән. Ильич үзен сабыйларча шат һәм күңелле итеп тойган.

Шундый сәяхәтләрнең берсе турында В. И. Ленин Швейцариядән әнисенә хат язып җибәрә: «Шушы көннәрдә без монда, Надя... белән Саләвка менеп, бик яхшы прогулка ясап кайттык. Түбәндә, Женевада бөтен җир томанлы, караңгы булып тора, ә тау башында (диңгез тигезлегеннән 1200 метрлар чамасы биеклектә) ялт иткән кояш, кар, чана шуу, нәкъ Россиядәгечә матур кышкы көн» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 37 том, 296 бит).

Россиядәгечә кышкы матур көн!.. Бөек пролетар язучысы Максим Горький да эмиграциядә вакытында бу сүзләрне еш кабатлый. Ленин аның Россия хакында һәм авыл турында сөйләгәннәрен тыңларга яраткан һәм авыр сулап әйтә торган булган: «Мин Россияне никадәр аз беләм икән әле. Сембер, Казан, Петербург, сөрген — ни-

---

[1] Е. В. — Елизавета Васильевна — Н. К. Крупскаяның әнисе.

бары шулар гына!» («Ленин шундый иде», М., Политиздат, 1965, 500 бит). «Җәен Идел буена барсаң, нинди шәп булыр иде! — дип яза Владимир Ильич Лондоннан әнисенә.— 1900 елның язында өчебез: син һәм Анюта бергә пароходта нинди рәхәт йөргән идек бит!» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 37 том, 284 бит). Ул шушы хатында пароходка утырып, Идел, Кама һәм Агыйдел буйлап Уфага баруын искә төшерә.

В. И. Ленин гаҗәеп оста йөзүче була. Шуңа күрә ул җәе чыкканда коенырга ярата. Себердә сөргендә булганда Ильич көненә икешәр мәртәбә Енисейга коенырга бара. Моның өчен аңа шактый ерак ара узарга кирәк була.

1901 елда Мюнхеннан язган хатында ул әнисенә көн саен коенуы турында хәбәр итә. «Володя су керергә бик ярата...»,— ди аның хакында Надежда Константиновна да (шунда ук, 426 бит). В. И. Ленин гомере буена үзенең бу шөгыленә тугры булып кала. Тимераякта шууны да ул коенудан һич ким яратмаган, бу аңа искиткеч ләззәт биргән, күңел күтәренкелеге алып килгән. «Боз өстендә бөтерелеп әйләнүче, тимераякта шуучы яшьләрчә җитез, шат күңелле бу кешене кем дә булса бераү күргәч, үзе каршында бөек юлбашчы һәм революцион пролетариат теоретигы басып тора дип уена да китермәс иде», дип яза С. Ю. Багоцкий (В. И. Ленин турында истәлекләр. 1 том, 2 нче басма, М., Политиздат, 1979, 283 бит).

Ильичның иң мавыккан, иң яраткан шөгыльләреннән берсе, әлбәттә, ауга йөрү була. Җәен дә, кышын да, мылтык асып, сунарга йөрергә бик яраткан. Шуңа ул аучылык серләрен бөтен нечкәлеге белән үзләштергән.

Ленин гимнастик күнекмәләр ясауны бер генә көн дә онытмый. Спортның шушы төре белән шөгыльләнү аңа сөргендә булганда һәм бигрәк тә төрмәдә утырганда сәламәтлеген һәм көчен саклап калырга ярдәм итә. Әнисенә язган бер хатында ул тоткынлыкка ябылган энесе Дмитрийның язмышы белән кызыксына. Анда мондый юллар бар: «Бердән, ул төрмәдә диета саклыймы икән? Юктыр. Ә анда, минемчә, диета саклау бик кирәк. Икенчедән, гимнастика белән шөгыльләнәме икән? Мөгаен, юктыр. Бу да бик кирәк. Мин һәрхәлдә үз тәҗрибәм белән әйтә алам: төрмәдә бик теләп һәм файдасын күреп һ ә р  к ө н йоклар алдыннан гимнастика белән шөгыльләнә идем. Шуннан соң, иң салкын вакытларда да, камера суп-суык булганда да җылынасың һәм бик әйбәт йоклыйсың. Мин аңа шактый уңайлы гимнастика алымын (көлке булса да) киңәш итә алам — 50 тапкыр җиргә кадәр иелергә. Мин үземә нәкъ әнә шундый дәрес билгеләгән идем һәм надзирательнең, ишек тишегеннән күз салып, бер тапкыр да предварилка чиркәвенә барырга теләмәгән бу кешедә кинәт шундый диндарлык каян килгән дип шаккатып караштыргалавына уңайсызланмый идем! Ләкин иелү берләттән 50 тапкырдан ким булмаска тиеш һәм, аякны бөкмәскә, иелгән саен кулны идәнгә тидерергә кирәк...» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 37 том, 87—88 битләр).

Гимнастика белән шөгыльләнү Ильичка яралангannan соң да кирәк була. Врачлар киңәше белән ул шушы алым ярдәмендә яралы кулын күнектерә. Бу күнекмәләрне хәтта Совнарком утырышы барганда да ясый торган була. Соңыннан яра төзәлә — кулы аны шактый ук яхшы «тыңларга» өйрәнә.

В. И. Ленинның физик культурага мөнәсәбәте барыннан да элек һәрьяктан гармонияле үскән шәхес тәрбияләүгә бәйләнгән. Даһи юлбашчы аны революционерлар тәрбияләүдә бик кирәкле чара дип саный. Шуңа күрә ул якыннарының һәм революцион көрәштәшләренең сәламәтлеген саклауга, аларның физик яктан камил, чыдам һәм какшамас көчле рухлы булуларына гаять зур игътибар бирә.

Даһи юлбашчыбыз төзегән Коммунистлар партиясе хезмәт ияләрен һәм яшьләрне Ленинча яшәргә, эшләргә һәм көрәшергә өйрәтә. Совет кешеләре рухи яктан да, физик яктан да камил, матур булырга тиешләр. Бөек Ленинның онытылмас васыяте бу.

**Әнвәр БУЛАТОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты.

# УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

## ӨЙ ТУЙЛАРЫ СОҢЛАМАС

Партия шәһәр комитетының беренче секретаре сүзне уратып тормыйча, турыдан ярып салды:

— Ничек карыйсың? Синең «Авангард»та партком секретаре вазифасын үти алуыңа ышаныч бар.

Зөфәр Хөснуллин мондый хәбәрне ишетермен дип уена да китермәгән иде. «Секретарь итеп? Авыл Советында эшли башлаганына да күп түгел бит әле. Иң элек үзеңне шул эштә күрсәтергә кирәк. Юк, ризалык бирергә ярамый»,— дип уйлап алды ул. Аннары бөтенесен берьюлы әйтеп бетерергә теләгәндәй, тезеп китте:

— Юк, моның өчен тәҗрибә кирәк. Ә миндә тәҗрибә дигәннең тамчысы да юк.

Беренче секретарь аны, әйтәсен әйтеп бетерсен дигәндәй, бүлдермичә тыңлап торды.

— Ярый, ярый. Түбәнсенмә. Авыл Советында эшләреңнең гөрләп баруын күреп торабыз. Тәҗрибәсе булмаганнар алай эшли алмый.— Беренче секретарь хушлашу өчен урыныннан торып басты.— Мичуринда хәзер сиңа алмашка башка яшьләр үсеп килә. Ә син үзеңне яңа җирдә күрсәт.

Сөйләшкәннән соң күп тә узмады, Хөснуллинны «Авангард» колхозына партком секретаре итеп сайладылар. Зөфәрнең хәзер һәр көне кешеләр арасында уза. Авыл халкы, колхозчылар да аның гомум эш өчен янып йөрүен тиз арада күреп алдылар. Икенче кат секретарь итеп сайлап калдырулары да тикмәгә генә булмады. Ул колхозчыларның олы ышанычы турында сөйли иде.

Хөснуллин олыны — олы, кечене кече итә белә торганнардан. Аның бу күркәм гадәте умартачы булып эшләгән чагыннан ук килә. Егетне моңа Сабирҗан бабай өйрәткән иде. «Улым, кешеләргә якты йөзең, җылы сүзең булсын, — ди торган иде ул.— Алар да сиңа якты йөзләре, җылы сүзләре белән карарлар».

Хәер, Сабирҗан бабай мондый холыкка бер Зөфәрне генә өйрәтмәгәндер. Аны күпләр олы хөрмәт белән искә ала. Менә шул кеше — авылның мөхтәрәм карты Зөфәрнең беренче остазы булды. Карт үзе белгән-күргәннәрне егеткә җанын салып өйрәтте.

Әйтик, аларның авылы нигә Мичурин дип атала? Баксаң, бу исемне игенчеләр үзләре кушкан икән. Авыл кешеләре игенчелек белән дә, бакчачылык белән дә шөгыльләнүчеләрне «мичуриннар» дип йөрткән. Шуннан авылның исеме Мичурин булып киткән.

Сабирҗан бабай авыл атамасына бәйле тагын бер хәлне сөйләгән иде. Ниндидер бер усал теллесе авылны «Кәҗә бистәсе» дип тә атамакчы булган, имеш. Җил исми — яфрак селкенми дигәндәй, моның да нигезе бар икән. 1932 елда кемнеңдер кушуы белән яңа гына оешкан колхозны совхозга үзгәртеп куялар. Ул кәҗә үрчетеп, брынза-сыр ише нәрсәләр җитештерергә тиеш була. Тик берни дә килеп чыкмый: халык бу шөгыльгә кул селти, үз кыйбласына хыянәт итмичә иген игә, алмагачлар үстерә.

Сабирҗан бабай — үз гомерендә күпне күргән, күпне кичергән кеше. Оешкан елларында күмәк хуҗалыкны җитәкләгән, бригадир булган. Зөфәр үзен белә башлаганнан бирле Сабирҗан бабай умарталыкта эшли иде инде. Мәктәпне тәмамлагач, ул аңа ярдәмче булып килде.

Беркайчан да кызмас, тузгымас, әйтәсе сүзен җайлап, әмма үзәгеңә җиткереп

әйтә белә торган сабыр холыклы карт иде ул. Эшне җиренә җиткереп үтәүне таләп итә. Зөфәргә болай ди торган иде: «Син, улым, минем өчен яки бал кортлары өчен эшлим дип уйлый күрмә. Иң әүвәл бу синең үзеңә кирәк: кешегә бәяне кылган эшенә күрә бирәләр. Шуны хәтереңдә тота күр!»

Шулай да Зөфәр бер тапкыр шушы тыйнак, сабыр картның кызып киткән чагына тап булды. Көннәрнең берендә умарталыкка бригадир килеп чыкты. Аны карт ачык йөз белән каршы алды, кәрәзле бал белән сыйлады. Ә инде бригадир кайтып китәргә юнәлгәндә Зөфәрне арбага утырырга кушып: «Әйдә, киттек. Мин сине алырга килдем. Сине төзүчеләр бригадасына билгеләделәр», — диде.

Зөфәр уналтынчы яше белән бара иде. Умарталыкта икенче елын үткәрә инде. Рамын да ясый, чыбыгын да тарттыра — нигә тотынса, кулы шуңа ятып, ябышып тора. Ул өйдә иң өлкәне. Үзеннән соң тагын өч туганы бар. Әтиләре сугыштан кайтып күп тә тормады — вафат булды. Үсмер малай әнисенә булышырга тырыша иде. Шуңа күрә Сабирҗан бабай өйрәткән һәр нәрсәне карусыз үзләштереп бара.

Карт менә шул мәлне кызып китте дә инде.

— Ничек инде ул — утыр? Сорау юк, нитү юк! Ә аны эшкә кем өйрәткән? Инде өйрәнеп җиткәч кенә, сакал сыйпап калыргамы?

— Үз белдегем белән килмәдем ләбаса. Идарә шулай карар кылды. Балта осталары җитешми.

— Күреп торасың, картаям. Сигезенче дистәне куам. Мин аны үз урыныма калыр дип йөрим тагын. Менә сиңа мә!..

Бригадир нидер әйтмәкче иде, карт тыңларга да теләмәде, аңа иреп, авылга кайтып китте. Умарталыкка икенче көнне генә әйләнеп килде. Шуннан ары аларны борчучы булмады...

Аннары умарталыкта Зөфәр үзе баш булып калды. Ярдәмче итеп аңа Коля Куракинны җибәрделәр. Аны эш җаена өйрәткәнче шактый җәфа чигәргә туры килде. Рамнан кәрәз кырырга кушасың, шундук эшкә тотына. Икенче карыйсың — йокыга киткән. Хәер, ундүртенче яшенә генә аяк баскан үсмердән ни көтәсең? Шунда Зөфәр Сабирҗан бабай әйткәннәрне исенә төшерде. Тора-бара Коля кул арасына әйбәт кенә кереп китте тагы.

... Көннәрнең берендә «Авангард» колхозының партком секретаре Зөфәр Хөснуллинны шәһәр комитетына чакырдылар.

Шәһәр комитетының беренче секретаре гәүдәгә озын, какча кеше. Урыныннан торды да, елмаеп, Зөфәрне каршы алды. Бер адым алга атлап, күрешергә кул сузды:

— Әйдә сөйлә, эшләрең ничек?! — Утыр дигәнне белдереп, ым кагып алды да, сорауларына җавап көтеп тормастан, дәвам итте. — Ни өчен дәшкәнне белмисеңме? — Беренче секретарь Зөфәр Хөснуллинга сынаулы караш ташлады. — Хәтерлисеңме, «Авангард»ка тәкъдим иткәндә, ике елга дип килешкән идек.

Дөресен әйткәндә, Хөснуллин бу хакта бөтенләй хәтерләми. Ул беренче секретарьның шәһәр комитеты тарафыннан тәкъдим ителгән яшь белгечләрне һәрчак күз уңында тотуын гына тоеп килә. Кеше ике ел эчендә эшкә җайлашып кына калмыйча, нәрсәгә сәләтле булуын күрсәтергә дә өлгерә диһ фикер йөртә шәһәр комитеты башлыгы.

— Сине «Җәлил»гә председатель сыйфатында тәкъдим итәбез. Тагын бәхәсләшәсеңме?

— Бу юлы юк.

— Монысы чын ирләрчә. Районыбыз тагын бер акыллы кешегә арткан алайса. Сиңа хәзер ничә яшь?

— Утыз ике.

— Җигелеп эшли торган чагың. Вакыты җиткәч, чакырырбыз.

1979 елның 15 мае. Кояш төшлеккә якынлашып килә. Муса Җәлил исемендәге колхоз председателе Зөфәр Хәлфиевич Хөснуллин үз кабинетында баш агроном белән сөйләшеп утыра.

Ул бөтенләй диярлек үзгәрмәгән. Йөзендә елмаю, карашы ягымлы. Кайчагын

да сине сынарга теләгәндәй йөзеңә озаклап текәлә. Алай да аны үзгәрмәгән диярлек түгел. Чигәсенә көмеш йөгергән...

Аның каравы ул җитәкләгәндә колхоздагы үзгәрешләрне саный китсәң, очына чыкмалы түгел. Иген уңышы икеләтә артты. Терлекчелек биналары төзәтелеп корылды, күбесе яңадан салынды. Нәселле маллар кайтарылды. Һәркайда төзелеш. Һәркемнең иркен, матур йортларда торасы килә. Белгечләр үз эшләрен яхшы үтиләр, яшьләр авылдан чыгып китәргә тормый.

Ел авыр башланды. Җирдә өченче майга хәтле кар ятты. Шушма елгасының суы ярларыннан ашып чыгарлык булмады. Кар эрегәч, тә, туфрак тиз генә өлгермәде: бер көнен җылы булса, икенче көнен яңә суытып җибәрә. Хәер, игенче өчен елның рәхәт булганы кайчан бар соң?

Чәчүгә 12 майда гына төштеләр. Туфрак тигез өлгермәгән. Борчакны әзер урыннар сайлап чәчтеләр.

Басуларның күп өлеше чүп үләненнән чистартылды. Бигрәк тә солычага карашы каты көрәш алып барылды. Бу-тирә елларда соңлап чәчү киң үткәрелә. Солыча шытып чыгуга, аны культивациялиләр. Шуннан соң гына тиешле ашлык орлыгы чәчелә. Күп чыгым сорала торган алым. Колхоз председателенең баш агроном белән сөйләшүе дә шушы хакта иде.

— Кәшәп-тау басуында эшләр ничек? — дип сорый Хөснуллин.

— Чәчә башладык. Тик бөтен басуны солыча каплаган.

Зөфәр Хөснуллин кинәт кенә баш агрономга текәлде. Ул аклана башлады:

— Әлбәттә, чәчүне ашыктырмаска дигәнне хәтердән чыгармадым. Нишләмәк кирәк: район вәкиле ашыктыра. Сезнең аркада бөтен районны артка өстерибез ди.

— «Артка өстерибез», имеш! Нишләгәнебезне без үзебез дә бик яхшы беләбез ләбаса!

Шуны гына көтеп торган диярсең: ишекне киң ачып, нейлон плащ, озын кунычлы резин итек кигән юан гәүдәле берәү килеп керде. Менә ул ялтыратып юылган идәндә пычрак итек эзләре калдыра-калдыра өстәл янына узды да, исәнләшергә дә онытып, председатель каршына килеп утырды.

— Сез, иптәш Хөснуллин, язгы кырчылык эшләрен алып бара белмисез ахры! Майның икенче яртысы тәмам, ә сез һаман иртә культураларны чәчмәгәнсез. Башбаштаклык! Шәһәр комитетына җиткермичә булмас,— диде ул кызганнан-кыза барып.

— Соңга калуның сәбәбе....

— Миңа сүз кирәкми, ә чәчү турында сан кирәк. Башкалар рапорт бирде инде, сез генә кыл кыймылдатмыйсыз, — диде район вәкиле, тавышын тагын да күтәрә төшеп. — Җәй буена мине монда яткырмакчы буласызмы әллә? — Хөснуллин эндәшми тора, ул ярсулы сүзләрен баш агрономга юдыра: — Ә сез нәрсә карыйсыз?

Җавап ишетмәгәч, ул бүлмә буенча йөрергә тотына. Каты итеп басуыннан идән такталары шыгырдап куя.

— Сез, Хөснулин, консерватор! Моның өчен башыгыздан сыйпамаслар! — һәм ул ишекне бар көченә бәреп яба да чыгып китә.

Председатель белән баш агроном сүзсез утырдылар. Давылдан соң кояш чыккан төсле, башта Хөснуллин җанлана төште.

— Кайда калдык әле? — диде ул. — Шулай итеп, быел Кәшәп-тауда эш майтара алмадык. Солычаны бөтенләй бетерү киләсе елга кала. Безнең эшне акырып-бакырып кына майтарып булмый шул...

1981 елның 6 августы. Кояш чыкмаган әле, әмма авылга таң яктысы төшкән чак. Берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, әтәчләр кычкыра башлый, ә Хөснуллин сәгать биштә идарәдә иде инде.

Аның бу колхозда унынчы елы инде. Бер генә ел да аңа быелгыдай борчу-мәшәкатьләр алып килмәде. Җәй буена җиргә яңгыр бөртеге төшмәде. Корылык. Кояш көн озын көйдерә дә яндыра. Чәчүгә соңлап төштеләр, ә игеннәр гадәттәгедән ун көнгә иртәрәк өлгерде. Бодай белән арпа тишелеп чыгар-ч. кмас ук башакка төрләнде. Адәм рәтле ни саламы, ни ашлыгы. Борчакка карарлык та түгел.

тишелеп чыгуга куырылып көйде. Аннары... уракка төшкән мәлдә үк, яңа чабылган участокка коеп яңгыр явып китте.

Шулай да зарланырга оят. 140 гектар мәйдандагы борчакның һәр гектары тугызар центнер уңыш бирде. Арыш начар. Башка елларны ул егерме сигез — утызар центнер чыкса, быел ундүртәр центнердан артмады.

Телефон шалтырады.

— Тыңлыйм сезне, Виктор Константинович... Бодайны тәгәлләп киләбез, арпага тотындык... Хәзергә тугызар чыга... Саламын мактап булмый... Шунда ферма янына кайтарабыз. Үләнгә катнаштырып силос салабыз... Кукурузмы? Кичә яңгыр явып узды. Соңрак шул — чукларын җибәрде, үсми ул хәзер... Әйе, әйе, үсмәсә дә, яшел килеш торачак... Суганның мәйданын быел унбиш гектарга киметтек, йөз гектар калды. Шул мәйданнан элекке уңышны алырга исәп тотабыз... Рәхмәт, Виктор Константинович. Сезгә дә уңышлар телим.

Ул, трубканы куеп, тәрәзәгә күз төшерде. Күлдән томан күтәрелә. Зәфәр Хәлфиевичнең кәефе шәп. Җылы сүзләр ишетү рәхәт шул ул.

Кичә кичтән, баш агроном белән килешеп, арпаны турыга урдырырга наряд бирделәр. Килешүен килештеләр, ә менә күңел тыныч түгел. Соңлап чәчү һәм җәй коры булу аркасында арпаның өске ягы өлгереп саргайды, ә аскы өлеше яшел килеш калды. Ләкин көтәргә ярамый — август аен яңгырлы була диделәр. Көнен-төнен ява башласа?

Басуга ул әнә шундый уйлар белән чыгып китте. Офык читендә кызыл флаглы комбайн күренде. Шунда ук таныды — Гата Монасыйповныкы. Улы белән эшли. Беренче көненнән алдынгылыкны үз кулында нык тота. Чирәм җирләрне күтәрүгә беренчеләрдән булып киткән иде, күренеп тора, казакъ далаларында яхшы чыныгу алган. Былтыр ул бөтенләйгә туган авылына әйләнеп кайтты. Аңа ияреп, Заһит Сәлахов комбайны килә. Ул тормыш юлын башлый гына әле: армиядән кайтты да комбайнга утырды. Каршыга бер-бер артлы тезелгән алты комбайн килә. Бункерына җиде йолдызчык төшерелгәне аның янына килеп житеп туктады. Сәет абзый Җамалиев. Утыз елдан артык механизатор булып эшли. Сугышның башыннан алып ахырынача йөреп кайткан кеше. Батырлыгы өчен Кызыл Байрак ордены алган, ә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән аны хезмәттәге батырлыгы өчен бүләкләделәр. Сәет абзый — ТАССРның атказанган механизаторы дигән мактаулы исемне алган остаз.

— Чыгуыгызга күптәнме, Сәет абзый?

— Беренче әйләнешне ясыйбыз.

Председатель белән икәүләшеп салам өемен актара башладылар. Хөснуллин эчтән саргаерга өлгермәгән салам тартып чыгарды, берничә арпа бөртеге җиргә коелды.

— Ни әйтерсең Сәет абзый?

Ул эндәшмәде, җилкәсен генә кагып куйды. Ни әйтәсең инде, янәсе, күреп торасың ич.

Бу басуда ашлыкны тезмнәргә салырга булдылар. Комбайннар өлгергәнне суктыру өчен башка җиргә юл алды.

Төшке аштан соң ул ындыр табагына сугылып чыкты. Монда бөтен эшләргә колхоз ветераны Һади Фәттахов җитәкчелек итә. Соңгы елларда авырып торса да эшләр тыгыз вакытта ярдәмсез калдырмый. Ул булганда борчылырга кирәкми: ашлык соңгы граммына чаклы исәпкә алына. Читтән караганда, ашыкмый кебек. Шофер машинасын үлчәүгә кертүгә, йөкне үлчәп, хисап кенәгәсенә язып та куйган.

— Кай арада өлгерәсең, Һади абзый? — дип сорый председатель.

— Һәр нәрсәнең үз җае бар инде аның.

Хөснуллин канәгать. Идарәгә кайтышлый аңа кукуруз төялгән машина очрады. Шоферы янәшәсендә аның улы Рафис утыра. Җиденче классны тәмамлады, көндәлегендә «бишле»дән ким билгесе юк, каникулга чыгуга колхоз эшенә йөри. Әти кеше улына карап елмаеп куя.

Зәфәр Хәлфиевич шоферына эндәште.

— Машинаңны авыл очына бор әле. Йорт салучы егетләр ни майтарып ята икән? Өй түбәләрен берүк соңлата күрмәсеннәр!

**Рәмзи МАКСУДОВ.**

*Лениногорск районы.*

# ЛЕНА ВАКЫЙГАЛАРЫНА — 70 ЕЛ

*Россиянең 1905 ел революциясе белән Бөек Октябрь революциясе арасындагы иҗтимагый тормышында 1912 елгы Лена вакыйгалары гаять мөһим этап буларак билгеле. Каты куллы Столыпин реакциясенең шактый озакка сузылган бөркү торгынлыгыннан соң Лена эшчеләренең бердәм социаль протесты, тарихчылар бәяләвенчә, яңа революцион күтәрелеш елларын башлап җибәрә.*

*Баю дәртен генә белгән комсыз алтын приискасы хуҗаларының эшчеләр яшәгән шартлар белән аз гына да кызыксынмавы бәхет эзләп килгән меңләгән кешене бердәм рәвештә күтәрелеп чыгарга мәҗбүр итә. Большевикларның оештыру эшчәнлеге монда зур роль уйный. Тарихи чыганаклардан да, түбәндәге истәлектән дә күренгәнчә, эшчеләрнең таләбе үтә гадел, җитәрлек тыйнак һәм тулаем экономик планда булган. Әмма прииска җитәкчелеге һәм властьлар моңа мөнәсәбәттә акылга сыймаслык дәрәҗәдә рәхимсезлек эшли. Тыныч митингка җыелган эшчеләрдән бер атуда 500 кешене үтерү үтә кешелексез һәм ерткыч сәясәт шартларында гына булырга мөмкин.*

*Шушы истәлекнең авторы — әти мәрхүм бу хакта еламыйча сөйли алмый иде. Һарчы Кавказдагы патша администрациясе генералының башта өендә, аннары канцеляриясендә хезмәт иткән татар егете өчен Лена вакыйгалары аңлы эшчеләр тормышына кереп китүнең җитди мәктәбе булган. Аннары әтиебез озак еллар Бакуда нефть промыселларында эшли. 1917 елның февраль революциясеннән соң Баку бистәләренең берсендә, Идел буеннан килгән мөселман эшчеләре вәкиле буларак, эшче һәм солдат депутатлары Советына да сайлана. Соңыннан туган авылы — хәзерге Чүпрәле районының Мунчәлигә кайтып, беренче авыл Советының председатель урынбасары булып эшли, гомеренең азагынача диярлек колхозда умартачы һәм бакчачы булды.*

*Әтидә үзе күргәннәрне язып калдыру фикере якташыбыз шагыйрь Шәрәф Мөдәррис киңәшеннән соң уянды.*

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## Бәхет хакына

**1911 елның маенда алтын приискасына чакырып, якташларымнан бер хат килеп төште. Майның уннары иде. Тифлистән [1] Иркутскига кадәр билет алып, унбер ел яшәгән шәһәрем белән хушлаштым.**

**Иркутскига килеп җиткәч, приискага бару юлын вокзалда носильщиктан сораштым. «Шушыннан караштыр, баручылар юкмы? Хәзер нәкъ вакыты», — диде. «Вакыты» дигән сүзе без эшчеләр телендә приискалардагы операция чоры дигәнне аңлата иде. Ягъни язын (хәтеремдә майда кебек) Лена алтын промышленностеның акционерлык җәмгыяте елга бер тапкыр эшчеләр кабул итә. Әүвәлге эшчеләр бе-**

[1] Тбилиси элек шулай аталган.

Яңадан килешү төзелә. Килешү гадәттә бер елга ясала иде. Өр-яңадан хезмәт кенәгәләре бирелә, искеләре җыеп алына...

Бераз китеп, водокачка янында яткан иске генә киемле дүрт кешене күрәм. Сәламләшкәч, кайдагы булуларын сораштым.

— Вятка буеннан, — дип җавап бирделәр.

— Кай якка юл тотасыз?

— Алтын прискасына.

Болар белән ярты сәгатьләр сөйләшкәч, иптәшләре дә кайтты.

— Постоялыйда олаулар бар,— диде бу.— Иркутскидан Лена пароходына чаклы мең чакрым чамасы. Тайгадан тире төяп килүчеләр кире буш киткәләр икән. Атларын карап барсаң, түләүсез дә алып кайталар. Һәркайсы 6-7 шәр ат белән килгән. Түләргә булса, бишәр сум сорыйлар.

...Икенче көнне без, тире ташучыларга ияреп, юлга чыгып киттек. Болар йөкчеләрнең атларын карап барды, миңа алты сум түләргә туры килде.

Пристань сыман җиргә килеп җиттек. Без иптәшләр белән үзләшеп өлгермәгән идек әле. Болар нишләптер пароход турында сүз кузгатмыйлар, ә үзләре ниндер киңәшеп йөри.

«Сезнең исәп нинди соң?» — мәйтәм.

— Пароходка акчабыз юк, көймә алып акмакчыбыз. Без су буенда яшәгән халык: көймә безнең өчен җайлы, — ди болар.

— Минем дә акча шулай гына, әйдәгез, мине дә алыгыз, — дим.

Утырып киттек. Безгә юлның өч урында: «Чуртан» (Щука), «Бозау» (Телок), «Исерек үгез» (Пьяный бык) дигән җирдә бик хәтәр булуын әйттеләр. Баштагы икесен без алдан чамалап, сакланып үттек. Алары Ләнаның кискен борылышлары булып чыкты. Болай да кызу су ул урыннарда бөтерелеп, кайнап, актарылып ага.

«Пьяный бык»ны да, кешеләр кисәткәнчә, өч-дүрт чакрымга алдан күреп бардык. Анда су кыя астына уелып керә.

— Эләксәгез, гомер буе бөтерелерсез. Зур пароходлар бирешми, көймә өчен хәтәр, — дип кисәткәннәр иде. Чыннан да, су, котырынып, үз бөтерелешенә ияртергә маташты. Алай да бу һәлакәтле өлешне әйләнеп уза алдык.

Барысы унбер тәүлек чамасы актык. Пристаньга килеп җиткәч, көймәне алган бәясенә — алты сумга саттык та, пароходка утырып, Бодайбо шәһәренә киттек. Бодайбода кечкенә поездга утырып, узкоколейка буенча Александровски станына, ягъни прискасына килеп җиттек. Мин шунда калып эшкә урнаштым. Иптәшләр Федосеев станына киттеләр: Алтынның иң күп чыга торган җире шунда диләр иде.

Бездән элек тә көймәгә утырып килүчеләр булган. Югары Каракитәдән минем якташларым Богатов Хөснетдин белән Шәрәфетдин шулай килгәндә боз кисәгенә бәрелеп, көймәләре әйләнеп капланган. Шәрәфетдин батып үлгән, Хөснетдин, элек матрос булганга, йөзеп чыккан. Берничә көн ярда торгач, пароход узганда кулмәген салып селкегән. Утыртып киткәннәр үзен.

Килгәч, казармага урнаштырдылар. Ике атна чамасы идәндә йокладык, аннары караватт бирделәр. Хезмәт кенәгәсе белән кухнядан икмәк, ит алабыз. Он, шикәр, май, балык бирәләр. Икмәк гел кара була иде. Иләнгән он икмәген хезмәткәрләр, акционерлар, смотрительләр, нарядчы, конторда эшләүчеләр, куштаннар гына ашый. Чүпле, көрпәле он икмәге — эшчеләргә.

Башта бу әле безнең исне китермәде. Борчулар яз-җәй артты. Исләнгән, хәтта кортлана башлаган ит бирәләр иде. Эш көне унҗиде-унсигез сәгатькәчә сузыла. Озакка калып эшләү атнага берничә көн була. Артык сәгатьләргә түләү юк.

Килгән көнне хезмәт килешүе төзелде. Бер кеше чыгып, контор янына җыелган халыкка эш шартларын аңлатты. «Эш вакыты ун-унбер ярым сәгать, кайвакыт артык та булыр», — диде. Ләкин тыңларга, карышмаска кирәк дип нәсыйхәт бирде. Ризыклар алырсыз, исәпләшү килешү вакыты тулгач ясалыр, берегез дә рәнҗерлек булмас, — дип вәгъдә бирде.

Шахтага егерме биш метр тирәнлеккә төшәбез. Чыкканда баскыч төбендә эшчеләрне городовой тикшерә. Алтынлы туфракны кул арбасы белән ташыйбыз,

зур ящикка бушатабыз. Аннары өскә күтәреп, вагонеткага бушаталар. Шуннан узкоклейка буйлап машинага озаталар.

Ташыганда өстән пар бәрә. Түбәтәй салып ташланган. Йөгерәсең. Илтеп бушатуга, тагын чабасың. Арка тир белән катыкланган. Әгәр эш нормасын йөз егерме-биш проценттан ким үтәсәң, шахтадан өскә чыгаралар, анда инде хезмәт хакы ашарга гына җитәрлек була.

Халыкта ашамлыктан ризасызлык ишетелә башлады. Бервакыт ит алырга баргач, шундый хәлгә тап булдым. Бакырчы татары Хәлил Бикчәнтәев дигән кеше: «Исләнгән ит ашаталар!» — дип ярсый. Шунда басып торган городовой итне сорап алды да иснәп карады. Шуннан кизәнеп, Бикчәнтәевнең яңагына ташлады. Сөяк очлары бернинчә җирдән тегенең битен җәрәхәтләде. Ләкин ашарга кирәк. Әчтән тынып, итне алып китте. Мин дә алып кайттым.

Бер елга якын вакыт узды. Язга таба тагын ризасызлык көчәя башлады. Баракларга кереп: «Әйдәгез, сабын сорыйк, җәймәләр сорыйк. Һәр якшәмбе ял булсын (юкса нарядчы, ялга-нигә карамыйча, теләгән вакытта эшкә куып китә)».— дип агитацияләп чыгалар иде. Барташев фамилияле большевик та, Александровскига килеп, аңлатып, агитацияләп китә иде. Башка прискалардагы ризасызлык авазлары да безгә ишетелеп торды.

Александровски станындагы эшчеләр ике кешене сайлап, таләпләрне җиткерү өчен Надеждинскига — прискаларының управляющие Иннокентий Николаевич Белозеров янына җибәрделәр. Январь тирәсе иде. Ул эшчеләрне тупас кабул иткән. «Бездә начар ит, начар икмәк, начар ризык юк. Сез — котыртып йөрүчеләр. Тагын килсәгез, казачийга эләгерсез», — дип орышып чыгарган. Шулай итеп, алар яхшы хәбәр алып кайтмадылар.

Халыкта дулкынлану көчәйде. Чит прискалардан делегатлар килә башлады.

— Болай булмый, эш ташлагыз, бездәгеләр ташлый!.. — диделәр. Барлык прискаларда бер көндә эш ташларга дигән белдерүләр таратылды. Бер кичне һәрбер баракка кереп, иртәсен эшкә бармаска дип әйтеп йөрделәр. «Иртән Александровскидагы мәйданга җыелырбыз», — дип сүз куелды. Таң атмас борын ук, әйтелгән урынга эшчеләр җыела башлады. 1000 гә якын кеше килгәч, берәү төпчек өстенә менеп басты да җыелышны ачты һәм президиум сайларга тәкъдим итте. Президиумны 6 кешедән сайладылар. Берсе — Куромин Максим, икенчесе — Ребецкий Гриша, өченчесе — Гайнуллин Гариф иде, башкаларын хәтерләмим. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — акционерлардан үзебезнең хаҗәтләребезне таләп итү диелде.

Җыелышта шундый таләпләр кабул ителде:

1. Хезмәт хакы арттырылсын;
2. Ашамлыклар яхшыртылсын;
3. Һәр кешегә карават куелсын, урын-җир кирәк-яраклары — мендәр, юрган бирелсен, идәндә йоклау бетерелсен.
4. Эш вакыты ун сәгатькә калдырылсын;
5. Баракларда һәр ун кешегә бер лампа булсын;
6. Өстән су ага торган шахталарда кожан бирелсен;
7. Пожог[1] белән эшли торган шахталарда башына ис тигән эшчене өскә чыгарып дәваласыннар. Аңа ярты эш көне язылсын.

Күренгәнчә, безнең таләпләр әллә ни зур түгел һәм гади-гадәти көнкүреш шартлары турында гына иде.

Җыелышта шундый карар чыгарылды: 1912 елның 4 апрелендә Надеждинскида булачак митингка барырга. Һәр станнан, һәр прискадан — ягъни Пророклинскидан, Прокопьевскидан, Александровскидан, Федосеевскидан, Ерак тайгадан, Ивановскидан, прискалар идарәсе урнашкан Надеждинскидан һәм вак шахталардан — эшчеләр иртән сәгать 8 дә үзәк прискада җыелачаклар дип игълан ителде. Шул хакта листовкалар таратылды.

4 апрель көнне без Александровскидан үзәк приска — Надеждинскига барырга чыктык. Җәяү барырлык ара. Бездән алда китүчеләр инде барып җиткән. Без-

---

[1] Туң җирне эретү өчен ягылган ут.

нең төркемдә биш йөзләп кеше атлый. Арттан тагын төркем-төркем кеше килә. Надеждинскига кергәндә соры офицер киеменнән, ука погонлы бер кеше безне каршылап:

— Бармагыз, егетләр, атарлар, үзегезгә генә зыян итәрсез, — дип үгетләп торды. Бу — инженер Тульчинский диделәр.

— Без бит коралланып бармыйбыз, сугышырга җыенмыйбыз. Үзебезнең гадел йомышыбыз белән киләбез — нишләп безгә атсыннар? — дибез.

— Анда ротмистр Трещенковның кораллы солдатлары тора, бу яхшыга илтмәс, — диде. Үгеткә колак салучы булмады.

Барып җиттек. Халык бик күп, Митинг бара. Ораторлар мичкәгә басып сөйлиләр. Уртада: «Сөйләүчеләр бармы?» дип берәү язып тора. Сөйләүләр бик кыска.

— Без бушлай диярлек эшлибез, ашамлык җитми, анысы да түбән сыйфатлы... — дип зарларны сөйли берсе. Мин дә трибуна янына үтеп чиратка язылдым. Сөйләргә икешәр минут кына рөхсәт итәләр.

Трибунага тагын берәү менде. Аны күп халык алкышлап каршы алды. Ул бик кызу сөйли, авызыннан ялкынлы сүзләр чәчә. Ә кешеләр җыелуда дәвам итә.

Шул вакыт бер кеше чыгып, калын һәм кырыс тавыш белән: «Тузылыгыз! Митинг таралсын, сезгә начар булыр!» — дип кисәтү ясады. Трибунадагы кеше ялкынлы чыгышын дәвам итсә дә, халык хафага төште. Кинәт залп яңгырады. Җир тетрәгәндәй булды. Бу — куркыту гынадыр дип уйладык, митинг дәвам итте. Икенче залп яңгырады.

Надеждински уйсулыкта урнашкан. Тирә-ягы таулар. Шул таулар буенча боланнар белән килүче якутларның тәгәрәп-тәгәрәп төшүләре күренде. Качу, йөгерү башланды. Без авылдашым Мөкатдәм Хәмзин белән тимер юлы буена өелгән шпалларга ышыкландык. Өсте-өстенә атып торалар. Шпаллар ышыгында инде унлап кеше торабыз. Шыгырдан авылыннан[1] бер кешенең (ул мич чыгаручы булып эшли иде) уң калак сөягенә пуля тиде. Тагын бер минут үтмәде, Фиганов фамилияле бер бик яхшы рус егете, башына пуля тиеп, тәгәрәп китте. Шуннан без тимер юлның аръягына шуышып чыктык һәм шунда яттык... Ату бераздан тынды. Халык арыш көлтәсе кебек түшәлгән иде. Үлекләрнең иң күп урыны трибуна тирәсендә булып чыкты. Яралыларны арбаларга салып, больницага ташый башладылар. Ат белән дә, поезд белән дә ташыдылар. «Биш йөздән артык кеше үлгән» — диделәр. Яралылар күбрәк иде.

Тукталыш вакытында (автор забастовканы шулай атый — Н. Х.)[2] Петербургтан Дәүләт Думасы депутаты килде. Буйга зур, корырак сөякле, озын муенлы, зур озын борынлы кеше иде бу. Ул безне җыеп: «Нигә рөхсәтсез эш ташладыгыз? Таләпләрегезне эш ташламыйча гына язарга иде. Әле соң түгел, иртәгәдән эшкә чыгыгыз», — дип үгетләде. Халык ризасызлыгы моның белән генә бетәрлек түгел иде.

Майның урталары җиткәч, безне бик нык алдадылар. «Сез Иркутскига чыгыгыз, — диделәр. — Анда сезнең белән исәп-хисап ясарлар. Эшләми яткан айларыгыз өчен дә уртача эш хакы бирерләр. Юл тотымнарыгыз да җитәрлек кадәр исәпкә алыныр». Халык Иркутскига агыла башлады. Без дә, юлга чыгып китеп, Бодайбога җиткәч, берничә кеше үзара киңәштек тә: «Болар безне алдарлар, түләмәсләр дә, өйгә дә кайта алмабыз», — дип, кире Александровскига кайтып эшкә керештек. Мин бит әле «бәхет алтынын» тапмаган идем. Иркутскига китүчеләргә йодрык кына исәнләткәннәр дип ишеттек.

Кыш җитте. Яз башында кайтырбыз дип, тагын да тырышып эшли башладык. Февраль башларында, мин эштән кайтып ашап утырганда, ишектән ике кеше килеп керделәр. Хәрби киемнән. Күрәм: городовойлар. Мин артым беләнрәк әйләндем. Болар бер хатыннан:

— Сезнең баракта татар Хисаметдинов Шаһвәли дигән кеше бармы? — дип сорадылар. Хатын мине күрсәтте. Тегеләр, яныма килеп, исем-фамилиямне сорадылар да: «Сезне начальник чакыра, бик тиз киенегез, — диделәр. Мин шундук киендем дә чыгып киттек. Юлда чакыруларының сәбәбен сорашып карадым — сөйләшмәскә боердылар. Шулай казачийга барып җиттек. Бер кечкенә бинага

---

[1] Хәзерге Чувашиянең Батыр районындагы татар авылы.
[2] Ул вакыт әтинең фамилиясе «Хисаметдинов» йөргән — Н. Х.

кертеп яптылар. Бүлмәнең буе 4 метрлап кына булса да, халык күп иде. Корымлы лампа һәм тәмәке төтененнән кешеләрне күрерлек түгел. Ишектән кергәч, сул як чатка лакан куелган — хаҗәтләр үтәр өчен. Стена буйлап ике катлы нарлар тезелгән. Аскы сәндерәдә кешеләр тулганга, урта катка кеше кысылып кына керә ала. Мин һәр кешене диярлек күздән кичерсәм дә, таныш йөзләр күрә алмадым.

— Шаһвәли, син түгелме соң?

Карасам, югары нәрдә төтен эчендә таныш кешем Гата кысылып утырган.

— Гата иптәш, сезмени?! — диюемә сикереп төште дә, мине кочаклап, ике яңагымнан үпте. Үзе елап җибәрде. «Безне апрельнең тугызында ук китереп япканнар иде, шуннан бирле ятабыз», — диде. «Моннан котылу өмете ничегрәк?» — дигәч: «Безгә Петербургтан нинди хәбәр килер инде, эш шуннан тора», диде.

Көзен октябрьның 15 ләрендә Иркутскидан губернатор килгән булган. Аңардан: «Без һич гаепсезгә ятабыз, безне гаиләләребез янына кайтарып җибәрергә әмер итсәгез иде», — дип үтенгәннәр. Губернатор: «Сез үз җинаятьләрегезне яхшы беләсез. Шуңа күрә Лена суында пароходлар йөри башлагач, сезне Иркутскига илтерләр. Анда сезне әлмәкле баулар көтә», — дигән.

— Без хәзер менә шуны көтәбез, — диде Гата.

Гата Яңа Чокалы[1] авылыннан (фамилиясен белмим) кызгылт сары сакаллы бер кеше иде. Тукталыш вакытында матур да, үткен дә чыгыш ясады. Ул минем ничек килеп эләгүемне сорады. Сөйләп бирдем. Ул:

— Сине монда безгә иптәш итеп ничек табып китергәннәрен беләсеңме? Без бит Надеждинскида митингта сүз сорап чиратка язылган идек. Шул исемлек болар кулына эләккән. Аның буенча инде бик күп кешене китерделәр. Сиңа чират хәзер генә килеп җиткән, — диде. — Мин сиңа бер акыл өйрәтим, барып чыкса, котылырсың. Хәзер сине китергән городовойлар ярты төннән соң алмашына. Таң аткач ук, син бик каты ишек дөбердәт. Дежур килеп: «Ник дөбердәтәсең?» — дип сорар. Син: «Мин хәзер айныдым инде, мине начальникка алып бар, тикшерсен»,— диген. Моннан котылсаң, Александровскида торма, ерак тайгага кач. Аннан таба алмаслар.

Гата миңа шундый киңәш бирде. Төтен, тузан эчендә төн буе косып чыктым. Иртән нәкъ Гата әйткәнчә эшләдем. Дежур: «Ни кирәк сиңа, нигә ишек ватасың?» — дип кычкырды. «Мине монда кемнәр ни өчен китергәнен белмим. Казармада кыйнашканны бераз гына хәтерлим», — дигәч: «Көт», — дип китеп барды. Бер сәгатьләп вакыт узгач, килеп: «Әйдә!» — дип, мине чакырды. Йөгереп барып, Гатаны үптем дә дежур белән начальникка киттек.

Барып кердек. Начальник креслосына утырган, карашы исереккенә охшый. «Ну ты что, князь что-ли?» — ди. «Әйе, Ваше благородие», — мәйтәм. «Син монда кайчаннан бирле?» — ди. «Мине кичә китергәннәр, үзем белмәгәнмен, фәлән кеше белән сугыш башлавымны гына бераз хәтерлим. Иртән күземне ачкач, кайдалыгымны белә алмыйча исем китте. Янымдагы кешеләр генә кич китереп япканнарын әйттеләр. Хәзер мин айныдым инде, эшкә соңга калам, моннан соң аракыны авызга да алмам», — дидем. «Ну, князь, драться не будешь?» — ди. «Никогда» — дим. «Азат итегез үзен», — дип, фамилиямне дә язып тормыйча, чыгарып җибәрде.

Мин аннан кайту белән аш пешерүче хатынга бурычымны түләдем һәм, авыр әйберләремне калдырып, җиңелләрен генә алдым да, тайгага китеп анда май азагына кадәр эшләдем. 1913 елның май ахырында өйгә кайтып киттем.

Лена приискыларында безнең якташ татарлар бик күп иде. Кушкуактан — Галләм абзый Мөхәррәмов, Яңа Чүпрәледән — Җәлалетдин Минһаҗев, Иске Чокалыдан Зиннур Әхтәмов, Яңа Чокалыдан[2] Абдылкадыйр Ибраһимов. Шыгырданнан Батдин, Минһаҗ, Сәлах, Җәлүк исемле кешеләр бар иде. Ул якның үзеннән генә дә 70 ләп кеше эшләде.

Гатаны шуннан бүтән күрмәдем. Бик күп сорашып эзли торгач, бер кеше болай дип сөйләде: «Федосеевскидан Надеждинскига таба стражниклар кырыклап кешене алып баралар иде. Безнең турыга җиткәч, берсе: «Шаһвәлине күрсәгез.

---

[1] Хәзерге Татарстанның Чүпрәле районындагы авыл
[2] Хәзерге Чүпрәле районы авыллары

сәлам әйтегез!» — дип кычкырды. Бу Гата булырга тиеш иде. Үзләре моржа тазартучылар кебек каралганнар». Авылдашларыннан күп сорашсам да, аның турында беркем бернәрсә әйтә алмады.

Гата миннән өч яшьләргә олырак иде. Үзе тулы түгәрәк йөзле, урта буйлы, киң җилкәле, калын тавыш белән ашыкмыйча гына, һәр сүзен ачык итеп сөйләүче бер кеше иде.

Бәхет эзләп килгән меңләгән эшчеләр Себердә дә шул ук михнәтне тартты. Баю хыялы кайберәүләрне үтә тәвәккәл, хәтәр адымнар ясауга илтә иде.

Бервакыт 4 кеше зур алтын кисәге тапты. Үлчәгәч, егерме бер ярым кадак тарткан. Табучылар моны бер читкәрәк куеп, өстен томалаганнар да болай киңәшкәннәр: «Конторда алтынның кадагына 96 тәңкә генә түлиләр. Кибеткә тапшырсаң, мыскалы (золотник) 4 сум тора». Боларның тиз йөгерүчесе һәм көчлерәге эшне үз өстенә ала. Тотсалар, алты ай төрмә икәне мәгълүм.

— Әгәр мин тотылсам, өчегез табышыгызны, хезмәт хакыгызны дүрткә бүләсез һәм минем өлешемне семьяма җибәреп торасыз, — дип шарт куя бу. Тышта 40 градустан артык салкын. Кибеткә чаклы ике чакрым ара бар. Бу күлмәкчән, оекчан гына. Ышыкланып городовойны күзәтә. Теге кораллы. Аның борылганын көтә дә, баскычтан йөгереп менеп тә китә. Городовой аны күреп, артыннан йөгерә башлый. Калын киемле городовой чыгып җиткәнче, бу шактый китеп өлгерә. Борылып карый: городовой якыная. Кибеткә бу ишектән керергә уйласа, теге куып җитәчәк. Алтынны тәрәзәдән ыргыта. Кибетче городовойга: «Алтын — кибетнеке!» — ди. Теге берни эшли алмый. Алтын китерүчедән пыяла хакын гына тотып калып, бәясен түлиләр. Ләкин мондый артык тәвәккәл һәм хәтәр уңыш әллә ничә бер генә була ала иде...

Эшчеләр зур баракта яши, аннан-моннан гына кадаклап ясалган тар ятакларда икешәр кеше йоклый иде. Ятаксызлары — идәндә. Асларына үзләренең киемнәрен җәяләр, баш астында капчыкка тутырылган салам. Бараклар пычрак, озын баракның ике очында кечкенә генә лампа яна...

Без үзебезнең табылмас бәхетебезне менә шундый шартларда эзләдек. Ләкин ул интегүләр эзсез калмады. Безнең иптәшләребез соңыннан совет властен актив төзүчеләр, аңлы колхозчылар булды. Без Чүпрәле сабан туенда алар белән очрашкан саен баштан кичкәннәрне кадерле истәлек итеп сөйләшәбез.

Шаһвәли ХИСАМОВ.

*1955 елның ноябрь*

Ибраһим Нуруллин

# ӘДӘБИЯТТА ШАРТЛЫЛЫК ТУРЫНДА

Кием-салым, чәч-баш һәм җиһаз модасы провинциягә беркадәр соңгарып килеп җиткән шикелле, шартлылык дип йөртелә торган күренеш тә безнең әдәбиятка үтеп керә башлады. Менә Әхәт Гаффарның Хемингуэй йогынтысында язылган «Теге гозер» повесте, картның аллегориягә тартым бүреләр белән көрәшүе. Менә Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле моңсу комедиясе — кеше кыяфәтендә сәхнәгә менгән Әҗәл. Яшь язучы Азат Вергазов та «Нәзер» повестенда, үз героен үлгән хатыны өрәге белән әңгәмә кылдырып, шартлылыкка сәлам биреп узды.

Проза һәм драматургиябезнең алга таба адым ясавымы бу, әллә бер чалулап алуымы? Шартлы-символик алымнар кулланып язу заман стилеме, әллә вакытлы бер модамы?

Шушы һәм шуңа охшаш сораулар рус совет әдәбият белемендә һәм тәнкыйтендә күптән инде куела килә. Шартлылыкны яклап һәм кире кагып, бик күп мәкалә һәм китаплар язылды, «Литературная газета» хәтта дискуссия дә уздырып алды.

Социалистик реализм әдәбияты символ һәм аллегория, гротеск һәм фантастика, миф һәм хикәят (притча) алымнары кулланырга хаклымы? дигән сорау тирәсендә генә сүз барса, кылыч чыңлатуның кирәге дә булмас иде. Чөнки бу сорауга тискәре җавап бирүче әдәбият белгече юктыр. Чынбарлыкны үз кыяфәтендә, үзенә охшатып, реалистик сурәт ярдәмендә чагылдыру безнең заман таләпләренә җавап бирәме, юкмы — бередә сүз әнә шул турыда бара. Шартлылык тарафдарлары: хәзер инде бу принцип белән генә чикләнеп булмый дип белдерәләр. Кайбер белгечләр исә, ачыктан-ачык янсә беркадәр томанга өртеп, социалистик реализмны модернизмның формаль казанышлары хисабына баету кирәклеген алга сөрәләр.

Мондый фикерләр — киртәдән чыгу дәрәҗәсендә үк булмаса да — татар тәнкыйтенә дә үтеп керде. Бу мәсьәләне беренче башлап Р. Мостафин күтәреп чыккан иде. «Соңгы елларда безнең әдәбиятта,— дип язды ул,— тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү стилендәге проза өстенлек итә». Ары табан тәнкыйтьче бу стильгә дә каршы түгеллеген белдерә дә, Көнбатыш Европа, рус һәм татар әдәбиятларыннан мисаллар китерә-китерә, прозабызны стиль ягыннан баету хакына «реаль булмаган, фантастик алымнар»дан да качмаска киңәш бирә[1].

Соңгы елларда тәнкыйтьче Ф. Мусин да үзен шартлылыкны кайнар яклаучы итеп күрсәтте. Аның фикеренчә, шартлылык, мифологизм һәм фольклоризм чынбарлыкны «тыгызлап» һәм калку итеп» чагылдырырга мөмкинлек бирә, «сәнгатьчә гомумиләштерү һәм типиклаштыруның үтемле чарасы» булып тора[2].

Тугандаш республикаларда да шартлылык белән кызыксыну күзгә ташлана. Күренекле башкорт әдәбият белгече Г. Хөсәенов, мәсәлән, М. Кәримнең «Салават» трагедиясен, Муса Гали поэмаларын һәм Ә. Мирзаһитовның «Аналар көтәләр улла-

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1972, 9 сан.
[2] «Социалистик Татарстан» газетасы, 1979, 20 май

рын» драмасын мисалга китерә дә, аларда кулланылган шартлы алымнар «үткеррәк һәм үтемлерәк поэтиклаштеругә», «әсәрнең төп идеясен тирәнрәк ачарга ярдәм итә» кебек сүзләр язып китә [1].

Бу фикерләрне логик ахырына җиткерсәк, нәрсә килеп чыга? Тормышны үз кыяфәтендә чагылдыру ысулын ташлап, бөтенләй шартлылыкка күчәргә кирәк, дигән нәтиҗә түгелме? Соңгысы «үткеррәк», «тирәнрәк», «тыгыз» һәм «үтемле» икән бит...

Күренә ки, сәнгатьтәге шартлылык проблемасы бүген саф эстетик мәсьәлә генә түгел икән.

Туарга тиешле хакыйкатькә кендек әбисе булуны дәгъва итмәстән, мин бу мәкаләдә шартлылык турындагы кайбер фикерләрем белән генә уртаклашырга телим.

Иң элек берничә теоретик мәсьәлә буенча уртак фикергә килергә кирәк.

Беренчесе: нәрсә ул шартлылык?

Мәгълүм ки, сәнгатькә, әдәбиятка гомумән шартлылык хас. Алар тормышның үзе түгел, ә чагылышы, хәтта копиясе дә түгел, бәлки әдип хыялында тудырылган сурәте генә. Язучы белән укучы арасында кәгазьгә язылмаган «килешү» яши. «Минем геройларымның,— ди әдип,— нәкъ шул рәвешендә дөньяда булганнары юк. Күп кешеләрне күзәтү нәтиҗәсендә мин аларны уйлап чыгардым». «Беләм,— ди укучы.— Геройларыгызның адресын сорап хат язарга җыенмыйм. Мин алар мисалында тормышны аңларга тырышам». Әдип белән укучы үзара аңлашу өчен, гүяки шарт куялар. Менә ул — ш а р т л ы л ы к.

Ф. Әмирхан Хәятнең Мясниковлар дачасыннан кайтканнан соңгы үз-үзен тотыш һәм кыланышларын вак детальләренә кадәр тәфсилләп яза. Әйтерсең лә, кыз бүлмәсенә кереп карап торган! Яисә ул, үзенә кешенең уй-фикерен уку кодрәте бирелгәндәй, кызның Лиза белән икәүдән-икәү сөйләшкән сүзләрен генә түгел, бәлки кояш чыкканчыга кадәр дәвам иткән уйлануларын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Яки менә Ш. Камалны тыңлыйк: чыпчыклар «бәләкәй канатлары белән кагынып-кагынып, яз якынлашуга шатланып бетә алмыйлар: «Менә, чорт возьми! Ах чорт подери!» диешкән булалар» («Матур туганда»). Болар да — ш а р т л ы л ы к.

Сәнгатьчә гомумиләштерүнең шартлы формаларын алга чыгарырга тырышучылар мондый алымнарны күздә тотып, болай диләр: реализм классиклары да шартлылыктан качмаганнар, хәтта еш кына тормышның үз рәвешен үзгәртеп сурәтләгәннәр. Фикерен раслау өчен бер автор «Анна Каренина» романыннан түбәндәге мисалны китерә. Левин белән Облонский, ауга чыккач, сүзгә мавыгып китәләр. «Алар бу хакта сөйләгән вакытта,— дип яза Л. Толстой,— Ласка, колагын торгызып, әле күккә, әле боларга таба шелтә белән карап-карап ала иде. «Тапканнар вакыт сөйләшергә,— дип уйлады ул.— Ә ул очып килә... Шул, үзе, менә бит, ә... Авыз ачып калалар ич...» Әнә бит, янәсе, эт кешечә уйлый алмый, ә Толстой язган. Әйе, бу шартлылык, ләкин тормышның үз рәвешен, кыяфәтен бозып күрсәтә торган шартлылык түгел. Ау этенең үз-үзен тотышы гаять табигый («колагын торгызып, әле күккә, әле боларга шелтә белән карап-карап ала иде»). Ласканың кичерешләрен, кирәк икән, аның этке хас уен Толстой кеше теленә генә күчереп биргән.

Әгәр алайга китсә, «авызы колагына җитте» яисә «күзләре маңгаена менде» дигән идиомаларны да тормышның үз формасын бозып күрсәтү итеп карарга кирәк булыр иде.

А. С. Бушмин болай дип яза: «Сәнгатьтә ике төр шартлылык бар: берсе конкрет сиземләнә торган реальлекне еш кына кискен төстә деформацияләп күрсәтүче махсус шартлылык, сәнгатьчә чагылдыруның үзенчәлекле чарасы; икенчесе — тормышны сурәт ярдәмендә танып белүнең табигатеннән чыга торган һәм сәнгатьнең тере булган... шартлылык» [2]. Соңгысын без, рус совет әдәбият белемендә күренеп киткән атаманы кулланып, «беренчел шартлылык» дип йөртербез.

Ласканың уйлавына яисә чыпчыкларның «чорт возьми» дип шатланышуларына охшаш алымнар «беренчел» шартлылыкка карыйлар һәм тормышны үз рәвешендә күрсәтү принцибы белән каршылыкка кермиләр, киресенчә, шуңа хезмәт итәләр.

---

[1] «Агидел» журналы, 1976, 10 сан.

[2] А. С. Бушмин. «Методологические вопросы литературных исследований». «Наука», 1969, 209 бит.

Икенче төр шартлылык исә, теге яки бу максаттан чыгып, тормышны үз кыяфәтендә түгел, бәлки кискен үзгәртеп, сәерләндереп, деформацияләп (кечерәйтеп яки гадәттән тыш зурайтып) сурәтләүгә кайтып кала. Әйтик, Ласка, Левин яисә Облонский кулыннан мылтыкны тартып алып, көртлеккә атып җибәрсә, бу икенче типтагы шартлылык булыр иде. Тормышның үз күренешләрен деформацияләп сурәтләүгә иң отышлы мисал итеп гадәттә Салтыков-Щедринның «Бер шәһәрнең тарихы»ннан градоначальник образын һәм Гогольнең «Борын» повестен китерәләр. Ми урынында кечкенә орган булуына яисә кеше борынының мундир киеп, урамда йөрү мөмкинлегенә хыялны никадәр генә көчләсәң дә ышанып булмый.

Шартлылык турында сүз алып барганда, мин, тормышны үз формасында чагылдыруның органик сыйфаты булган шартлылыкны түгел, бәлки тормышның үз төсен, кыяфәтен һәм формаларын бозып күрсәтә торган, ягъни «икенчел» шартлылыкны күздә тотам.

Икенче мәсьәлә тормыш күренешләрен деформацияләүче шартлылык һәм жанрлар спецификасы арасындагы бәйләнешкә кайтып кала. Баштанаяк шартлы булган опера һәм балетка тукталырга хаҗәт юк. Шартлылыкка шулай ук шактый урын бирә торган драматик театрны да телгә алып китү белән генә чикләник.

Реализм әдәбиятындагы аерым төр һәм жанрларга күз ташлыйк. Менә лирика. Ул кешенең эчке дөньясы, уй-хисләре, рухи омтылыш һәм хыяллары белән эш итә. Ә кеше күңелендә — әгәр ул шагыйрь табигатьле дә икән — нинди генә теләк һәм хыяллар булмас! Менә телгә килгән беренче җыр:

> **Әй, дускаем, син кайда!**
> **Әллә мендеңме айга!**
> **Йөгереп чыгып айга карыйм,**
> **Айда да юк, син кайда!**

Халык шагыйре дустын айдан эзләмәгән һәм эзли дә алмаган. Ул үзенең иң якын, ихтимал, бердәнбер дустын өзелеп сагынганлыгын тәэсирле итеп әйтеп бирү өчен шартлы-поэтик сурәт кулланган. Әгәр берәү болытка яки җилгә, кояшка яисә айга карап озын-озын монолог сөйләсә, без бу кешенең акылга тулы булуына шикләнер идек. Әдәбиятта исә романтикка гына түгел, бәлки реалист шагыйрьгә дә бу килешә, табигый тоела. Маяковскийның кояш белән өстәл янына утырып әңгәмә коруына без, мәсәлән, бер дә гаҗәпләнмибез. Батыр егет белән Шүрәле эпизоды да безне аптырашта калдырмый. Әнчекнең, филгә өреп алгач, мактанып куюы да, идеалист кәрәкә белән чуртан арасындагы бәхәс тә гаҗәпләндерми. Чөнки без беләбез: болар мәсәл һәм әкият.

Сатирада деформация — фантастик образлар, гипербола, гротеск, алогизм шулай ук мул кулланыла. Бу хәл аның асылы белән турыдан-туры бәйләнгән. Сатирик жанрлар, К. Маркс сүзләре белән әйтсәк, дөньякүләм тарихи форманың иң соңгы фазасына җиткән, ягъни искергән, картайган һәм анахронизм хәленә килгән күренешләр белән эш итәләр. Бу күренешләр инде аек акыл һәм билгеле бер нормалар белән каршылыкта булганга, тормышның үзендә үк беркадәр д е ф о р м а ц и я л ә н - г ә н рәвеш алалар. Сатира гротеск ярдәмендә андый күренешләрнең асылын ялангачландырып, калкытып күрсәтә. Крепостнойлык калдыгы булган дәүләт аппараты үткән гасырның сиксәненче елларына таба прогрессны буып торган рәхимсез, җансыз машинага әверелгән иде. Орган башлы градоначальник образы әнә шул хакыйкатьне гаҗәеп төгәл һәм тапкыр итеп әйтеп бирде. Йөз ел элеккеге тәртипләрне яшәтергә азапланучы Фәтхулла хәзрәтләрнең асылын ачып бирүдә фантастик сурәтләр шулай ук файдалы эш башкарды.

Ассызыклап тагын шуны әйтергә кирәк: хәтта с а т и р а д а д а ш а р т л ы - ф а н т а с т и к а л ы м н а р б е р д ә н б е р ч а р а т ү г е л. Гогольнең «Ревизор»ы, Салтыков-Щедринның «Головлев әфәнделәр»е яисә безнең Г. Камалның «Беренче театр»ы кебек, тормышның үзенә охшатып язылган сатирик әсәрләрне күпләп санарга мөмкин. Сүз арасында шунысын да искәртик: модернизмдагы деформацияләү белән реалистик сатирадагы деформацияләү арасында принципиаль аерма яши. Соңгысында шартлы алымнар хакыйкатьне ачуга хезмәт итә, шуңа күрә аларда билгеле бер

логика, тормышка якынлык була. Әгәр инде киресенчә Фил Әнчеккә өрсә, яисә Кәрәкә Чуртанны тотып ашаса, бу инде хакыйкатьтән читкә алып китә торган шартлылык булыр иде.

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, бәхәс сатира төренә карамаган реалистик проза һәм драматургиядә шартлылык ни дәрәҗәдә зарур дигән мәсьәлә тирәсендә генә барырга тиеш. Чөнки аллегория, гипербола, гротеск, фантастика алымнары әдәбиятның лирика һәм сатира кебек төрләрендә үзләрен өйләрендә кебек хис итәләр һәм беркемнең дә бу хакыйкатьне шик астына алганы юк.

Ниһаять, өченче мәсьәлә.

Тормышны үз формасында чагылдыру принцибы беренче башлап тәнкыйди реализм әдәбиятында аңарчы булмаган күләмдә тормышка ашырыла башлады. В. Г. Белинский ике поэзия турындагы мәгълүм өйрәтмәсендә, реаль поэзияне идеаль поэзиягә каршы куеп, поэзиянең бу тармагы тормышны «...бөтен ялангачлыгында һәм дөреслегендә, чынбарлыкның барлык ваклыкларына төс һәм төсмерләренә турылыклы калып гәүдәләндерә»[1],— дип язган иде. «Реаль поэзия» дигәндә, ул башында Гоголь торган «натураль мәктәп»не, яисә икенче төрле әйткәндә, тәнкыйди реализмны күздә тота. Димәк, җитлеккән, ягъни тәнкыйди, реализм өчен чынбарлык күренешләренең табигатен, асылын, эчке мәгънәсен ачып бирү мәсьәләнең бер ягы, дөрес, иң мөһим ягы, әмма бер ягы гына. Чөнки барлык әдәби юнәлешләр һәм күп кенә сәнгать төрләре дә шул ук функцияне башкаралар. Тәнкыйди реализмның аңа кадәрге юнәлеш һәм методлардан принципиаль аермасы шунда: ул чынбарлыкның асылын, аның үз формасында, ягъни тормышның үзеннән үзгәртми-нитми күчерелгән дип уйларлык, реаль яшәеш иллюзиясе тудырырлык итеп гәүдәләндерә. Белинскийның югарыда китерелгән сүзләрен бүтәнчә аңлап булмый. Әсәрдәге һәр вакыйга яки эпизод ихтималлык кысасыннан читкә чыкмасын, персонаж һәрбер төймәсенә чаклы, конкрет-тарихи чорга туры килсен, уй-фикерләре һәм хис-тойгылары характерына тәңгәл булсын, һәр репликасы тормыштагыча яңгырасын. Ф. Энгельсның реализм турындагы атаклы формуласындагы «детальләр дөреслеге» дигән сүзләр дә очраклы гына кулланылмаган. Л. Толстойның Шекспир иҗаты турында язылган һәм заманында шау-шу тудырган мәкаләсе белән, тулаем алганда, әлбәттә, килешү кыен. Әмма аның түбәндәге сүзләре игътибарга лаеклы: «Шекспирның барлык шәхесләре дә (персонажлары — И. Н.) үз сүзләре белән түгел, бәлки бер үк тел — Шекспир теле белән, купшы, гайре табигый тел белән сөйлиләр. Беркайчан, беркайда һәм беркемнең җанлы кешеләр дә мондый телдә сөйләшмәгән кебек, иҗат ителгән персонажлар да болай сөйләшә алмыйлар»[2]. Тормышның эчке һәм тышкы ягын бөтен чынлыгында чагылдыру принцибын аеруча тулы тормышка ашырган, аз гына ясалмалылык белән дә килешә алмаган бөек реалистны, Толстойны, димәк, Яңарыш чоры реализмындагы шартлылык канәгатьләндермәгән.

Ачык булса кирәк, инглиз, француз һәм рус әдәбиятларында тәнкыйди реализм метод һәм әдәби юнәлеш сыйфатында мәйданга килгәннән соң, тормышны үз формасында чагылдыру принцибы реализм поэтикасының төп юлы, магистраль юлы булып китте.

Ә менә чынбарлыкны деформацияләүче шартлылыкны алга чыгарырга тырышучылар әйтәләр: ул принцип гаять катлауланган безнең чорны канәгатьләндерә алмый. Фикерләрен ныгыту өчен хәтта тәнкыйди реализмның үзен шаһитлеккә чакыралар. Әнә бит, диләр алар, классиклар да шартлылыктан, гротеск һәм фантастикадан баш тартмаганнар. Ә мисаллар? Әлеге дә баягы «Борын», «Бер шәһәрнең тарихы», «Пингвиннар утравы», Маяковскийның «Мунча»сы һ. б. һ. б. Соң бит болар — барысы да сатира! Без исә сатира төренә кермәгән әсәрләр турында сүз алып барабыз.

Бу очракта шартлылык тарафдарларының эше кыенлаша. Эзлиләр, мисал таба алмыйлар һәм мең дә беренче мәртәбә Бальзакның «Шагрень күне» романына килеп ябышалар. Әмма «Кешелек комедиясе»н тәшкил итә торган 92 әсәрнең (күбесе роман) тик берсендә, әлеге романда гына, шартлы-фантастик деталь кулланыл-

---

[1] В. Г. Белинский. Полн. собр. соч., 1 том, 1953, 262 бит.
[2] Л. Толстой. Полн. собр. соч., 1950, т. 239 бит.

ган. Алар хәтта Л. Толстойдан да бер мисал тапканнар: «Холстомер». Әйе, бирedә «икенчел» шартлылык бар. Әсәрнең беренче яртысында без әле аны артык сизмибез. Карт алашаның уйлanулары Ласканың уйлануларыннан принципта аерылмый. Бервакыт Холстомер, атлар чолганышында калып, үзенең тормыш юлын сөйләп бирә. Ләкин бит бу кечкенә повесть Толстойның 90 томлык мирасында шартлы алым белән язылган бердәнбер әсәр! Өстәвенә ул әчкә яшерелгән сатира.

Бик тырышканда, сатира төренә карамаган шартлылыкны тәнкыйди реалистлардан тагын да табып булыр иде. Әйтик, И. С. Тургеневның «Призраки» хикәясе, Пушкинның «Пиковая дама» повесте, Достоевскийның «Двойник» романы. Әмма мондый бер мисалга җавап итеп без йөз мисал китерә алабыз.

Үз әдәбиятыбызның үткәне дә шартлылык тарафдарларын куандыра алмый. Гротеск һәм фантастика хәтта сатирада да сирәк кулланылган. Менә «Фәтхулла хәзрәт» повесте. Тагын нәрсә? Ш. Камалның «Сәмруг кош» исемле хикәясе дияр идек, ул берәүнең төше итеп язылган. Ә төштә ни булмас!

Сатира төренә карамаган әсәрләр арасында да шартлы алым кулланылганнары бар. Әмма оппонентларыбыз шатланырга ашыкмасыннар. Г. Коләхметовның «Ике фикер» драмасындагы аллегорик образлар пролетариат һәм марксизмга таба адым ясаучы интеллигент Давытның башындагы бер-берсенә каршы булган ике фикер генә. Давыт үзе үк болай ди: «Бер фикерем ике булды, ике булып, бер-берсе белән сугыша да башладылар».

Конкрет-тарихи чорда драматург, татар укучы һәм тамашачысына пролетар идеологияне популяр төстә аңлатып бирү максаты белән мондый алым кулланган икән, бу очрак үзен аклый. Һәм ул аерым очрак кына булып калды да.

Ф. Кәриминең «Хыялмы, хакыйкатьме?» исемле кечкенә повестенда реаль депутат белән беркадәр идеаллаштырылган курсистка аңгәмә кылып утырганда, кыз кинәт эреп юкка чыга. Ф. Әмирхан, әсәрне ачы тәнкыйть итеп, болай дип язган иде: «Ходай насыйп итсен дә, мондый курсисткалар, тар милләтчеләребезнең хыялларында гына калып, хакыйкать була күрмәсеннәр!»

Ф. Кәрими кулланган алым шулай ук бүтән кабатланмады.

Совет классикасы да шартлылык тарафдарлары файдасына сөйләми. Ара-тирә, билгеле бер максат белән, аллегория һәм әкиятләр язган А. М. Горькийның социалистик реализмга нигез ташы булып яткан әсәрләре арасыннан да шартлы-романтик яисә шартлы-фантастик алымга корылганнарын таба алмабыз. А. Н. Толстой турында да шуны ук әйтергә мөмкин. «Аэлита» һәм «Инженер Гарин гиперболоиды» дип әйтәләр икән, болары фантастик яки фәнни-фантастик жанрга карыйлар. А. Серафимовичның «Тимер ташкын» романында «тимердән ясалган теш казнасы» дигән метафорадан бүтән шартлылык шулай ук очрамый. А. Фадеев, М. Шолохов, Н. Островский һәм К. Федин иҗатлары уңае белән дә шуны ук әйтергә мөмкин. Күп кенә авторларның, саламга ябышкандай, Шолоховтагы «кара кояш» сүзенә сыланулары күп нәрсә турында сөйли. Бит бердәнбер бәхет чыганагы булган Аксиньядан мәхрүм калган Григорийга ул, ягъни кояш, кара булып күренсә, гаҗәпмени? Бу исә — «беренчел» шартлылык.

Талантлы татар совет прозаиклары, шартлы алым куллануга чакыру авазларын колакка да элмәстән, классиклар күрсәткән юлдан бара бирәләр. Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, А. Расих, Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, Ш. Бикчурин кебекләр, «традицион» стильдә язуларына карамастан, яратып укылалар. А. Гыйләҗев та, драматургиясендә кайбер экспериментлар ясап караса да, укучыга тормышның үз кыяфәтен аклап язылган повестьлары белән якын.

Драматургиядә дә шул ук хәл. Сатира яисә әкият төренә кермәгән пьесаларның «тормыш формасында» язылганнарын бер якка, шартлы алымнарга корылганнарын икенче якка өеп куйсаң, Һималай тавы белән Ослан тавы хасил булыр иде.

Менә ни өчен шартлылык тарафдарлары мисал эзләп күбрәк Көнбатышка — капиталистик яисә халык демократиясе илләре әдәбиятына мөрәҗәгать итәләр. Әнә В. Незвал,— диләр алар,— әнә Э. Ионеско, К. Чапек, Б. Брехт... Болар, янәсе, тормышны үзгәртеп, сәерләндереп сурәтлиләр, гипербола, аллегория, символ, гротеск алымнарын мул кулланалар, чынбарлыкта булмый һәм акылга сыймый торган әйбер һәм хәлләр турында кыю язалар. Шул ук вакытта алар янәсе — чын реалистлар, ул гына

да түгел, реализмны тагын да баетучылар, алга әйдәүчеләр. Хәтта Кафка һәм Джойс кебек декадент язучыларны да реалистлар дип игълан итүчеләр табылды. Янәсе, алар XIX гасыр классикларында яралгы хәлендә генә булган шартлы алымнарны үстергәннәр, хәзерге реализмның төп сыйфатына әверелдергәннәр.

Социалистик реализмны чынбарлыкны деформацияләүче шартлылык хисабына баетырга теләүчеләрнең дәлилләре нидән гыйбарәт соң?

Хәзер, диләр алар, космик очыш, гадәттән тыш тизлекләр, информация ташкыны заманы, ифрат катлауланган чынбарлыкны яңача күрү, яңача фикерләү һәм яңача хис итү заманы. Әнә шул яңа чынбарлыкны, яңача фикерләүне чагылдыру өчен реализмның моңарчы гамәлгә кергән чаралары инде җитми. Реализм баерга, аның алымнар арсеналы тулыландырылырга тиеш. Дөнья әдәбияты уптым илаһи алынса да, андагы сыйнфый тенденцияләр күләгәдәрәк калдырылса да, бу кадәресе белән килештек ди. Әмма ни өчен әле классик реализмның «чикләнгәнлегеннән» котылу өчен нәкъ менә шартлы-фантастик чаралар тәкъдим ителә? Чөнки, янәсе, әйбернең яки күренешнең тышкы кыяфәте аның эчке табигатен тулысынча дөрес чагылдыра алмый. Шуңа күрә тышкы формасын үзгәртергә, хәтта аны җимереп, асылына үтеп керергә кирәк. Аннан соң бит әле, күрәмсең, атом төше кебек, күз белән күреп, колак белән ишетеп, кул белән тотып булмый торган нәрсәләр бар. Традицион реализм чаралары белән аларны, янәсе, ничек күрсәтәсең? Ниһаять, шартлы-фантастик алымнар, янәсе чынбарлык күренешен, детальләрдән арындырып берьюлы иңләргә, бербөтен итеп тыгызлап күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Кайбер белгечләр, шартлы формаларны яклаганда, еш кына «тыелган алым» кулланалар. Тормышны үз формасында чагылдыру принцибының яңа таләпләргә җавап биреп җиткермәгәнлеген исбат итү өчен, алар натурализмны дөмбәсләргә керешәләр яисә бүгенге уртакул сәнгатькәрләрнең уртакул әсәрләрен дәлил итеп китерәләр. Шартлы формага төренгән әсәрләрне XIX гасыр һәм совет классикасы белән янәшә куеп карасыннар иде алар. Менә шунда инде кемнең кемлеге күренер иде!

Шартлылык тарафдарларының кулында уен тузы булып хезмәт итә торган әсәрләрнең кайберләренә махсус тукталып китик.

Менә В. Незвалның «Бүген әле Атлантида өстенә кояш чыгачак» (1955) исемле пьесасы.

Тиран кулы астында изелә торган мифик Атлантида иле демократик Афина дәүләтенә каршы сугыш алып бара. Сугышның гадәти ысуллары белән алдыра алмаган хөкемдар, ачуына чыдаша алмыйча, коточкыч шартлау көченә ия булган металлны эшкә кушарга карар итә. Нәтиҗәдә Атлантида утравы шартлап су астына күмелә. Әдәбият белгечләреннән берсе фикеренчә, әсәр, атом катастрофасына ымлый, һәм бу трагедияне булган хәл итеп күрсәтү кешелек дөньясының язмышы турында борчылу, тынычлык өчен көрәш идеясен үтемлерәк итә.

Әйе, пьесаны зур талант иясе язган. Әмма дөньяга куркыныч янаганны бу пьесага кадәр үк Хиросима трагедиясе күрсәткән иде инде. Аңа калса, атом һәм водород бомбаларының җимерү көчен аңлаткан популяр брошюра катастрофаның колачын әлеге легендага караганда тулырак ачып бирә ала. Инде килеп, атом сугышының куркынычын аңлату өчен иң кулай форма шартлы фантастика икән, аны тормышның үз күренешләренә охшаган сурәтләр ярдәмендә чагылдыруның кирәге дә калмый бит. «Мәскәү, мәхәббәтем минем» исемле кинофильмда бер япон кызы, Мәскәүгә килеп, балет студиясендә укый, әмма талантын күрсәтергә өлгерә алмыйча, радиациядән үлеп китә. Дөрес, бу фильм җиңел кулданрак эшләнгән. Әгәр В. Незвал талантына тиң талант шундый бер фаҗигане драма итеп язса, мондый әсәр тетрәтер идеме, атом катастрофасы куркынычын ачып бирер идеме?! Ничек кенә әле! Бәхеткә хаклы булган һәм халкын бәхетле итү эшенә өлеш кертергә сәләтле баланың униҗидегә дә җитмичә һәлак булуын, теләсәгез нишләгез, мин, укучы яисә тамашачы буларак, мифик Атлантиданың һәлакәтенә караганда йөрәгемә якынрак алам.

Шартлылык тарафдарларының иң җитди терәге, әлбәттә, Б. Брехт иҗаты. Атаклы драматург иҗатындагы шартлылык метафоризмга, кинаялелеккә кайтып

кала. Ул бер нәрсә турында яза, әмма аннан икенчерәк нәрсәне аңларга кирәк. Әйтик, «Артуро Уи карьерасы» пьесасында сүз Чикаго гангстеры турында гына бара. Әмма моны фашизмның властька килүе дип аңларга кирәк. Икенче төрле әйткәндә, аның пьесалары притча (хикәят) алымы белән язылган. «Әнә шуңа күрә,— дип яза А. Михайлова,— тарихның бөтен логикасы шул чаклы кысып, тыгызлап бирелгән ки, аны бер карауда күреп була. Шуның фонында канлы фашизмның әшәкелеге эре, калку булып, бөтен шәрәлегендә гәүдәләнә»[1].

Болар шулай да булсын, ди. Әмма биредә дә искәртмә сорала. Беренчедән, Б. Брехтның барлык пьесалары да дип әйтерлек сатирик характерда; икенчедән, ул күтәргән проблемаларны Гоголь һәм Островский, Чехов һәм Горький, Тренев һәм Погодин, Корнейчук һәм Розовлар өчен уртак булган иҗат принциплары ярдәмендә сәнгатьчә хәл итеп булмыймыни? Өченчедән, әгәр һәрбер драматург бүген Б. Брехтча хикәят-притчалар да язарга керешсә, нәрсә килеп чыгар иде? Шунысын да онытмыйк: притча Ионеско яки Б. Брехт уйлап чыгарган жанр формасы түгел. Ул барлык әдәбиятларның да борынгы чорларында гаять зур урын тоткан. Безнең әдәбиятта, мәсәлән, XIX гасыр ахырына кадәр хикәяттән күп нәрсә юк. Әдәбият тарихы нәкъ менә хикәят стиленнән тормышны тарихи-конкрет сурәтләүгә таба хәрәкәт итте. Инде бүген социалистик реализмны баету чараларының берсе итеп притча алымнарын тәкъдим итү комбайнны ташлап кире уракка кайтырга чакыруны хәтерләтә түгелме?

Үз әдәбиятыбызга кайтыйк.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы — шартлы алым куллануның урынлы һәм уңышлы очрагы.

Яшәеш, үлем, үлемсезлек... Мәңгелек проблема. Күп гасырлар буе акыл ияләре, шагыйрь һәм әдипләр бу проблеманы хәл итәргә омтылганнар, төрле тәгълиматлар тудырганнар, үлемсез әсәрләр иҗат иткәннәр. Тормышта да һәр кеше шул ук мәсьәләне үзе өчен хәл итәргә мәҗбүр. Чөнки ул, иртәме, соңмы, Әлмәндәр карт кебек үк, әҗәл белән очрашачак. Теге дөнья һәм оҗмах дигән нәрсәләргә өмет юк. Оптимизм чыганагы булып бердәнбер нәрсә кала кешегә: үзеңне галәм үзәге итеп түгел, бәлки тере организмның бер күзәнәге, үлемсез коллективның, халыкның бер әгъзасы итеп хис кылу, бүген һәм киләчәк өчен үзеңне җаваплы итеп тою, коллективның бүгенге һәм киләчәк уңышлары хакына көч түгү, чын күңелдән хезмәт итү. Ягъни шагыйрь әйткәнчә:

**Үзең турында уйлама,**
**Илең турында уйла.**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Т. Миңнуллин пьесасы шушы һәм шушыңар охшаш уйлар кузгата.

Электроника белән җиһазландырылган «күк канцеляриясе»нә шушы чаклы урын бирү бәлки кирәк тә булмагандыр. Финалда Әлмәндәр карттан хур кызын кочаклаттыру һәм кызны чырыйлатып кычкыртуның кирәклеге шулай ук ким дигәндә бәхәсле. Әмма үлемнең кеше кыяфәтендә хәрәкәт итүе, Әлмәндәр картның Әҗәл белән «качышлы уйнавы» гаять табигый итеп, тормыш логикасына туры китереп язылган. Әҗәл биредә, Давытның ике фикере кебек үк, аллегорик персонаж. Пьесаның бүтән катнашучылары аны бөтенләй күрмәгән кебек, тамашачы да Әҗәлнең сәхнәдә йөрүенә сәерсенми.

Әйе, билгеле бер очракта, билгеле бер идеяне укучыга җиткерү өчен сайланган алым үзен аклады. Ләкин бу уңыш моннан соң Т. Миңнуллин үзе дә, бүтән драматурглар да аллегория, символ, гротеск, әкият алымнары гына кулланып язарга тиешләр дигән нәтиҗә ясарга хокук бирми.

Бу юлларның авторы, Ш. Хөсәеновның «Әни килде» спектаклен караганда, театрда утырганын онытып җибәргән иде. Тәнкыйтьче буларак ул пьеса язу техникасын да, сәхнә кануннарын да азмы-күпме белә дип уйлыйк. Спектакльдә роль башкарган артистларның күбесе белән ул кул биреп күрешә. Шулай да аларның, әйтик,

[1] А. Михайлова. О художественной условности. Изд-во «Мысль», 1970, 233 бит.

Г. Шамуков яисә Ш. Биктимеров булганлыкларын оныткан кебек, үзенең спектакль караганын оныта! Менә бу сәнгать! Шартлылыкның кирәклеген инкарь итмәгән хәлдә, болай дип әйтәсе килә: театрда утырганыңны оныттырырлык пьеса һәм спектакльләр күбрәк булсын иде.

Әхсән Баяновның «Тавыш — табигать бүләге» повесте тулысынча дип әйтерлек шартлы алым белән язылган. Әсәр герое булган Нажар дөньякүләм әһәмияткә ия фәнни ачыш ясау алдында тора. Ә аның җитәкчесе әлеге ачышка берниндди өлеш кертмәсә дә, ачышның авторын читкә этәреп, иң зур калҗаны эләктермәкче.

Әсәрнең сюжет схемасы әнә шуннан гыйбарәт. Моңа охшаш схема белән без рус совет прозасында яисә кинофильмнарда күп мәртәбә очрашкан идек. Тик әле моңа карап кына әсәрне тәнкыйтьләргә ашыкмыйк. Дөнья әдәбиятында, мәсәлән, мәхәббәт «өчпочмагы»на корылган йөзләрчә шедеврлар бар. Һәркайсы — кабатланмас үзенчәлеккә ия оригиналь әсәр.

Ә. Баянов үз повестеның сюжет схемасына аллегория һәм метафора, символ һәм кинаялардән һәм сәер кыланышлар кебек парчалардан җыеп типчелгән шактый сәер кием кидергән. Әсәрнең кайбер персонажларына игътибар итик: Мөдир, Директор, Каравылчы, Прораб, Вәкил, Әпә. Әсәрдә аларның исем-фамилияләре булмаган кебек, индивидуаль йөзләре дә юк. Алар теге яки бу принципның кеше кыяфәтендәге гәүдәләнеше генә. Алар — аллегорияләр. Кайдандыр килеп адашкан телсез малай Әпә, мәсәлән, табигать символы. Каравылчы — Табигать Каравылчысы. Прораб, киресенчә, табигатьне корытучы ниндидер көчләргә иллюстрация.

Билгеле инде, бу шартлы персонажларның кылган гамәлләре һәм сөйләгән сүзләре дә шартлы, ягъни «кешечә» түгел, гадәттән тыш сәер, тоташ киная, философик мәгънәгә дәгъва. Үз исемнәре белән бирелгән өч персонаж — лаборатория башлыгы Нажар Зәбиров, аның хатыны Фәнүсә һәм кызы Энҗе дә характер ягыннан «исем-сез»ләрдән күп ерак китмәгәннәр.

Нажарны алыйк. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр аның үз-үзен тотышы, кыланышлары сәер, сөйләшү рәвеше, сүзләренең мәгънәсе сәер. Дөрес, бер урында автор моны мотивлаштыргандай итә: янәсе, тамагында тонзиллит, температурасы — утыз сигез градус.

Менә ул кабан дуңгызы атарга һәм аның тиресеннән карачкы ясап, музейга куярга уйлый. Әмма ялгышып аю ата. Шуннан башлана үкенү, үз-үзен шелтәләү. Каравылчы да, Энҗе һәм Әпә дә аны гаепләләр. Нажар аю тиресенә төренгән кызын да ялгыш атып үтерә яза. Ул аю карачкысы белән сөйләшә, аның тавышы югала.

Тавыш дигәннән, бу детальне уйнатып, автор ниндидер фикер, ниндидер идея үткәрергә омтыла булса кирәк. Әсәрнең исеме дә шул турыда сөйли. Ә нинди фикер? Бу сорауга җавап бирү шактый кыен. Чөнки тавыш мәсьәләсендә логика җитми. Туры мәгънәсендә тавышсыз калган Нажар ресторанда көчле тавыш белән бер артист булып җырлый. Аннары, авторга кирәк булгач, тагын тавышсыз кала. Ниһаять, кызы югалгач, «Үтерделәр, үтерделәр!» дип бик каты кычкырып җибәрә, ягъни тавышы кире кайта.

Әсәрне тырышып җентекләсәң, анда табигатьне саклау идеясенең өстенлек иткәнен чамаларга мөмкин. Булыр-булмас препаратлар белән, янәсе, кош-кортларны харап итәләр, Нажар авылында «елганың башын ук кисkәннәр». Прораб читлектәге җәнлекләрне харап итә яза һ. б. һ. б.

Бу темага моңарчы бик күп әсәр язылды. Рус һәм башка халык әдәбиятларында да, үзебездә дә. Яхшылары да бар, уртачалары да. Яхшы дигәннәре адәм телендә, адәм аңлый һәм ләззәт бирә торган итеп язылган. Ә. Баянов повесте исә, фәлсәфи гомумиләштерүгә дәгъва итсә дә, фикер ягыннан ул әсәрләргә күп нәрсә өсти алмый. Ышандыру көче ягыннан да оттыра. Чөнки ул тормышның реалистик чагылышы булудан бигрәк, Нажар Зәбировның төштә күргәннәре тәэсирен генә калдыра.

Шулай итеп, бу әсәрендә Ә. Баянов әдәбиятта күп кабатланган сюжет схемалары ярдәмендә яңалыгы чамалы булган фикер үткәрә. Шартлы сурәт, алым һәм чаралар әлеге оригинальлегенең җитенкерәмәвен каплау өчен генә хезмәт итә. Бу мисал ачыклыгында тормышны үз төсендә, үз кыяфәтендә, үз формасында чагылдыруның көч-куәте һәм өстенлеге тагын бер кат раслана кирәк. Натурализмга авышмаган

очракта, бу принцип чынбарлыкның асылына үтеп керү, җәмгыятьнең үсеш-үзгәреш закончалыкларын чагылдыру һәм, димәк, философик гомумиләштерү ясау мөмкинлегенә тулысынча ия. Л. Толстойның «Анна Каренина»сында яисә М. Шолоховның «Тын Дон» эпопеясында тирән философия юк дип кем әйтә алыр? Шуның өстенә, мондый әсәрләрдәге вакыйгалар һәм персонажлар булып үткән хәл, реаль яшәгән кешеләр рәвешендә күз алдына килеп басалар. Аларның ышандыру көче гадәттән тыш куәтле була.

Үз урынында, билгеле бер максатка буйсындырылганда, лирика һәм сатира төренә карамаган реалистик әсәрләрдә дә сәнгатьчә гомумиләштерүнең шартлы-фантастик формасы үзен акларга мөмкин. Отышлырак чара сыйфатында миф һәм хикәят алымнарына, фантастика һәм гротескка өстенлек бирү, бу алымнарны системага әверелдерү омтылышы исә сыналган һәм ныгыган реализм теориясе белән яраша алмый.

Мәсьәләнең болай куелышы, минемчә, практик әһәмияткә дә ия. Шартлы-фантастик алымнарга өстенлек бирү тенденциясе яңа, оригиналь фикере булмаган авторлар өчен гаҗәеп кулай. Реалистик стильдә язар иде — укучы шаблон ситуация, шаблон конфликт, үтә таныш персонажлар белән очрашачак. Көнбатыштан килә торган модернистик экспериментларны файдалансаң, мәсьәлә үзгәрә: фикер ярлылыгы шартлы сурәтләр эченә күмелә дә кала. Мондый авторның эзләнүчән, үзенчәлекле һәм хәтта оригиналь язучы исемен күтәрүе дә мөмкин...

Социалистик реализм иксез-чиксез эстетик күренеш булмаса да, сәнгатьчә гомумиләштерүнең төрле формаларын үз эченә сыйдыра торган система. Тормышны үз формасында чагылдырган әсәрләр һәм авторлар да (сүз талантлылар турында бара) һич тә бер-берсенә охшамаганнар. Мондый язучылар да туктаусыз эзләнәләр. Алар, барыннан да элек, тормышның үз эченә үтеп кереп, андагы яңа, характерлы тенденцияләрне тотып алырга, мәсьәлә күтәрергә омтылалар, шуңа лаеклы сәнгать чаралары эзлиләр. Реалистик сәнгатьтә чынбарлык күренешләрен җанлы итеп күз алдына бастырып та, үзе сизелми торган форма гына — яхшы форма. Моңа ирешү исә җиңел түгел. Эзләнү дигәнебез формага гына кайтып калса, бу инде формализмга таба өстери.

«Литературная газета» үткәргән һәм без югарыда телгә алып узган дискуссия дә чынбарлыкны үз кыяфәтендә чагылдыру принцибы файдасына булды дип әйтергә нигез бар. Дөрес, хикәят һәм миф-риваять стилендә язуны прозаның алга таба адым ясавы итеп каручылар анда байтак булды. Әмма «Литературная газета»ның бәхәсне Морат Ауэзов мәкаләсе белән тәмамлавы һәм бу мәкаләне «аеруча нигезле, полемикага хас чиккә ташланулардан азат» дип бәяләве күп нәрсә турында сөйли. М. Ауэзов болай дип яза: «...реалистик сәнгатьнең чынбарлыкны үз формасында үзләштерү принцибын кулдан ычкындырмаска чакырган Л. Аннинский белән килешми мөмкин түгел. А. Бочаров позициясен исә кабул итеп булмый. Чөнки ул миф тудыру симптомнарын прозаның «интеллектуаль коэффициенты»н күтәрү чарасы итеп күрә һәм мифның акыл-аң чигенгән очракта гына философияне алыштыруын онытып җибәрә» («Литературная газета», 1978 ел, 7 июнь).

Мәкаләне танылган әдәбият галиме А. Метченко сүзләре белән тәмамлыйсым килә. «Социалистик реализм поэтикасының диапазонын миф, притча, символ кебек сәнгать чаралары хисабына киңәйтүне ничаклы югары бәяләсәк тә, социалистик реализмның төп бурычы социалистик яшәеш рәвешен чынбарлыкның үзендә булганча дөрес итеп сурәтләүгә кайтып кала» («Литературная газета», 1980, 16 апрель). Әйе, тормышны үз формасында чагылдыру классик реализмның төп принцибы булган кебек, социалистик реализм әдәбиятында да ул әйдәүче ролендә булды һәм шулай калачак.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# БИК КИРӘКЛЕ ЭШ

Равил Кукушкин. «Шигъри бишек». Татарстан китап нәшрияты. 1981

Газет-журналларда балалар әдәбияты мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, рецензияләр басылгалап тора. Хәтта ике кандидатлык диссертациясе дә язылды. Әмма алар вакытлы гына күренеш булдылар, эш арасында бәбинең бишеге яныннан бик тиз узып китүне генә хәтерләттеләр. Ә балалар әдәбияты, бигрәк тә нәниләр поэзиясе, бишеге янында утырып багучысын күптән һәм һәр даим көтте.

Яшь белгеч Равил Кукушкинның «Шигъри бишек» китабын укып чыккач, башка иң беренче булып шундый уй килде: татар балалар поэзиясенең «шигъри бишеге» янында утырырга тиешле игелекле кеше менә шушы түгелме?

«Шигъри бишек» татар әдәбияты белемендә балалар поэзиясе тарихына багышланган беренче зур фәнни хезмәт. Ул Бөек Октябрьга кадәрге балалар поэзиясенең үсеш баскычларын билгели, нәниләр әдәбияты өлкәсендәге эшләрнең җанлы картинасын бәян итә. Иң башта автор укучының игътибарын балалар шигъриятенең нигез ташы булган фольклор жанры поэтикасына, аның эстетик һәм тәрбияви әһәмиятенә юнәлтә. Ул балалар фольклорына аңлатма бирү белән генә чикләнмичә, нәниләрнең рухи тормышы белән алар телендәге халык иҗаты әсәрләренең эчтәлеге арасындагы бәйләнешләрне ачарга тырыша. Р. Кукушкин баланың эстетик һәм психологик эволюциясен ул кулланган фольклор әсәрләре белән янәшә куеп, чагыштырып карый һәм кызыклы закончалык күрә: балалар фольклорының һәр жанры билгеле бер яшьтәге һәм рухи интеллектуаль үсеш баскычындагы балага төбәлгән була. Халыкның репертуарында теләсә кайсы яшьтәге, эстетик һәм интелектуаль үсешнең теләсә кайсы дәрәҗәсендә торган балага да хуш килерлек әсәр бар. Кыскасы, баланың физик һәм рухи яктан үсеш юлында фольклор жанрлары билгеле бер эзлеклелек белән тезелеп бара һәм алар балага балигъ булганчы юлдаш икән. Бу «теземдәге» әсәрләрнең поэтикасына күз салганда баланың эстетик завыгы үсешенең эволюциясен дә чамаларга була икән. Тикшеренүче нәкъ шул юл белән китә. Ул балалар фольклоры жанрларын бала репертуарына керү тәртибендә тезеп чыга да, әсәрләрнең эчтәлегенә күз сала һәм кызыклы бер закончалык күрә: баланың дөньяны эстетик үзләштерүе билгеле бер эзлеклелек белән

һара икән. Мәсәлән, ул баштагы чорда юш-кортлар, җәнлек-җанварлар, табигать күренешләренә күбрәк игътибарын юнәлтә, үсә төшкәч аны кешеләрнең хәрәкәт-шөгыльләре кызыктыра, соңрак — ул кешенең эчке дөньясына «керергә» тырыша. Балаларның дөньяны эстетик үзләштерү объектлары табигать дөньясыннан кешенең үзенә күчү чоры аларның такмазалар куллана башлау вакытына туры килә дип күрсәтә автор һәм фикерен конкрет мисаллар белән дәлилли. Аннары китапта балалар фольклорын җыю тарихы кыскача ачыклана, балалар поэзиясе үсешендә классик әдәбиятның әһәмияте күрсәтелә.

Профессиональ балалар поэзиясенең тууы XIX гасыр ахырында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең көчәеп китүе белән бәйләнгән. Мәгърифәтчеләр, укыту-тәрбия эшен яңача үзгәртеп кору белән бергә, балалар өчен дөньяви, реалистик язма әдәбият булдыруны да бурыч итеп куялар. Шул чорда К. Насыйри, Т. Яхин, Г. Фәизханов кебек укымышлылар балалар өчен хрестоматияләр, уку китаплары бастыра башлыйлар.

1905 елгы буржуаз-демократик революциядән соң татар телендә газета-журнал бастыра башлау да балалар әдәбиятын үстерүгә зур ярдәм итә. Көндәлек матбугатта һәм аерым җыентыклар рәвешендә Г. Рахманколый, С. Рәмиев, М. Укмаси, Н. Думави, С. Сүнчәләй, З. Ярмәки, Ш. Бабич, М. Гафури, Г. Сәлимов, З. Бәшири һ. б. шигырьләре басыла башлады. Автор балалар әдәбиятының нигез ташларын салучы бу шагыйрьләрнең иҗатына кыскача күзәтү ясый.

Татар балалар поэзиясе тарихында да Г. Тукай иң дәрәҗәле урынны били. Аның (Тукайның) «балалар әдәбиятына үз булып килеп керүе һич тә очраклы хәл түгел...,— ди автор бу турыда. — Моны барыннан да элек, ...күңеле белән сабый җанлы булып калуы, художестволы фикерләвенең дә нәкъ менә шул сабыйлык рухына буйсындырылган булуы итеп аңларга кирәктер...» Әмма тикшеренүче Г. Тукайның балалар поэзиясендәге уңышларын субъектив сәбәпләргә генә кайтарып калдырмыйча, аның төп объектив сәбәбен шагыйрьнең үз халкының патриоты булуында күрә. Шагыйрь әдәбият мәйданына 1905 елгы революция китергән сүз иреге, азатлык идеяләре белән рухланып килеп керә. «Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә» дип дулкынланган шагыйрь, балалар әдәбиятының бик фәкыйрь хәлендә икәнлеген күрә һәм, үз халкының патриоты буларак, бу җитешсезлеккә күз йомып кала алмый, җиң сызганып эшкә чума — балалар өчен шигырьләр, хикәяләр яза, әдәбият буенча уку китаплары төзеп бастыра. «Шигъри бишек»тә сөекле шагыйрьнең балалар шагыйре һәм педагог буларак эшчәнлеге шактый тулы ачылган.

Г. Тукай шигырьләренең поэтикасы турында хезмәтләр байтак язылган. Шулай да Р. Кукушкин бу мәсьәләгә тагын бер кагылып узуны кирәк тапкан. Шунысы куанычлы, бу очракта ул әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү, тематик анализ ясау кебек традицион алымнардан читләшеп, шагыйрьнең иҗат психологиясенә үтеп керергә тырыша, баланың рухы җиңел кабул итә алырдай үтемле детальләрнең, шигъри табышларның шагыйрь күңелендә ярала механизмын күрсәтергә омтыла, шагыйрьнең эстетик критерийларын танып белү юнәлешендә эзләнә. Г. Тукай әсәрләре поэтикасы турында кызыклы гына күзәтүләре дә бар.

«Шигъри бишек» китабы — әйбәт башлангыч. Киләчәктә бу хезмәт дәвам иттерелсен иде. Ише янына куш булып балалар прозасы тарихына багышланган хезмәт язучы да өстәлсә, «Татар балалар әдәбияты тарихы» булып куюы бар. Кыскасы, шуны булдыру юнәлешендә беренче адым ясалды. Хәзер ярты юлда туктап калмаска гына кирәк. Шуңа ышанганга күрә, кайбер теләкләрне дә әйтү кирәктер дип уйлыйм.

Хезмәт балалар фольклоры әсәрләренең специфик үзенчәлекләре, поэтикасы турында төпле фикерләр әйтә. Әмма ул аның бөтен жанрларына да игътибар итми әле. Эндәшләр, алдавычлар, тел көрмәкләндергечләр һ. б. жанрлар читтә калганнар. Кайбер урыннарда жанрларның атамаларын конкрет әйтмәү, яки башка жанрлар белән бутау кебек җитешсезлекләр күзгә чалынып китгәли.

Балалар поэзиясе тарихына багышланган беренче зур хезмәт булуына карамастан, моңа кадәр бу юнәлештә татар әдәбият белемендә кыл да кыймылдатылмаган дип әйтергә ярамый. Аерым алганда, бик күп кенә язучыларның, Н. Юзеев, Г. Халит, И. Нуруллин, Х. Курбатов, Ф. Ибраһимова кебек әдәбиятчы һәм телчеләрнең хезмәтләрендә балалар әдәбиятына кагылышлы мәсьәләләр байтак күтәрелгән. 1938 елда «Совет әдәбияты» журналында Г. Тукайның балалар өчен язган әсәрләрен тик-

шерүгә багышланган Ф. Габдрахманов мәкаләсе дә бар. Фәнни хезмәт язганда үзенә кадәр эшләнгән эшләрне, бигрәк тә үзең нигезләнгән хезмәтләрне билгеләп үзү зарурлыгын онытырга ярамас. Болар әлдагы көндә җиңел төзәлә торган кимчелекләр, әлбәттә.

Иң кыйммәтлесе шул: балалар әдәбияты тарихын тудыру юлында мөһим бу адымны балаларны ярата, аларның күңелен яхшы аңлый ала торган, матур телле, ачык фикерле әдәбиятчы башлап җибәрде. Нәниләрнең «шигъри бишеге» янына сәләтле әдәбиятчы, тәнкыйтьче килде.

**Рәшит ЯГЪФӘРОВ,**
балалар фольклоры белгече.

# БИШЕК ТИРБӘЛЕРГӘ ТИЕШ

Безнең әдәби тәнкыйть чын мәгънәсендә сыйфат үзгәреше кичерә, күзгә күренеп ныгый, үсә бара. Моның белән без барыбыз да хаклы рәвештә горурланабыз. Ләкин балалар әдәбияты тәнкыйте үсмичә, әдәби тәнкыйть беркайчан да камил була алмый. Күптән түгел КПСС Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть турындагы мәгълүм карарына ун ел тулуны билгеләп үттек. Бу — безнең әдәбиятта олы вакыйга. Ул балалар әдәбияты тәнкыйтенә дә уңай яктан тәэсир итәргә тиеш иде, югыйсә. Ләкин, кызганычка каршы диикме, әллә ни үзгәреш күренмәде. Бердәнбер юаныч — Равил Кукушкинның «Шигъри бишек» китабы. Тәнкыйтьченең әлеге хезмәте татар балалар поэзиясе тарихын чагылдыручы җитди хезмәт. Тик, ни сәбәптәндер, китапка аның кечкенә бер өлеше — Бөек Октябрьга кадәрге балалар поэзиясенә кагылган ике бүлеге генә кертелгән. Шуңа да карамастан, «Шигъри бишек» балалар әдәбияты белән кызыксынучылар өчен кыйммәтле хезмәт булып тора.

Бу тәнкыйтьче балалар әдәбиятына күтәрелеп, үзенең бу өлкәгә кирәк икәнен аңлап килде кебек. Гыйльми әзерлекле, әдәбиятка тирән мәхәббәте булган, шигъриятне нечкә тоючы шундый тәнкыйтьче балалар әдәбиятына күптән кирәк иде. Чөнки бу өлкәнең ишеген җитди шакучылар ишетелмәде һәм күренмәде диярлек. Язылası хезмәтләр, эзләнү-тикшеренүләр, китаплар, диссертацияләр үз авторларын көтә бирде. Беренче кыю адымны Р. Кукушкин ясады, соңгы берничә ел эчендә ул татар балалар әдәбиятын өйрәнүгә җиң сызганып тотынды. Вакытлы матбугатта аның Г. Тукай, А. Алиш, Б. Рәхмәт, Ш. Галиев иҗатларына багышланган күләмле һәм җитди мәкаләләре дөнья күрде. Балалар әдәбиятына, аның адипләренә теләктәшлек белән, мәхәббәт һәм хөрмәт белән эшләнгән ул язмалар үз укучыларын тиз тапты. Инде менә «Шигъри бишек»...

Шигъри бишек! Бу исем — безгә калса, тирән мәгънәле сурәт тудыручы, символик образлы төшенчә. Татар өендә бишек, гадәттә, түр башында тирбәлә. Өй эчендәгеләрнең бөтен игътибары шул бишектә — якты өмет-хыяллар да, гасырлардан килгән җыр-моң да, елмаюлар да, күз яшьләре дә... Бишекле өйнең эче нурлы, бишекле өйдә җыр-моң өзелми. Бишекле өйнең киләчәге бар! Ә бишек янында — Ана! Шул моңнарның, җырларның чыганагы, бетмәс-төкәнмәс чишмәсе ана күңелендә. Китапның авторы язганча, «бала, туу белән, халык рухының шигъри авазлары кочагында тирбәлә башлый». Китапның беренче битләреннән үк шушы шигъри күренеш күңелгә килә. Һәм үзең өчен ачыш ясыйсың: шигърият әнкәйләрнең күкрәк сөтеннән, күкрәк моңыннан башлана икән. (Ә без аның башлангычын еш кына бөтенләй башка җирдән эзлибез һәм... таба алмый интегәбез.) Бу инде, югыйсә, мәңгелек хакыйкать, һәркемгә мәгълүм нәрсә. Барыбыз да әнкәйләрнең күкрәк сөтен имеп, бишек җырын тыңлап үскәнбез. Ләкин ул җырлар безнең күңелләргә, ана сөте кебек, шул кадәр сеңгән, алар инде күңелләрнең нечкәлегенә, моңсулыгына, шатлыкларга, якты хисләргә әверелеп беткәннәр. Шуңадырмы, бишек җырлары турында онытып та барабыз, аның мәгънәсен истән чыгарабыз түгелме? Ана! Бала! Бишек! Менә шушы өч изге сүзгә җыр-моңның үзәге, бүгенгесе һәм киләчәге сыеп беткән түгелме?!

Китапның беренче бүлеге тулысынча балалар фольклорына багышланган. Мәгълүм булганча, без бу өлкәдән әзме-күпме хәбәрдар инде. Мин биредә, иң беренче чиратта, әлбәттә, Нәкый ага Исәнбәтнең онытылмас эшчәнлеген күз алдында тотам.

Шуңа күрә, башка бүлекләр белән чагыштырганда, бу бүлекне язу авторга күпмедер дәрәҗәдә җиңелрәк булгандыр дип уйлыйм. Аның бу бүлектә Н. Исәнбәткә еш мөрәҗәгать итүе үзе үк шул хакта сөйли. Әйтергә кирәк, шигъри фольклорга багышланган бүлек балаларга да, фольклорның үзенә дә олы мәхәббәт белән язылган. Бүлекләрнең исемнәре үк тикшеренүнең киң колачлы, тирән эчтәлекле булуын, бу өлкәнең бөтен якларын да колачларга омтылыш турында сөйли: «Бишек янында», «Табигать белән сөйләшү», «Бар иде, ди, юк иде, ди», «Халык хикмәтләре», «Шигъри уеннар»... Автор балалар фольклорында еш очрый торган жанрларга (такмаклар, такмазалар, санамышлар, табышмаклар...) киң тукталa, аларга җентекле анализ ясый, серләрен ачыкларга омтыла, баланың хисен, акылын, белемен, дөньяны күзаллавын формалаштырудагы әйтеп бетергесез ролен күрсәтеп бирә. Тәнкыйтьче укучыларны яңадан бер тапкыр балачакларына алып кайта. Бөтенләйгә түгел, әлбәттә. Кунакка гына. Таныш такмаклар-такмазалар. Китап белән танышканда, иҗексездән, үзебез үскәндә ишеткән, җанга сеңеп калган такмаклар кабат искә төшә. Әйтик, багу такмаклары. Безне дә бит такмак әйтеп уятканнар, җыр җырлап йоклатканнар, уйнатканнар, хәтта эшләргә өйрәткәннәр. Безне дә бит һәр даим шул шигырьләр-такмазалар юаткан, дәртләндергән. Автор үзе әйткәнчә, «җыр-такмазалар баланы хәрәкәт иттерү рәвешенә нигезләнеп иҗат ителгәннәр. Җыр-шигырь белән хәрәкәт, эш, уен һәрвакыт янәшә йөргән. Алар иң зур тәрбия чарасы булганнар», баланы шат, сәламәт итеп үстерүгә турыдан-туры ярдәм иткәннәр.

Р. Кукушкин «Бишек янында» бүлекчәсендә менә шушы такмазаларга, бишек җырларына күзәтү ясаса, бала белән олылар мөнәсәбәтенә тукталса, «Табигать белән сөйләшү»дә инде баланың аякка баскannan соң, җир буйлап атлап китүкәч башланган дөньясын тасвирлаган такмакларны барлап чыга. Биредә балалар такмакларны үзләре такмаклый. Такмакчы балалар — бар булмышлары белән табигать кочагында. Ә бит алар, бигрәк тә авыл балалары, чын мәгънәсендә, мәҗүсиләр. Табигать алар өчен барысы да: дөнья белән танышу да, бөтен җан ияләре белән дуслашу да, күренешләрнең серләренә төшенергә тырышу да... Баксаң, боларның һәммәсе дә балалар фольклорында бар икән. Такмазалар әйткәндә бала шатлана, дулкынлана, кайгыра, уйлана, уйный, табигать буенча беренче белемнәрне ала. Баланың бөтен матур сыйфатлары шушы такмазаларга сыеп бетә сыман. Автор әлеге такмазаларның үзенчәлекләрен ачыклый, бала фантазиясенең байлыгын күрсәтеп бирә.

«Бар иде, ди, юк иде, ди» исемле бүлекчә исә такмазаларның аерым бер төренә — әкият алымнары кулланып иҗат ителгәннәренә багышланган. Һәм, әйтергә кирәк, биредә шулай ук кызыклы күзәтүләр ясалган. Бу жанр балалар фольклорында ифрат күп кулланыла, чөнки аның мөмкинлекләре чикләнмәгән: күңелең булганчы, теләсәң күпме ялганла! Ләкин бала уйлап чыгарганнары аның үзе өчен ялган да булып тоелмый. Менә шушы фольклор алымы хәзер балалар поэзиясендә киң кулланылыш тапты. Рус балалар поэзиясендә ул, билгеле, 20—30 нчы елларда ук бар иде. Мәсәлән, Чуковский һәм Маршак иҗатларында. Соңгы елларда бу алым безнең балалар поэзиясенә дә үтеп керә башлады. Ул бигрәк тә Рөстәм Мингалим шигырьләрендә ачык сизелә. Әгәр дә автор такмазаларның бүгенге поэзиягә тәэсире турында да әйтеп китсә, шулай ук рус фольклоры (небылицы-перевертыши, прибаутки, считалки, дразнилки...) белән чагыштырып караса, хезмәтнең бәясе бермә-бер артыр иде. Югыйсә, без андый алымнарны балалар поэзиясенә кемдер алып килгән яңалык дип кабул итәргә әзертабыз. Карасаң, ул «яңалык» дигәнебез балалар фольклорында гасырлар буе яшәп килә торган күренеш булып чыга.

Китапта мәкаль-табышмакларга да күп урын бирелгән. Биредә аларның ясалу формалары тикшерелә, шигъри әсәрләр булулары исбат ителә. Баланың тапкырлыгын үстерүдә мәкаль-табышмакларның роле, чыннан да, әйтеп бетергесез. Чуалтмышлар исә халкыбызның җорлыгын да, тапкырлыгын да, көр күңеллелеген дә ачык чагылдыра. Җитди әйберләрне дә уен-көлке белән аңлата алу сәләте турында сөйлиләр алар. Санамышлар, үртәвечләр, иярткечләр дә баланың рухи дөньясын баетуда, эстетик культурасын үстерүгә булышалар. Нишлисең, элекке заманнарда аларга шагыйрь, композитор абыйлары махсус җырлар, сценарийлар, уеннар язып бирмәгәннәр шул. Шуңа күрә дә бу уеннар театр вазифаларын да үтәгәннәр, халык педагогикасының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткәннәр. Китапта такмак-

ларның универсаль тәрбия чарасы булуларына басым ясала.

Китап белән танышканда шундый бер фикергә киләсең: бүгенге балалар поэзиясе алдында торган бурычларның барысы да электән үк аларның фольклорын әйдәп барган икән. Туган җиргә, туган телгә мәхәббәт тә, тапкырлык та, фикер йөгереклеге дә, бетмәс-төкәнмәс хыял-фантазия дә... Балалар авыз иҗаты белән балалар шигъриятендәге уртак якларга тукталып, автор үзе дә мондый нәтиҗәгә килә: «Тормыш кырыслыгына туры карау, явызлык, гаделсезлеккә каршы протест, киләчәккә ышаныч, тирән оптимизм һәм әхлак сафлыгы — фольклорның да, балалар әдәбиятының да аерылмас үзлекләре. Алар аның югары идея, мораль сыйфатын барлыкка китерә».

Китаптан күргәнчә, автор балалар фольклоры әсәрләрен тирәнтен тоя, аларның мәгънәләрен җентекләп аңлатып бирә ала, һәм, үзе дә сизмәстән, уйлануларында аның самимилеге калкып чыга. Ә бу исә балалар әдәбияты тәнкыйтьчесе өчен иң кирәк сыйфатларның берсе. Балалар әдибенә кирәк сыйфатлар аның тәнкыйтьчесенә дә шул ук дәрәҗәдә кирәк. Бу сыйфат китапта адым саен сизелеп бара, бер генә мисал китереп үтик. «Табышмакны ишетү белән бала уй-зиһене, фантазиясе артыннан ерак сәяхәткә чыгып китә:

**Диңгезе бар — суы юк,**
**Каласы бар — халкы юк,**
**Урманы бар — агачы юк.**

Чынлап та, кызыклы сәяхәт бит. Кемнең әле әнә шундый сусыз диңгез, агачсыз урманнарга барып йөргәне бар?! Сизгерлегең җитмәсә, шунда адашып калуың да бик мөмкин. Инде әлеге шигъри лабиринттан чыгып, яңадан үзеңә таныш, реаль дөньяга кайтасың икән, син икеләтә-өчләтә бәхетле. Табышмакның җавабын табуың белән генә түгел, аның шигъри телен аңлый алуың белән дә, иптәшләрең арасында ихтирам-хөрмәт казануың белән дә...» Шулай итеп, сиздермичә генә, мәҗбүр итмичә генә, үзенең балаларча тасвирлау сәләте белән, мавыктыргыч сөйләү алымы белән автор безне фольклордагы балалар дөньясына алып кереп китә, безне җитәкләп диярлек такмак-такмазалар аланына, табышмак-мәкаль урманына, чуалтмыш-үртәвеч-санамыш чытырманлыгына, нәртмеш-үчекләвеч урамына алып китә. Әйтерсең, ул безне, аттракционда йөрткән шикелле, балалар фольклоры бакчасында йөртә. Р. Кукушкинның әнә шундый кызыксындыру, җәлеп итә алу сәләте бар. Китапта ул балалар фольклоры әсәрләрен классификацияләп кенә калмый, аны өйрәнүнең, кыскача гына булса да, тарихына да кагылып китә, тарихи күзәтүләр ясый. Аны өйрәнүгә күп көч куйган К. Насыйри, Г. Толымбай, Г. Рәхим, Г. Бәширов кебек галимнәрнең иҗатын олылап искә ала. Н. Исәнбәт иҗатына аерым туктала.

«Шигъри бишек»нең икенче бүлеге Бөек Октябрь революциясенә чаклы татар балалар поэзиясе турында. Бу бүлек тә кызыксынып укыла. Башта ук балалар поэзиясенә караган кызыклы мәгълүматларга юлыгасың. Баксаң, бүгенге буын укучылары бөтенләй белмәгән шагыйрьләр дә яшәгәннәр, иҗат иткәннәр, балалар поэзиясенә үзләреннән шактый өлеш керткәннәр икән. Г. Рахманколый, С. Рәмиев, М. Укмасый, С. Сүнчәләй, З. Ярмәки, Х. Сәлимов, И. Башмаков, С. Габделмәннан... Болар — татар балалар поэзиясен башлап җибәрүчеләр. Әлеге авторлар хакындагы белешмәләр, әлбәттә, энциклопедик характерда гына. Аларның иҗатына зуррак урын бирелгәндә дә яхшы булыр иде. Күрәсең, материал азрак булгандыр. Әмма шул чаклысы да ул чор балалар әдәбиятын күзалларга, һичшиксез, ярдәм итә. Автор югарыда саналган шагыйрьләрнең кайбер әсәрләренә дә тукталa, аларның үзенчәлекләренә кагыла, ачышлар ясый. Мәсәлән, табигать шигырьләрендә ул «олылар — балалар» дигән чикнең бөтенләй диярлек булмавын әйтеп үзә. Дәрдмәнд шигъриятенең балалар поэзиясе өчен мәҗбүри булган сурәтлелеккә бай булуына басым ясый. Чыннан да, Дәрдмәнд шигырьләрен укыганнан соң аның шигъриятенең югары поэзия булуын, андагы сурәтлелекнең балалар поэзиясендә әле булса сирәк «кунак» булуын күрербез.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай турында фәнни хезмәтләр күп язылса да, аның балалар өчен язылган әсәрләре турында махсус язылган күләмле тикшеренүләр күзгә чалынганы юк иде әле. Р. Кукушкин шагыйрь иҗатының шул өлкәсенә, аеруча шигъри әсәрләренә, иркенләп тукталa. Балалар шагыйре Габдулла Тукай. Бөек шагыйрьгә мондый билгеләмә бераз гына ябышмый да кебек. Шулай булуга да карамастан, Тукай — балаларның бөек шагыйре. Бүгенге балалар шигъриятенә, гомумән, балалар әдәбиятына нигез салучы. Ул гомере буе балалыгыннан аерыла ал-

маган: авыр бала чагы аның күңеленә җуелмаслык булып сеңеп калган. Без моны «Исемдә калганнар»дан да бик ачык күрәбез. «1912 елның апрелендә «Свет» номерларында яшәгәндә бер иптәшенә: «Каһәр суккыры, бу номердагы күселәр мине йөдәтеп бетерделәр, «чи-чи» киләләр. Алардан куркып, төн буе йоклый алмыйм. Күсе тавышларын басар өчен, песи булып кычкырып утырам»,— зарлануында да шагыйрь күңелендәге сабыйлыкны күрми мөмкин түгел». Автор китергән бу истәлектә сабыйларча беркатлылык та, фаҗига да, шаянлык та — барысы да бергә төйнәлгән. «Даһи сабый» дип атый автор Тукайны. Р. Кукушкин юлдан-юлга, биттән-биткә акрын гына, сабыр гына, ышандырырлык дәлилләр аша Тукайның бөек балалар шагыйре булуын ачу юнәлешендә эзләнә. Тукайның чынбарлыкны эчкерсезлек белән үзләштерүе олыларга атап язганда да ачык чагылуын күрсәтә. Чыннан да, автор әйткәнчә, сабыйлык рухы Тукай әсәрләренең тематикасына да килеп керә һәм бик күп балалар шигырьләре балалар өчен дә, олылар өчен дә уртак хәзинә була. Балалар шигърыятенең иң зур кыйммәте дә шунда, минемчә. Балалар шигырьләре шундый көчкә ия булмаса, Тукай иҗаты халык арасында ул кадәр киң таралмас та иде, мөгаен. Тукайның балалар шигърыятендәге бөеклеге, әлбәттә, үзеннән-үзе генә яшәми. Аның исеме телгә алынуга ук үзенә педагоглык, мәгърифәтчелек, җәмәгать эшчәнлеген һәм тәрҗемәчелекне бергә туплаган гигант күз алдына килеп баса. Бу җәһәттән, аның Сүнчәләйгә язган хатыннан китерелгән өзек гыйбрәтле: «Минем мәктәп китапларына керешкәнемне «җәл» дисең. Алай түгел. Мин мәктәпләребезне хәл теле илә миннән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын кан белән карый алмадым. Мәктәп китаплары язарга башладым. Мин язган китапларымда (әлбәттә, хрестоматия) русларның Пушкине, Лермонтовы, Аксаковы, Майковы, Плещеевы вә башка да бик күбе булып являться итәм...» Китап битләрендә Тукайның «Ана мәктүпләре» кебек педагогик язмаларын чыгаруын, балалар өчен дәреслек-хрестоматияләр төзүен, татарча балалар журналы чыгарырга хыялланып йөрүләре турында укыганнан соң, шагыйрьнең балалар поэзиясенә килү юлларын ачык төсмерли башлыйсың. Авторча әйтсәк, «болар барысы да әнә шул бер эшнең, гомум бер омтылышның төрле чагылышлары».

Р. Кукушкин Тукайның тәрҗемә эшчәнлегенә аеруча киң тукталa. Һәм юкка гына түгел, билгеле. Шагыйрьнең балалар өчен язган шигырьләренең байтак өлеше рус һәм дөнья поэзиясе үрнәкләренә таянып язылган. Ләкин ул шигырьләр инде күптән Тукайның үз шигырьләренә әйләнеп беткәннәр. Я, кайсыбыз «Бала белән күбәләк», «Мужик йокысы», «Җәйге таң хәтирәсе» кебек шигырьләрне тәрҗемә әсәрләре дип кабул итә? Әлеге тәрҗемәләрдә шагыйрьнең зур эрудициясе дә, нечкә зәвыгы да, таланты да бергә тупланган.

Китап Тукай белән тәмамлана. Дөрес, Октябрьгә чаклы балалар поэзиясен киңрәк итеп тасвирларга да булыр иде. Әйтик, шул чорда башка халыкларның балалар әдәбиятында күзәтелгән яңа күренешләр белән чагыштырып карау, шул чор вакытлы матбугатында күренгән шигырьләргә күз салу, шул вакытта чыгып килгән балалар журналы «Аң»га күзәтү, әгәр дә булса, шәһәр җире балалары фольклорын да искә алу китапның даирәсен киңәйтер иде. Ул кадәресе, бәлки китапның дәвамында булыр? Чөнки ул әле кинәт өзелә, үзеннән-үзе аның дәвамы сорала. Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Р. Кукушкинның «Шигъри бишек» китабы, гомумән, укучылар өчен дә, балалар әдәбияты белән кызыксынучылар өчен дә, укытучыларга да кыйммәтле хәзинә, күп мәгълүмат бирүче чыганак булачак. Аны укып чыкканнан соң шундый практик нәтиҗәгә дә киләсең: балалар өчен искиткеч бай фольклорыбыз бар. Нәшриятта төсле рәсемнәр белән кечкенә генә фольклор китаплары сериясе чыгарып булыр иде. Әйтик, такмаза, санамыш, чуалтмыш китаплары. Югыйсә, Нәкый ага Исәнбәт китапларын, табышмак һәм әйтемнәр җыентыкларын исәпләмәгәндә, андый китапларның бөтен чыкканы юк шикелле. Аларны башлангыч класс дәреслекләрендә дә киңрәк файдаланырга булыр иде. Элегрәк аларның кирәкләре дә булмагандыр, бәлки. Көндәлек тормышта киң кулланылганлыктан, аларга мохтаҗлык ул кадәр сизелмәгәндер. Ә хәзер алар бик кирәк.

Кыскасы, безнең шигъри бишегебез бар. Ул — исән! Гасырлардан килгән балалар шигърияте, гомумән, балалар әдәбиятын югалтмас өчен, «елатмас» өчен, шигъри бишекне тирбәтергә кирәк. Шигъри бишек тирбәлергә тиеш!

**Роберт МИҢНУЛЛИН,**
балалар шагыйре.

# ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ КУЛЪЯЗМАСЫ

Атаклы галим Шиһабетдин Мәрҗани тарих, философия, астрономия һ. б. фәннәр буенча 30 дан артык зур әсәр язган, ләкин аларны нинди чыганакларга таянып яисә алып язганын ачык күрсәтмәгән. Мондый хәл борынгы гасырлардан алып XIX гасыр ахырынача яшәп килгән һәм шактый ук традициягә дә әйләнгән булган. Шул традициягә ияреп, Ш. Мәрҗани да чыганакларны күрсәтүгә җитәрлек игътибар итмәгән. Ләкин фәнни әсәрдәге төп фикернең нәрсәгә нигезләнгәнен, яңа фикерләрнең һәм дәлилләрнең нинди чыганаклардан алынуын укучыларга күрсәтү әсәргә ышанычны арттыра һәм аның фәнни дәрәҗәсен күтәрә. Шуның өчен Ш. Мәрҗани кулланган чыганакларны эзләп табу бик зур әһәмияткә ия иде.

Ш. Мәрҗани әсәрләр язганда киң рәвештә кулланган чыганаклардан берсе Хаҗи Хәлифәнең «Җиһан-нума» дип аталган әсәре. Хаҗи Хәлифә (икенче исеме — Кәтиб Чәләби) 1609 елда Стамбулда кече хәрби чиндагы кеше гаиләсендә туган һәм үзенең үтә тырыш, үткер зиһенле булуы аркасында дин белемнәрен, гарәп, фарсы, төрек грамматикаларын һәм әдәбиятларын, логика, тарих, география, математика, астрономия, медицина фәннәрен тәпле өйрәнгән. Ул кайбер фәннәрдән дәресләр дә биргән һәм зур абруй казанган. Хаҗи Хәлифәнең тулысынча география фәненә багышланган яисә аңа бәйле булган 4 зур әсәре бар: 1. «Кәшф әз-зунун», 2. Төхвәт әлкибәр фи әсфәр әл-бихәр», 3. «Ләвәмиг ән-нур фи зулмәт Атлас минур», 4. «Җиһан-нума» — ягъни гомуми тарихи географиянең фундаменталь йомгагы. Бу әсәрләр һәм аларның авторы турында күренекле галим И. Ю. Крачковский: «Европа фәнендә алар тиешле күләмдә бәяләнгәннәр һәм без кыюлык белән әйтә алабыз: Хаҗи Хәлифә үзенең хезмәтләре белән Якын Көнчыгышның XVII гасырдагы иң зур географы булып танылган»,— дип яза. (Әсәрләр, т. 4, АН, М-Л, 1957, 624 бит). Немец тюркологы Ф. Бабингер да Хаҗи Хәлифәне — госмани төрекләрнең бөек полигисторы (яңа фәнни белемнәр таратучы — Ш. С.) дип атый, аның белемнәре барлык өлкәләргә җәелгәнлеген әйтә. (Шунда ук, 603 бит).

«Җиһан-нума» әсәрен Хаҗи Хәлифә тарихта беренче мәртәбә Европа һәм Көнчыгыш галимнәренең иң ышанычлы хезмәтләрен кулланып, 1645—1658 елларда язган һәм аны 1732 елда Стамбулда 500 данә итеп бастырып чыгарганнар.

Шиһабетдин Мәрҗани да тарих, география, әдәбият һәм астрономия фәннәрендә бик игътибарлы булган. Шул өлкәләрнең сирәк очрый торган китапларыннан нөсхәләр күчереп алган, борынгы кулъязмалар һәм фәнни китаплар җыйнаган. Аның Идел буендагы Болгар дәүләтенең батыр сугышчыларын мактап язган һәм «Шәһәри Болгар газыйлары» дип аталып йөртелгән поэмасы да булганлыгы билгеле. Ләкин Ш. Мәрҗанинның китаплары вакытлар үтү белән төрле якка сибелгән. Аларны мин дә күп еллар буе эзләдем һәм, ниһаять, 1973 елда Ш. Мәрҗанинның оныгы Габделхәмидтән калган китапханәдән 300 гә якын китап һәм кулъязма таптым. Алар Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына сатып алындылар.

Шушы китаплар арасыннан 730 битле бер кулъязма килеп чыкты. Ул XVII гасырдагы госмани төрек телендә язылган, ә бу телнең 90 процентын фарси һәм гарәп сүзләре, бары уннан бер өлешен генә госмани төрек сүзләре тәшкил итәләр. Шулар арасында V—VI гасырлардагы иске төрки сүзләр һәм җөмләләр дә еш очрый. Нокта, өтер, сорау һәм өндәү билгеләре бөтенләй куелмаган. Әйе, бу кулъязманы

уку җиңел түгел, ләкин аның эчтәлеге тарихи-географик һәм этнографик материалларга бай. Шуңа күрә аны укырга теләүчеләр, билгеле, аз булмаган. Кульъязма бик оста күчерелгән, хәрефләре яхшы танылa. Арада язылмаган битләр дә калдырылган. Алар географик карталар, глобус, компас, җир шары, таблицалар һәм Кояш, Ай тотылу рәсемнәрен сызып урнаштыру өчен калдырылган булганнар. Бу кульъязма төрле фәннәр һәм аларның тарихы белән таныштыра, шулай ук Көнчыгыш Азиядән башлап Америка илләренәчә һәр дәүләтнең ачылышын, тарихын, табигатен, халкын киң аңлата. Кульъязманың астрономиягә караган битләрендә Җир шары һәм аның хәрәкәте, күк гөмбәзе һәм андагы җисемнәр, Кояш һәм Ай тотылу сәбәпләре, шулай ук Аристотель, Птолемей, Коперник, Тихо-Браге кебек галимнәрнең әсәрләре киң яктыртыла. Урта Азиядәге Коканд, Фергана, Әсфара, Әндиҗан, Сәмәрканд, Бохара, Ташкент, Ош, Мерв шәһәрләренең төзелеш тарихлары, байлыклары киң язылa һәм Чыңгыз ханның аларны чиктән тыш талавы, җимерүе сурәтләнә.

Кульъязманы җентекләп тикшерә бару нәтиҗәсендә аның «Җиһан-нума»дан күчермә булуы ачыкланды. «Җиһан-нума» китабын Ш. Мәрҗани Сәмәркандтан Бохарага кайткач Хөсәен Каргалидан алып укыган, күрәсең. Табылган кульъязманың 670 бите Ш. Мәрҗани кулы белән язылган, ә ахырдарак 60 битен исә өченче кеше күчергән.

Ш. Мәрҗани «Җиһан-нума» китабыннан күчереп кульъязма алганда һәрбер теманы ачык күрсәтеп язган һәм кульъязмадан темаларны эзләп табуны бик җиңеләйткән. Ул чын дөньяви гыйлемнәр тупланган бу кульъязмадан зур тырышлык белән галәм тарихы, география, геометрия, тригонометрия һәм астрономия фәннәрен өйрәнгән, үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлегендә кульъязманы төп чыганак итеп файдаланган, тарихи һәм философик әсәрләр язганда аны киң кулланган. Мәсәлән, Казанда Учительская школада Ш. Мәрҗани белән бергә эшләгән Шакирҗан Таһиров болай сөйләгә: «Мәрҗани дәрес вакытларында тарихтан сөйләргә бик ярата, Габбасилар хәлифләре Һарун Рәшид, Мәэмун заманнарындагы хәлләр хакында җентекләп аңлата иде. Кайбер дәрес араларында шәкертләрнең дәфтәрләренә дә тарихи нәрсәләр язып куя. Мәрҗани, тарихны яраткан кебек, математиканы да яраткан булса кирәк: кайбер вакыт шәкертләргә тригонометрия фәненнән мәсьәләләр бирә, алар чыгара алмаса, үзе чыгарып бирә иде. Математиканы гарәп чыганакларыннан алган булса кирәк: мәсьәләне гарәп ысулы белән чыгара иде». («Мәрҗани», 128, 130 битләр). Бу сүзләр Мәрҗанинең гомуми тарихны, математиканы тирән белүен һәм яратуын, укучыларны мәгърифәтчелек белән кызыксындыруын ачык күрсәтә. Ә инде «Һарун Рәшид, Мәэмун вакытындагы хәлләр турында җентекләп аңлата иде» дигән сүзләре ислам динен, шәригать законнарын аңлату турында әйтелмәгән. Алар Мәрҗанинең укучыларга тарих, география, математика, астрономия, медицина, философия, әдәбият һәм башка фәннәрне үстерүдә Габбасилар нәселеннән булган гарәп хәлифәләре Мансур, Һарун Рәшид һәм Мәэмунның гыйльми җитәкчелек итүләре хакында. Бу мәсьәләләрне укучыларга тирән аңлатуны ул чорда Ш. Мәрҗани бик актуаль бурыч итеп санаган. Чөнки XIX гасыр уртасына кадәр Европада хакимлек иткән «европоцентризм» теориясе башка илләрне һәм халыкларны «тарихның дөрес үсү юлыннан читтә калганнар»,— дип күрсәтергә тырыша. Ш. Мәрҗани моңа катгый рәвештә каршы чыга һәм Көнчыгыш халыкларының да дөнья цивилизациясенә зур өлеш кертүләрен аңлата. Бу турыда Ш. Мәрҗани үзе дә бик ачык итеп: «Монда укучы шәкертләргә шәригатьнең тормышка һәм һәртөрле гыйлем һәм фәннәргә карашын, мөселманнарның һәртөрле гыйлемнәргә гаять бөек хезмәтләр иткәннәрен күрсәтергә тиеш күреп, шул урынны белергә уйладым»,— дип язган («Мәрҗани», 128 бит). Димәк, Ш. Мәрҗани үзе дә шәригать законнарына караганда тарихны мөһимрәк санаган һәм укучыларга да тарихи үсешне тирән аңлаткан.

Ш. Мәрҗани үзенең астрономия белән шөгыльләнүе һәм 1880 елда Стамбул галиме Сәед Гаун белән сөйләшүе хакында болай яза: «Сәед Гаун хәзрәтләре тарих, география, иске һәм яңа астрономиядән һәм һәртөрле фәннәрдән белемле, галим, олуг бер кеше. Яңа астрономия турында сүз барганда, «шул хакта бер язган рисаләм бар»,— дип хәбәр бирдем. Моңа каршы: «Казанга кайткач шул рисаләгезне һәм «Нәзүрәтелхак»ны миңа җибәрегез, вәгъдәгез булсын»,— диде. Ш. Мәрҗанинең «Яңа астрономия хакында бер язган рисаләм бар»,— дип сөйләве аның иске астро-

номияга, ягъни «Җир түгәрәк түгел һәм ул Галәмнең мәркәзе»,— дигән тәгълиматка турыдан-туры каршы чыгуы була. Бу аның яңа астрономияне — Коперникның: «Галәмнең уртасында Кояш урнашкан, аның тирәсендә Җир, Ай, Марс һәм башка планеталар әйләнәләр»,— дип аңлаткан теорияне дә дөрес тануы, үз чорының зур батырлыгы дип аңларга кирәк. Ш. Мәрҗанинең Галәм төзелешен шулай яңача аңлатуы татар халкы арасында 1870 елларда зур бәхәсләр тудырган. Кадимче муллалар халыкка фанатизм белән: «Җир яссы, ул үгез мөгезендә тора, үгез — балык мыегында, балык — диңгез өстендә, диңгез — караңгылык өстендә. Караңгылык астында тәмуг; күк үзе җиде кат, анда фәрештәләр яши, оҗмах шунда. Кояш кич белән шул караңгылыкка кереп ял итә, аның урынына Ай калкып чыга»,— дигән ялган тәгълимат аңлатканнар һәм шуның белән халыкны күктәге оҗмахка өндәгәннәр. Г. Тукай да, бу реакцион тәгълиматтан көлеп, 1909 елда «Ай һәм Кояш» дигән шигырь язган.

Татар халкының дөньяга карашында искелек белән яңалык арасында шундый көчле идеологик көрәш барган чорда астрономия буенча бәхәсләр дә бик актуаль булган. Мәсәлән, Архангельск мәдрәсәсе мөтәвәлие Мөхәммәд Гариф дигән кеше Малмыж өязе Түнтәр авылындагы Ишмөхәммәд муллага 1908 елда язган хатында: «Хәзерге мөселман мәдрәсәләрендә яңа география укыту дөрес булырмы икән?»— дип сораган. Ишмөхәммәд мулла исә моңа җавабында: «Мондый китаплар Франция алласызларының яңа астрономия буенча төзегән китапларының төрекчә яки гарәпчә тәрҗемәләреннән файдаланып язылган. Бу француз астрономнарыннан алынган китапларны тискәрелек беләнме, бераз мавыгыпмы, ышаныпмы уку кешеләрне үзләре сизмәстән үк мөселманлыктан чыгара, кяфер итә. «Вәфия» авторы Мәрҗанинең Җир һәм Кояш турысында язганнары коръәндәге бик күп аятьләргә каршы килә, шуңа күрә ул кяферләр рәтендә»,— дип язган. (Х. Хисмәтуллин. Шиһабетдин Мәрҗани. Казан, 1968, 29 бит).

Татар халкының алдынгы фикерле кешеләре үткән гасырның 70 елларында ук Мәрҗанинең гыйльми батырлыгын Галилей сыйфатларына охшатканнар, аны «татар Галилее» дип йөрткәннәр. Шулай ук Мәрҗанинең укучылары да аны «олуг галим Мәрҗани» дип йөрткәннәр һәм үзләренең аңардан белем алулары белән горурланганнар. Кайберләре хәтта аны каберләренең өстендәге ташларга да язганнар. Мәсәлән, Кәшаф мөгаллимнең ташында: «Мөгаллим Кәшафетдин бине Гыйбадулла Уфалы, ...бөек галим Мәрҗани укучысы»,— дип язылган. Каюм Насыйри да бер әсәрендә: «Бүген Болгар илендә иң галим кеше турында һәм аңа дошман кешеләр барлыгын әйтәм: галимнәрне җитәкләүче кеше — ул Шиһабетдин Мәрҗани, барлык фәннәрне, гыйлемнәрне үзенә җыйнаган, ул вакытын бушка уздырмаган, китап язу белән мәшгуль булган»,— дип яза, Мәрҗанинең төрле фәннәр өлкәсендә олуг галим булуын аңлата. Күренекле татар галиме Ризатдин Фәхертдинов та 1914 елда «Шура» журналында «Мәрҗани — Русия мөселманнарының бөек галимнәреннән» дигән мәкаләсендә аның татар халкы арасында бөек галим һәм мәгърифәтче булып танылганын тасвирлаган.

Ш. Мәрҗани киң танылган тарих галиме һәм Европа галимнәрен Көнчыгыш белән таныштырган галим. «Җиһан-нума» кулъязмасыннан алган белемнәренә нигезләнеп, ул, беренче булып: «Казан татарлары монгул татарлары нәселеннән түгел, ә Идел буе болгарларының чын варислары» дигән тарихи фикерне 1877 елда IV Бөтенроссия археология съездында чыгышында фәнни яктан ачык аңлата. Аннары ул «Мөстәфадел-әхбар» исемле тарихи хезмәт яза һәм шул әсәре белән Казан татарлары тарихына фәнни нигез салган тарих, археология һәм этнография галиме булып кәрә.

Ш. Мәрҗани Казан университеты каршында төзелгән археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив әгъзасы булган һәм зур тырышлык белән Казан губернасы районнарында тарихи, археологик, этнографик сәяхәтләрдә йөреп, татар, чуваш, удмурт, мари, башкорт, мордва, буртас халыклары турында бик күп кыйммәтле мәгълүмат җыйган, аларны үз әсәрләрендә чагылдырган һәм фәнни җәмгыятьтә рус галимнәренә дә бәян иткән. Ул Алтын урда, Башкортстан һәм Урта Азия халыкларының тарих һәм этнографияләрен тирән өйрәнгән, аларның тарихларын киң язган. Шулай итеп ул Көнчыгыш мөселман халыклары белән Көнбатыш христиан дөньясы арасындагы калын чаршауны беренче булып ача. Ш. Мәрҗани рус галимнә-

ре И. Готвальд, В. В. Радлов, С. М. Шпилевский, В. В. Вильяминов-Зернов һәм П. Н. Загоскиннар белән якын элемтәдә булган.

Ш. Мәрҗани үзенең гыйльми эшләрендә хакыйкатьне танып-белү өчен: «Акыл белән уйлап беленә торган эшләрдә, дәлилләрне файдаланып, фәкать акыл карашына таянырга; дини мәсьәләләрдә фәкать пигамбәр сүзләренә (хәдисләргә) һәм коръәнгә таянырга»,— дигән фәнни ысулын мөстәкыйль эшләп чыккан, шуны гыйльми эшләрендә үткен корал итеп кулланган. Әлеге фәнни ысул белән ул алланы — табигать тормышыннан, фәнне диннән аерган. Кеше акылын аллага буйсынудан азат итеп, акылга киң юл ачкан. Бу ысулны кулланып язган әсәрләрендә Мәрҗанинең дөньяга карашы рациональ материализм дәрәҗәсенә күтәрелгән. Дөньяны, тормышны гел үзгәрештә, хәрәкәттә күрүе исә — диалектик аңлавын күрсәткән.

Ш. Мәрҗанинең бу кульязмасы 40 ел буена дөньяви фәннәрдән иң бай чыганак булып хезмәт иткән һәм татарлар арасында фәнни белемнәр таратуда зур роль уйнаган.

Ш. Мәрҗани — Россиядәге мөселман халыкларының бөек мәгърифәтчесе һәм мәгърифәт реформаторы. Ул гомере буена иске ысул белән укытуны тәнкыйтьли һәм 1849 елда Казанда үзе мәдрәсә ачып шәкертләрне дөньяви фәннәр белән таныштыра башлый. Аннары ул җәмәгатьчелек көче белән Европа тибында мәктәп төзетә, анда парталар куеп, расписание буенча дәресләр бирүне юлга сала. Укыту дәвамында иске укыту программасыннан 5 предмет искергән дип сызыла, алар урынына 7 яңа предмет кертелә. Ш. Мәрҗани үзенең «Җиһан-нума» кульязмасыннан файдаланып, Казанда беренче булып тарих, география, геометрия, тригонометрия, астрономия, әдәбият фәннәрен укыта башлый.

Ш. Мәрҗани 50 ел буе зур тырышлык белән мәдрәсәдә шәкертләр укытып, 200 дән артык яхшы белемле укытучы хәзерләгән. Аның шәкертләреннән, мәсәлән, Шакирҗан Таһиров яңа ысул белән укыту өчен «Башлангыч укыту» исемле әлифба язган. Хафиз Шаһморадов Мәрҗани мәдрәсәсендә геометрия, математика һәм астрономия дәресләре биргән. Астраханлы Габделрахман Исмәгыйлов тарих һәм башка фәннәрдән уку китаплары язган, җиде ел дәвамында «Идел» газетасын чыгарып килгән. Хыялетдин Хөсәенов һәм Хәбибәннаҗар Мөхәммәдов шулай ук яңа ысул белән укыта башлаганнар һәм тарихтан, әдәбияттан дәреслекләр язганнар. Хөсәен Фәезханов тарих һәм көнчыгыш телләре галиме булып Петербург университетында эшләгән. Аларның һәммәсе тарих, география, геометрия, тригонометрия, астрономияне Мәрҗанидагы «Җиһан-нума» кульязмасыннан өйрәнгәннәр һәм аерым бүлекләреннән үзләренә конспектлар язып алганнар. Мәсәлән, Биектау районы Олы Кавал авылыннан Гобәйдуллин Әхмәтзәки аганың Мәрҗани мәдрәсәсендә шәкерт вакытында язган дәфтәрендә: «Хисаметдин бин Шәрәфетдин 992 елда язылган шул рисаләсендә әйтәдер: Мөхәммәд пигамбәр гасырында Болгарга сахабәләр килеп, Болгар халкын исламга китерделәр,— дип. Әмма Кәтиб Чәләби «Җиһан-нума»сында әйтәдер: Бу таифә Габбасилар гасырында динне белү белән исламга килделәр,— дип әйтәдер». (Бу сүзләр һичшиксез Ш. Мәрҗанинең Хисаметдин Мөслими язган «Тәварихи Болгария» китабын тәнкыйтьләгән сүзләре, ә ахыргы җөмлә «Җиһан-нума» кульязмасының 374 битеннән күчерелгән). Бу дәфтәрнең икенче битендә: «Мәккә шәһәре икенче икълимда озынлык 70 градус, киңлеге 21 градус 40 минут. «Җиһаннумадан»,— дип язган. Димәк, Мәрҗани мәдрәсәсендә «Җиһан-нума» кульязмасы буенча астрономияне шактый тирән, хәтта шәһәрләрнең координатларын билгеләүгә кадәр өйрәткәннәр. Әхмәтзәки аганың бу дәфтәрендә тагын шундый алты өзек «Җиһан-нума»дан алып язылган.

Югарыда китерелгәннәрдән шул ачык аңлашыла: тарих, география, геометрия, математика, астрономия фәннәре Ш. Мәрҗани тырышлыгы һәм кыюлыгы нәтиҗәсендә 1849 елда Казанның 1-мәхәллә мәдрәсәсе шәкертләренә беренче мәртәбә ишетелә башлый. 30—40 елдан соң бу фәннәр башка мәдрәсәләргә дә күчә. Ә инде 50—60 елдан яңа ысул белән укыту кадимчә укытуны җиңә һәм Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия мәдрәсәләрендә дә гамәлгә кертелә. Хәтта Ташкент шәһәрендә «Мәрҗани мәктәбе» исемле мәктәп тә ачыла һәм 1930 елгача эшләп килә. Шуның нәтиҗәсендә яңа ысул белән укыту халыкларда дөньяга яңа караш тәрбияли, аларның күңелләрендә яңалыкка омтылыш тойгысын көчәйтә. Бу процесста Шиһабетдин Мәрҗанинең «Җиһан-нума» кульязмасы да зур роль уйный.

**Шамил САФИН.**

# МИН ТУКАЙГА ЫШАНАМ

Габдулла Тукай үз тормышы турында язган «Исемдә калганнар» әсәрендә болай ди: «Минем анамның анасы булган үз әбием (Камилә әби — Х. З.) әни кыз чактук үлгән булганга, бабай (Зиннәтулла бабай — Х. З.) кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны (Латыйфаны — Х. З.) ияреп килгән алты баласы илә алган булган.... Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам — юатучы, иркәләнәм дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә — кызганучы бер дә булмаган, мине этkәннәр дә төрткәннәр... Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Сәҗидә исемле кыздан башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип кенә караганнар».

Моның өстенә тагын шуны да онытмаска кирәк: 1903 елның 30 июнендә апасы Сәҗидәгә язган хатында Г. Тукай болай ди: «...Бабайлар өендә бәңа мәрхәбәт күзе илән караучы юк иде, мәгәр син бар идең... Җәберләренең җәрәхәте җәннәте гаденгә керсәм дә йөрәгемнән китмәс». Әйтелгән алты «күгәрченнәр»нең исемнәре билгеле. Аларның берсе, Тукайга зур шәфкать белән караганы, шагыйрь фәрештә дип таныганы — Сәҗидә апа (Бибисәҗидә). Калганнары, Габдуллага «ичмасам чәнчелсә иде» дип караганнары, җәннәткә керсә дә йөрәгеннән китмәс рәвештә шагыйрьне җәберләгәннәре — Гандәлип (иң олысы), Гөлҗәһрә, Кәбир (Кәшфелкәбир), Кашфинур һәм Шәмсемөнир. Хәзер боларның берсе дә исән түгел инде. Тукайның язуларына караганда, (шагыйрьгә ышанмыйча булмый) Латыйфа әбинең ияреп килгән алты баласының («күгәрченнәренең») шагыйрьнең анасы Мәмдүдәгә кан ягыннан туганлыгыгы булмаган. Аларның Мәмдүдә белән аталары да башка, аналары да башка булганнар. Бу турыда Тукай ачыктан-ачык, турыдан-туры, һич бер шик һәм бәхәскә урын калдырмыйча язып калдырган. Шулай булуга карамастан, хәзер ул алты бала Мәмдүдәнең кан туганнары, аларның аталары бер, аналары гына башка дигән риваять күп кенә китапларга кертелде (Тукайның фотоальбомнарына, 4 томлы әсәрләренә һәм башка китапларга). Нигә алай? Тукай үзе дөрес язмаган, хата язганмыни? Ничек инде белмичә, тикшермичә, мәсьәләне ачыкламыйча Тукайның язуларын хаклы түгел дип чыгарырга? Югарыда әйтелгән риваять нинди документлар, нинди архив язулары белән дөресләнгән? Ул риваятьне дөрескә чыгара торган материалларның булуы бик шикле. Тукай үзенең «Исемдә калганнар»ын 1909 елның 29 сентябрендә язган. Ул елларда Тукай яхшы танылган, күпне күргән, күпне белгән шагыйрьләрдән була. Ул Казанга кайтып (1907 елда) кирәкле материаллар җыеп, күп кешеләр, шаһитлар белән очрашканнан соң гына үзенең «Исемдә калганнар»ын язган. Тукай белмичә, тикшермичә, мәсьәләне ачыкламыйча язмас. Шагыйрь үзенең Шәрифа карчыкта торган көннәрен дә белмичә, тикшермичә язмаган. Шагыйрьнең язуларына караганда, ул авылларга барган, күп хатыннар, карчыклар белән очрашкан, сорашкан, мәсьәләне ачыклаган. Фәкать шуннан соң гына язган. Казанга кайтып Тукайның очрашкан кешеләре арасында бабасы Зиннәтулла һәм Латыйфа әбинең балалары да була (Сәҗидә, Кәбир һәм башкалар). Аларның да Тукайга кирәкле материаллар биргәненә бер дә шикләнеп булмый. Зиннәтулла хәзрәт, Кәбир мулла да үз вакытында Тукайның «Исемдә калганнар»ын укымыйча калмаганнардыр. Әгәр Тукайның язуы дөрес булмаса, алар шул елларда ук каршы чыгарлар иде. Әмма Тукай хаклы булганга күрә алар шагыйрь исән чагында бу язуларга каршылык күрсәтә алмаганнар. Фәкать шагыйрьнең һәм башка шаһитларның вафатыннан соң гына Латыйфа әбинең «күгәрченнәре»нә карата булган риваять (Тукай язуларына каршы

риваять) килеп чыга. Тукай язганны аклау һәм дөресләү өчен архивлардан тиешле материалларны эзләргә кирәк. Бу мәсьәләне әдәбият белгечләре ачыкламый калмас, әлбәттә. Минемчә, Тукайның үзенә ышанырга кирәк. Мин Тукайга ышанам. Хәзер хәлләр шул дәрәҗәгә килеп җитте: Тукайны бала чагында йөрәгеннән китмәс рәвештә каһәрләгәннәре, газаплаганнары (Кәбирне һәм башкаларны) күтәреп чыгып, хөрмәтләп, рәсемнәрен җыеп, үзләренең һәм туганнарының шәҗәрәләрен төзеп игълан итәләр. Бу хәл шагыйрьнең истәлеген хурлау, мәсхәрәләү түгелме? Тукай сүзләре белән әйткәндә алар барысы да Тукайга ятлар: «бу Миңгали, Бикмулла кем? Бикмөхәммәт, Биктимер — берсен дә белмим әллә кем!»нәр. Нигә кирәк алар белән шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен чуплəргә?

Тукайның тормышы хәзер тарих булып калды. Тарихның пакъ, керсез, чүпсез булырга тиешлегенә беркем дә каршы булмас. Тукайның тәрҗемәи хәлен төрле чүпләүләрдән сакларга кирәк. Кайберәүләр Тукайны 1911 елда Кәбир мулла Өчиледә кабул иткәнен искә алалар. Әйтегез әле, 1911 елда мәшһүр шагыйрьне, Тукай хәтле Тукайны кем генә кабул итмәс иде? Шагыйрьне Акчурин, Петербург байлары да кабул иткәннәр, Оренбурга да Рәмиев алтыннары белән тартырга тырышканнар.

Өчилегә Тукай буш кул белән бармаган. Шагыйрь юмарт кешеләрдән була. Шул көннәрне ул үзенең киез итеген дә авылда күрше малаена бүләк итә. Вафатыннан соң Тукайның 500—600 сум чамасы акчасы кала. Ул акчаларны да кем алды икән? Бу эштә «күгәрченнәр»нең катнашы булуы мөмкин. Моны да тикшерү урынсыз түгел.

Зур кешеләрнең тормышында вак-төякләр булмый, диләр. Тукайга карата да әйтергә була: аның тормышының һәр вакыйгасы, детале — безнең өчен кыйммәт, мәгънәле һәм изге. Аларны ачыклап бетерергә тырышу кирәк.

**Х. ЗӘБИРОВ.**

# ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

Шәйхи Маннур белән без 1926—27 елларда таныштык. Белоруссиядә кызыл кавалериядә хезмәт иткәндә ул миңа берничә хат язган иде. Яхшы хәтерлим, «Кызыл яшьләр» газетасын соратып язган. Анда тәнкыйтьче Гомәр Галинең Шәйхи турында мәкаләсе урнашкан иде. Бу инде калын журнал — «Безнең юл» редакторының яшь шагыйрьгә ышаныч һәм өмет баглавын күрсәткән кечкенә генә бер дәлиле дә булды. Хәтерем ялгышмаса, бу мәкалә-рецензиядә «Бозлар актарылганда» поэмасы һәм «Соңгы рәсем белән соңгы хат» шигырьләренә тәнкыйть сүзләре әйтелгән иде. Ул чорда бу поэма яшь шагыйрьнең иң зур язмасы булды. Тик нинди генә фикер әйтелмәсен, Маннур үзе «Бозлар актарылганда» дигән поэмасының чын вакыйгаларга нигезләнгәнен бик еш искә ала иде.

Шәйхи белән кара-каршы килеп очрашуларыбыз бер дә онытылмый.

1969 елның апрель ае. Кич. Ара-тирә шахмат фигураларын күчергәләп, өстәл янында утырабыз. Озак кына гәп сугып та алабыз.

— Мин Габдрахман Әпсәләмовның бер ягын мактыйм. Ул миннән яшьрәк булса да, аңардан үрнәк алырга кирәк,— диде шагыйрь.

— Нинди үрнәк?

— Ул язмасын нәшриятка тапшырганчы, башта гади укучыларга биреп укыта. Аларның фикерләрен белә, замечаниеләрен тыңлый. Шунда әйбәт сүзләр дә ишетә. Кульязмасына төзәтмә кертә. Аннан соң гына матбагага бирә. Дөрес бит, ә? (Биредә Шәйхи «Яшел яр»ны кайбер укытучылар укуын күздә тота иде.) Әпсәләмовның тырышлыгын, бирелеп эшләвен шагыйрь мактап сөйләде. Әйтергә кирәк, ул үзе дә чокчынырга бик ярата иде. Кырыслыгы да җитәрлек иде. «Кеше калын түгел, бүрәнә калын, кеше юан. Тәринкә түгел, тәлинкә. Кеше кечкенә дә түгел, карсак та түгел, кеше бәләкәй!» Инде мишәрчәрәк кыланып: «Кодаем, кацан мин сине татарца сүләргә өйрәтермен, әдә, ход яса» — дип тә җибәргәли иде.

Әмма үз адресына тәнкыйть сүзләрен авыррак кабул итә, суга чумса да коры

чыгарга тырыша торган гадәте дә бар. Драматург Риза Ишморатка «Муса» романындагы Абдулла Алиш образы ошап бетмәгән. «Примитив язылган, тарайтып тасвирланган. Тулы канлы, мул, үткенрәк хисле итеп бирә алмагансың» дигән (төп мәгънә шундыйрак). Шәйхи шунда геройга, каһарманга кайта төшеп болай диде: «Муса да, Алиш та — корбан. Алар вафат. Гильотинадамы, атыпмы, асыпмы — авторга аның әһәмияте юк. Төп сызык, образлар дөрес». Ул түземсезлек белән Муса турында яңа әсәр чыгуын көтте. Тел төбеннән бераз шикләнүе дә сизелә иде. Кем белә бит, бәлки бу романны бәреп егар! Көткән әсәр дөнья күргәч: «Әпсәләмов үз юлында, мин үз юлымда. Каршылык та, кабатлау да юк» — дип тынычланды. Мин үз нәүбәтемдә «әсәрең яхшы, вә ләкин калынрак, китап юкарак булса да зыян итмәс иде» дигәч: «Болай да йөзләгән битен төшердем» диде. Бу романның рус телендә тәрҗемә ителүен, дөнья күрүен теләде. Тәрҗемәче табалмавы турында зарланды. Кайбер иптәшләргә үпкәләү дә белдерде. Ниһаять, «Муса» рус телендә дә басылып чыкты. Тик автор үзе күрә алмады. Ана телендә нәшер ителгәне, калын китап булуга карамастан, отышлырак, милли бизәкләр, тапкыр сүзләр, уңышлы җөмләләр хисабына җиңелрәк, йөгерегрәк укыла.

...Язучылар — кызык кешеләр. Шагыйрь булып әдәбият дөньясына килеп керәләр, прозаик әдип булып гомерләрен чиклиләр. Кави Нәҗми, Фатих Хөсни һ. б. Маннур урталыкта калды, прозага картая төшкәч күчте. Ләкин үзен аяк терәп, шагыйрь дип атады. Урталык дигәч, аның дөньяга, табигатькә карашын, үз фәлсәфәсе булуын әйтеп үтәсем килә. Без диннәр, табигать һәм фән турында сөйләшәбез.

— ...Мин бер дингә дә ышанмыйм. Аларны уйлап чыгарганнар. Фән өстен тора. Тик мин табигатьнең шундый рациональ булуына, ялгышмавына сокланам. Ни өчен табигать ялгышмый? Мин шуның серенә төшенә алмыйм. Нинди көч управляет? Кайда ул көч? Ни өчен һәр нәрсә үз урынында? Ни өчен камил, төгәл? Әгәр дә фән тагы да бер планетада тереклек барлыгын исбат итсә, һәм элемтәгә керсә, мин фән алдында башымны иям,— диде шагыйрь.

— Айга мендек бит.

— Ул азрак, ул гына җитми,— дип өстәде.

Бу юллар, бу сүзләр аның күп төрле үзгәрешләр турында үз фәлсәфәсе, үз фикерләве иде. Җитди булу белән бергә Шәйхи вакыт-вакыт шаяртып алырга да онытмый иде.

Бер вакытны ул кунак итеп берничә иптәшне «Парус» ресторанына чакырды. «Кызлар була, матуррак киенеп килегез» диде. «Акча?» дидем. «Кайгырма акча байдан, үлем ходайдан» диде көлемсерәп.

Бу чакыруны без бик теләп кабул иттек. Ресторанга барасы булгач, өйдә ашамадык та. Киендек-ясандык, хушбуйлар сөрттек. Читләр алдында сынатасы килмәде. Бардык, өстәл тирәли тезелдек. Көтәбез. Хуҗа юк. Ак тастымалын беләгенә салып официантка килде. «Пожалуйста, что Вам»,— диде, карандашын, блокнотын алып. «Хәзер, хәзер, бер иптәшебез килергә тиеш» дидек, рәхимле күренергә тырышып. Ишек төбенә чыгабыз, тәрәзәдән карыйбыз. Бер зат та күренми. Байтак утырдык. Нәтиҗәдә официантка түзмәде, «торыгыз, өстәлне бушатыгыз!» диде.

Күңелсез кайттык. Хуҗаны таптык, Ленин бакчасында кызарынып, бүртенеп шахмат уйнап утыра. «Монда корольнең хәле начар әле, Хәмзин. Әй, әйт әле бер яхшы ход!» диде.

Күңеле көр чакта, хозур минутларда ул шулай шаяртып алырга ярата иде.

— Шахматны син шәп уйныйсың, шундый оста итеп хикәя дә язсаң, мин сиңа бүләк итеп зур бер шоколад бирер идем! — диде миңа бер чакны.

1969 ел. 31 декабрь. Шәйхи миндә кунакта булды, кунды. Төрле сүзләр арасында «онытылган» әдипләрне дә искә алдык.

— Карале, Шәйхи, М. Галәү дигән бер язучыны Дорохово дигән ял йортында очраттым, Мәскәү янында. 1931—32 еллар иде бугай. Нигә ул тынды? Нигә күренми? — дидем мин. Күп сөйләде кунак. Хәтердә калганнары болар.

— Мәхмүт Галәүне мин яхшы беләм. Мәскәүдә Мәхмүт абзаң белән икē ел бергә эшләдек. Артык якыннан аралашмадык. Исәнлек-саулык сорашудан узылмады. Икебез дә тыйнак булдык. Ә син беләсеңме, ул бит хәзрәти Шиһап Мәрҗани нәселеннән иде. Чыгышы — зыялы, укымышлы тамыр... Ул — талантлы язучы. Рәхмәт

русларга. Аның иң зур әсәрен башлап рус нәшрияте бастырды. Мәхмүтнең әсәрләре яхшы. Әдәбиятта урын алырга хаклы,— диде шагыйрь.

Ул иске мирасны барлау, кайтару, яңарту, әрәм-шәрәм итмәү ягында иде. Үзе ярлы крестьян, ярым ятим булып үссә дә, шахтер булса да, берәүнең дә чыгышына карамыйча, әсәренә карап үз үлчәве белән үлчәде.

1970 ел. 15 январь.

Маннурга 65 яшь. Берничә иптәш шагыйрьнең фатирында туган көнен бәйрәм итәбез. Өстәлдә иң кәттә ризыклар. Әмма тәлинкәләр җитми. «Ялгыз кешенең шулай инде»,— дип, сөйләнеп күршедән тирән тәлинкәләр алып чыкты. Өстәл тирәсенә утырыр алдыннан без бүләк бирдек.

— Рәхмәт олылавыгызга, әнә шул почмакка, портрет янына куегыз,— диде. Почмак ярым караңгы иде. Бичара бүләкләр шул урында тыныч кына гомер иттеләр. Байтак еллардан соң аңа тагын зур телевизор бүләк иттеләр. Телевизор картон әрҗәдә иде. Һәм шул килеш өйнең бер почмагында идәндә айлар, еллар буе торды.

— Бу ни хикмәт, сөйләтергә, карарга кирәк, Шәйхи,— дидем мин бер көн аңа.

— Юк, вакытны күп ала. Урыны әйбәт, ашарга сорамый, ятсын,— диде.

Маннур пөхтәлекне ярата иде. Машинкага бирергә әзерләнгән кульъязмасында ике-өч урында төзәтмә булса, ул аны яңадан акка күчерә, бер генә тап та булмасын. Кайбер шаяннар: «Шагыйрьләргә илһам төнлә генә, кеше йоклаган чакта килә» диләр. Шәйхинең расписаниесе исә үзгә булды. Ул иртәнге сигезгә кадәр йоклый. Торып вак-төяк эшләрен бетергәч, сәгать уннарда тәрәзә каршындагы кухня-аш өстәле янына утыра. Ишектәге звонокка игътибар итми, телефон трубкасына оныткандa бер тотына. Кичке дүрткә, бишкә чаклы йомылып яза. Аннан: «Ай, соңга калдым ахры» дип, татар ашлары йортына төшке ашка чаба. Кайбер хадимәләр аның киләсен беләләр, токмачлы-калҗалы ашны барыбер табып бирәләр.

Көндез утырып эшләвенең сере гади: ул соңгы елларда профессионал язучы иде, рәсми учреждениеләрнең хезмәткәре булмады. Вакыт күп, мәшәкатьләүче юк, рәхәтләнеп яз да сыз, яз да сыз! Шулай тынычлыкта яшәп, ялгызлыкка да иялəште.

Шәйхидә ораторлык куәсе зурдан түгел иде. Әмма аргумент, исбатлау чаралары көчле. Бер вакытны ул үзенең якын бер дустына фәннәр докторы исемен яклау өчен оппонент (яклаучы) булып Алма-Ата кадәре ерак калага бара.

— Озак сөйләдеңме? — дип сорадым мин аннан кайткач.

— Бер дә сөйләмәдем, каршы чыгучы булмады, мин запасной гына идем,— диде.

Шәйхинең сөйләшүендә дә, әсәрләрендә дә юморга караганда, михнәт, авыр кичереш чалымнары күбрәк була иде, яшь чактагы үгилек тә, акчасызлык та, ана җылысыннан мәхрүмлек тә үз тамгасын салган булса кирәк. «Агымсуларга карап» дигән повестьта бу кыенлыклар образлы рәвештә бирелә. Автор үзе дә аңа мөһим әсәр итеп карады.

— Ни өчен «Агымсуларга карап» дигән тарткылы-сузгылы исем бирдең? — дидем мин.

— Агымсу — ул минем тормышым, ул минем үткәнем, ул минем елларым, ул минем гомеремнең өзлексез үтеп торуы. Мин аның нинди баскычлар, нинди киртәләр, нинди сукмаклар буйлап туктаусыз агуын бүгенге биеклектән, чал башлы тау өстенә басып карыйм. Шуны күзәтәм һәм шатланам да, көрсенәм дә. Әйе, гомер агып, агылып уза ул.

Җәйге кичләрдә Шәйхине күрергә теләсәк, аны Ленин бакчасыннан, зур тирәк төбендә, яшел эскәмиядә бер төркем шахматчылар арасында таба идек. Шахмат — аның иң яраткан уены булды. Җиңелергә һич яратмый. Кәкре сукмактан барса да җиңәргә тырыша. «Әй, әй, туктале, бу хутымны кире алыйм әле». Ә син кире алырга теләсәң: «Йөрдеңме?! Закон джунгли. Бала булма»,— ди. «Соң үзең кире алдың ич!» «Юк, мин төзәттем генә, давай, тотканыңны йөр».

Ленин бакчасыннан, ә кышларын шахмат клубыннан иң соңгы чыгучы, әлеге дә баягы шул Маннур иде. Яшьрәк чакта икенче уены бильярд булды.

Инде, «шагыйрь нindирәк кеше иде?» дип, конкрет сораучыга, югарыда әйткәннәргә өстәп, кыска гына итеп, картларча җавап бирергә туры килә: Яхшы кеше иде. Инсафлы, игътибарлы, кунакчыл, партияле, Ватанчы, тотнаклы һәм таләпчән әдип иде ул.

**Касыйм ХӘМЗИН.**

# ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНЫҢ КӨЛКЕ КАПЧЫГЫННАН

*Бөек Ватан сугышында безнең социалистик җәмгыятьнең какшамаслыгы, партиябез һәм халыкның бердәмлек көче, Тын океан ярларынача сузылган тылыбызның бетмәс-төкәнмәс резервлары һәм, ниһаять, Совет кешеләре һәм Совет солдатларының һәрвакыт иң зур хәрефләр белән язып кабатларга лаек булган рухи көче җиңде.*

*Юк, тарихта моңарчы тиңе булмаган кыю һөҗүмнәрдә һәм атакаларда, кыскасы, сугышның чиксез-чамасыз авыр хезмәтендә генә сыналмады, ә вакытлыча җиңелү һәм чигенүләрнең, зур югалтуларның коточкыч авыр минутларында да сыналды бу көч. Җиңүгә тирән ышаныч, төшенкелеккә бирелмәү, җор һәм оптимист булып кала белү, бер-береңнең күңелен күтәрергә әзер булу да яу кырларында җиңү коралы иде.*

*Кайчан һәм нинди бүтән армиядә булганы бар Василий Теркин шикелле зирәк, куркусыз, һәрвакыт юмарт елмаюлы һәм үткен телле сугышчының? Ә андыйлар күбәү иде. Аларның елмаеп-көлеп тә дошманны кыйнаганнарын раслап, без журнал сәхифәләребездә дистә еллар буе инде хәрби темага «көлке капчыкларыннан» әледән-әле материаллар тәкъдим итә килдек. Менә бу санда да шундый туплаонма бирелә.*

## Безнең һөҗүмнәрдән соң

* * *

1943 елның көзендә безнекеләр фашистларны Азов буе далаларыннан куа. Фашистлар өере төялгән бер машина зур авыл уртасына кереп туктала. Тирә-юньдә җан иясе күренми. Аулак тыкрык башындагы бүрәнәләр өстендә колакка катырак, күзләре ярымсукыр бабай утыра икән. Килмешәк узгынчылар шунда туктала да:

— Бу авыл ничек атала? — дип сорыйлар бабайдан.

— Нәрсә кирәк дисезме?

— Авылыгызның исеме ничек? — дип кычкыра русча бераз сукалый алганы.

— Ә, авылның аты?! Партизан аталабыз. Күптән инде. Буденный заманнарыннан ук Партизан.

— Партизан?.. Партизан?! — дип пышылдаша машинадагылар. Һәм... мотор каты гүли башлый да, куе тузан күтәреп, машина тиз-тиз китеп бара.

Күрәсезме, матур исемле авылда тору ничек әйбәт икән бит!

* * *

— Сезнең партизаннар кайсы тирәдәрәк? — дип сорый немец автоколоннасы начальнигы бер колхозчыдан.

— Кем белгән аны, пан. Кайдыр урмандадыр инде...

— Ә урман еракмы?

— Ничек аңлатыйм икән? Минә шул юл белән туп-туры барасыз, ә авылны чыккач елга һәм күпер булыр. Әйиеме. Әгәр шуның аша чыгалсагыз, аллага шөкер диегез, әгәр чыктым юк икән — партизаннар белән очрашу шул үзе була инде.

*
* *

— Белдерергә рөхсәт итегез, пан генерал... Автоматчылар бер рота солдатны кырып салды.

— Хайль Гитлер! Командирны бүләккә тәкъдим итегез.

— Моныһын һич эшләп булмый, пан генерал.

— Ник?

— Чөнки рота — безнеке, ә автоматчылар — совет солдатлары иде.

*
* *

Җәза отряды партизаннарны «ауларга» килә. Урманда немецлар күке кычкырганны ишетәләр.

— Күке, күке, мин күпме яшәрмен? — дип санатмакчы бер фриц.

— Минем пулям очып барып тигәнче,— дип тамак төбе белән кычкыра имән башында утырган «күке» — снайпер.

*
* *

1944 елда өченче Империядә бөтен ирләрне армиягә рәттән алалар. Яше житмештән узган Карл Сукенцукс та фронтка китерелә һәм ул Карпат тауларында оборонага урнаштырылган бер ротага эләгә.

Менә алар текә биеклектә: менеп-төшеп йөрүләре чамасыз кыен — түбәнгә я шуасың, я бөтенләй тәгәрәвең мөмкин...

Шул биеклектән төшеп качар минутлар да килеп җитә. Рота командиры Карлга карап тора-тора да кинәт учы белән маңгаена сугып ала:

— Эврика!

Аннары янына ике солдат чакыра һәм әлеге Сукенцуксны биеклекнең бик шома җирләреннән генә култыклап түбәнгә төшерергә куша. Шулай итеп түбәнгә иң алдан «Грос-фатер» озатыла. Бүтән солдатлар үзләре исән-имин төшә алалар. Ничек дисезме? Карл Сукенцукс койган... ком бәләдән коткара һәм рота командиры аны Тимер тәре ордены белән бүләкләргә тәкъдим итә. Ләкин соңыннан командирлар бер нәрсәне уйлап аптырарга тиеш булалар: бу орденны кая тагып йөртергә соң? Фюрерны күкрәк белән яклаган орден урыны — әлбәттә күкрәктә... Бу очракта бит күкрәк белән яклау булмады?![1]

*
* *

Майор фон Гольц Днепр ярында басып тора.

— Гей, син! Кем әле?.. — дип сорый ул бер авыл кешесеннән.— Кай төш була бу? Нинди шәһәр тирәсе?

— Бирелә,— ди мужик,— нәкъ менә син торган урында, кайчандыр князь Владимир Киев кешеләрен чукындырган.— Аннары ул, як-ягына караштырып, якында беркем дә юклыгын белгәч, өсти икән:

— Ә әнә теге уйсулык тирәсендәрәк 1918 елда Киев кешеләре немецларны чукындырды... Менә шулай! — Һәм, бергә укмаштырылган өч бармагы белән майорны чукындырган итә дә, аны биек ярдан түбәнгә мәтәлдерә.

---

[1] Украин сатиригы Остап Вишня язмаларыннан.

• • •

Немец генералы безнекеләр һөҗүменнән качып барышлый полковникка кычкыра:

— Дәрәҗәсе үзеңнекеннән олырак кешене узып чабарга нинди хакың бар синең?

— Гафу итүегезне үтенәм, пан генерал,— ди полковник туктап та тормыйча,— әнә күрәсез ич минем полк пленга бирелә, ә мин, аның командиры буларак, үз солдатларым белән бергә булырга тиешмен.

• • •

«Исән калган яки яралы немецлар әсирлеккә кабул ителә. Эш сәгатьләре — тәүлек буе!»

• • •

— Ничек уйлыйсың, Ганс, Днепр бик тирән елгамы икән?

— Минемчә шулай булырга тиеш... Чөнки моннан өч көн элек безнең батальон чумган иде һәм... әле һаман калкып чыкканы юк.

• • •

— Ник кулларыңны күтәрдең, Вшивке? Соңгы солдаткача каршы торырга кушылган иде бит!

— Соңгы дигәне менә шул мин булам инде, пан фельдфебель. Ә рота моннан бер сәгать элек әсирлеккә бирелде бит.

• • •

— Рота командирын телефонга чакырыгыз әле. Ашыгыч сөйләшәсе бар

— Пан полковник, ул сөйләшә алмый.

— Нинди дә булса эше бармы әллә?

— Юк, телдән язды...

— Ничек?

— Бүген совет снарядлы шулай миңгерәтте.

• • •

Полковник фон Гоп-Скок бер обер-лейтенантның итекләрен дә салмыйча ятканын күрә.

— Ник чишенмәдең? Гигиенаны оныттыңмы әллә?

— Эш анда түгел, болай кулайрак: батальоныма караганда үз аякларыма ышана төшәм мин...

• • •

— Ишеттеңме, Фриц, бүгенге көннән башлап безнең баш командующий Гитлер үзе булачак.

— Әйтәм без бүген чигенеп кичәгегә караганда озаграк һәм ераграк чаптык

## Хатлардан юллар

*

* *

«...Сталинград кышы чамасыз салкын булган диләр. Дөресме, Фрицман?»

«...Андый тәмуг утларында тирләп-пешәргә, янып-көяргә янадан язмасын иде...»

*

* *

«...Командирыбыз полковникның тиресе дә коры сөяге генә калды инде. Ә полкның яртысыннан сөяк тә калмады...»

*

* *

«...Сез инде советларның шул хәтле жирен басып алгансыз, хәтта аны нишләтергә дә белмәссең?!»

«...Киресенчә, иркәм, бу жирләрдә үзеңне нишләтергә белмисең, инде бары жир астында гына урын калып бара кебек...»

## Хәрби хезмәткә алганда

*

* *

Бөкресе гәүдәсеннән дә зуррак булган бер бабайны карый врач.

— Минем кебек гарип-горабаны да фронтка жибәрергә ниятлисезме әллә? — дип сорый бичара карт.

— И жанкисәккәй, рус жирендәге кабер мондый гына бөкреләрне бик тиз турайта ул! Әллә шуны да белмисеңме әле? — ди аңа врач.

— Отто Шмюцке, солдат. Бәкәле каймыккан. Кызу атлап яки чабып руслардан качалмый. Сафта калдырырга.

— Ганс Трипке, ефрейтор. Кулларым сызлый, ди. Төннәрен йоклый алмый икән. Утта пешкән булып чыкты: куллар, чыннан да күтәрелә ала торган түгелләр. Димәк, теләсә дә пленга бирелә алмый. Күзәтү постына куярга ярый.

*

* *

— Сезгә ничә яшь?

— Ни бары белән, офицер әфәнде, инде артыгы булмастыр...

*

* *

— Карале, Отто, син уң кулсыз бит. Ничек армиягә алсыннар ди?

— Аның каравы аякларым таза-сау минем. Ә Көнчыгыш фронттагы хәзерге шартларда тиз йөгерә алу — зур бәхет ул.

## Немец мәктәпләрендә

*
* *

— «Чигенү» сүзен берлектә һәм күплектә төрләндер әле, Пупке!
— Мин чигенәм, син чигенәсең, без чигенәбез...
— Ә алар?
— Ә алар... һөҗүм итә.

*
* *

— Тагын буталчык җавап бирдең бит, Швейдер. Кайчан төпле уйларга өйрәнерсең икән син?
— Уйлый белүнең миңа кирәге булмаячак инде, кадерле укытучы әфәндем.
— Ник алай дисең?
— Бер атнадан мине сугышка алалар. Минем өчен фюрер уйларга тиеш була.

*
* *

Әйтегез әле, кадерле мөгаллим: Сталинград урамнары бик озыннар маллә?
— Ник моны сорыйсың әле син?
— Фронттагы абыем Курттан кичә хат алдык: «Дивизиябез бер урам буйлап инде ай буе уза, ә аның очы-кырые һаман күренми әле...» дип яза.

## Теркинча әйтсәк...

*
* *

— Син фашистлар белән ничек сөйләшәсең?
— Өч телдә: я пуля тидереп, я граната ыргытып, я штык кадап!

### Такмаклар тезмәсеннән

Такмак дибез, такмак дибез,
Такмак түгел, тукмак ул —
Көн-төн безнең сафта йөри
Фашистларны тукмап ул.

Суларга кармак салабыз,
Кайтабыз балык белән.
Халык гаскәр белән көчле,
Ә гаскәр — халык белән.

Иген яндырды фашистлар
Һәм ут төртте өйләргә.
Инде суыкта биилләр
Без уйнаган көйләргә.

Повар юри сорый миннән:
«Кем ул Адольф Гитлер?» дип.
Мин әйтәм: «Суйсаң итен дә
Эт ашамас эттер!..» дип.

## Бару... һәм кайту

*Белорусчадан*

«Мәскәүләргә юл аласың»
Дип әйттеләр фрицка.
«Димәк, потлап сало була,
Мае, балы — бер мичкә.

Миңа да җитәр анда мал
Һәм гаиләм өчен дә.
Барып та җитәрбез бәлки
Ике-өч көн эчендә!..» —

Зур хыялга чума, бөтен
Дөньясын онытып бирән.
«Мәскәүне инде үземнең
Җәннәтем итеп күрәм...»

Чү, ни булды? Төсе китеп
Ник калтырый башлады?
Юл буенда аунап ята
Үле фриц башлары.

Мәскәү якынайган саен
Башы иелә бара.
Кара тәреле «Тигр»лар
Тау-тау өелә бара.

Салкын окопларда яту
Аны хәйран калдырды.
Ярый әле бер мужикның
Иске тунын салдырды.

Һәм... Кинәт яшен балкыды.
Һәм... Кинәт күк күкрәде...
Күз алларын караңгылап
Аяк асты тетрәде.

Эшелон кайта Берлинга,
Фрицлар белән тулы:
Кайсының күрер күзе юк,
Кайсының — аяк-кулы...

## Фронттан еракта

*
* *

— Иренне госпитальгә салганнар дигән идең. Яңа хәбәре бармы — ничек ята?
— Язды, тыныч ята.
— Кем язды?
— Штаб начальнигы.

*
* *

— «Әтиеңне руслар әсир иткән икән...» диде миңа бер дус малай. Дөресме бу, әни?
— Беләсеңме ничек ул: русларны әтиең үзе пленга алган, ләкин алар бик күбәү булганнар икән дә, әтиеңне дә үзләренә ияртеп киткәннәр.

*
* *

— Тагын күңелсезлек: минем Карл операциядән соң үлгән...
— Операцияне хлороформ биреп эшләделәрме икән?
— Юктыр, ахрысы, кәгазендә «Смоленск операциясе» һәм «Кургашын» дигән ят сүзләр генә бар.

## Окопта сөйләшүләр

*
* *

— Ганс, синең партизаннар белән очрашканың булдымы?
— Әлбәттә!
— Нинди иләр соң алар?
— Моны өзеп әйтү кыен: чөнки нигәдер аларга гел артым белән торырга, алардан алда атларга туры килде миңа.

*
* *

— Фриц, ник син һавага гына атасың?
— Партизаннарны куркытам.
— Ә ник үзең дер-дер калтырыйсың?
— Партизаннардан куркам.

*
* *

— Белмисеңме, Вилли, бүген кич утырасы эшелон безне кая илтер икән?
— Билгеле инде — вагоннарын әйләндереп каплатырга.

*
* *

— Ә Карл тәки үзенә партизан пулясы тидерми калган бит. Ничек шулай булдыра алды икән?
— Димәк, минага эләгеп дөмеккән.

## Берлин урамнарында

*
* *

Гитлер, Геринг һәм Геббельс үзләренә халык карашы нинди икәнен белергә теләп урамга чыгалар да беренче очраган немецтан сорыйлар:

— Әйт әле, хөкүмәтебез турында халык арасында нинди сүзләр йөри?

Немец аларга башындагы эшләпәсен салып суза. Дәүләт башлыклары берәр марка акча салалар. Тиз-тиз генә акчаларны ала да эшләпәне тагын сузып тагын өч марка ала. Аннары шул ук нәрсә тагын берничә кат кабатлана. Ниһаять, түземен җуйган Гитлер акыра тегеңә:

— Күренмә күземә, инде җиткәндер бездән!

— Үз хөкүмәте турында немец халкы нәкъ менә шуны әйтә дә инде,— ди дә әлеге узгынчы, күз ачып йомганчы юкка чыга.

*
* *

Фридрихштрасседагы киоскта «Яңа тәртип» дигән журнал саталар. Шунда берәү килә дә, тиешле акчасын сузып:

— «Яңа тәртип» бирегез! — ди.

— Бетте,— ди сатучы.

Бер-ике минуттан шул ук кеше тагын сорый:

— Миңа «Яңа тәртип»!

— Бетте,— ди сатучы тагын.

Минут үтүгә әлеге билгесез агай тагын шул ук сатучыдан «Яңа тәртип»не сорый икән.

— Әйтелде бит инде сезгә ул бетте дип. Ни чуртыма аптыратасыз тагын?

— Менә шуны ишетүе бик күңелле булды! — ди дә юкка чыга журнал сораучы.

Кызыл Армия бик кызып һөҗүм иткән көннәрдә ниндидер бик җитди сәбәп белән кыскá сроклы ялга кайткан бер солдат, кирәк буласы бар дип, «Гитлер капут!» дигән тәкъбирне ятлап йөри икән. Урамда бер офицер очрагач аны ул, «Хайль Гитлер!» диясе урынга, шул «Гитлер капут»ны әйтеп сәламли.

Җене чыгып ачуланган офицер солдатны юл читенәрәк чакырып ала да сорый:

— Ә син моны чынлап беләсеңме әллә?

## Кәшфелзадә

### Бер риваять

Борынгыдан бу хикәят —
бер риваять:
Дөнья инде яратылгач, бер көн,
Тәңре үзенең сараена
барлык затларны чакырды,
һәм күрсәтеп үзенең иң зур иҗат җимешен —
Адәмне! —
аңа баш иярга әмер кылды.
Хөрмәт белән һәркем
килеп Адәмгә баш иде.
Тик урынында калды берәү — иелмәде.
Бу тыңлаусыз — Иблис иде!
Чиксез ачуланды Алла!
(Шулай булмый, ул бит бөек иҗатчы ла!
Әле зәгыйфь шигыребезне
бер-бер ишәк танымаса,
шундый үпкәлибез ләса!)
— Ни өчен син әмеремә буйсынмыйсың? —
дигәч, Иблис нәрсә ди соң?
— Мин, ди, уттан яратылган,
Газазил мин, бер гали зат.
ә ул, Адәм — тик балчыктан.—
Аңа килеп баш иялмам, теләсә нишләт,—
диде Иблис, баш имәде.
Бу бунты өчен куылды ул ахыр күктән.
һәм шул көннән
бүгенгәчә Иблис, имеш, хак дошманы.
Ул котырта Адәм затын. Ни кушканы?
— Бул горур син, бул тыңлаусыз!
Күр, менә мин —
һичкемгә дә баш имәдем...

Бу риваять — бер хикәят,
Тик, хакыйкать:
күңелендә бик күпләрнең яши бу хис.
Шагыйрьдә дә горурлык — ул иң зур көч ич!
Буйсынмыйча яшәү уе — бар иманы...
Мәңге үзе булып калды — баш имәде!
һәм ул әйтә килә сезгә —
үзен аңламаган кешеләргә:
— Уттан яратылган ахры җаныбыз!
Уттан — җырыбыз.
Күтәрәлми безнең рухыбыз
сезне тыңлап,
сезнең салкын акыл белән килешүне.
Белегез шуны:
ул Аллага каршы хәтта баш күтәрде!
Рухта — Иблисме ул, я бүтәнме,
һаман ярсу, горур, һаман исән әле.
Баш иярга — юк исәбе!

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР

Хөрмәтле иптәш Миргазиян Юныс!

«Казан утлары»нда басылган «Биектә калу» әсәрегезне укып бик күңелем булды. Тагын да шундый матур әсәрләр язсагыз иде. Авыр эшегездә зур уңышлар телим.

**Хөснетдинов,**
Алексеевск районы, Биләр авылы.

И. Юзеевның «Мәхәббәт китабы»н яратып укыдым. Әсәрнең күләменнән эчтәлеге зуррак. Бу әсәрне укыганнан соң, яшь шагыйрьләр мәхәббәт турында язганда саграк булырлар. Югыйсә, мәхәббәтне «җаным», «бәгърем»гә кайтарып калдыручы шигырьләр дә очрый әле.

**А. Абязов,**
Чүпрәле районы.

Мин И. Юзеевның «Мәхәббәт китабы» турында бер-ике сүз әйтергә телим. Бу әсәрне кат-кат укып чыктым. Иптәшләремә дә укыдым. Укыйм-укыйм да, татар поэзиясенә булган карашымның үзгәрүен тоям. Юк, дим, бу гади әсәр генә түгел, ә Такташ, Туфаннарның классик әсәрләре рәтенә басачак китап бу. «Мәхәббәт китабы»н кулымда тотып, барлык поэзия сөючеләр белән бергә-бергә шатланам мин.

**Әмир Фатыйхов,**
Башкортстан, Яңавыл районы.

«Казан утлары» журналына ел саен язылып, аны яратып укып барам. Республикабызның әдәбият-сәнгать дөньясын яктырткан бик күп мәкаләләрне укыганда күңелдә төрле-төрле уйлар туа. Әйтәсе фикерләремне сәнгать оешмаларына журнал аша җиткерәсем килә.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 64 еллыгын бәйрәм иткән көндә кич белән телевизор аша бәйрәм концерты карадык. Концертта нигә бер генә революцион җыр, туган ил, хезмәт, батырлык турында җыр яңгырасын! Барлык артистлар да мәхәббәт турында җырлыйлар. Андый җырлар кирәкми дию(е)м түгел. Кеше мәхәббәтсез яши алмый. Шундый олы бәйрәм көннәрендә гражданнар сугышы, Ватан сугышы батырлары, беренче бишьеллыкның хезмәт батырлары, бүгенге яшьләр катнашында кичә уздырылса, аның тәрбияви нәтиҗәсе искиткеч зур булыр иде. Революцион

җырлар ник җырланмый, кайда хезмәт турында яңа җырлар? Андый җырлар язылса да, музыкаль белеме булмаган кешеләр җырлый алмый, башкару өчен алар бик авыр, шуңа популярлык казана алмыйлар. Ярый әле, моннан шактый күп еллар элек язылган, язылган көннән бирле халык җырлары булып киткән С. Сәйдәшев әсәрләре бар. Мәктәптә укучылар белән концерт куярга хәзерләнә башласаң, башка бәла төшә, заманыбыз турында матур җырлар юк. Русча җырларга да мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булабыз яки балалар зурлар өчен язылган мәхәббәт җырларын җырларга тотыналар. Шагыйрь Р. Миңнуллин «Социалистик Татарстан» газетасында бу мәсьәләне бик вакытлы күтәреп чыккан иде. Хәзер нәтиҗәсен көтәбез.

«Казан утлары»ның былтыргы 10 санында «Проблемаларның үзәгендә — кеше» дигән баш астында язучыларның түгәрәк өстәл янында сөйләшүләре, фикер алышулары бирелде. Шушы фикер алышуларны укып чыкканнан соң үземнең дә тагын бер фикеремне әйтәсем килә. Бүгенге көндә проза өлкәсендә М. Мәһдиев иҗаты өскә калкып чыкты. Аның һәр әсәрен, газеталарда басылган һәр мәкаләсен яратып укыйбыз. «Торналар төшкән җирдә» повестен дә яраттык. Бу әсәрдә яшьлекне сагыну да, тормышны бик якты итеп күрә белү дә, ә иң мөһиме — яшьләрне тәрбияләүгә кирәкле бик матур фикерләр дә бар.

М. Мәһдиев туры сүзле, ачык фикерле, әйтергә теләгән фикерен бер җөмлә белән аңлата ала, язганы күңелдә кала, онытылмый.

**М. Кәримуллина,**
Кама Тамагы районы, Келәр авылы.

М. Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестен зур кызыксыну белән укып чыктым. Әсәр башыннан алып ахырына кадәр мине «үз дулкыны» эчендә йөртте. Иң элек, бер күз йөгертүдә үк аңлашыла торган тәзек, тирән эчтәлекле җөмләләр сокландырды, халык телендәге әйтемнәр, мәзәк сүзләр кирәкле урыннарда оста кулланылган. Бу әсәрне телебезне баетучы, аның хәзинәләрен яктыга — дөньяга алып чыгучы әсәр дип бәяләп булыр иде. Әсәрдәге образлар матур, ышандырырлык, төгәл итеп сурәтләнгән.

Асаф — озак вакыт хәтердә калырлык, нык ихтыяр көченә ия булган, тулы канлы образ. Аның бер генә адымында да ясалмалылык юк. Кеше буларак өлгерепкамилләшеп җитүе дә артык күзгә бәрелеп тормый. Ә карасаң, чәчләренә көмеш яуган Асаф әнә кем булып күтәрелгән! Хатын-кызга, балаларына, әнисенә, туып-үскән җиренә, ата-баба нигезенә мәхәббәте һәм ихтирамы аның чиксез. Бу сыйфатлар аны матур итәләр. Дөрес, Асафның кайбер чакта хатын-кыз матурлыгына «эреп» китә торган чаклары да була. Мәсәлән, Зәйтүнә белән очрашуы. Зәйтүнә дә кеше буларак күңелдә кала. Гомумән, әсәрдә яхшы кешеләр күп, алар өчен күңел куана.

Фатыйма апа барлык аналарның берләштерелгән образы. Шулай күз алдына килә. Ул гади, киң холыклы, бөтен кешегә дә яхшылык эшләргә әзер торучы авыл карчыгы. Шәрәф Солтанов сугыш кырларында батырларча көрәшкән кебек, тыныч төзелеш елларында да шулай ук көрәшә. Уй-теләкләре бердәм булгач, Асаф белән алар тагын бер сафта. Бу бергәлек аларга көч-дәрт бирә. Җыеп кына шуны әйтәсе килә: әсәр укучыларны тирән уйларга салырлык итеп язылган. Авторга рәхмәт.

**С. Сөләйманова,**
Түбән Кама районы, Каенлы авылы.

М. Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестен укып чыккач, бик тә гаҗәпләнеп калдым әле. Халкыбызның тел мирасын барлап, баетып тору бик кирәк. Ләкин бу әсәрдә телдән әйтергә, кәгазьгә язарга оят булган сүзләр, җөмләләр дә бар. Автор Миңҗан карттан да нәкъ шундый сүзләрне шактый еш әйттерә. Татлы әйбер ашаганда авызга ялгыш эләккән әрем кебек алар.

**Ә. Вахитова,**
Үзбәкстан, Ангрен шәһәре.

М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестен укыгач, зирәк күңелле бу язучы каршында башымны иясем килде.

Халкыбызның матур традицияләре, авыл тормышы, урман-кырларыбыз турында язу күркәм эш. Мин бүген бу мәсьәләнең икенче ягы турында да уйланам. Шул матур традицияләрнең кими баруына, олы-олы авылларыбызның таркалуына, урманнарыбызның кимеп-кибеп баруына ниләр сәбәпче соң? Шуларга җавап бирерлек әсәрләр дә укыйсы килә. Хәзер урманнарда имән агачлары бетеп килә, усак агачларының 10—12 яшьтән дә олырагын табу кыен. Урманнар зәгыйфьләнә. Әбит халкыбызның бик матур традицияләре авыл һәм урман белән бәйләнгән.

**З. Низамов,**
Казан.

12 ел рәттән инде мин «Казан утлары»на язылам һәм укып барам. Шигырьгә сусаган чакларымда узган елларда иҗат ителгән шигъри әсәрләрне кулыма алам. Әлегә хәтле Гәрәй Рәхим шигырьләрен дә яратып укып килдем. Ләкин журналның былтыргы 7 нче санында басылган «Олыгаю» циклы мине аптырашта калдырды. Менә бер өзек:

**Кайчандыр сине куркыткан**
**Күзләремдә ак томан...**
**Бер дә куркытмый торган...**

Тизрәк таратырга кирәк бу томанны. Әгәр бу шигырьләрне Гәрәй Рәхимнең олыгаю чоры иҗаты дип кабул итсәк, картаю чорында безгә ниләр күрсәтер ул?

**М. Вера,**
Башкортстан, Уфа шәһәре.

«Проблемаларның үзәгендә — кеше» дигән материалны укып чыккач, минем күңелдә дә төрле-төрле уйлар кузгалды. Бүгенге көн кешесе — үз бабаларының иң яхшы сыйфатларын үзләштергән, аны тормышка керткән, баеткан, эше белән тормышта шуларны раслаган кеше булырга тиеш. Шуларның иң беренчесе — туган телгә, туган җиргә хөрмәт дип саныйм.

**Н. Ибраһимов,**
Башкортстан, Яңавыл поселогы.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» дигән мәгълүм карары чыгу уңае белән Язучылар союзы партия оешмасы һәм СССР фәннәр академиясе филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең берләштерелгән җыелышы булды. Җыелышта доклад белән тәнкыйтьче Р. Мостафин чыкты.

Фикер алышуларда язучы Г. Ахунов, тәнкыйтьчеләр Н. Юзиев, Х. Хәйри, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Миңнуллин һәм башкалар катнашты.

## РЕСПУБЛИКАДА ЯМАШЕВ КӨННӘРЕ

Республика җәмәгатьчелеге күренекле революционер-ленинчы, сәләтле оештыручы ялкынлы публицист, татар телендә беренче большевистик газета чыгаручы Хөсәен Ямашевның тууына йөз ел тулуны киң билгеләп үтте. 18 январьда ук Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында данлы Юбилейга багышланган тантаналы җыелыш булды. Җыелышны ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев ачты. Х. Ямашевның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турындагы доклад белән КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин чыкты.

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы конференц-залында юбилейга багышланган фәнни конференция булды. Аны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. Докладлар белән тарих фәннәре докторы Х. Х. Хәсәнов, философия фәннәре докторы Я. Г. Абдуллин, филология фәннәре докторы И. З. Нуруллин, тарих фәннәре кандидатлары Ф. И. Әгъзәмов һәм Р. У. Әмирханов, Казан шәһәренең Ямашев исемендәге 9 нчы мәктәп музее мөдире Н. Һ. Закирова иптәшләр чыкты.

Бу юбилей уңае белән «Правда» газетасында КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусинның «Халык күңелендә» дигән мәкаләсе басылды. Татарстан китап нәшрияты тарих фәннәре докторы Х. Х. Хәсәновның «Революционер-интернационалист» дип исемләнгән монографиясенең икенче, тулыландырылган басмасын бастырып чыгарды.

1905 елның ноябрь-декабрь айларында Х. Ямашев берничә мәртәбә ялкынлы речь белән чыккан элекке Алафузов театры (хәзер В. И. Ленин исемендәге җитен комбинаты культура йорты) бинасы янында күренекле революционер хөрмәтенә мемориаль такта ачуга багышланган митинг булды. Митингны партиянең Киров райкомы беренче секретаре Э. А. Канчурин ачты. Биредә тарих фәннәре докторы Х. Х. Хәсәнов, партия һәм хезмәт ветераны Х. М. Сибгатуллин, җитен комбинаты ВЛКСМ комитеты секретаре урынбасары И. Петрина сөйләделәр.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВ ЮБИЛЕЕ

11 январьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле татар совет язучысы Габдрахман Әпсәләмовның тууына 70 ел тулуга багышланган кичә булды. Анда республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре катнашты.

Кичәне ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов Габдрахман Әпсәләмовның тормышы һәм иҗаты турында сөйләде.

Язучылар С. Хәким, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин олы әдип турында истәлекләр белән чыктылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Әлмәт язучылар оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Отчет докладыбелән оешманың җаваплы секретаре Ә. Маликов чыкты.

Доклад буенча фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин, Татарстан Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе Р. Даутов, шагыйрьләр К. Булатова, Э. Мөэминова, Ә. Габиди, Н. Әхмәдиев, прозаиклар А. Хәсәнов, Ф. Гыйльметдинов, Лениногорскидагы «Чишмә» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Р. Вәлиуллин катнашты.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов ил күләмендә һәм республикада барган әдәби хәрәкәттәге яңалыклар белән таныштырды.

Җыелыш оешма бюросының эшен уңай яктан билгеләп үтте һәм киләчәккә яңа бурычлар куелган, кимчелекләрне бетерүгә юнәлдерелгән карар кабул итте.

Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре итеп язучы һәм драматург Ә. Гаффар сайланды.

*

* *

Оешма утырышында Әсрар Галиевнын «Гөләрия» исемле яңа повесте тикшерелде

әсәр шахтерлар тормышы җирлегендә язылган. Фикер алышуда катнашкан Ш. Бикчурин, Җ. Рәхимов, Х. Хәйруллин, Ә. Маликов, Ф. Гыйльметдинов, Х. Хәйруллин, Ә. Габиди, Р. Вәлиуллин һ. б. әсәрнең уңай якларын күрсәтү белән бергә, сюжет һәм тел мәсьәләләренә нык игътибар ителергә тиешлегенә басым ясап әйттеләр.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

«Орфей» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь шагыйрь П. Юлаевның «Молодая гвардия» нәшриятында басылып чыккан «За окном метель» дигән беренче китабы хакында фикер алышу булды. Анда шигырь сөючеләр дә катнашты.

* * *

Күптән түгел генә Чаллы язучылар оешмасының Түбән Кама шәһәрендә күчмә утырышы булды. Анда «Данко» һәм «Кама таңнары» берләшмәләренең шигъри җыентыклары тикшерелде. Фикер алышуларда язучылар Разил Вәлиев, Э. Касыймов, Н. Мадьяров, К. Сибгатуллин, Г. Кашапов, А. Чурбанов, «Орфей» һәм «Ләйсән» берләшмәләре членнары катнаштылар.

* * *

«КамАЗ» культура сараенда шагыйрь һәм прозаик Разил Вәлиев, «Орфей» берләшмәсе членнары Н. Алешков, Е. Кувайцев, И. Лимонованың иҗат кичәсе уздырылды.

* * *

Чаллы язучылары шәһәрнең профессиональ-техник училищелары белән тыгыз элемтәдә яшиләр. 64 нче техник училищедагы очрашу да кызыклы үтте. Анда язучылар Э. Касыймов, Н. Мадьяров, К. Сибгатуллин, Г. Кашапов, Я. Игәнәй, Х. Хөснуллин катнашты.

* * *

Язучы Э. Касыймов республика сукырлар җәмгыятенең Казандагы махсус китапханәсендә «Чулман — оныклар дәрьясы» романы буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Татарстан Язучылар союзының яшьләр белән эшләү бүлегендә яшь язучы Заһит Мәхмүтовның хикәяләре турында сөйләшү булды. Фикер алышуда Л. Ихсанова, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Ф. Яруллин, Г. Шәрәфи, Ф. Шәфигуллин, Н. Гиматдинова, К. Кәримов катнашты, яшь авторга киңәшләр бирелде, уңышлы хикәяләре матбугатка тәкъдим ителде.

* * *

Поэзия секциясенең бюро утырышында яшь шагыйрә Асия Минһаҗева шигырьләре хакында фикер алышу булды. Шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Гатауллин, Р. Мингалим һәм Р. Низамиев яшь автор иҗатына эшлекле анализ ясадылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Проза секциясенең чираттагы утырышында «Бүгенге прозада авыл» дигән темага зур сөйләшү үткәрелде. Утырышка Актаныш районының «Чишмә» колхозы председателе Ясәви Хөсәенов белән Арча районының «Чулпан» колхозы председателе Наил Сабиров та килделәр. Колхоз җитәкчеләре язучыларны кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап бирделәр.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы уздырылды. Анда яшь язучы Р. Гыйззәтуллинның хикәяләр җыентыгы турында сөйләшү булды. Фикер алышуларда Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, А. Тимергалин, Р. Кәрами, Р. Миңнуллин һ. б. иптәшләр катнашты. Авторга эшлекле киңәшләр бирелде.

Аннары секция бюросының отчеты тыңланды. Утырышта Р. Миңнуллин (председатель), Ш. Галиев, Ш. Рәкыйпов, Л. Ихсанова, А. Тимергалин, Р. Кукушкин, К. Кәримов (секретарь) составында секциянең яңа бюросы сайланды.

## ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының кунакханәсендә алты автономияле республиканың «Идел һәм Урал арасында» радиотапшыруы программасының киңәйтелгән утырышы булды. Анда татар шагыйрьләре һәм язучылары С. Хәким, М. Хәбибуллин, Р. Гатауллин һәм Р. Миңнуллин да катнашты. тапшыруларның эчтәлеген баету хакында эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ТАССР Язучылар союзы идарәсе һәм ВЛКСМ өлкә комитеты карары нигезендә Кукмара районының Зур Сәрдек авылында Л. И. Брежневның «Истәлекләр» китабы буенча укучылар конференциясе үткәрелде.

Конференциядә драматург Т. Миңнуллин, шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Мингалим, республика әдәби түгәрәкләре җитәкчесе яшь язучы Н. Гыйматдинова катнашты һәм чыгыш ясады.

## ШИГЪРИ ТРАГЕДИЯ ПРЕМЬЕРАСЫ

Минзәлә дәүләт драма театры коллективы шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеевның «Соңгы төн» исемле шигъри траге-

диясен сәхнәгә куйды. Бу спектакль СССР төзелүнең 60 еллыгы уңае белән әзерләнгән.

Режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Мостафин, композиторы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабыз комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты М. Яруллин булган бу спектакль Чаллы һәм Ижевск тамашачыларына да күрсәтелде.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Актерлар йортында РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты, республика комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты драматург Туфан Миңнуллинның очрашу кичәсе булды.

Танылган драматургның иҗаты турында РСФСРның халык артисты, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург А. Гыйләҗев сөйләде.

Соңыннан Т. Миңнуллин үзе чыгыш ясады, тамашачыларның күп санлы сорауларына җавап бирде.

* * *

Язучылар Б. Камалов, Р. Кәрами, шагыйрьләр Ф. Сафин, Ә. Рәшитов, җырчы Р. Ильясов, баянчы Р. Халитов Әгерҗе районында әдәбият һәм сәнгать атналыгы уздырдылар, әдәбият сөючеләргә шигырьләр һәм хикәяләр укыдылар, авыл хезмәтчәннәрен халкыбызның һәм композиторларыбызның популяр җырлары белән таныштырдылар.

* * *

Минзәлә педагогия училищесында шагыйрь И. Юзеев һәм композитор М. Яруллин булдылар. Алар студентларны кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр, әсәрләренең язылу тарихын сөйләделәр, киләчәк планнары белән уртаклаштылар.

* * *

Шагыйрьләр Ш. Галиев һәм И. Юзеев «Үрнәк» совхозында, Арча районы колхозсовхозлары өчен механизаторлар әзерләүче профессиональ-техник училище курсантлары алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Язучы Р. Кәрами Чабаксарга Анатолий Емельяновка 50 яшь тулу юбилеена барды. Чувашстан Язучылар союзы председателе прозаик А. Емельянов иҗаты киң катлау рус һәм татар укучыларына да яхшы таныш. Аның роман-повестьлары рус телендә Мәскәүдә берничә тапкыр басылып чыкты, хикәяләре журналда дөнья күрде. Р. Кәрами Татарстан язучылары исеменнән А. Емельяновны кайнар котлады һәм аңа бүләкләр тапшырды.

* * *

«Татхимфармпрепараты» производство берләшмәсе үзенең 50 еллык хезмәт юбилеен билгеләп үтте. Коллективны тәбрикләргә язучылар һәм сәнгать осталары да килгән иде. М. Галиев, К. Кәримов, М. Зарецкий, Д. Гисметдинов, А. Арсланов, Ф. Сөләйманова, Р. Гатауллин, Ф. Бәдретдинов катнашында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

* * *

«Казаньхимстрой» трестының утырышлар залында Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты прозаик А. Расих белән очрашу булып узды.

* * *

Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы Тәтеш районы хезмәтчәннәре белән иҗади очрашулар оештырды. Драматург Р. Батулла, яшь прозаиклар К. Кәримов, Ә. Сәйфетдинов һәм яшь композитор Р. Гатауллин бу районның «Заря», Вахитов исемендәге, «Россия», «Татарстан» «Алга», Энгельс исемендәге хуҗалыкларында һәм Олы Торма, Зур Әтрәч, Алабирде, Бакырчы, Олы Тархан, Сөендек авылы мәктәпләрендә булып кайттылар.

## ӘДӘБИЯТ ИНСТИТУТЫ ЧАКЫРА

СССР Язучылар союзының М. Горький исемендәге Әдәбият институты проза, поэзия, драматургия, әдәби тәнкыйть, очерк һәм публицистика (читтән торып уку бүлегенә) жанрлары буенча студентлар кабул итә. Көндезге бүлеккә урта белеме һәм ким дигәндә ике ел хезмәт стажы булган кешеләр кабул ителә.

Институтка керергә теләүчеләр иҗади конкурс үтәргә тиешләр. Конкурс өчен материаллар 1 майга кадәр, түбәндәге күләмдә кабул ителә: поэзия — 350—400 юл, хикәяләр һәм повестьлар, драма әсәрләре — 35—50 бит, әдәби тәнкыйть, очерк һәм публицистика — 35 бит. Милли телдә язылган әсәрләрнең юлга-юл тәрҗемәсе булырга тиеш.

Конкурска әсәрләрен җибәргәндә автор үзе турында түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итәргә тиеш: исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, милләте, партиялелеге, кайсы уку йортын кайчан тәмамлавы, хезмәт стажы, эш урыны һәм вазифасы, өй адресы һәм кайсы бүлеккә (көндезгегәме, кичкегәме) керергә теләве.

Кабул итү имтиханнары көндезге бүлеккә 1 августта, читтән торып уку бүлегенә 15 августта башлана: рус теле һәм әдәбиятыннан (язма һәм телдән), СССР тарихыннан һәм чит ил теленнән.

Кабул итү комиссиясенең адресы: 103104. Москва, Тверской бульвар, 25. Телефон 202-06-02.

# ГОСМАН БАКИРОВ



Шушы елның 12 мартында Татарстан АССРның атказанган культура работнигы, 1927 елдан КПСС члены, танылган балалар язучысы Госман Бакиров вафат булды.

Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елның 13 мартында Татарстанның Арча районы Югары Курса авылында туа. 1912—15 елларда укытучы булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, армия хезмәтенә алына. Шунда Октябрь революциясен каршылый. Гражданнар сугышында катнаша.

1922 елда Госман Бакиров Казанга килә. Башта җир төзелеше техникумында, аннан Казан педагогия институтында укый. Укуын тәмамлагач, «Мәгариф» («Совет мәктәбе») журналының редакторы була, бер үк вакытта Татарстан дәүләт нәшриятының укыту-педагогия әдәбияты редакциясендә дә эшли.

1942 елдан 1945 елга хәтле ул Бөек Ватан сугышында катнаша. Башта миномет батальонының орудие командиры һәм хәрби частьның партком секретаре була, 1944 елдан «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасына күчерелә.

Сугыштан кайткач, Г. Бакиров озак еллар буе Татарстан китап нәшриятында редакция мөдире булып эшли. Шул ук вакытта балалар өчен хикәяләр, сәхнә әсәрләре дә яза. Ул — ике дистәдән артык китап авторы. Аның «Классташлар», «Партизан малае», «Минем укытучым», «Борылмалы юллар» исемле китаплары укучылар арасында зур популярлык казанды.

Коммунист Госман Бакиров актив иҗат тормышы белән яшәде, күп төрле җәмәгать эшләре алып барды. Яшь язучыларга булышты, даими төстә мәктәп балалары һәм укучылар белән очрашып торды. Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте язучының хезмәтләренә лаеклы бәя бирделәр. Ул Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнде. Аңа «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән исем бирелде.

Танылган балалар язучысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, коммунист каләмдәшебез Госман Бакировның якты образы безнең күңелләрдә озак саклаunion.

...се 90 тиен.
...на коп.

Индекс 73210

## КИЛӘСЕ САНДА:

*«Казан утлары»на 60 ел*

*Проза*

Нурихан Фәттах. **Сызгыра торган уклар.** Роман

Фатих Хөсни. **Мәшәкатьле озын сәфәр.** Юл язмалары

*Поэзия*

Сибгат Хәким. **Эзлиләр Европа буйлап.**

Төрле буын татар шагыйрьләренең шигырьләре.

*Очерк һәм публицистика*

Шәмси Хамматов. **Яңадан сафка.**

*Әдәби тәнкыйть*

Салих Маннапов. **Хәтер.**

**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии